Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең
Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты

Институт языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова
Академии наук Республики Татарстан

Казан • Казань
2024

**Духовное наследие**

Поиски и открытия

*Выпуск 24*

**Габдрахман Сагди**

# ИЗБРАННЫЕ СОЧИНЕНИЯ

Том 3

**Рухи мирас**

Эзләнүләр һәм табышлар

*24 нче чыгарылыш*

**Габдрахман Сәгъди**

# САЙЛАНМА ӘСӘРЛӘР

3 нче том

УДК 94 (093)
ББК 63.2
С 93

*Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең*
*Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты*
*Гыйльми советы карары нигезендә нәшер ителә*

Проект «Татар халкының милли үзенчәлеген саклау»
ТР Дәүләт программасы кысаларында ТР Фәннәр академиясе
Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының
Язма мирас үзәге тарафыннан гамәлгә ашырыла

**Редколлегия:**
***И.Г. Гомәров*** *(проект җитәкчесе),*
***Д.Ф. Заһидуллина, А.М. Ахунов***

**Фәнни редактор**

*филология фәннәре кандидаты* ***И.Г. Гомәров***

**Рецензентлар:**

*филология фәннәре докторы* ***Ф.Ф. Гыйлемшин,***
*филология фәннәре докторы* ***Р.Ф. Мирхәев***

**С 93** **Сәгъди Г. Сайланма әсәрләр.** Т. 3 / Г. Сәгъди; төз., текст. иск. һәм аңл. әзерл.: Л.Р. Надыршина, Л.Ш. Гарипова, Г.М. Ханнанова, И.Г. Гомәров, А.М. Сәлахов; кереш сүз авт. Л.Р. Надыршина. – Казан: ТӘһСИ, 2024. – 256 б. («Рухи мирас: эзләнүләр һәм табышлар = Духовное наследие: поиски и открытия» сериясе. 24 нче чыгарылыш).
ISBN 978-5-93091-507-5

«Рухи мирас: эзләнүләр һәм табышлар» сериясенең чираттагы чыгарылышы тел һәм әдәбият галиме, мәгариф эшлеклесе, педагог Габдрахман Сәгъдинең (1889–1956) «Кешелек дөньясында тел, әдәбият, язу һәм аларның тарихи үсүләре» хезмәтен үз эченә ала. Әлеге хезмәт гамәлдәге хәрефләр белән беренче тапкыр басыла.

Басма белгечләр, татар тарихы һәм мәдәнияте белән кызыксынучы киң катлау укучылар игътибарына тәкъдим ителә.

ISBN 978-5-93091-507-5 (3 т.)
ISBN 978-5-93091-495-5

© ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге
Тел, әдәбият һәм сәнгать институты, 2024

# «ХАЛЫК БЕЛӘН ТЕЛ ИКЕСЕ БЕР НӘРСӘ КЕБИДЕР»

«Рухи мирас: эзләнүләр һәм табышлар» сериясенең чираттагы чыгарылышы татар фәнендә олы мирас калдырган Габдрахман Сәгъдинең (1889–1956) «Кешелек дөньясында тел, әдәбият, язу һәм аларның тарихи үсүләре» хезмәтен үз эченә ала.

Тел-әдәбият теориясе һәм тарихы, методика һәм педагогика буенча күпсанлы хезмәтләр авторы, төрле уку йортларында белем биргән педагог буларак, галим, әлбәттә, бу юнәлештәге мәгълүматларны бергә туплап бирүнең, татар халкының тел-имля мәсьәләләрен системалы итеп яктыртуның нәзари һәм гамәли әһәмиятен яхшы аңлый. Шуңа күрә дә мәсьәләгә үзенә хас принципиальлек, колачлылык белән якын килеп, темага кагылышлы күпсанлы чыганакларны анализлый, чит ил һәм рус белгечләренең фикерләрен җентекле өйрәнә. «Сүз башы»нда автор үзе үк искәрткәнчә, китап А.А. Потебня, А.Н. Веселовский, В.А. Правдолюбов, Карл Вейле, Я.Б. Шницер, Н. Гасыйм кебек язу тарихын өйрәнүдә әйдәп барган күренекле галимнәрнең эзләнүләренә нигезләнеп язылган, шулай ук басма ахырында китерелгән чыганаклар исемлеге дә хезмәтнең эчтәлек ягыннан тирәнлеген, мәгълүматка бай икәнлеген күрсәтә.

Хезмәт ике зур бүлектән – бабтан тора. Беренче бабта «кешелек дөньясында борынгы заманнарның мәдәни байлыкларын соңгы яңа заманнарга күчерә баруда иң кирәкле, иң кыйммәтле бер корал, иң көчле бер чара» булган телләр эволюциясенә гомуми күзәтү ясауны максат итеп куеп, галим сөйләм һәм тел үсешен иҗтимагый барыш белән тыгыз бәйләнештә карый, телләр формалашу закончалыкларын барлау, аларны генеологик һәм морфологик төркемләү принципларын күрсәтә. Шулай ук бүлектә тел һәм әдәби фикерләүнең үрелеп-берегеп үсүе синкретик текстлардан бүленеп чыккан борынгы җырлар, тезмә текстларга киң тукталу аша күрсәтеп-тасвирлап бирелә, халык авыз иҗатының тел үсешендәге роле игътибарга алына. Г. Сәгъди телнең иҗтимагый-мәдәни кыйммәтен һәрдаим ассызыклап килә, бер халыкның рухи-мәдәни хәзинәсе киләчәк буынга фәкать тел ярдәмендә генә тапшырыла алуын тәкрарлый, нәкъ менә телнең милли үзбилгеләнүдә беренчел булуын ассызыклый («...“халык” дигәч тә – “тел”, “тел” дигәч тә «халык» хәтергә

килә. Бер милләтне әйтәләр икән, без шунда ук аның үзенең бер теле барлыгын да хәтерлибез»).

Китапның икенче бабында дөнья цивилизацияләрендә язу-имляның төп үсеш баскычларына аерым күзәтү ясала. Төрле чыганаклар нигезендә, Г. Сәгъди татар укучысын әйбер язуы, чөй язуы, рәсем язуы, төен язуы, ниһаять, әлифба язуы кебек кешелек яшәешендә очраган язу төрләренең һәрберсенә җентекле туктала. Галим язу-әлфибаның фәкать мәдәни яктан үскән халыкларга гына хас була алуын күрәсәтә, аның «кешелек дөньясының матди вә мәгънәви бөтен мәдәни байлыгын, мәдәни мирасын югалтмастан саклап килә торган ышанычлы киң бер хәзинә» икәнлеген раслый.

Китапның бу бүлегендә урын алган Европа, гарәп, яһүд, һинд һ.б. халыкларның әлифбалары турында мәгълүматлар янәшәсендә төркиләрдә язу тарихына багышланган бүлекчәләр татар укучысы өчен аеруча кыйммәтле. Төрки халыкларда кулланылган рун, уйгыр һәм гарәп язуларының тарихи үсеш баскычларын күрсәтеп, Г. Сәгъди аларның һәрберсенә тулы характеристика бирә, бик борынгы заманнардан ук төркиләрнең алфавит иҗат итәрлек югары мәдәниятле халык булуын раслый. Татарларда гасырлар дәвамында кулланылып килгән һәм әле шушы китап басылган чорда да гамәлдә булган гарәп графикасына махсус тукталып, галим XIX гасырның ахырыннан башланган имля реформасын яктырта һәм бу нисбәттән төрле фикер ияләренең карашларын китерә. Фактик мәгълүматны күпсанлы мисаллар белән аңлатып-шәрехләп бару, иллюстрацияләрнең күплеге материалны тагын да аңлаешлырак итә.

Гомумән, Г. Сәгъдинең укучы хөкеменә тәкъдим ителгән бу китабы үз чоры өчен шактый киң колачлы, актуаль хезмәт булып чыккан. Ул хәзерге вакытта да тел галимнәре, фольклорчылар һәм этнографлар һ.б. өчен дә кыйммәтле чыганак булыр дип ышанабыз.

Хезмәт, гамәлдәге графикага үзгәртүсез күчерелеп (фәкать китапның автор тәкъдим иткән мөндәриҗәсе – эчтәлеге генә, аерым төгәлсезлекләр булу сәбәпле, төзүчеләр тарафыннан текстка тәңгәл итеп үзгәртелде), фәнни аңлатмалар һәм шәрехләүләр белән тулыландырылып, фәнни даирәгә тулы рәвештә беренче тапкыр тәкъдим ителә.

*Л.Р. Надыршина,*
*филология фәннәре докторы*

# СҮЗ БАШЫ

## I

Тел-әдәбият белән шөгыльләнүчеләр, шул фәнне мәктәпләрдә өйрәнүче һәм өйрәтүчеләр өчен бу фәннең байтак гомуми вә киң яклары бар. Кайсы гына бер халыкның тел вә әдәбияты, әдәбият вә матбугат тарихы тикшерелергә, укылырга башланса да, аны һәм аның тәрәккый баскычларын ачыграк, тулырак аңлау өчен, һәрхәлдә, тел вә әдәбият бабында бөтен кешелек дөньясы өчен уртак булган тарихи мәсьәләләргә, гомуми мәгълүматларга кагылмыйча үтеп булмый. Хәтта бу турыда гомуми мәгълүматлар иң элек бирелеп үтелергә тиеш була.

Кирәк үз-үзеннән вә кирәк мәктәпләрдә тел-әдәбият тикшерү белән шөгыльләнүчеләр өчен боларның кирәклеге – ачык нәрсә.

Кешелек дөньясында, ягъни җир йөзендәге бөтен халыкта тел вә әдәбият, язу-элифба дигән нәрсәләр ничек һәм кайчан туып та, һәр халыкта шуларның ничек үсә, ничек үзгәрә баруы турысындагы мәсьәләләр, мәгълүматлар әнә шундый гомуми мәсьәләләрдән, гомуми мәгълүматлардан саналалар.

Әлифбалар тарихы мәсьәләсендә үз матбугатыбызда татарның имля вә хәреф мөтәхассыйсе[1], орфография кешесе Гыйбад иптәш Алпарның[2] «Хәреф вә имлябыз» дигән кечкенә әсәрендәге[3] 5–6 битлек бик кыска бер мәкаләсе, телләр турысында мәрхүм Солтан Рахманколыйның[4] Рубакиннан[5] тәрҗемә иткән «Телләр тарихы» дигән

---

[1] Мөтәхассыйс – белгеч.

[2] Гыйбадулла Хәбибулла улы Алпаров (1888–1936) – тел галиме. Хезмәтләре татар теленең орфографиясе, морфологиясе, синтаксисына карый, татар һәм төрекмән телләре буенча дәреслекләр, «Шәкли нигездә татар грамматикасы» (1926) дигән фундаменталь фәнни хезмәт авторы.

[3] Бу китап 1912 ел Казанда басылды. 30 бит зурлыгында. Тел-имлябызны тикшерүчеләр өчен әһәмиятле әсәр. *(Авт. иск.)*

[4] Солтан Габделмәннан улы Рахманколый (1888–1916) – язучы, тәрҗемәче, тел галиме. «Мәликә куаклыгы» исемле хикәя җыентыгы авторы, «Русча-татарча кесә лөгате»н (1915) төзүче.

[5] Николай Александрович Рубакин (1862–1946) – язучы, библиограф. 1907 елда Швейцариягә китеп, Лозанна шәһәрендә яши һәм анда зур китапханә булдыра. 1948 елда китапханәсе Мәскәүгә кайтарыла.

36 битлек кечкенә кулдагы бер рисаләсеннән[1] башка бернәрсә бу көнгәчә күрелгәне булмады. Шунлыктан бу турыда махсус язылган аерым бер зур әсәрнең, бу кулланманың кирәклеге күп еллардан бирле һәркемгә бик нык сизелеп килде.

Алдыгызга куелган бу китап әнә шушы кирәкне үтәшү исәбе белән язылды. Икенче төрле әйткәндә, күп еллардан бирле тел-әдәбият белән шөгыльләнеп килүдән хасил булган мәгълүматларымның гомуми бер өлешен шушы китабым аркылы шуңа мохтаҗ булган иптәшләр белән уртаклашырга теләдем.

Китап үз тарафымнан язылган асыл «Татар әдәбияты тарихы»мның гомуми мәгълүмат бүлеге рәвешендә [19]22 елда ук язылып тәмам булган һәм шул вакытта ук Казанга Гыйльми Үзәккә[2] җибәрелгән иде. Ләкин ниндидер сәбәпләр белән ул бәхетсез бер язмышка очрады да басыла алмастан калды.

Бастырырга мөмкинлек юлы ачылганны, форсаты килгәнне көтеп йөрдек. Ниһаять, әсәрне бастыру форсаты килде. Гыйльми Үзәктән әсәрнең яңадан җибәрелүе соралды, әсәрне җибәрү өчен кулга алдым. Ләкин бу юлы инде Гыйльми Үзәк рәисе Галимҗан иптәш Ибраһимовның мәслихәте буенча әсәрне «Татар әдәбияты тарихы»ма кушылган бер «Мәдхәл» яки аның аерым бер бүлеге рәвешендә генә бастыртмыйча, бәлки үз бабында кулга тотарлык тәмам аерым бер китап хәленә куюны муафикъ күрдем.

Шуның өчен моннан өч еллар әүвәлге рәвешеннән күп үзгәрттем, күп яңа мәгълүматлар арттырдым, рәсемнәр, шәкелләр кергездем. Үземнең мөстәкыйль тикшерүләрем бу юлы тагы да күбрәк катышуга имкян[3] булды.

Китапның болай тагын да тулырак булып чыгуы турысында биргән киңәше вә фикерләре, күрсәткән хосуси ярдәмнәре һәм көтебханәсендәге үзләрен табу кыен булган кыйммәтле тарихи әсәрләрдән файдаландыруы өчен Галимҗан Ибраһимов иптәшкә бу урында аеруча рәхмәт әйтеп үтүгә үземне бурычлы саныйм.

---

[1] С. Рахманколыйның бу тәрҗемәсе 1909 елда Казанда басылды. *(Авт иск.)*

[2] Гыйльми Үзәк – 1921–1930 елларда ТАССР Мәгариф халык комиссариаты карамагындагы гыйльми оешма.

[3] Имкян – мөмкинлек.

## II

Кешелек дөньясында тел вә әдәбиятның, язу-әлифба дигән нәрсәнең ничек тууы, ничек үсү тарихын язганда төп таяныч рус һәм госманлы телендә шул турыда [19]25 елгача нәшер ителгән гыйльми, тарихи әсәрләр булды. Хосусан, Лезин[1] идарәсендә чыгып килгән «Вопросы теории и психологии творчества»[2] дигән гыйльми-тарихи мәҗмуганың бөтен җөзеләреннән, Потебня[3], Веселовский[4], Карл Вейле[5], Рубакин, Шницер[6], Струве[7], Правдолюбов[8] вә төрекләрдән Нәҗип Гасыйм[9] китапларыннан файдаландым. Шәкел вә килешләрнең күбесе Шницер, Правдолюбов, Карл Вейледан алындылар.

Халыкларның иҗтимагый-мәдәни, этнография якларын танытуда рус вә госманлы һәм гарәп телләрендәге тарихлар мәнбәгъ[10] ителделәр.

Төрк халыкларының үзләре, телләре, язулары, әдәбиятлары турысында Томсон, Радлов, Мелиоранский, Бартольд, Катанов, Корш, Вамбери, Самойлович, Малов кебек фән дөньясында мәшһүр галимнәрнең тикшерүләреннән, изахларыннан[11], шул хактагы һәртөрле фикер вә карашларыннан файдаландым. Шуның өстенә төркләр турысындагы ышанычлы гарәп вә төрек мәнбәгъләренең һәммәсе диярлек нык тикшерелеп чыгылды.

---

[1] Борис Андреевич Лезин (1880–1942) – әдәбият галиме, «Вопросы теории и психологий творчества» җыентыклары мөхәррире, нашир.

[2] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*

[3] Александр Афанасьевич Потебня (1835–1891) – тел һәм әдәбият белгече, философ.

[4] Александр Николаевич Веселовский (1838–1906) – филолог, тарихчы.

[5] Карл Вейле (1864–1926) – немец галиме, географ, этнолог. Лейпциг университеты профессоры. Төп хезмәтләре: «Культура бескультурных народов» (1910), «Элементы человеческой культуры» (1911).

[6] Яков Борисович Шницер (1870–?) – галим. Төрле халыкларның язу тарихын Россиядә беренче һәм системалы рәвештә өйрәнеп, «Иллюстрированная всеобщая история письмен» хезмәтен язучы.

[7] Василий Васильевич Струве (1889–1965) – күренекле шәрыкшинас, Мисыр һәм Ассирияне өйрәнүче.

[8] Владимир Анатольевич Правдолюбов (1888–1937) – рус галиме, «История письма» (1924) китабы авторы.

[9] Нәҗип Гасыйм Языксыз (1861–1935) – төрек галиме, тарихчы.

[10] Мәнбәгъ – чыганак.

[11] Изахларыннан – аңлатмаларыннан.

Китапны фәкать тәкълид һәм күчерү белән генә түгел, бәлки мәнбәгъләргә вә тарихи материалларга ачык күз белән ныклап тикшереп карап, берсен икенчесе белән чагыштырып, тәхкыйкләбрәк[1] язарга тырышылды.

Сүз ахырында шуны да әйтеп үтәргә кирәк: бу юлы китапка, тәмам үзем теләгәнчә үк, кирәге булган килеш вә шәкелләрне тәмам кертеп бетерә алмадым. Инде бу ягын төгәлләү китапның икенче басмасына калдырылды.

*Г. Сәгъди*

*1925 ел, 10 сентябрь*
*Казан*

[1] Тәхкыйкләбрәк – дөреслеген тикшереп.

# БЕРЕНЧЕ БАБ

## ТЕЛЛӘРНЕҢ ТУУЛАРЫ ҺӘМ АЛАРНЫҢ ҮСҮЛӘРЕ

**Тел.** «Тел» сүзе ике төрле мәгънәдә йөри: 1) кешенең әгъзаларыннан билгеле булган бер әгъза, ягъни авыздагы бер ит кисәге. «Нәрсәләрнең тәмнәрен белә торган сизү тамырлары тел өстенә түшәлгән» дигәндәге кеби. 2) «Сөйләм» (кәлям – речь) яки «гәп» мәгънәсендә: «төрек теле, рус теле, тел дәресләре» дигәндәге шикелле. Телнең сөйләм мәгънәсенә куелуы – сүзләрнең ясалыш вә туышларында телнең әсас булуыннандыр. Димәк, икенче мәгънәсенә күрә, «тел» дигән сүз – «үзләре белән һәр халыкның үз мәгънәләрен, үз аң вә төшенчәләрен аңлата торган барлык сүзләр» дигән мәгънәдә була.

Бөтен халыкның телендә сөйләмнәр (кәлям) – сүзләрдән, сүзләр исә авазлардан туа. Авазлар сулыш чыгарудан, ягъни бугаз аркылы һава сулап чыгарудан һәм тел вә иреннең төрлечә хәрәкәтләреннән хасил була.

Сүз һәм сөйләм булыр өчен авазлар бер-берсе белән билгеле бер мәгънә вә тәсаувыр[1] аңлатырлык, кешенең уй һәм аңын белдерерлек бер рәвештә кушылырга вә шулай оешырга кирәк. Киресенчә булганда, сүз һәм сөйләм хасил була алмый. «Лмб» дисәк, бу сүз булмый. Әмма бу авазларны икенче төрле кушканда, «белем» шәкеле хасил булып, бу вакыт ул сүз була. Чөнки бу вакытта аның бер мәгънәсе бар.

**Телнең файдасы һәм хезмәте.** Кешелек дөньясында борынгы заманнарның мәдәни байлыкларын соңгы яңа заманнарга күчерәбаруда тел – иң кирәкле, иң кыйммәтле бер корал, иң көчле бер чара.

Икеләнеп торырга түгел: хәзерге кешелек мәдәниятенең бөтен мәдәни байлыклары – ничә мең еллар буенча меңнәрчә буыннарның чиксез авыр хезмәтләре аркасында гаять читенлек һәм бик әкренлек белән мәйданга китерелгән уртак маллары, уртак хәзинәләре алар.

[1] Тәсаувыр – сурәтләп күз алдына китерү.

Хәзерге мәдәният баскычына килеп баскан кешелек дөньясы бар. Һичбер кызгану белми торган яратылыш дөньясы алдында тетрәп торучы һәм әле кием-салым, йорт вә кораллар белән яңа гына таныша алган иң борынгы кешеләр җәмгыяте вә шундый бер караңгы тереклек дәвере бар.

Менә шушы ике дәвер, шушы ике төрле кешелек дөньясында чиксез тирән катлаулар, әллә нихәтле тирән чокырлар, төпсез упкыннар кичерелгән.

Кешеләр берләшмәсе әнә шундый бик ерак сәфәрләрдән чиксез күп авырлыклар чигеп, күп чокыр вә упкыннар аша кичеп, элгәрегеләрнең күп йөкләрен соңгыларга күтәреп килүче һәм тагын кая тикледер һаман шуларны туктаусыз күтәреп баручы башы-ахыры булмаган хәяти бер кәрван тезмәсе булып күренә.

Үзенең барлыгын саклау юлында кеше вә кешелек җәмгыяте бик күп тартыш вә көрәшләрне башыннан уздырып килә. Шуның аркасында кешенең гаять бай булган рухи кабилияте, истигъдады[1] киткән саен ачыла, үткенләнә барды. Кәшеф[2] вә ихтирагъ[3] эшләре күбәйгәннән-күбәя бирде. Мәдәни һәм иҗтимагый тәҗрибәләр артканнан-арта барды, белек вә мәдәният хәзинәсе, мәдәни байлык, шулай итеп, һаман арту һәм киңәю юлын тотты.

Әнә шушы байлык һәм хәзинәләрнең һәммәсе сүз вә тел аркасында югалмыйча саклана, карт буыннардан яшь буыннарга бөтен мәдәни вә фикри байлыклар тел ярдәме белән күчерелә килә.

Кешелекнең матди һәм мәгънәви бөтен тәрәккыйсе, бөтен үсүе тел нигезенә торгызыла, тел аркасында тәэмин ителә. Кешенең уй һәм тойгыларының вә бөтен хыял һәм хиссиятенең барлык ингыйкясенә[4] яраклы булган һәм дә тереклекнең бөтен кирәкләрен үтәрлек булып үскән, камилләшкән бу тел – кешене хайваннар дөньясыннан аера торган һәм аларны мәдәни җәмгыять хәлендә бергә оештыручы, тәшкил итүче иң мөһим бер васита[5] вә корал, шуның белән бергә ул кешенең җисмани-рухи бер хосусиятеннән гыйбарәт.

Сүз, бердән – уй һәм тойгыларны, хыял вә хиссиятне башкаларга аңлатуның тагын да җиңелрәк вә уңайлырак бер юлы, икенчедән, кешелек берләшмәләренең үзара багланулары, бер-берсе белән

[1] Истигъдады – сәләте.
[2] Кәшеф – ачу, яңалыкны мәйданга чыгару.
[3] Ихтираг – уйлап табу.
[4] Ингыйкясенә – чагылышына.
[5] Васита – чара.

якынлашулары, тәшкил ителүләре өчен иң яхшы бер чара. Әмма йөздәге үзгәрешләр, ымнар, кул-аяк вә бөтен әгъзаның, газаләтләрнең хәрәкәтләре (жест һәм мимика[1]) исә – алар ялгыз телгә бер ярдәмче вә күмәкчеләр генә.

Тел бөтен мәдәни тәҗрибәләрне, белекләрне, белмәүне үзе белән баглап, югалтмыйча саклый, шуның өстенә ул шуларның башкалар, ягъни замандашлар һәм киләчәк буыннар өчен кулайлыгын тәэмин итә бара.

Шул ук тел вә сүз аркасында электә кешелек дөньясында меңнәрчә еллар кирәк булган мәдәни үсү, күтәрелү, камилләшү баскычларын бик кыска бер мөддәт[2] эчендә бик тизлек белән үтеп китә алабыз.

Икенче яктан, тел – мәгънәне аңлату һәм бүтәннәргә күчерү, саклау коралы гына түгел, ул бәлки, шуның белән бергә, ул мәгънәне тудыручы һәм оештыручы да. Ул – кешенең уйлау, төшенү эшләренә бик нык тәэсир итә торган бер нәрсә.

Чынлап та, бу көндә гыйльми рух һәм физиология фәннәре карашында шиксез бер хакыйкать булса, ул да – телнең үсүен вә тәрәккыйсе белән минең үсү һәм камилләшүе арасында бик тыгыз бер бәйләныш барлыгыдыр. Телнең тууы, корылуы димәкебез – минең һәм сүз коралы булган әгъзаларның бәрабәр үсүе, бәрабәр тәрәккыйсе димәк була. Кыскасы, фикер вә мәгънә сүз белән генә саклана, сүз аркасында гына үзенә чынбарлык, төгәл бер сурәт казана ала. Муафикъ бер лөгать вә тәгъбир таба алмаган чагыбызда фикер вә мәгънә һәм мәфһүмнәребезгә[3] анык бер сурәт бирә алмыйбыз, бу вакытта аңлатырга теләгәнебезне ачык иттереп аңлатудан гаҗиз калабыз. Шулай ук фикер вә төшенчәләребез эчке яктан вә эчке телебездә ачык билгеләнә һәм аныклана алмаган чакта да бер яраклы сүз вә тәгъбир таба алмыйча азап чигәбез.

Димәк ки, без телдән нәкъ мәгънәнең үзен тудыру ягыннан да файдаланабыз. Әгәр дә кеше кирәк авазлар, кирәк хәрәкәтләр белән булсын, үзенең тәсаувырларын вә бөтен мәфһүмнәрен ифадә итмәсә[4] иде, ул чагында кеше уйлый да, төшенә дә алмас иде.

[1] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*
[2] Мөддәт – ара, вакыт.
[3] Мәфһүмнәребезгә – аңланган, төшенелгән нәрсәләргә.
[4] Ифадә итмәсә – аңлатып бирә алмаса.

Биш сизү әгъзасы аркылы нәрсәләрдән килгән тәэсирләр белән аерым нәрсәләр турысында башыбызда сакланып калган тәсаувырлар бар. Менә шулар – ялгыз безнең күргән, ишеткән яки иснәп, үзләренә тиеп киткән вә татыган аерым нәрсәләрнең миебезгә төшкән, хәтеребездә сакланган гади сурәтләре, гади эзләре генә, болар бәлки хайваннарда да бардыр. Тәсаувырлар алынган вакытта әле безнең миебез, безнең идракебез[1] үзенең һичбер төрле эшен күрсәтә алмый, эшләми. Ул бу вакытта бер көзге шикелле генә булып тора. Ул әле бу хакта фәкать табигать вә хәяттә булган нәрсәләрне үзендә ингыйкяс иттерә[2] генә.

Әмма уйлау-төшенү исә бу – аңлау-идракь (сознание) эше. Ул менә шуннан гыйбарәт: нәрсәләр хакында казанылган аерым-аерым тасвир вә тәэссерләр[3], сизүләр, аерым тәсаувырлар безнең аңыбызда бер-берсе белән төрлечә чагыштырыла, алардагы уртак һәм дәвамлы булган төп сыйфатлары белән китмәле һәм хосуси булган сыйфатлары бер-берсеннән аерылып алына, төп вә уртак сыйфатлары аерылып билгеләнеп куела. Менә болар безнең аң вә мәгънәбезне тәшкил итәләр. Сүз, әнә шушы аң вә мәгънәләрне ифадә[4] коралы булган кеби, ул шуларны тудырышуга да хезмәт итә.

Аерым нәрсәләр турысындагы һәрбер тәсаувыр фәкать нәрсәләрнең безнең аңыбыздагы вакыйгда – чынында бар булган гади чагылма вә күләгәләреннән, анда басылып калган гади эзләреннән генә гыйбарәт. Безнең тәсаувырыбыз – идракебездәге бер нәрсә, әмма нәрсәләр, әйберләр – тышкы дөньяда алар. Шул хәлдә нәрсәләр хакында тәсаувырлар – рухи хәлләр булып, нәрсәләрнең үзләре – җисмани вә матдидер. Нәрсәләрне күрергә, тотып карарга, тикшерергә, иснәргә, татып карарга мөмкин. Әмма тәсаувырлар турысында болар мөмкин түгел. Тәсаувырларның галәмдә нәкъ үзләре, үрнәкләре (нәмунә)ләре бар, әмма аң вә мәгънәләрнең тышкы дөньяда үрнәкләре дә, үзләре дә юк. Чөнки төсләреннән, сакал-мыекларының төрле рәвешләреннән башка вә болардан аерым рәвештә тик кеше кыяфәтендәге һәм тел вә гакылга малик булган адәмнәрне тышкы дөньяда сез таба да, очрата да алмыйсыз. Шулай ук төрле яфракларыннан, төрле ис вә шәкелләреннән башка

[1] Идракебез – аңлап житүебез.
[2] Ингыйкяс иттерә – чагылдыра.
[3] Тәэссерләр – сизем, сиземләү.
[4] Ифадә – аңлату.

тик тамыр вә үзәкләрдән генә гыйбарәт үсемлекләрне дә табигатьтә күрә алмыйсыз.

Хайваннар хакында янә шулай ук. Мәсәлән, төсләреннән, симезлек вә арыклык, зурлык вә кечкенәлек кеби сыйфатларыннан башка фәкать һәр каюбызга мәгълүм бер сурәттә булган ат кыяфәтендә койрыклы, дүрт аяклы һәм тояклы бер хайван янә табигать эчендә юк. Мондый бер ат яки андый тик төп вә уртак, дәвамлы сыйфатлардан гына торган гомуми адәм һәм үсемлекләр – ялгыз мәгънәдә, ялгыз кешенең гакылында гына мәүҗүд[1] нәрсәләр. Болар ялгыз кешенең аң вә мәгънәсен тәшкил итәләр.

Аң вә мәгънәнең тышкы дөньяда җисмани вә матди бер үрнәге, сурәте булса, ул да – сүз вә сөйләм. Моның белән аң вә мәгънә ифадә ителә, һәм ул шуның белән гәүдәләндерелеп күзгә күрсәтелә. Чөнки сүз авазлардан, телнең вә иреннең төрлечә хәрәкәтләреннән, сулыш алып чыгарудан тора, болар барысы да – җисмани вә матди нәрсәләр.

Без фәкать аң вә мәгънәләребезне сүз белән аңлата алу аркасында гына уйлый һәм төшенә алабыз. Сүзләр булмаса, бездә уй вә төшенчә, мәгънә дигән нәрсә булмас иде. Шулай ук без тик рухи бер нәрсәдән гыйбарәт булган аң вә мәгънәләребезгә сүз вә тел аркасында җисманилек, сурәт бирәбез. Аларны аваз һәм сүз рәвешенә куеп гәүдәләндерәбез.

Без, мәсәлән, «әдәбият кешенең рухи хәлләре белән танышуга ярдәм итә», «фән кешенең күзен ача» яки «куян – бик куркак хайван» дип уйласак, шушы сүзләрне, әле авызыбыздан чыгарып аваз әйтмәс борын, үз-үзебездән шуны уебыз белән әйтәбез, боларны фикеребездә чагында ук авазлаган булабыз.

Безнең аң вә мәгънәбез дә әнә шуннан, шулай итүдән гыйбарәт.

Безнең шушы сөйләмнәребезне башка кешеләр ишетсә, гүя алар да моны эчләреннән, уйларыннан үзләре әйткән рәвештә ишетәләр, шуларны алар да уйларыннан тәкрарлыйлар.

Кешенең һәртөрле гаклый вә фикри эшләре, төшенчәләре менә шушы рәвешчә сүзләрне уйдан әйтүдән, мәгънәне тәләффыз кылудан[2] гыйбарәт була.

Кыскасы, без нәрсә генә уйламыйк, шуларның һәммәсен уйдан әйтә, тәләффыз кыла, уйдан сөйли, уйдан ишетә алабыз.

[1] Мәүҗүд – бар, булган.
[2] Тәләффыз кылу – сүзне әйтү.

Шулай булгач, кешенең уйлары һәм төшенүе – аның үз эченнән, ягъни тик миясе[1] эченнән генә сөйләве дигән сүз була.

Сүзләрне уйдан әйтү яки аларны уйдан ишетү кешенең «эчке тел»ен тәшкил итә. Тышкы авазлар, тышкы сөйләмнәр, эчке, ягъни уйдагы сөйләмнәрнең үзе булып, тышкы сөйләмнәр сүзләрдән торган кеби, эчке сөйләмнәр дәхи шул ук сүзләрдән торадыр.

Бу сөйләгәннәребездән менә шул ачык аңлашыла.

Әгәр дә сүз булмаса иде, кешедә гаклый эшләр, мәгънәләр, уй вә төшенчәләр дә булмас иде. Шулай ук кеше сөйләшә белмәсә яисә нинди дә булса берәр төрле ишарә вә галәмәтләр белән аң вә мәгънәсен аңлата алмаса иде, ул чагында һичбер төрле уйлый да, төшенә дә алмас иде.

Телнең әһәмияте, хезмәте – бу яктан менә шушы рәвешчә гаять бөек вә гаять зур бер нәрсә.

Кыскасы: тел – эчке тереклекнең мөһим бер әгъзасы. Ул өзексез рәвештә үсеп, үзгәреп тора. Менә ул – үзенең шушы хосусияте белән бергә бөтен аерым кешеләрнең вә бөтен халыкларның фикри тәрәккыйләре, фикри яктан күтәрелүләре белән бик нык баглы булган бер нәрсә. Тел, аларны һәрнәрсәдән артык иттереп яхшылап сыйфатлап, аларның табигать вә хосусиятләрен ялтыратып ачып бирә ала. Һәр кешенең вә бөтен халыкның фикри вә әхлакый салынышларындагы, рухи хәлләрендәге бөтен хосусиятләрен телләре аркасында гына яхшы һәм җиңел аңлап була. Кыскасы, халык белән тел икесе бер нәрсә кебидер. Шуның өчен «халык» дигәч тә – «тел», «тел» дигәч тә «халык» хәтергә килә. Бер милләтне әйтәләр икән, без шунда ук аның үзенең бер теле барлыгын да хәтерлибез.

**Тел вә мәдәният.** Тел – кешегә яратылган, туган чагында хәзерләнеп бирелгән һәм аны башта ук бүтән җанлы барлыклардан аерып куйган «илаһи» бер бүләк түгел, бәлки ул – соңыннан тәдриҗән[2] хасил ителгән бер нәрсә. Ул – кешенең матди вә рухи мәдәниятенең җимеше. Аны кешенең үз иҗтимагый вә икътисади тормышы тудырды. Әкренлек белән аны кешенең үз иҗтимагый тормышы чыгарды, аны кеше үзе эшләп, үзе үстерде, үзе тәрәккый иттерде, үзе камилләштерде. Бу да аның коллективлы хезмәтләре белән бәйләнеп барды.

Башка яклардан булган шикелле, тел ягыннан да кешенең бер заманнар хайванлык дәрәҗәсендә булган чагы бар иде. Ул әнә шушы

[1] Миясе – мие.
[2] Тәдриҗән – акрынлап.

дәрәҗәдән кешелек баскычына ничек үрмәләп тә, ничек тәрәккый иткәнен ачык аңлау өчен иң яхшы мисал – яңа туган баладыр. Баланың йөрүгә өйрәнмәс борын дүрт аяклы булып, аяк вә куллары белән шуышып йөрүе – менә бу кешенең ике аяк белән йөрергә өйрәнүеннән элек, башка хайваннар кебек, күп заманнар буенча дүрт аяклы булып йөрүен уйлата. Шуның өстенә бер баланың рухи яктан үсүен, рухан[1] күтәрелүен тикшергәндә дә, аның әзер бер тел белән тумаганын, бәлки ул башта үзенең ачыгуыннан, бер җире авыртудан, шатлык вә кәефләнүеннән хасил булган хисләрен фәкать кычкыру, тавышлану белән генә аңлата алганын күрәбез. Менә бу янә иң элгәреге кешеләрнең, балалар шикелле, төрле хис вә газапларын коры бер тавыш һәм кычкыру-бакырулар аркылы гына аңлаткан икәнлекләрен күрсәтә.

Болай булу бик табигый дә, чөнки иң элгәреге кешеләр дә балалар мисалында булып, аларда аң вә мәгънә юк иде. Шуның өчен аларда әле башта аң вә мәгънәләрне аңлатучы сүзләр дә булмады. Аларның уйлау, төшенүләре үсеп, күтәрелеп тә, телләре корылганчы әллә ничә мең еллар үтеп китте.

Кешенең уе иң элек аерым хәлләрендә атлар белән этләр арасындагы гомуми сыйфатларны аерып билгели белде һәм шуның аркасында ат вә этләрне белдерә торган сүзләр туды. Соңга табарак ул ат һәм эт белән, имән вә каеннар арасындагы гомуми-төп сыйфатларны аера алды. Моннан янә «хайван», «агач» дигән аңнар вә шуларны аңлата торган сүзләр туды.

Ләкин кешенең тел вә мәгънәсенең үсү һәм күтәрелүе, тәрәккыйсе бик әкрен барды. Моның өчен әллә никадәр гасырлар үтте.

Бу турыда түбәндә тәфсилле мәгълүмат биреләчәк булганга, бу урында шуның белән канәгатьләнеп торабыз. Фәкать сүзнең хөласасы[2] итеп, тагын шуны әйтәбез: тел – кешенең үз мәдәниятенең җимеше һәм кешенең үз эше вә үзе тудырган бер нәрсә. Һәртөрле белемнәр, сәнгатьләр, һөнәрләр кебек үк, тел дә аның үз миясенең, үз акылының хезмәт нәтиҗәсе.

**Телләрнең туышы, ясалыш һәм үзгәрешләре.** Кешеләрнең иң беренче телләре авазланмаган, ягъни авазлар белән әйтелә алмаган коры аптырашлардан, тән вә әгъза хәрәкәтләреннән, тегеләй, болай ымлаулардан башланды. Аннан соң төрлечә кычкыру-чакыру

[1] Рухан – рухи яктан.
[2] Хөласасы – нәтиҗәсе, йомгагы.

һәм бакырулардан гыйбарәт булды. Борынгы кешеләрнең сөйләшүләрендәге ымлаулар, төрлечә кыланышлар, баш, күзләрдәге хәрәкәт вә үзгәрешләр үзләренең максатларын, теләкләрен аңлату өчен зур хезмәт үтәделәр (нитәкки[1], хәзер телсезләр дә шулайдыр).

Боларның барын да кеше ерткычлардан һәм кошлардан күреп өйрәнде. Шундый кычкырулардан «ымлык» дип аталган сүзләр туды. Ымлыклардан дәхи башка сүзләр ясала башлады.

Ымлыклар кешеләрнең бер-берсенә билгеле бер фикер вә тойгыларын билгеле бер тон берлә төрле авазлар аркылы аңлатышуларыннан гыйбарәт иде. Кешеләрдә аваз чыгара башлау табигатьтәге нәрсәләргә, төрле тавышларга иярү нәтиҗәсе булганын югарыда әйттек. Менә бу авазлар тыныч чакта, шатлык вә рәхәтлек вакытында – бертөрле тынычсызлык, рәхәтсезлек, кайгы вә һәлакәт заманнарында икенче бер тонда булганнар, әлбәттә.

Кешеләрнең үзләренең эчке хәлләрен, уй вә тойгыларын аңлатуда төрле өзек һәм сузылмалы авазлардан гыйбарәт булган шушы ымлыклар (междометия[2]) кешеләрнең тудырган иң беренче сүзләре булды. Шулай итеп, кешеләрнең телләре туган чагында берәр иҗектән башланды һәм күп заманнар буенча, гомумән, бөтен телләр берәр иҗекле булып дәвам иттеләр.

Вәхшиләрдә сүзләрнең микъдары аларның аң һәм белемнәренең микъдары белән бәрабәр үсә бара. Бәгъзе бер вәхшиләрдә төс, уй (фикер) һәм акыл кебек нәрсәләр турысында аң булмаганга, аларда боларны аңлата торган сүзләр дә юк. Җөмләдән, кызыл тәнле һиндиләр шулай. Кайсыбер һиндиләр «идән, вакыт, ераклык, матдә, нәрсә» кеби сүзләрне дә белмиләр. Чөнки аларда әле нәзари аңлашлар (мәфһүмнәр) юк. Бу сүзләр аркылы аңлатыла торган мәгънәләр дә әле аларның башларында, миләрендә тумаган. Шулай булгач, аның өчен яңа сүзләр дә тумый, әлбәттә. Паровоз, телефон, пароход, лампа, граммофон кеби нәрсәләрне күрмәгән, белмәгән кешеләрдә яки вәхшиләрдә болар тугрысында бер аң булырмы да, боларны аңлата торган сүзләр боларда туармы? Әлбәттә, юк. Шуның өчен, вәхшилек дәверенә барган саен, кешеләрдә сүзгә ярлылыкны, сүз аз булганлыкны күрә барабыз. Мәдәниләшкән саен тагын сүзгә байлык һаман арта бара.

[1] Нитәкки – ни рәвешле.
[2] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*

Хәзерге кешелек авазлары белән сөйләшү мәләкәләре[1] кайсыбер вәхши халыкларда хәзердә дә юк әле. Җәнүби Африка вәхшиләре булган готтентотлар – шулар җөмләсеннәндер. Болар сөйләшкәндә нәкъерткыч хайваннарның тавышларына охшаш тавышлар чыгаралар икән. Боларда сөйләшкәндә үзләренә махсус бер тавыш белән ирен шапылдату, тел шартлату кебек хәлләр дә бар икән (казакъларда да бәгъзән шул хәл күрелә).

Америкалы һиндиләр дә шундый халыклардан. Болар күп вакытта тамак төпләре белән сөйләшәләр, диләр.

Чынлап та, шундый бер заманнар булган, ул заманнарда хәзерге сөйләшү телләре һич булмаган кешеләр бер дә сөйләшә белми, тик хайваннар шикелле кычкыру-бакыруны гына белгәннәр. Әнә шундый бакыру-чакырулардан, кычкырулардан сүзләр туган икәнен югарыда аңлап үттек.

Җәнүби Американың җәнүби очында «Утлы утрау» яки «Утлы җир» дигән бер җир бар. Менә шунда «пещерец» яки «әләкүл» (алаколуф)[2] дип аталган вәхши халыклар яши. Моннан җитмеш еллар элгәреге сәяхәтчеләрнең сүзләренә, риваятьләренә күрә, боларның сөйләшүләре һичберебезнең сөйләшүләребезгә охшамый, аларның сөйләшүләре бөтенләй кеше сөйләшүе төсле түгел икән. Аларның сөйләшүләре – нәкъ күркә коркылдаган кебек бер лыгырдавыктан гына гыйбарәт бер нәрсә, имеш. Яки бер кешенең тамак чайкаганда бугазыннан чыгарган гырылдавык авазларның чуалулары кебек бер кычкырынудан гыйбарәт икән. Хәтта хәзерге көндә дә пещерецларның сөйләшүләре шул рәвешчә, диләр. Болар хәзерге заманда җир йөзендәге вәхшинең дә иң вәхшиләреннән саналалар.

Африка вәхшиләреннән инглизләрнең «бушмен»нар дип атадыклары халыкларда да пещерецларныкына охшаш хәлне, шулар шикелле үк яшәү, шулар кебек үк сөйләшүләрне күрәбез.

Бөтен кеше ыругларында хәзерге көндә дә «ай, әй, ах, ух, уф, һәй, аһа, их, һа» кеби кычкыру-чакырулар бар. Һәр халыкның телендә «ымлык» дип аталган менә шундый кычкыру-чакыру сүзләре күп табылалар.

Менә башка бөтен сүзләрнең аналары һәр халыкта да шулар булганнар. Татарчада «ах» ымлыгыннан алынып – «ахылдау»; «пыш»

[1] Мәләкәләре – күнекмәләре.

[2] *Кирилл хәрефләре белән язылган*, алаколуфлар – Көньяк Америкадагы индеец халкы.

сүзеннән – пышылдау; «тук»тан – тукылдау; «дөп»тән – дөбердәү; «ялт»тан – ялтырау; «тер-тер»дән – тетрәү; «ши»дән – шуу; «сс, се»дән – сызгыру; «шак»тан – шакылдау; «тес»тән – теселдәү; «ыррр...»дан – ырылдау; «мү»дән – мөгрәү; «чуп»тан – чупылдау; «кых»тан – кыхкылдау; «кыт-кыт»тан – кытнау, кыткылдау; «шыгыр»дан – шыгырдау; «ыңңң...»нан – ыңгырау, ыңгырашу; «мү-мү-мү»дән – мыгырдау, мөгердәү, лыгырдау; «чек, шек» ымлыкларыннан – чыңгырдау, шыңрау, чыңгырдак, шыңрамак, шыңгырдамак; «мияу»дан – мияулау; «шарт»тан – шартлау; «тьфү» ымлыгыннан – төкермәк, төфермәк; «шау-шу»дан – шауламак; «эһү»дән – эңрәмәк; «эмм»нән – моңланмак, моң; «ө»дән – өн, өндәү; «кың, дың»нан – кыңгырау; «чеп-чеп»тән – чыпчык, җомҗык; «быт-быт»тан – бытбылдык; «тар-тар»дан – тартай; «карк-карк»тан – карга; «гү-гү»дән күгәрчен сүзләренең ясалулары шикелле. Мондыйлар телебездә бик күпләр.

Бер тамырдан әллә ничә тармаклы үсемлекләр үскән кебек, шулай ук бер тамыр сүздән дә, ягъни ымлыклардан да әллә никадәр сүзләр ясалып чыгарга мөмкин.

Һәр телнең үзенең тамыры яки нигезе урынын тоткан менә шундый ымлык сүзләр һәр телдә башка сүзләрнең иң мөһим кисәкләрен, сүзләрнең җилек вә маяләрен тәшкил итәләр. Югарыдагы татарчадан алынган мисаллардан күренгән шикелле, һәр телдә дә шул рәвешчә ымлык сүзләр бик күп сүзләрнең тамырлары булалар.

Төрле ыруглан булган телләрнең һәркайсында менә шушы түбәндәге хәл дә бар: кешеләр хайван һәм кошларны аларның чыгарган тавышлары белән дә атыйлар. Мәсәлән, татарлардагы «кәккүк, күке» сүзе шундый бер тавышны чыгаручы кошның тавышыннан алынып, аңа ат кушылган, шул ук кошка руслар «кукушка» дисәләр, немецлар – «кукук», французлар да «куку» диләр. Кызыл һәм кара тәнле вәхши вә ярымвәхши халыклар да бу кошны «куку» дип атыйлар икән.

Менә шул рәвешчә, югарыда сөйләнгәнчә, ымлыклардан, хайван вә кошларны һәм нәрсәләрне аларның чыгарган тавышлары белән атаудан бөтен халыкларның телләрендә күп сүзләр туды. Болардан туган сүзләр үзләре тагы күп сүзләргә тамыр булу хезмәтен үтәделәр.

Шулай итеп, бер сүздән – икенчесе, икенчесеннән – өченчесе, өченчесеннән дүртенчесе илх[1]... туып, сүзләрнең берсе икенчесенә

[1] Илх – һәм башкалар.

тамыр була торгач, телләр әкренлек белән сүзләргә һәм аңлатмаларга (тәгъбирләргә) баеп киттеләр.

Мәсәлән, этнең «ыррр» диюеннән «ырылдамак», «өрмәк» сүзләренең ясалулары шикелле. Менә монда элеккесе – соңгысына, соңгысы өченчесенә янә тамыр булып, болар бер-берсеннән туганнар. «Утны яки тузанны өрү» мәгънәсендәге «өрмәк» сүзе ярыкка авызны куеп, арасыннан тын белән һава чыгаргандагы яки авызны бөреп һәм очлайтып, тын белән һавага суктырганда чыгарган авазны белдерүче «өф» ымлыгыннан – «өферү», моннан янә «өрү» сүзенең ясалуы да шул җөмләдән.

Кешеләр, нәрсәләргә исем кушканда, башта ул нәрсәләрдән алынган беренче тәэсир белән файдаланганнар. Ягъни аның нинди дә булса бер сыйфаты элгәрерәк күзенә бәрелсә яки кайсы да булса берәр сизү әгъзасына элгәрерәк һәм ныграк тәэсир итсә, әнә шушы сыйфатны ул нәрсәләргә исем иткәннәр. Мәсәлән, америкалы бер һинди иң беренче кабат сыерны күрә дә, аның мөгрәвеннән тәэсирләнеп, аңа «му» дип исем куша. Кытайча песигә «мау» диелә. Моның да, билгеле, аның тавышына, мияулавына карап кушылган бер исем икәнендә шик юк. Бездә, татарларда, «песи» диелүе исә, аны чакырып, «пес-пес» дип әйтелгән ымлыктан алынган, әлбәттә. «Мачы» сүзе дә «мияу»дан алынган булса кирәк.

Кыскасы, кешенең табигатендәге иярүчәнлек сыйфаты вә аның шушы истигъдады кешеләрдә тел вә сүзләр туу һәм күбәюдә зур тәэсир күрсәтте һәм күрсәтә килә. Кешеләрдәге бу истигъдад һәрбер ыруг вә кавемнәр өчен яңа сүзләр тудыруга ярдәм итте.

Бөтен хайваннарның исемнәре дә шулай уйланып чыгарылды. Моны да һәр халык үзенчә һәм үзенә башка бер юл белән тудыра барды. Үз алдына эшләнде.

Яратылыш ягыннан кешенең авызы – искиткеч бер рәвештә эшләнгән бер әгъза ул. Ул аның белән сандугач сайравына-сызгыруына, чыпчык чыпылдавына, сыерчык сызгыруына, елан ысылдавына яки ысгыруына, чебен-черки вә кошларның, кигәвеннәрнең безелдәү һәм гүләүләренә – һәммәсенә үзләре шикелле үк килештереп тәкълид итә[1] ала. Агач сынганда һәм ярылганда яңгыраган тавышлары, шыгырдау, шакылдау, сыелдау, дыңгырдау, дөбердәү (күк күкрәгәндә вә башка чакларда) кебиләрнең барысын да авызыннан шулар шикелле килештереп әйтә ала.

[1] Тәкълид итә – иярә.

Кешенең авызындагы менә шушы истигъдад та төрле халыкларның телләрендә янә бик күп төрле сүзләрнең тууына нык ярдәм итте.

Алыйк борынгы һиндуслардагы «дүндү» (нечкә әйтелә) сүзен. Менә бу аларда «барабан»га исем булган. Бу исем, билгеле, аның тавышына тәкълид белән шуннан алынган икәне күренеп тора.

Молиз (Малак) һәм Полинезия телләрендә сыбызгыга «пипит» диләр икән, моның шул ук сыбызгы тавышыннан алынганлыгында шөбһә юк. Татарча «сыбызгы» – үзе дә шундый бер сүз.

Зәнҗиләрдә бер ыругның телендә тупны (пушка[1]) «пу» дип атыйлар икән. Билгеле, бу да тупның тавышыннан алынган, әлбәттә. Зәнҗи һәм кара тәнле, тупның атылуын беренче мәртәбә ишеткәч һәм әле беренче мәртәбә күргәч тә, аңа тупның үзенең тавышын исем иткән була.

Татарчадагы «туп» сүзе дә, һич шөбһәсез, «дөп» сүзеннән үзгәртелгән булып, бу да туп тавышыннан башка бер нәрсә түгел. «Мылтык» дигән исем дә шулай кушылган булыр. Моның асылы «пулт» булу бик мөмкин. Шуннан «пултык» рәвешенә кереп, аннан «мылтык» булып әйләнгән булыр.

Менә шундый тәкълиди сүзләрдән һәр телдә тагын күп сүзләр туган. Мондый сүзләр башка күп сүзләргә һәм тамыр була барганнар.

Телләрнең һәркайсында төрле-төрле яңа сүзләрне тудыруга балалар да катнашалар. Бу турыда аларның да хезмәтләре бар. Әлбәттә, моны балалар яңа бер сүз тудырабыз дип уйлап эшләмиләр. Бу – балаларның авызларын төрлечә итендерүдән, төрлечә кыландырып, төрлечә боргалауларыннан үз-үзеннән табигый вә механик буларак килеп чыга. Мәсәлән, бала, уйнап, шаярып яткан чагында яки, гомумән, уйнаган вакытында, үзенең иреннәре белән уйный, иреннәрен төрлечә боргалый, кыса, тарта, җәя, бөрә... һәм бала ничек кенә булса да, нинди дә булса берәр төрле сүз әйтергә маташа, маташа торгач, шуны әйтә дә[2].

Балалар өчен, һәр нәрсәдән бигрәк, бытылдау җиңел була. Бала эмелди һәм бетелди торгач, аның авызыннан үз-үзеннән «ә», «мә»,

[1] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*

[2] Балаларны телләре чыкмас борын күзәтеп торсагыз, аларның хайваннарга, кошларга мотлакан аларның үз тавышларын исем иткәнлекләрен һәм аларны үз тавышлары белән чакырганлыкларын күрерсез. Мәсәлән, этка «ау-ау» диюләре кеби («маэмай» сүзенең нәселе шундадыр). *(Авт. иск.)*

«тә», «бә», «пә», «ба», «па» кеби авазлар килеп чыга. Боларны да, бала тәкрарлый торгач, «ә-ә», «бә-бә», «пә-пә» рәвешенә китерәләр.

Ата-аналар исә балаларның шушы сүзләрен ишетеп, отып алалар да, аларны, билгеле, бер-берсе белән бергә кушып, тагын да оештырып вә килештеребрәк әйтәләр. Шулай итеп, балаларның югарыдагы сүзләреннән «мәмә», «мәмәй», «мәммәм», «әннә», «әттә», «бәүбәү», «пәпә», «папа», «баба» сүзләре туа.

Әнә шул рәвешчә, балалар авызыннан туган авазлардан, ниһаять, һәр телдә «мә-ма», «ә-а», «бә-пә», «ба», «па», «нә», «на», «нәнә», «нана», «мәм», «мәмәй», «әннә», «баба», «бабай», «мама», «папа» сүзләре заһир булган.

Татар баласының үзенә ашарга сораганда әйткәне: «мәм-мәм» (мәммәм) сүзе белән руслардагы рус балаларының аналарына – «мама», гарәпләрдә «әм» (әм), фарсыларның, иранлыларның – «мадәр», немецларның – «муттер», латинча «мате» – бер-берсенә гаять мөнәсәбәтле һәм якын сүзләрдер.[1]

Бөтен халыкта дип әйтерлек ата-аналар шушы югарыдагы яки шуларга бик якын булган сүзләр белән аталалар. Күп телләрдә атага «папа» яки «па» диләр. Кайсы бер телләрдә менә болай да була: берсендә анага әйтелгән сүз – атага, атага әйтелгән сүз дә анага әйтелә. Мәсәлән, русларда «мама» дип анага әйтелсә, грузиннарда атага шулай дип әйтелә икән. Шулай ук русларда «бабушка» яки «баба» сүзе хатыннарга әйтелсә, гомумән төрк халыкларында да «баба» сүзе (яисә «бабай» сүзе) карт, ягъни олы кешеләргә әйтелә. Руслар исә бабайга «дед» диләр, әмма грузиннарда «деда» дип анага әйтелә икән.

Төрле халыкларның телләрендә күптөрле сүзләр, шул рәвешчә, балаларның башта һичнәрсә уйламастан яки мәгънәсез эмелдәү һәм бытылдауларыннан туып, гамәлгә куелып, гомумиләшеп киткәннәр. Бу сүзләр дәхи уйланып түгел, үз-үзеннән табигый уларак туганнар.

Балалар – алар һәр нәрсәне тудыручы һәм зурлар өчен һәр турыда үрнәк булучылар. Алар, тәмам үсеп, олы кеше булып җиткәнче, кирәк уйнаган чакларында, кирәк ачуланган вә елаган чакларында булсын – һәркайчан яңадан-яңа сүзләр тудыру, үзлекләреннән нәрсәләргә яңа исемнәр кушу белән маташалар. Хәтта баланың үзе

[1] Авыл русларының тятясы белән безнең «әттә, ата, әткәй» сүзләре бар, аларның нянялары белән дә безнең «әннә» әни, ана, әнкәй» дигән сүзләребез бер-берсенә якын сүзләрдер. *(Авт. иск.)*

тудырган бер сүз, аның картлык көнендә дә хәтерендә булып, берәр нәрсәгә исем булып китәргә мөмкин.

Башка сүзләрдән яңа сүзләр ясалган кебек, шушындый балалар тудырган сүзләрдән дә күп яңа сүзләр туарга яхуд[1] ясалырга мөмкин. Кыскасы, яңа сүзләр өчен балалык сүзләре дә икенче тамыр булалар.

**Иске сүзләрдән яңа сүзләр туа.** Иске сүзләр һаман яңадан-яңа сүзләргә тамыр булып, яңа сүзләрне тудыра баралар.

Иске сүзләрдән яңа сүзләр ясала бару менә шул рәвешчә булган: кайсыбер халыклар үзләренең сөйләшүләрендә ике яки берничә сүзне бер-берсе белән бергә кушып, бергә укмаштырып, яңа мәгънәне аңлата торган яңа сүзләр ясаганнар һәм ясыйлар.

Бу хәл бигрәк тоташ һәм авышма телләрдә ачык күренә. Бу урында бер-ике мисал күрсәтик. Мәсәлән, бездә читек сүзе «эч итек» (яки эчке итек) дигән ике сүздән оештырылган булса, кытайча «төркем» (толпа[2]) мәгънәсендәге «җиндү» сүзе кеше мәгънәсендә булган «җин» сүзе белән «күп» мәгънәсендәге «дү» сүзеннән оештырылгандыр. Шулай итеп, яңа бер мәгънә аңлату өчен ике сүзне бергә кушып, укмаштыру-ябыштыру юлы белән яңа бер сүз туган була. Русчада «благочестие»[3] сүзе дәхи «честь»[4] белән «благо» сүзләреннән ясалып, өченче яңа бер сүз мәйданга килгән.

Кешеләрнең сүзләрне болай бер-берсе белән кушып, яңадан яңа сүзләр тудырулары – шулай булсын дип уйлап, алдан исәпләп эшләнгән эшләр түгел, бәлки бу үз-үзеннән табигый уларак эшләнгән бер нәрсә. Икенче төрле әйткәндә, кешеләр моны, гомумән, аңлап түгел, аңламыйча – механик бер рәвештә эшләгәннәр.

Моның үз-үзеннән туган булуы бик билгеле дә. Менә шул рәвешчә, башта, берничә төрле мәгънәне яки берничә төрле тәсаувыр вә аңлашны белдерү өчен, берничә төрле сүзләр әйтелә. Болар башта һәркайсы аерым-аерым әйтелсәләр дә, бара торгач, бер-берсе белән кушылып, бергә укмашып әйтелә башлыйлар. Шуннан соң әнә шулардан укмашкан, бөтен яңа бер мәгънәне аңлатуга махсус бер сүз килеп чыга.

[1] Яхуд – яки.
[2] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*
[3] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*
[4] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*

Кешенеӊ уйларын, тойгы вә хыялларын, белекләрен аӊлату өчен яӊадан-яӊа сүзләр тудыруның кирәклеге – шөбһәсез бер нәрсәдер. Русия Октябрь үзгәрешеннән соӊ туган «Халкомшур» (Халык комиссарлары шурасы), «Якомош» яки «Яшьком» (Яшь коммунистлар оешмасы), исполком, кантком, инпрос, уездком, наркомпрос[1], «Саусак» (Саулыкны саклау бүлеге) кеби тәгъбир вә истыйляхлар[2] да берничә сүздән оештырылып эшләнгән дә соӊра шулардан кыскартылган түгелме? Әлбәттә, шулай. Ләкин болар – уйланып, төшенелеп эшләнгән сүзләр.

Төньяк Америка һиндиләреннән бәгъзе кабиләләрдә бакырның исеме ике сүздән мөрәккәб булып[3] – «кызыл таш», тимернеӊ дә «кара таш» икән. Болар өчен аларда шуннан башка исемнәр юк, имеш. Алар менә шул ике сүзне беректереп сүз ясаганнар.

Иске сүзләрне бер-берсе белән кушу, укмаштыру, ябыштыру юлы белән ясалган вә тудырылган яӊа сүзләр төрк халыкларының телләрендә вә татарчада бик күп. Болардан мисаллар:

Иске сүзләр Яӊа сүзләр

1) Эч+итек = читек.
2) Көн+бакыш = көнбагыш.
3) Таба+агачы = табагач.
4) Алып+бару = аппару.
5) Уӊга+уӊга+иелү = иӊкәю.
6) Кил+ин = килен.
7) Бәхеш+кылмак = багышламак.
8) Бигә+иш = бигәш, бикәч.
9) Дәст+мал = тастымал.
10) Ду+пуст = дуст[4].
11) Кашында ак яки кашы+ак = кашка.
12) Күз+тикмәк яки тимәк = күзекмәк.
13) Күмер+ өрмәк = күрек.
14) Кайтыш+илә = кайтышлай.
15) Кул+ач = колач.

---

[1] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*
[2] Истыйлях – термин.
[3] Мөрәккәб булып – кушылып.
[4] Ду – «ике», пуст – «бер җан» мәгънәсендә. Дуст исә «ике тән, бер җан» мәгънәсендәдер. *(Авт. иск.)*

16) Сары+таг = Сирдык[1].
17) Юк+исә = юкса.
18) Беләк+йөзеге = беләзек.
19) Аргы+як = аръяк.
20) Абыз+тутай = абыстай.
21) Ат+таныш = атдаш, адаш.
22) Аб+руй = абруй.
23) Телен+ ач = тылмач.
24) Билге+вар = билгевар=болгар.
25) Күк+тетрәү, дөбердәү = күкрәү.
26) Сүек+тәкин яки сәвекле+ тәкин = сәбәктәкин.
27) Эч+кор = эчкор.[2]
28) Ак+ирмәк = агарма.
29) Чанак+аяк = чынаяк[3].
30) Иң+эч = инеч.[4]
31) Оч+белән+алмак = очламак.
32) Һич+булмаса = ичмаса.
33) Ал+төн = алтын.[5]
34) Казак+ага яки ака яисә әкә = казаки.
35) Мулла+әкә = муллакә.
36) Чү+чык = чуҗук.[6]
37) Хуҗа+Хәсән = Хуҗасән.
38) Ни+эшләмәк = нишләмәк.
39) Арка+таяныч = аркадаш.
40) Ыссы, эссе+чак = сыйчак.
41) Ян+таймак = янтаймак[7].
42) Дүн+көн = түнә көн = төнәген.
43) Ябыну+лык = яулык.

[1] Болгарларда борынгы шәһәр исеме. *(Авт. иск.)*

[2] «Эчкор» дип эч бавына, билбауга әйтелә. Штан бавына да әйтәләр. Златоуст өязендәге типтәрләрдә шулай әйтелә. Борынгы төркчәдә исә «кор» – «бау» мәгънәсендә. *(Авт. иск.)*

[3] Чанак – борынгы төркчәдә балчык савыт, «аяк» – «савыт». *(Авт. иск.)*

[4] «Инеч» дип ныклык өчен күлмәкнең эчке ягына салынган (арка һәм түш тапкырына) эчке катлавына әйтәләр. «Иң» яки «иң, киңлек» мәгънәсендәдер. *(Авт. иск.)*

[5] «Ал» – төснең рәвеше, «төн» исә борынгы төркчәдә «кием» мәгънәсендә дә йөртелгән. *(Авт. иск.)*

[6] «Чу» – борынгы төркчәдә «иркәк» мәгънәсендәдер. Чуҗук – кечкенә иркәк димәктер. *(Авт. иск.)*

[7] Ян – «тараф»; таймак, авышмак, янтаймак – «бер якка авышу, кыйшаю» мәгънәсендә. *(Авт. иск.)*

44) Аш+яулык – ашъяулык.

45) Алып+лил = акил (казакъча).

Шулай итеп, ике яки аннан артык сүзләр янәшә китерелеп, әлеге сүзләр бер сүз булып әверелеп киткәннәр.

Күрелә ки, шул рәвешчә бик аз сүзләрдән күп яңа сүзләр тудырырга мөмкин икән. Һәм бу бөтен кешелек дөньясында шулай булып чыккан да: берничә йөз генә тамырдан әллә ничә меңнәрчә яңадан-яңа сүзләр тудырганнар. Бу бөтен җир йөзендәге барлык халыкның телендә, барлык кавемдә, барлык ыруглар тарафыннан башы беленмәс ерак заманнардан бирле тәдриҗән[1] шулай эшләнеп килгән һәм шулай эшләнеп барадыр. Шулай итеп, һәрбер телдә сүзләр үз-үзеннән үрчеп, күбәюендә дәвам итә бирә.

Сөйләшкән чакта иске сүзләрдән яңа сүзләрнең ясалуы үз-үзеннән әкренлек белән сиздермичә барган. Бу хәзерендә дә күп вакытта шул эз белән бара. Бер телдә сүзләрнең болай күбәюенә шул телдә сөйләшкән кешеләрнең һәркайсының азмы-күпме хезмәтләре катнаша. Мәсәлән, шул халык арасыннан кем дә булса берәр бик җайлы бер форсатка туры китереп, бер дә аны-моны уйлап тормыйча, аңсыздан (тәсадефи уларак) нинди дә булса бер матур гына, дөрес кенә сүзләр оешмасы тудыра, берничә сүзне бергә укмаштырып әйтә. Шул ук вакытта икенче берәү аны ишеткән, хәтеренә алган була: бу да, теге тудыручы үзе дә әлеге сүзне уңайлы бер форсат чыккан саен яңадан тәсаувырларына алып, аны тәкрарлый баралар. Болардан тагы башкалар ишетеп, шулай эшлиләр. Менә шуннан әлеге сүз, колактан колакка, авыздан авызга күчеп яки күчерелеп, халык арасында йөри башлый. Бара торгач, бөтен халыкка үзен тәмам танытып, ахырда шул халыкның телендә тәмам урнашып калу бәхетенә ирешә. Шул телдә үзенә муафикъ бер урын алып яши башлый, хезмәткә тотына.

Бу бер ялгыз сүзләрдә генә түгел, бәлки бөтен җөмлә, бер тәгъбир, бөтен бер гыйбарәдә, сүзләрнең тезмәләрендә, мәкаль вә табышмакларда да шулай, шундый ук юл белән барыла. Яңа гыйбарәләр, яңа сүз тезмәләре, яңа атама вә төрле яңа аңлатышлар (ифадәләр) телләрдә шундый ук бер юл белән тудырылып урнаштырылалар.

Кирәк аерым сүзләр, кирәк тезмәләр булсын, телләр дә һаман артканнан-арта, күбәйгәннән-күбәя баралар. Боларның бу рәвешчә

[1] Тәдриҗән – акрынлап.

артып күбәюләре менә шул юл белән дә була: бер кабат сүз булып кабул ителгәннәре һаман яңа туачак сүзләр өчен тамыр була баралар. Болары тагы шулай башка яңа сүзләргә тамыр булып әйләнәләр.

Шундый ук юл белән күп халыкның телләрендә тамырларның, ягъни төп иске сүзләрнең баш һәм соң якларына бүтән тамыр сүзләр ялгап, үзләренә гүя баш һәм аяклар үстерәләр. Шулай итү аркасында мөрәккәб, ягъни оешкан берничә мәгънәне аңлату өчен үзенә махсус бер генә сүз тудырылган була. Берничә төрле аң вә мәгънә гүя бер сүз белән генә аңлатыла башлый.

Мәсәлән, татарчада яхшы+кылык сүзен бергә кушып яки «яхшы» сүзенә «кылык»ны кушып, «яхшылык» диелү кеби[1]. Шул ук бөтен бер сүз булган «кылык» сүзе, бара торгач, күп заманнардан соң әкренлек белән сыйфат һәм фигыльләрне, саннарны исем хәленә китерә торган бер галәмәт булып әверелгән яки шуннан соң сүзләрнең соңгыларына кушыла торган бу яңа галәмәт килеп чыккан. Ул да – «лык»тыр, бу галәмәт тә, бара торгач, дәхи нечкә сүзләргә дә кушыла барып, «лек» рәвешен алып киткән. Шулай итеп, «кылык» сүзеннән калын сүзләргә – «лык», нечкә сүзләр[гә] «лек» галәмәте тудырылган. Менә телләрдә сүзләр ни рәвешле эшләнә икән. Электә урын мәгънәсендә йөртелгән вә аерым бер сүз булган «лак» (яки «лаг», «лах») сүзе дә, бара торгач, тик бер кушымта хәле генә алып киткән, хәтта аерым үз башына кулланылмый башлаган: «кышлак», «улак», «пычрак», «комлык», «утынлык», «утлак», «болынлык», «печәнлек» сүзләрендәге кеби.

Русчадан раздача[2] сүзен мисал итеп алырга мөмкин. Бу сүзнең тамыры, нигезе булган иске матдәсе «да» булып, «давать»[3]тандыр. Шушы да тамыры монда нинди дә булса бер бирү эше барганын аңлата. Менә шушы тамырга инде баш ягыннан – «раз»[4], соң ягыннан да «ча»[5] кушылган. Хәзерендә бу сүзләр, аерым әйткәндә, бер мәгънә аңлатмыйлар. Әмма болар кайчан да бер, мотлак, һәркайсысы үз башына торганда да аерым бер мәгънә аңлата торган тәгәл

---

[1] «Яхшы», асылда, «якшы» булып, «якшылы» тамырыннандыр. Якшылык – яхшылык. *(Авт. иск.)*

[2] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*

[3] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*

[4] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*

[5] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*

сүзләр булганнар. Русча «моего», «твоего», «моему», «твоему»[1] сүзләре дә икешәр сүздән оештырылганнар: твой-ему, твой-его, мой-ему, мой-его[2].

Болар янә һәрберсе башта, кайчан да булса бер заманны, әлбәттә, шөбһәсез, аерым-аерым сүзләр булганнар. Ә хәзерге заманда исә болар рус телендә фәкать сүзләргә «соң кушым» гына булып, сүз тагылмасы рәвешендә генә кулланалар.

Иң килешле, җиңел, гомумән уй вә тойгыны аңлату өчен иң яраклы бер сүз яки бер гыйбарә, бер җөмлә һәр телдә эшкә ашып, гомумиләшеп киткән, әмма килешсез, авыр, яраксыз булганнары эшкә аша алмыйча онытыла, югала яки үзенең рәвешен, шәкелен һаман үзгәртә барган.

Үсү, тәрәккый, камилләшү кануны табигатьтә башка турыларда үзенең эшен нык йөрткән кебек, телләр хакында да ачык күрсәтә.

Телләрдә никадәр гаҗәп үзгәрешләр, үсү һәм камилләшүләр туа барганын югарыда күрдек.

Кешеләрнең бер-берсенә, икенче кешеләргә үзләренең уйларын, тойгыларын, теләкләрен, белекләрен аваз вә тавышлар аркылы аңлатышулары һәм шуларны эстәгәннәренчә аңлата алулары – кинәт карашта кешенең акылын тәмам аптыраашта калдырырлык гадәттән тыш бер нәрсә, бу – чынлап та, бер могҗиза: имеш, ерткычларча бер кычкыру, бакырулардан бу көнге шикелле камил телләр, максудларны төгәл иттереп аңлата алырлык төрле киң мәгънәле сүзләр, авазлар хасил булсын! Шулай шул, табигатьтәге, яратылыш дөньясындагы һәр нәрсә шулай, бер яктан, кешеләрнең акылларын тәмам аптыраашта калдыра торган бер искитәрлек булса, икенче яктан да иң гади бер нәрсә ул. Бу – шулай булырга тиеш булган иң җиңел, иң садә, иң табигый бер эш.

Әйе, әгәр дә ул кинәттән кыска бер вакыт эчендә шушы хәзерге рәвештә килеп чыккан булса, без моны, шөбһәсез, акыл төшенүдән өстен булган бер нәрсә, бер могҗиза иттереп санар һәм шуңар хаклы да булыр идек. Ләкин бу алай кинәттән бердән хасил булган һәм башта ук камил бер хәлдә туган хадисә булмады. Тереклек вә табигатьнең башка күренеше вә хәлләре кебек, бу да бик күп йөз мең еллар буенча өзексез камилләшү нәтиҗәсе булып туды. Җир йөзендәге бөтен халыкларның телләре хасил булу өчен чиксез күп заманнар

[1] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*
[2] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*

үтәргә туры килде, бу шуның өчен төп шарт булып табылды. Иң кимгә куйганда, моның өчен әллә ничә йөз мең еллар кирәк булды.

Әнә шул ничә йөз мең еллар адәмнәргә хәзерге телләрен тудырып бирде.

**Телләрнең үсү һәм яшәүләре, тамырлары.** Телләр дә терек, ягъни җанлы бер әгъза шикелле туалар, үсәләр, үзгәрәләр, картаялар, бетәләр, үләләр. Хәтта телләрнең үсү һәм үзгәрүләре шул дәрәҗәгә җитә: бер гасыр соңында шул тел белән сөйләшүчеләр үз телләрен аңлый алмас булалар. Бер гасыр яки берничә гасыр элгәреге тел вә әдәбиятлары соңгы яшь буыннарга ят бер тел булып әверелә. Шулай итеп, ул борынгы тел, борынгы әдәбият инде үз гомерен уздырган, картайган, үлгән була.

Вәхшиләрнең телләре сүзгә ярлы, җитешсез, зәгыйфь, чөнки алар гаять тар булган бер тереклек тирәсендә генә әйләнәләр. Чамалап әйткәндә, вәхшиләрнең тел хәзинәсе берничә сүздән генә гыйбарәт булыр. Ләкин аларда сүзнең җитешсезлеге ым вә әгъза хәрәкәтләре белән тутырыладыр.

Әмма хәзерге мәдәни халыкларның ничә мең еллык тәҗрибәләре белән баетылган телләре вәхши халык телләренең бөтенләй киресенчә, болар сүзгә бай һәм күп җитеш. Боларда сүзләр тегеләрнекенә чагыштырылмаслык дәрәҗәдә күп. Мәсәлән, мәдәни халыклардан кытай теле 40–50 мең сүзгә малик булса, инглизләр теле йөз мең сүзгә маликтер. Мәдәни халыкларның телләрендәге бу сүзләр әллә ничә гасырлар буенча әкренләп, биннисбә[1] аз микъдарда булган тамырлардан зоһур иткән[2] вә үрчегәннәр. Мәсәлән, кытай телендә – 450, инглизләр телендә 490 тамыр бар икәнлеге мәгълүм.

Бер телнең үсүе, камилләшүе шул тел белән сөйләшүче халыкның гомумән, мәдәни вә иҗтимагый үсүе белән бәрабәр бара. Теле белән бергә үк, әдәбияты да шулай. Мәдәният вә мәдәни хәятның киңлеге, югарылануы үзе белән бергә телнең киңәюен, югарылануын, тәрәккыйсен лязем[3] итә.

**Телләрнең тамырлары, алардагы иске сүзләр – тарихи яктан бик кыйммәтле сәрмаяләр[4].** Телләрнең һәркайсында яңа матдәләр белән бер рәттән үк искеләре дә саклана, хәтта ул мат-

[1] Биннисбә – чагыштырмача.
[2] Зоһур иткән – килеп чыккан.
[3] Лязем – тиеш, зарур.
[4] Сәрмая – *биредә:* төп элемент, материал.

дәләрнең, ул гонсырларның тарихы барып җитә алмаслык бер заманнарга туктаганнары да бар. Телләрдәге әнә шундый иске карт матдәләр һәркайчан безгә кешелекнең тарихка чаклы булган тереклек рәвеше, сыйфаты турысында иң кыйммәтле материал-сәрмаяләрне бирәләр.

Төрле телләрдәге бер-берсенә якын һәм үзара охшаулы булган сүзләр безгә төрле халыкларның тарихка чаклы булган бер дәвердә бер-берсе белән кардәш вә бер «сәви» (гыйрк)тан[1] булганлыкларын билгеләп куярга имкян[2] бирә, шуңа ярдәм итәләр.

Телләрдәге төрле аерым тамырларның мәгънәләре безгә тарихка кадәр булган тормышларның күренешләрен ача, борынгы заман фикерләрнең уйлау юлларының рәвешләрен күрсәтә. Мәсәлән, «үлгән телләр» дип аталган күп телләр бар (латин, санскрит, гыйбрани, сөрьяни[3], уйгур, финикә[4], асури[5] телләре кеби) менә шулар безгә күптән үлгән, сүнгән иске мәдәниятләре ничек булганлыгын ачып бирәләр. Мисыр, Асур, кәлдани[6] яки Бабил, Финикә, уйгур мәдәниятләре шикелле.

**Телләрнең тәрәккый итеп камилләшүләрендәге дәверләр вә төрле юллар.** Бөтен халыкларның телләре башта ымлыклардан, берәр иҗекле сүзләрдән башланып киткәнен һәм күп заманнар шулай дәвам иткәнлекләрен югарыда аңлап үткән идек. Менә бу башлангыч заманнар телләрнең үсү һәм камилләшүләрендә беренче дәвер һәм беренче баскыч хисаплана. Һәм бу «ялгыз иҗекләр дәвере» яки «тамыр дәвере» дип атала. Бу беренче дәвердән соң телдә үсү вә камилләшүнең икенче дәвере башланды. Монысы күп иҗекле сүзләр оештыру дәвере иде. Күп иҗекле сүзләрне тудыру төрле аерым иҗекләрне бер-берсе белән тоташтырып оештырудан [гыйбарәт] булды. Болай күп аерым иҗекләрне бергә укмаштырып, шулардан яңадан-яңа сүзләр ясау, шулай иттереп, телләрне үстерү,

[1] Гыйрктан – ырудан.
[2] Имкян – мөмкинлек.
[3] Сөрьяни – сирияле.
[4] Безнең эрага кадәр 2–1 меңьеллыкларда кулланылышта булган финикиялеләр теле. Семит телләре төркеменә кергән, «юкка чыккан телләр»дән санала.
[5] Асури – борынгы дәверләрдә Тигр һәм Евфрат елгалары арасындагы җирләрдә, ягъни Месопотамиядә яшәгән ассирияләр теле.
[6] Кәлданилар – Көче Азиядә Гыйракның көнбатышында борынгы заманда яшәгән кабиләләр.

камилләштерү кешеләрнең матди вә мәгънәви, ягъни эчке һәм тышкы яктан тәрәккыйләренең җимеше иде.

Ләкин алар күп иҗекле булган төрле сүзләрне ясауны башта күп вакытта аңлап эшләүдән бигрәк, аңламыйча, тәсадефи уларак эшләделәр.

Тормыш үзгәрә бару, фикер вә тойгыларның һаман үсә, камилләшә торуы аркасында кешеләрдә яңадан-яңа тәсаувырлар, яңадан-яңа аңнар хасил булды. Шулар белән бергә төрле-төрле яңа сүзләр, яңа тәгъбир вә атама (истыйлях)лар, яңа исемнәр туды, болар, шулай итеп, һаман күбәйгәннән-күбәя барды.

Бара торгач, телләр үзләренең төзелешләрендә, ясалыш вә тәрәккыйләрендә төрле юллар алып, үзләренә махсус төрле хосусиятләр хасил иттеләр. Үзләренең тәрәккыйләрендә телләрнең кайсыберләре төрләнми һәм үзгәрми торган төп тамыр сүзләрдән генә гыйбарәт булган бер ифадә рәвешен тудырдылар. Кытай, һинду-кытай, сиам телләре һәм шәркы җәнүби Азиядәге башка телләр шул җөмләдән санала. Боларда сүзләрнең игъраб[1], падеж юлы белән дә, сарыфлану юлы белән дә төрләнүләре юк. Шуның өчен бу телләрнең морфологиясе дә юк. Боларда фәкать нәху бар. Нәрсәләр, эшләр вә төрле хәлләр арасындагы төрле мөнәсәбәтләр бу телләрдә сүзләрнең бер-берсе белән төрлечә тезелүләре, җөмләдә төрле урын алулары, интонация, ягъни җөмлә эчендә сүзләрне әйткәндә тавышларның үзгәрүе, басымнар һәм башка төрле юллар белән күрсәтелә. Мондый телләргә тел фәнендә «тамыр телләр» дип йөртәләр. Боларның болай дип аталуы да боларда сүзләрнең «төп сүз – тамыр» вә «шәкли кисәкләр» (формальные части) яки «вак сүзләр»гә аерылмавыннандыр.

Телләрнең бәгъзеләрендә сүзләр нәрсәләр арасындагы төрле мөнәсәбәтләрне аңлату өчен төрләнсәләр дә, төп сүзләр белән аларны төрләндерә торган вак сүзләр вә ялгаулар арасында баглану, кушылу зәгыйфь бер рәвештә булып калган. Болар бер-берсеннән аерым йөртелүгә дә үзләренең истигъдадларын[2] саклый алганнар. Җир йөзендәге күп телләрне шундый телләрдән саныйлар. Урал-Алтай телләре яки төрк телләре гөруһы – шулар җөмләсеннәндер. Тел фәнендә бу телләр «тоташмалы» яки «ялгаулы телләр» – агглю-

[1] Игъраб – төрләнү.
[2] Истигъдадларын – сәләтләрен.

тинативные языки[1] дип йөртеләләр. Латинча «агглютинация» сүзенең тәрҗемәсе итеп, бу телләргә «җилемле» яки «ябештермәле» телләр дип тә әйтәләр.

Мондый телләрдә нинди дә булса бер яңа мәгънәне аңлату өчен һәрвакыт бер-берсе белән янәшә китерелә торган төп сүзләр, гүя бергә үсеп чыккан һәм бер-берсе белән ябештерелгән кебек, яңа бер сүз рәвешендә дә берләшә алалар. Ниһаять, берсе икенчесе белән тыгызлашып тоташып китеп, башка бер яңа сүз тәшкил итәләр. Шуның өстенә болар үзләренең аерым рәвештә кулланылуга яраклы булуларын да югалтмыйлар.

Бу рәвешчә ике аерым вә ике төп сүзнең, янәшә китерелеп, күп истигъмаль ителүе сәбәпле, күп заманнардан соң тәмам бер сүз булып әверелүләре – мондый телләрнең мөһим хосусиятләреннән.

Гомумән, төрләнә вә сарыфлана торган телләрнең сарыф кылынуларына хезмәт итүче һәм грамматикада «башкушым» (приставка[2]), «соңкушым» (суффикс[3]) дип аталган ялганмалар бер заманны болар да аерым вә бөтен бер сүз булганнар. Хәтта кайсыбер сүзләр кушымта вә ялганмалар белән үзләрене бер-берсеннән һич аерып булмаслык бер дәрәҗәдә нык берләшкән, кушылган булалар. Аларда төп сүз белән кушымнарны аеру фәкать телнең тарихын тикшерә торган аерым бер фән – тел тарихы фәне аркасында гына мөмкин була.

Гомумән, төрк телләрендә вә татарчада «бараем», «киләем», «барың», «килең», «барсам», «килсәм», «килсәң» кебек шарт фигыльләре дә, асылда, «бара идем», «килә идем», «бар идең», «кил идең», «барса идем», «килсә идем», «килсә идең» рәвешендә «имәк» фигыле белән «бармак» фигыленнән, ягъни ике төп сүздән ясалгандыр. «дыр» кушымы да «торыр» (яки «дорыр») фигыленнән үзгәртелгән. Димәк, бу да башта үзенә аерым бер сүз иде. Ләкин заман үтүе белән «дыр» рәвешендә вак сүз вә ялгау булып калган.

Вакыт фигыльләренең һәм киләчәк заман хәбәр фигыленең бер төре янә «чак» дигән төп сүзнең башка фигыльләргә кушылып әйтелүеннән аерым бер фигыль булынган дип уйлый алабыз. «Баргач», «килгәч», «барачак», «киләчәк» дигән фигыльләр дә, асылда,

---

[1] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*
[2] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*
[3] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*

«барган+чак», «килгән+чак», «барасы+чак», «киләсе+чак» рәвешендә хасил булгандыр. Бу фигыльләрнең юклыгы да шулай.

Тоташмалыкка рус теленнән мисал итеп добр+и белән добро+яго[1] сүзләренең, үзара тоташып, добрый вә доброго рәвешенә килүләрен күрсәтү мөмкин.

Телләрнең кайсыберләре үзләренең төзелеш вә ясалышларында тәрәккый юлларын менә болай билгеләгәннәр: боларда сүзләрнең шәкелләре төп сүзләргә (основа[2]га) кушымталар (аффикслар), ялгаулар белән генә төрләнмиләр, бәлки шуның өстенә боларда төп сүзләр (тамыр түгел) флексияләнү белән дә үзгәрәләр. Ягъни боларда падеж белән үзгәрү яки игъраблану[3] да була. Флексияләнү димәк – төп сүзләрнең ахырлары үзгәрү димәктер. Мондый телләрдә төп сүзләрнең ахырлары да, үзләре аваз ягыннан әллә ничә төрле үзгәрешләргә очрап, төрлечә авыштырылып, әүмәштерелеп бетерелә.

Кыскасы, мондый телләр дә – төп сүзләр фикерләрне һәм алар арасындагы төрле мөнәсәбәтләрне аңлату өчен төрле үзгәрешләргә очрауга, төрле рәвешчә авыштыруларга тәмам истигъдадлы булган телләрдер.

Тел фәнендә мондый телләр «авышмалы» яки «игъраблы телләр» (флективные языки[4]) дип атала.

Тагы телләрнең тәрәккыйләреннән менә шундый юл алганнары бар. Болар үзләренең ясалулары ягыннан тоташмалы яки ялгаулы телләр катарында[5] торалар. Ләкин шуның белән бергә боларның үзләренең характерлы бер сыйфатлары бар. Ул да – сүзләрнең үзләренә башка бер төрле тәркиб кылынуларыдыр[6]. Боларда аерым сүзләрнең тамырларыннан «сүз-җөмлә» ясала. Бу сүзләр, бер караганда, аерым сүз булып күренсәләр, икенче яктан, аерым сүз булмыйча, бер җөмлә булып күренәләр. Мәсәлән, тәкърибән[7] әйткәндә, «мин су эчәм» дигән җөмләне «мисучәм» дисәк, шушы телләрдәгечә, бер рәвешне күрсәткән булырбыз.

[1] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*
[2] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*
[3] Игъраблану – төрләнү.
[4] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*
[5] Катарында – рәтендә.
[6] Тәркиб кылыну – җыелу, кушылу.
[7] Тәкърибән – *биредә:* мисал өчен.

Мондый телләр «полисинтетик телләр» (полисинтетические языки[1]) дип аталадыр.

Мондый телләрдән шимале Африка һиндиләренең телләрен саныйлар.

Мәсәлән, астекларның[2] телендә «нинакаква[3]» дигән сүз «мин ит ашыймын» дигән мәгънәдә булып, ни (мин), накаил «нака»ның тамыры – (ит) һәм ква (ашамак) тамырларыннан җыйналып ясалгандыр.

Телләрне менә шул рәвешчә ясалышлары ягыннан тикшерү һәм шуның нәтиҗәсендә телләрне бу яктан «тамыр телләр», «тоташмалы телләр» (боларга «аналитик телләр» дип әйтүчеләр бар), «авышмалы телләр» (боларга «синтетик телләр» диючеләр дә бар) дип сыйныфларга аеруны тел фәнендә «телләрне ясалыш ягыннан тасниф» (морфологическая классификация языков[4]) дип йөртәләр.

Телләрнең «тамыр», «тоташма», «авышма» булуларыны аларның тәрәккый баскычлары вә тәрәккый дәверләре дип уйлап, тамыр телләрне – иң түбән, авышма телләрне – иң тәрәккый иткән, тоташма телләрне дә урта баскычта торган телләр дип санаучылар булса да, бу фикер – инде көчен югалткан бер фикер. Бер телнең тамыр тел яки тоташма тел булуы аның әле тәрәккый итеп җитмәгәнлек галәмәте түгел. Болар фәкать аларның алган үсү, тәрәккый юллары гына. Боларның һәркайсы үз юлларында тәрәккый итә, камилләшә баралар. Бөтен кешелек фикерләрен, кешелек тойгыларын тәмам иркен рәвештә аңлата алу өчен, тамыр тел яки тоташма тел булучылык һич манигъ[5] түгел. Үзләренең тәрәккыйләрендә шушы өч төрле юлдан киткән телләрнең һәркайсы бу турыда бик иркен эш итә ала.

**Телләрнең нәселләре.** Телләр үзләренең туышлары, аналары ягыннан төрле нәселләргә, гаиләләргә бүленәләр. Моңа «ыруг яки ана ягыннан сыйныф» диләр (генеалогическая классификация языков)[6].

Телләр түбәндә кайсы маядан, кайсы тамырдан туып үрчегән, кайсы оядан чыккан булсалар, шуларның һәммәсе бер ана вә бер

[1] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*
[2] Сүз Төньяк Америкадагы индеецларның ацтек (астек) кабиләсе турында бара.
[3] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*
[4] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*
[5] Манигъ – киртә.
[6] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*

гаиләдән җыелып санала. Һәм шуңа нисбәт ителеп, шул тамыр өчен гомуми булган бер исем белән аталып йөртеләләр.

Җир йөзендәге бөтен телләр әле тәмам тикшерелеп бетмәгәннәр. Бер дә тикшерелмәгән телләр дә әле күп. Шулай булса да, тикшерелгәннәре дә аз түгел. Әнә шушы тикшерелгән, беленгән телләрне һәммәсене шушы түбәндәгечә өч зур гаиләгә аералар:

1) Урал-алтай гаиләсе.

2) Һиндү-Яурупа гаиләсе.

3) Сами[1] гаиләсе.

Урал-алтай гаиләсенә шушы тармаклар керәләр:

1) Төрк тармагы. Орхон-тукю[2], уйгур-таранчы, госманлы, азәрбайҗан, төрекмән, чыгтай, кыпчак (коман), үзбәк, башкорт, кумык, казакъ-кыргыз, якут һәм чуваш-болгар телләре вә шуларга охшаган башкалар шушы бер тармактан аерылган ботаклардыр.

2) Самоед тармагы. Самоед шивәләре – Яурупа һәм Азиядә.

3) Фин яки фин-угор тармагы. Чын фин теле (Финляндиядә), лапланд, карель, эстон, венгр-маҗар, вогул, астек, мордва, чирмеш, ватяк, зырян вә башкалар шул тармактан булган телләр.

4) Магул тармагы. Монголиядәге нәгыз[3] магул теле, бурят һәм калмык телләре – шушы тармакның ботаклары.

5) Тунгус-маньчжур тармагы. Тунгус һәм маньчжур телләре.

Ләкин шунысын әйтеп китәргә кирәк: менә шушы биш тармакның һәммәсенең дә теле хәзергә бер-берсенә ыругдаш икәнлекләре тәмам катгый рәвештә карарланып җитмәгән бер мәсьәлә дип санала. Фәкать болар эченнән фин вә самоед телләренең ыругдаш икәнлекләре тәмам катгый бер хакыйкать дип игътираф кылына[4].

**Һиндү-Яурупа гаиләсе.** Телләрнең бу гаиләсе тел фәнендә башка һәммә тел гаиләләреннән дә яхшы тикшерелгән бер гаилә дип

---

[1] Сами – семит.

[2] «Тукю» яки «ту-куе» төшенчәсе төркиләрнең бик борынгы бабаларын аңлата. Бүгенге фәндә аларны рус теленнән алынган прототөркиләр (прототюрки) атамасы белән йөртәләр. VI гасырда самилар телендә төрки кабиләләрнең атамасы «турк» рәвешендә яңгырый, күплек санда – «туркут». Шуннан кытай теленә кереп, ул «ту-куе» («туцзюе» – «тюркют») төсендә урнашып кала. Чөнки төрки халыклар һәм Кытай арасындагы дипломатик мөнәсәбәтләр башта самилар ярдәмендә, сам телендә алып барыла. Кара: *Кляшторный С.Г., Султанов Т.И.* Государства и народы Евразийских степей: от древности к Новому времени. СПб.: Петербургское востоковедение, 2009. 105 с.

[3] Нәгыз – *бередә:* алга киткән.

[4] Игътираф кылына – таныла.

санала. Фәнни тел гыйлеме үзе хәзердә менә шушы гаиләдән булган телләрне тикшерүдән мәйданга килде. (Бу гаиләне «ария, һиндү-җәрмән, ария-Яурупа телләре» дип тә йөртәләр). Бу гаиләдән булган телләрне ун тармакка аералар:

1) Һинд тармагы. Һиндстан халкының яңа һәм борынгы телләре. Һинд телләренең иң борынгысы – ведда теле. Борынгы һиндләрнең брахман динендәге дүрт мөкаддәс китабы «Ведда» дип атала. Миладтан[1] ике мең ел элек язылган бер дини мәҗмуга. Бу исем шуннан алынган. Икенче борынгы һинд теле санскрит теле булып, болар икесе дә үлек тел саналалар. Санскрит теле хәзер дә һиндлыларда фәкать әдәбиятта һәм гыйбадәттә генә сонгый[2] бер рәвештә кулланыла. Бу телдә бай бер әдәбият сакланып калган. «Рамаяна», «Махабһарат», «Нал һәм «Дамаянти» кебек дастаннар – шушы телдәге әдәбияттан.

Бу тел чыннан да әдәби бер тел булган, «санскрит» дигән сүз үзе дә «эшләнгән» дигән мәгънәдәдер.

2) Иран тармагы. Бу – Иран халкының телләре. Иң борынгы Иран телләреннән борынгы фарсы теле мәгълүмдер. Бу телдә Иран шаһларының (Дарә, Камбиз вә башкалар) «чөй язу» дип аталган язулары сакланып калган. Икенче борынгы Иран теле – зәнд теледер. Зәрдәшт[3] хакименең дине шул телдә язылган. Яңа фарсы теле, көрд теле, Әфганстан теле, Кавказдагы осетин теле яңа фарсы теле дип йөртелә. Скифларның телләрен дә Иран телләреннән санаучылар бар.

3) Әрмән тармагы. Бу тармакта хәзерге әрмән теле тора.

4) Албан тармагы. Балкан ярым атәсендә[4] яшәүче албаннарның теле шул тармактан.

5) Юнан теле. Борынгы юнанның әдәби, гыйльми телләре шул тармактан.

6) Италия тармагы. Борынгы рума яки латин теле. Бу телдән роман телләре: француз, Италия, Испания, Португалия телләре хасил булган.

7) Кельт тармагы. Бу телдән калма әсәрләр аз. Хәзерге көндә кельт теле белән үткән бер заманда бөек бер нәсел тәшкил иткән

[1] Миладтан – миладидан.

[2] Сонгый – ясалма.

[3] Зәрдәшт (Заратуштра, Зороастр) – зәрдәштилек диненә нигез салучы. Зәрдәштиләрнең изге китабы булган «Авеста»ның авторы дип исәпләнә.

[4] Ярым атәсендә – ярымутравында.

кельт халкының калдыклары булган халыклар сөйли. Болар хәзер дә Ирландия, Шотландия, Бөекбритания, Франция Британиясендә яшәүче халыклардыр.

8) Герман (Җәрмән) тармагы. Моңа гот, Скандинавия, гарби Германия ботаклары керә. Бу соңгы ботактан англо-саксон вә аның нәселе инглиз теле санала.

9) Балтыйк тармагы. Моңа өч тел керә: Пруссия, литва һәм латыш телләре. Литва телендә сөйләүчеләр – Октябрь инкыйлабына кадәр Русия мәмләкәте эчендә саналган Кауна, Вильна, Солоки вилаятьләрендә һәм гарби-җәнүби Пруссиядә яшәүче халыклардыр. Литва теленең иң якын туганы латыш теле булып, бу телдә Лифляндия һәм кыйсмән Витебский вилаятендә яшәүче латышлар сөйлиләр.

10) Славян тармагы. Бу тармак өч төркемгә аерыла: а) җәнүб төркеме – моңа болгар, серб, хорват һәм эслау телләре керә; ә) гарби төркем – чех-словак, лужит, Польша, кашуб телләре шул төркемнән; б) шәркый төркем – великорус, белорус һәм украин телләре шушы төркемнән.

11) нче тармак буларак һинду-Яурупа гаиләсенә тоһар телен дә кушалар. Күптән түгел Кытай Төркестанында шушы телдә язылган язу табылган. Моның телен мотлак һинду-Яурупа теленнән саныйлар. Миладның беренче гасырында Урта Азиядә булган дип уйлыйлар.

**Сами гаиләсе.** Бу гаилә яки бу ыругка арами, асури[1], кәлдани яки бабили, яһүди (үзендә Инҗил язылган яһүд теле), гыйбрани, финикә, асыл гарәп теле, сөрьяни, кыйбти[2] (борынгы мисырлыларның хәләфләре булган халыкның теле)[3], химьяри, бәрбәр һәм хәбәши[4] телләре мәнсүбдер[5]. Бу соңгы дүртесе «хам телләре» дип тә атала (кәлдани, асури, сөрьяни, арами тармаклары).

Шушы ыруттагы булган телләрнең иң борынгысы – асури вә бабил теле. Сами нәселеннән булган бер ыруг халык, сумерилар җиренә килеп, алар белән катнашты һәм, аларга (сумериларга) үзләре-

---

[1] Асури вә кәлданиләр, асылда, гарәп ыругыннан булган халыклар иде. *(Авт. иск.)*

[2] Биредә копт (кобыт) теле күз алдында тотыла.

[3] Борынгы мисырлыларның бәгъзе һәйкәлләре вә андагы язулар тәкърибән миладтан дүрт мең ел элек булган бер заманга гаидтер. *(Авт. иск.)*

[4] Хәбәши – эфиопиялеләр.

[5] Мәнсүб – карый, *биредә:* керә.

нең сами телләрен йоктырганнары хәлдә, үзләре вә сами нәселдән булмаган сумериларның мәдәниятен кабул иттеләр[1].

Сами ыругыннан булган телләрнең әйтелеп үтелергә тиешле аерым хосусиятләре шушы: боларның һәркайсында сүзләрнең тамырлары өч тавышсыз (кыска) авазлардан гына торалар. Сарыф кылынганда, авыштырылганда, болар үзгәрмиләр. Сүзләрдә төрле үзгәрешләргә тавышлы (сузгыч) авазлар гына очрыйлар.

Сами ыругыннан бәгъзе үрнәкләр:

| | | |
|---|---|---|
| Гарәби | вәсеб, зикер ма, гарәб | Гарәпчә: изен, гайн, аб, баб, лисән, ма, нәһр |
| Сөрьяни | вәтеб, дикер ма, гарәб | Асурича: узун, ин, абу, бабу, лисан, мә, наһер |
| Гыйбрани | вәтеб, зикер ма, гарәб | Гарәби: галим, мәүт, тыйб, рәб |
| Гарәби | әлә, инсан, исем, сәма | Асури: әламү, галәмү, митү, табу, рәбу |
| Асури | әлү, нәсү, сәмү, сами | Гарәби: әна, әнт, әнтә, нәхен, әнтүм |
| | | Асури: әнкү, әтә, әти, әнәхини, әтнә |
| | | Гарәби: әнтән |
| | | Асури: әтин |

Бәни Исраил[2] теле булган гыйбрани теле[3] сөрьяни теленә якындыр. Гыйбрани теле белән сөрьяни теле – һәр икесе борынгы Фәләстыйн халкының теледер. Гайсәнең зоһуры вакытында Фәләстыйн халкы гыйбранча сөйләшкәннәр.

Сөрьяни теле борынгы яһүди теленә якын булып, борынгыда бай әдәбиятка (хосусан дини әдәбиятка) малик булган.

Сами ыругысы икегә бүленә: 1) көньяк, 2) төньяк. Төньяк төркемгә асури, кәлдани, яһүди, финикә һәм арами тармаклары керә. Көньяк төркемнән гарәп шивәләре: асыл гарәп теле, сөрьяни, хәбәши, Мисыр кыйбты, химьяри, картаҗа һәм бәрбәр телләре санала.

Бу урында шуны да әйтеп үтәргә тиешле: гәрчә кавемнәрнең телләрен, сүзләрен тикшерү аларның кайсы ыругка мәнсүб икәнлекләрен аерып бирсә дә һәм шуның аркасында кавемнәрне аерым-аерым ыругларга бүлү җиңеләйтелгән булса да, тел белән каумият вә гыйрк[4] арасында мөнәсәбәт ул кадәр көчле вә катгый бер нәрсә

[1] Асур вә бабил телләрендә чөй язуы белән язылган һәйкәлләр Бабил һәм «Нива» хәрабәләрендә табылгандыр. Бу һәйкәл вә язулар миладтан элек өч мең елдан артык бер заманга гаидтер. *(Авт. иск.)*

[2] Бәни Исраил – яһүд халкы.

[3] Гыйбрани – бәни Исраилгә мәнсүб дигән сүз. Бу бәни Исраилләрнең борынгы исемнәре. Чөнки гыйбранилар – «Исраил» дип ләкабләнгән Ягкуб пәйгамбәр балаларыдыр. «Исраил» сүзе, гыйбранча булып, «Габдулла» дигән мәгънәдә. *(Авт. иск.)*

[4] Гыйрк – нәсел, токым.

түгел. Шуның өчен дә тел кавемнәрне сыйныфка – ыругка аеруда төп әсас булып санала алмый. Тел белән гыйрк, ягъни сәви вә ыруг арасында мөнәсәбәт көчле бер әсас түгеллеген, бәгъзесе – африкалы, ягъни зәнҗи, кайсылары да Азия вә Яурупа нәселеннән булып та, Америкада яшәүче төрле кавемнәрнең гүя инглиз сәвиеннән әймешләр кеби бер ана теле белән инглизчә сөйләшүләре ачык күрсәтә. Тамырлары турани вә бәлки төрк-татар ыругыннан булганы хәлдә, хәзерге Балкан болгарларының телдә эслаулашулары[1] да шул җөмләдән санала. Анатулыдагы рум һәм әрмәннәрнең төрекчәдән башканы белмәүләре дәхи югарыдагы дәлилләргә ялгау була ала.

Тел белән гыйрк арасында мөнәсәбәт булмауга бер мисал – тагы француз теледер. Француз халкы кельтләрдән булып, хәзерендә дә үзләрендә кельтләрнең аергын сыйфатлары (әүсафи мөмәйизәсе) бар. Хәлбуки француз телендә кельт гонсыры көчкә генә сизеләдер. Бу тел – тәмамән руманча булып, иске латинчаның яңа бер рәвешедер. Катышсыз бер җенес булмаган кеби, дөньяда катышмаган аз тел бардыр[2].

**Телләрнең төрлеләнүләре, шивә һәм ләһҗәләргә аерылулары нидән.** Җир йөзендә түгел, төрле ыругтан булган төрле халыкларның телләрендә генә, хәтта бер ыругтан булган бер төрле халыкның телендә дә без күп төрлелек күрәбез. Бер үк тел әллә ничә төрле сөйләшүгә, әллә ничә төрле ләһҗә вә шивәләргә аерыла. Туран, ари, сами телләренең күптөрле тармаклары вә аларның да күптөрле ботаклары булган шикелле.

Менә бу хәлләр нидән була? Моңа сәбәп нәрсә? Моңа сәбәп – яшәгән урынына, сулаган һавасына, эчендә яшәдеге түгәрәкнең икълименә[3] карап, халыкның тормышы-тереклеге үзгәрүдер. Тереклек рәвеше үзгәрү, башкару[4] телгә дә, сөйләшүгә дә үзгәреш ясаган, бер үк телгә әллә ничә төрле төс биргән. Башка ыругтан булган халыклар белән катнашу да – телнең үзгәрүенә, башкалануына көчле сәбәпләрнең берсе. Халыклар бер-берсе белән катнашулары, тереклек рәвешен бер-берсенекенә охшатулары аркасында, болар бер-берсенең телләренә дә тәэсир итешкәннәр һәм һаман тәэсир итешә баралар.

---

[1] Эслаулашу – славянлашу.

[2] Госманлы төрекләренең мәшһүр тел галимнәреннән вә Истанбул дарелфөнүненең профессорларыннан Нәҗиб Гасыйм лекциясеннән алынды. *(Авт. иск.)*

[3] Икълименә – климатына.

[4] Башкару – башка рәвешкә керү, үзгәрү.

Шулай итеп, бергәлек тереклегенең башкаруы, тормышның яңаруы яңадан-яңа сүзләр, атамалар (истыйляхлар), аңлатмалар, сүз тезмәләре уйлап чыгаруга, төрле яңа гыйбарә вә җөмләләр тудыруга халыкны ирексез мәҗбүр иткән һәм итә килә. Күрше халыклардан да яңа сүзләр алына яки аларның сүзләренә каршы һәм шулар бәрабәренә торырлык яңа сүз вә тәгъбирләр, атамалар туа бара. Шулай итеп, телләр һаман үзгәрүгә табан йөз тота. Хәтта бер йөз яки берничә йөз ел эчендә бер үк ыругтан булган һәм башта бер үк тел белән сөйләшүче халыклар арасында сөйләшү ягыннан шактый аерма туарга мөмкин. Бу аерма бер-берсе белән җиңел аңлаша алырлык бер дәрәҗәдә генә булып калса да (госманлы төрекләре белән татарлар, төрекмәннәр, кумыклар, үзбәкләр, башкортлар һәм казакълар кеби), бәгъзән бөтенләй тылмачсыз аңлашылмаслык бер дәрәҗәгә дә җитәдер (фин, чуваш, мажар, татар, якут телләре кеби).

Рус теленең ләһҗәләре дә шулайдыр. Йөз еллык бу мөддәт эчендә әкренләп үзгәрә-үзгәрә, ниһаять, малорусларныкы да великорусларга аңлашылмаслык бер рәвешкә кергән. Хәзерендә хохол (кацап)[1]ны (Малорусиядә великорус мужикларына ләкаб) аңлый алмаган кеби, кацап та хохолны аңлый алмый. Болар икесе дә тагы белорусларны аңлый алмыйлар.

Бер йөз ел эчендә эслау телендә менә шушындый төрлелекләр туган һәм болар, бара торгач, гүя аерым-аерым телләр рәвешен алып киткәннәр.

Тагын югарырак китсәк, бик иске эслау теленнән, шушы төп тамырдан чех, поляк, рус, болгар, серб телләре хасил булган. Хәлбуки, хәзерендә чех болгарны аңламаган кеби, рус та полякны аңламыйдыр.

## Тел һәм борынгы иҗатлар

**Тел һәм дөньяга караш.** Иң борынгы халыкларның телләре турылык, садәлек (конкретность) һәм тасвирыйлык белән аерылалар. Бу халәт тә – иң борынгы замандагы кешеләрнең дөньяга карашларына баглы булып туган бер хосусият.

Иң борынгы кешеләрнең дөньяга карашларындагы төп хосусиятнең берсе менә шул булды: борынгы кешеләр дөньядагы, табигать галәмендәге бөтен нәрсәләрне җанлы вә терек иттереп күрделәр, табигатьтәге һәрбер вакыйга вә хадисәләрне, һәрбер күренешләрне

[1] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*

терек вә җанлы бер рәвештә нәкъ күзгә күренгән җанлы бер сурәт мисалында тәсаувыр кылдылар[1].

Иң борынгы кешеләрнең бу рәвешчә бөтен дөнья вә табигатькә җанлы һәм терек бер нәрсә иттереп караулары, бу рәвештә дөньядагы һәрнәрсәдә җан вә тереклек күрүләре «анимизм» дип атала.

Үзен чолгап алган тышкы хәятны вә тышкы нәрсәләрне аңлау, төшенү юлында кеше башта менә болай булган: үзендә ни нәрсә һәм нинди бер хосусият күрсә, үзенә үзенең эчке сынаулары белән ни нәрсә мәгълүм булса, шуларның һәммәсен тышкы дөньяда бар иттереп күргән, тышкы дөньяны да һәрьяктан нәкъ үзе кебек иттереп уйлаган, аңа бөтен табигать, бөтен нәрсә җанлы, ягъни рухка малик кеби күренгән. Дөньядагы нәрсәләрне фараз иткән чагында да ул нәкъ үзе рәвешендә яки үзенә охшаш бер сурәттә фараз кылган, ягъни кеше үзендә уйлау истигъдадын[2], сизү, тою һәм ирек кеби рухи хосусиятләрне табигатьтәге бөтен нәрсәләрдә дә бар дип уйлаган.

Кеше үзендә эш вә хәрәкәтләр аркылы күренгән төрле ирек (ирадә) эшләренең һәм башка һәртөрле көчләрнең зоһурын күрә. Күрә дә, ул үзендә берәр төрле хәрәкәт вә кузгалыш күренгән һәрнәрсәдә, һәрбер хәрәкәт вә кыймылдауда да шундый ук хәрәкәтләнүче көч эзли, аларда да үзендәге кеби шундый ук «ирек» дигән бер рухи хосусият барлыгын төшенә, һәрнәрсәдә бер энергия булуын уйлый.

Мәсәлән, яшь кешегә нинди дә булса күктәге бер атучының ук атышыннан туган бер ут кеби күренгән кояш янә уттан булган бер күз мисалында тәсаувыр кылынып, аны да кеше үзенә охшаткан: кояшны җир йөзенә карап тора, һәрнәрсәне күрә, һәр җиргә барып керә, шуның өстенә ул мәрхәмәтле яхуд бик куркынычлы бер нәрсә, ул һәрнәрсәгә ярдәм кылучы яки ул һәрнәрсәне һәлак итүче дип уйлый.

Җил, ут, аккан су, йолдыз, ай вә бөтен күк йөзендәге яктырткычлар иң борынгы кешеләргә һәммәсе дә терек һәм җанлы бер нәрсә булып күренәләр. Шуның өстенә тагы кешенең үзенең зәгыйфьлеген, көчсезлеген сизүе һәм дә үзенең табигатькә бәйләнышын аңлавы кешене табигатьтә яшеренгән көчләр бар дип уйлаттырып, шуларга табынуга мәҗбүр итә.

[1] Тәсаувыр кылдылар – күз алдына китерделәр.
[2] Истигъдадын – сәләтен.

Иң борынгы кешеләр хайваннарда да кешегә охшаш нәрсәләр күргәннәр яки хайваннарны да кешегә охшатканнар. Хайваннарда күрелгән бу хосусиятләр дә кешенең үзендәге хосусиятләрдән күп вакытта күп мәртәбә артык көчле һәм күп мәртәбә өстен дип уйланган.

Менә бу караштан кешеләрдә хайваннарга табыну һәм бәгъзе бер аерым кешеләрнең яки ыругларның хайваннардан зоһур итүләренә инаныш вә шулай ук аллаларны хайваннар сурәтендә тәсаувыр кылу кеби хәлләр туа. Бу рәвешчә аллаларны хайваннар сурәтендә тәсаувыр кылулары зооморфизм дип атала. Дәхи антропоморфизмның зоһуры да шул җөмләдән. Бусы Алла һәм рухларны кеше сурәтендә тәсаувыр кылудан гыйбарәт.

Кешеләрдәге дөньяга карашның менә шушы рәвештәге иң борынгы рәвеше, ягъни бөтен табигатьне җанлы һәм терек бер нәрсә рәвешендә тәсаувыр кылу – телләргә дә нык тәэсир итә, бу караш телдә үзен нык чагылдыра ала. Дөньяда тормышка нәкъ шушы борынгы карашның нәтиҗәсендә телләрдә истигарә[1], киная вә мәҗазлар[2] заһир була, шулар аркылы кешегә хас булган эш вә хәлләр тышкы дөньядагы нәрсәләргә һәм тышкы дөнья күренешләренә нисбәт ителә.

Шуның белән бәрабәр иң борынгы аңлашта бу истигарә вә мәҗазлар игътибари бер нәрсә түгел, бәлки тәмам чын мәгънәгә малик булалар. Чөнки болар, чыннан да, бөтен табигатькә җанлы бер нәрсә иттереп карауның нәтиҗәсе булып туа һәм үзләре аркылы шушы караш вә инанышны аңлату хезмәтен үтиләр.

Шушы югарыдагы караш вә инанышлар, ниһаять, кешеләрдә «хорафат – миф» дип аталган тәсаувырларны мәйданга чыгаралар. Аерым бер вакыйга вә хәлләрдән мөрәккәб[3] һәм бөтен бер рәвешләр тудырыла. Шушы хорафат аркылы иң борынгы кешеләр үзләренә табигатьнең бөтен зоһуратын изах кылырга[4] тотыналар. Хорафат белән гореф-гадәт вә йолаларда (обряд) бик тыгыз бер бәйләнеш күрсәтелә. Болар да, киткән саен, һаман ата-баба гадәте хәленә әверелә барып, (традиция хәленә кереп), тәдриҗән[5] дөрес оештырылган

[1] Истигарә – метафора; сүзне күчерелмә мәгънәдә куллану.
[2] Мәҗазлар – күчерелмә мәгънәдәге сүзләр.
[3] Мөрәккәб – оешкан.
[4] Изах кылырга – аңлатырга.
[5] Тәдриҗән – эзлекле рәвештә.

бер «дини мәрасим» рәвешен алалар. Ягъни «күрәнек» яки «табынык» вә «гыйбадәт» (культ) сурәтенә кереп китәләр.

Хорафат һәм күрәнекләрдә иң борынгы кешеләрнең дини аңнары ифадә ителә. Боларда аңның төп матдәсе (объект) табигать көчләре була. Бу көчләр дәхи зооморфизм һәм антропоморфизм рәвешләрендә тәсаувыр кылыналар. Тикшерү юлы белән кеше үзендә хәрәкәт итүче вә эш күрүче эчке бер куәт, ягъни рух бар дип белә. Ниһаять, кеше, моны бөтен табигатьтә дә бар дип уйлап, табигатьне рухлар белән тулган дип фараз итә һәм табигатьтәге шушы рухларга табына башлый.

Шуның белән бергә кеше борынгыларның, ягъни ата-бабаларның рухларына да табынырга тотына. Үзенең йорт һәм гаиләсенең нәселен саклаучы рухларга гыйбадәт кылына башлый. Болар «ата-баба күрәнеге»не тәшкил итәләр. Шул ук вә шундый ук рухларны кеше җир астында, күктә яисә нинди дә булса бер диңгез артларында, тауларда һәм диңгездәге утрауларда да бар дип уйлый.

Табигать күрәнеге кешеләрдә «ата-баба күрәнеге»ннән күп борын була. Ата-баба күрәнеге исә гаиләви һәм ыруглык мөнәсәбәтләреннән туа.

Борынгы юнаннарның диннәре, мәсәлән, шундый ук юл белән хасил була.

Халык аңында хорафат тудырыш бик тирән бер эз калдыра. Уйларның хорафи корылышы вә салынышлары ачык вә фәнни аң туып тәрәккый иткәнгә тикле даимән көчле вә исрарлы[1] була. Мондый хорафатлар, һәр соңгы пәйгамбәрләрнең диннәренә катнашкан кеби, ислам диненә дә катнаштырыла. Соңгы диннәрнең дә күбрәк өлешләрен хорафат тәшкил итә.

Фәкать заманнар үтү белән, кешеләрнең караш вә инанышларында әсаси үзгәрешләр хасил була. Әнә шуның аркасында үзләрендә борынгы «җан көрәшлек» карашын гәүдәләндерүче истигарә вә мәҗазлар тәдриҗән үзләренең элгәреге тасвирыйлыкларын югалта баралар, шулай итеп, бара торгач, болар игътибари вә шартый бер рәвешкә керәләр. Борынгы истигарә вә мәҗаз сүзләре игътибари бер нәрсә булып кулланылучы истигарә сүзләре булып әвереләләр. Мәсәлән, инде без «кояш карый», «яңгыр килә», «көн батты» кеби тәгъбирләрдән элгәреге тасвирыйлыкны аңламыйбыз, чынлап килә дип белмибез.

[1] Исрарлы – ныклы.

Шул рәвешчә, телләрдә ике төрле халәт бер-берсе белән ярыша башлый: 1) иң элгәреге тасвирыйлык; 2) нәзарилек вә киңәйтелеш. Бу ике халәтнең һәр икесе дә бездәге ике төрле төп рухи кирәкне үтиләр: 1) гүзәллек рәвешләре (художественные образы)[1] тудыру кирәклеге, 2) аң вә фикерләрне тагын да дөресрәк, тагын да садәрәк аңлатуга омтылу. Ләкин телнең тәрәккыйсендә никадәр соңгы дәвер алынса, шулкадәр анда сүзләрнең турыдан-туры булган тасвирыйлыклары азайганын һәм шул тикле аларда тасвирыйлыкның ялгыз сүзләр белән түгел, бәлки сүзләрнең бер-берсе белән кушылып, тәркиб кылынышлары[2] аркылы иҗат ителә барганын күрәбез.

Моны тагын да ачык аңлатсак, болай булыр: иң борынгы телләрдә сүзләр хәзерге безнең телләрдәгегә нисбәтән бөтенләй үз алларына рәвешле вә тасвирый булганнар («җитмичә егъласың» – «аңлап җиткермичә эш кыласың», «сез миңа йөрәк белән түгел, ирен белән сөйлисез» – «мине алдарга телисез», «минем авызымны яба алмассың» – «мине сүздән туктата алмассың» кеби). Икенче төрле әйткәндә, борынгыда сүзләргә тасвирыйлык вә рәвешлелек һич уйламастан, бушка бирелгән, әмма хәзердә инде бу – шәхеснең иҗат нәтиҗәсе, аның илһам җимеше. Шуның белән бергә бу тасвирыйлык кабатлану һәм үз-үзенә гадәтләнүдән әһәмиятсезләнә дә. Шуның өчен дә ул һәркайчан яңарып торуны таләп итә.

**Тел һәм шигырь.** Кешеләр ике төрле уйлыйлар: 1) рәвешләр, сурәтләр аркылы, 2) аң белән, ягъни аңлау юлы белән. Димәк, кешеләр һәм шигырь, һәм нәсер сармаясенә маликләр. Аң вә аңлау, төшенү сүзләре тәдриҗән[3] рәвеш вә сурәт сүзләреннән туып чыгалар. Бу да борынгы сүзләрдәге тасвирыйлыкның киму вә җимерелү нәтиҗәсе була. Безнең хәзер шигырь дип атаган нәрсәбез иң башта сүздә гәүдәләнде. Рәвешле вә тасвирый сүз (кәлимә) иң борынгы кешенең бөтен рухи тормышын ифадә кылды[4], аның инанышын, белеген, фикер вә хисләрен аңлатты. Ул чакта әле шигырь үзен аерым бер нәрсә итеп күрсәтә алмады. Бу үзенә аерым бер нәрсә уларак әкренлек белән үз-үзеннән тәрәккый итеп аерылып чыкты. Телнең тәрәккыйсенең нәтиҗәсе булып туды.

[1] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*
[2] Тәркиб кылынышлары – җыйналулары.
[3] Тәдриҗән – акрынлап.
[4] Ифадә кылды – аңлатты.

**Иң борынгы шигырьнең кайчан туышы.** Шигырьнең туышы кешелек мәдәниятенең башлангыч заманнарында шигырьнең иң беренче рәвеше җыр булды. Кирәк кайгылы, кирәк шатлыклы чакларында булсын, ул һәр заман тормышын җыр белән үткәрде вә шулай үткәреп килә дә. Шулай ук җыр үзе музыка, бию, танцы вә төрле әгъза хәрәкәтләре белән бәйләнышлы булды. Җыр башта нинди дә булса бер хисне белдерүче аерым-аерым кычкыру һәм нидалардан[1], шатлыклы яки кайгылы ихайлаулардан гыйбарәт кеби бер нәрсә иде. Ләкин болар үзенә бертөрле көй белән әйтелү иде. Бара торгач, көй вә тоннар сузылып вә сызылыбрак әйтелә башлады. Моның нәтиҗәсендә тәдриҗән дөрес вә төзек моң, аһәңле бер авазлар сөзентесе һәм бер-бере артыннан шигъри бер тезмә вә гыйбарәләр булып әверелделәр. Бу юлдагы тәрәккый аларны шул дәрәҗәгә җиткерде.

Шушы башлангыч җыр вә ихайлауларда кешегә табигать ягыннан салынган бер нәрсә булган вәзен, сәҗгы[2] вә тезмәчелеккә[3] омтылу хәле заһир булды. Вәзен вә тезмәчелек хәзердә, гомумән, шигырьнең төп шәкеле, бер хосусияте булса, бу хәл башлангыч шигырьләрдә аеруча шулай иде.

**Вәзен вә тезмәчелек һәм аның әһәмияте.** Һәр эштә вәзен вә тезмәчелек – кешедә яратылыштан ук бар булган бер нәрсә. Идракь вә иркебезнең эшен теләми торган бер гадәти хәрәкәтләр, бара торгач, ирекләнтыш бер хәрәкәт, автоматлык хәрәкәтләре һәм вәзенгә салынган бер тезмә хәрәкәтләр булып әвереләләр. Мондый эш вә хәрәкәтләр исә ит бәйләмнәре вә сизү тамырларының (газаләт вә әгъсабнең) көчләре – энергияләре аз сарыф ителүгә сәбәп булалар. Шулай ук моның аркасында болар аз арыйлар һәм шуның аркасында көчкә билгеле бер тәртип кертелә, анда шуның белән икътисад та ясала.

Кеше үзенең көндәлек тәҗрибәләре аркасында вәзен вә тезмәчелекнең әһәмиятен бик иртә аңлый алуга муаффәкъ була: үзенең барлыгын вә хәятын саклау юлындагы тартыш вә көрәшләрендә ул һаман киткән саен моннан күбрәк файдаланырга тырыша, ягъни

[1] Нидалардан – өндәүләрдән.

[2] Сәҗгы – рифмалаштырган чәчмә сүз.

[3] Монда *вәзен, тезмәчелек* сүзләре киң мәгънәдә алына. Һәрбер дөрес һәм үлчәүле хәрәкәтләр, билгеле бер төрле хәрәкәт вә эшләрнең, авазларның күтәренке яки нечкә тоннарның мәгълүм вә бер төрле мөддәт аркылы нәүбәтләшүләре барысы да «вәзен вә тезмәчелек» тәгъбире астына керә. *(Авт. иск.)*

моны эш вә хезмәтләренең һәртөрлесендә татбикъ кыла[1]. Табигыйдер ки, эш вә хезмәт никадәр катлаулы һәм ялыктыргыч-ардыргыч булса, ул шулкадәр вәзен вә тәртип тели. Бу – табигый бер нәрсә. Әгәр дә бер эштә күп кеше катнашып эшләсә, вәзен төрле-төрле хәрәкәтләрне бер-берсе белән яраштыра, тәртипләндерә һәм уртак бер эстәккә[2] юнәлтә. Вәзен булмаса, болар бер-берсенә комачаулык итәрләр иде. Мәсәлән, берәр урынга берләшкән көч белән берәр багана, берәр нәрсәне берләшеп күтәрергә, тартырга, төшерергә кирәк булса, күп кешеләр бергә төпләнеп күтәрәләр. Менә шушы чакта һәрбер күтәрү, тарту һәм оруда бөтен кеше беравыздан бер тон белән кычкыра, шуның аркасында бөтен көч бердән нык бер тәртип астында хәрәкәт күрсәтә, эш тә җиңел башкарыла ала.

Иң борынгы кеше үзенең тормышындагы башка бөтен хәлләрне җыр вә моң белән үткәргәне кеби, эшне дә ул шуның белән башкарды. Бер эшкә багланган бу җырны да әлеге эшнең вәзен вә интизамына[3] яраклandырды. Ниһаять, менә шул рәвешчә, иң борынгы шигырь рәвешләреннән берсе булган вәзенле эш җырлары мәйданга чыкты.

**Җырлы яки такмаклы уен.** Иң борынгы кешеләрнең тереклегендә җырлы вә такмаклы уен дигән нәрсә бөек бер әһәмияткә малик[4] була. Балалар өчен ничек булса, иң борынгы кеше өчен дә җырлы-такмаклы уен шулкадәр тормыш кирәкләреннән берсе иде. Чөнки бу – борынгы кешегә үзенең эштән арып талган җисмани һәм рухани көчләрен тышка чыгаруның чаралары булып табыла, бу уеннарда бәгъзән тән вә әгъза хәрәкәтләренең сәхнәсе ясалган. Болар балык аулау, сугышлар һәм башка һәртөрле вакыйга вә хәлләрне тасвир кылганнар. Яхуд[5] һәртөрле йола вә үрнәкләр, дини эшләр белән багланышлы булган. Мондый уеннарга хәзерге вәхшиләрнең тәмам йотылганлыкларын бәян кылалар. Бу уеннар аларда төрлелек һәм төрле катлаулылык белән аерылалар икән.

Шулай ук мондый уеннарның борынгы кешеләрдә илһами (импровизированный)[6] җырлар, бию, такмак вә такмазалар һәм

[1] Татбикъ кыла – куллана.
[2] Эстәккә – максатка.
[3] Интизамына – тәртибе, кагыйдәсенә.
[4] Малик – ия.
[5] Яхуд – яки.
[6] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*

музыкави кушылышлар (аккомпанемент)[1] белән бергә булганлыгын хәзерге заманның вәхши, ярымвәхши вә бәдәви халыклары безгә ачык күрсәтәләр.

**Хорның башлануы.** Уртак вә коллективлы эшләр, уртак уеннар кешеләрне бергә туплап, бербөтен кылып, алардан хор тууга сәбәп була. Бу иң борынгы заман шигырьләренең бөтенесенең ысул вә куелышларына ингыйкяс итә[2]. Тел шикелле үк, җыр вә көйләр дә гаммәнең шөгуриятсез[3] уртак хезмәтләре аркасында тезелеп мәйданга китереләләр. Башта эшне башлаган шәхесләр боларда соңыннан күпчелек эчендә югалып китә һәм рәвеше һәм дә үзенең мөндәриҗәсе игътибары белән җыр вә көй иң элек шигырь, музыка, бию-танцы сәнгате кебиләрнең барысының да баш орлыкларын үз эченә җыйный. Барысы да шәкелиятсез бер сурәттә бер-берсе белән катнашкан бер хәлдә була. Анда башта шигырь төрләренең барысы да, ягъни ривая, лирика, драма кебиләрнең һәммәсе дә үзләренең бөтен кыйсемнәре белән берләшкән, бергә укмашкан бер хәлдә булалар.

Тормышка муафикъ вә киләчәктә тәрәккыйгә мөстәгыйд[4] булган һәм дә тәрәккый вә камилләшү юлында бара торгач, тагын да бер-берсеннән ник аерылышып киткән шушы төрле матдәләрнең барысы да (ягъни ривая, лирика, драма кебиләрнең һәммәсе дә) үзләренең бөтен тармаклары белән бергә бер-берсе белән бу рәвешчә катнашу-берләшүләре «иң борынгы катнашлык» (халитә – первобытный синкретизм[5]) дип атала.

**Иң борынгы шигырьнең катнашлыгы.** Иң элгәреге катнаш җырлар хор белән үтәлгәндә, боларга драмаландыру да кушылган, ягъни эш вә хәрәкәтләр аркылы күрсәтелгәннәр. Үзләренең мөндәриҗәләренә яраклы йөз вә әгъза хәрәкәтләре белән бергә үтәлгәннәр. Мәсәлән, аучылык хакында җырлана икән, ул чагында аучыларның эш вә хәрәкәтләренә тәкълид ясалган, хор белән башлап җырлаучы (запевала)[6] арасында яки хорның өлешләре арасында бәгъзән сөйләшмәләр (диалог)[7]та булып алган, бәгъзән мәүзугъ вә хәлгә муафикъ рәвештә төрле сурәттә бизәнеп, төрлечә

[1] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*
[2] Ингыйкяс итә – чагыла.
[3] Шөгуриятсез – аңга, зиһенгә бәйсез рәвештә.
[4] Мөстәгыйд – сәләтле.
[5] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*
[6] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*
[7] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*

киенә дә торган булганнар: кайсылары аучыны тасвир итсәләр, кайсыберләре дә ауланучы хайваннарны, җәнлек вә киекләрне тасвир кылганнар.

Башлап җырлаучылар фиркасе бөтен ривая сөйләшүләрендә (эпический рассказ)[1] бик иртә тәрәккый итәләр.

Хорның җавап бүлемендә вә җыр кушымтасында күтәренке рәвештәге лирик матдәләре яңгыратыла. Шуның белән бергә боларның һәммәсе дә музыка һәм дә йөз вә кул хәрәкәтләре белән берләштереләләр. Вәхшиләр моңа, гомумән, үзләрендә аерым бер мәел[2] саклыйлар.

Югарыда сөйләнгән нәрсәләрнең калдыкларын күбесен хәзерге көндә дә күп халыкларда күрәбез. Хосусан, шәрыклыларда, Кавказ һәм Төркестан халыкларында бу калдыклар күп очратыла. Бу халыкларның уен мәҗлесләрендә, күңел ачу кичәләрендә булучылар бу хәлләрне ачык күрәчәк һәм шулардан бөек бер кызык вә ләззәт табачаклар.

**Илһами җырлар.** Мәдәнияттә никадәр ярлылык вә җитешсезлек булса, шулкадәр дә шигырьнең мөндәриҗәсендә ярлылык вә җитешсезлек күреләә. Бу хәл вәхшиләрдә дә, мәдәнияттән түбәнрәк торучы халыкларда да күзгә ачык бәреләә.

Бу халәт вә мондый җырлар әлеге халыкларда үзенә хорда җавап биреләә торган яки үзе хорда тәкрарланучы нинди дә булса берәр гыйбарәне садә, беркатлы һәм дә нәүбәтле рәвештә илһами бер юл белән (импровизация) әйтеп торудан гыйбарәт. Мондый җырлар – гадәттә, хор белән әйтелгән кыска җырлардан вә иң дөресе дә такмаклар турыннан булган бер нәрсәләр. Башлап җырлаучы тезмәләрне (мәнзумәләрне) җырласа, кушылучылар да җырның кушма бүлекләрен алып китәләр. Шундый ук җырларга күп вакытта үзенә бертөрле музыкави нәрсәләр дә катнаша: таяклар шакылдатып, җир һәм такта вә идәннәрдә аяклар тыпырдатып, кул шапылдатып, бармаклар шартлатып, җырларның вәзен өзекләрен һәм сиҗгыларын кисеп, аһәңләндерә баралар. Гомумән, биючеләр биегәндә яки йөз вә кул-аяк хәрәкәтләре, ишарәләр белән нинди дә булса берәр төрле эш вә хәлне тасвир кылганда, башкалары бергә кушылып җырлыйлар яки вәзенле бер аваз белән тавышлар чыгара

[1] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*
[2] Мәел – омтылыш.

вә кычкыралар, һай-һу салалар. (Музыкага биегәндә, кавказлыларда, кул шапылдату, бармак шартлату һәм «һап һап...» дип, вәзенгә салып аяк басуына вә көйләрнең кисентесенә карап, бергәләп авазлар чыгару кебиләр хәзердә дә бик куәтле дәвам итәләр. Монда булынучыларның ләззәт вә хозурлары, кәефләре шул дәрәҗәгә җитә, хәтта бу мәҗлестәгеләр һәммәсе вәзенле авазлар, көй вә музыка, тән вә әгъзалар хәрәкәтеннән җыйналып туган гомуми аһәңнәргә тәмам исерә һәм дә шуларга тәмам мәҗлүб булалар[1]).

**Җырның тормыштагы мөнәсәбәтләргә карап үзгәрешләре.** Тормыш мөнәсәбәтләренең көчәюе һәм катлаулашулары сәбәпле, җырларның мөндәриҗәләре дә үзгәртелә барды. Шигърият әсәрләрен авыздан авызга, колактан колакка күчерүләр һәм киләчәк яшь буыннарга калдыра барулар башланды. Җырлар бер буыннан икенче буынга, бер халыктан икенче халыкка күчерелә башлау фәкать кызыклы бер көй вә моң булганлыкларыннан гына түгел, бәлки шуның белән бергә җырлар үзләре һәрьяктан кызыклы бер сүз тезмәләре булып табылганлыктан булды. Бара торгач, җырлар үзләренең хордагы кушымталарыннан башка ук күчерелә башладылар.

Шигъриятtә йолачылык (традиция)нең бу рәвешчә үсүе иң борынгы катнаш җырлар (синкретизм)[2]ның бер-берсеннән аерылышулары һәм таралышулары белән бәйланышлы булды. Бу катнаш эчендәге һәрбер бүлекләр шәхеснең үсүе һәм аның иң борынгы бер җәнлектән – халыкчанлыктан аерылулары белән ачык бер төс алды.

Табигый, бер үк кешедә җырчылык, шагыйрьлек, музыкачылык, биючелек вә артистлык кеби төрле сыйфатларның җыйналуы – фәкать иң башлангыч дәверләрдә вә иң беренче баскычларда гына булырга мөмкин булган бер нәрсә. Иң борынгы заманда җыр техникасы зәгыйфь иде. Ул чакта һәркем җырчы вә илһамланучы булырга, барабаннар сугуга вә музыкага кушылып, кул шапылдатуга, такта кагуга, бармак шартлатуга (бездәге иске мәдрәсәләребездә кубыз уйнаулар, поднос кагулар шуңар керә) мөмкин иде. Ләкин, бара торгач, тел, музыка кораллары һәм җырлар тәрәккый итү юлына керде, камилләшә башлады. Шушы вакытларда үзләрендә яратылыштан булган, ягъни фитри истигъдадлары буенча аерым

[1] Мәҗлүб булалар – җәлеп ителәләр.
[2] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*

шәхесләр (личность[1]) килеп чыга башлады. Бу да мондый шәхесләрнең бу турыдагы эшләрне – осталыкларны башкалардан артык күрсәткәнлекләреннән һәм дә бу хактагы элгәреге уртак тәҗрибәләрне үзләренең шәхси истигъдад[2] нәтиҗәләре белән һаман баета баруларыннан булды.

**Хор һәм хорда башлап җырлаучылар.** Җырларның гыйбарәләре ныгып, утырып җитеп тәрәккый итә башлагач та, хорда җырны башлап җырлаучылар вә хорны башкаручылар хор һәйәтеннән аерылып чыктылар. Чөнки бөтен кешегә дә катлаулы гыйбарәләрне җырлау мөмкин булмады яки кыенлашты. Ниһаять, хор фәкать башлап җырлауга җавап кына бирә барды яисә башлап җырланган җырның соңгы гыйбарәсен эләктереп алып, шуны кушма җыр рәвешендә кушылып әйтү вазифасын үти башлады.

Җырда җөмлә вә гыйбарәләр никадәр бер-берсе белән тагын да ныграк һәм катлауланган рәвешкә килсәләр, шулкадәр дә хорда җырны башлап җырлаучы вә дәвам иттерүчеләрнең әһәмиятләре артты, рольләре үсте. Җырлар ничаклы озын булсалар, шул тикле дә хор белән аз тәкрарлау мөмкин була башлады. Бу турыда хорның катнашы һаман кимегәннән-кими барды.

Җырда башлап җырлаучыларның рольләре мәсьүлиятле бер роль булып әверелде, бу – үзенә аерым бер осталык, аерым бер һөнәр. Эш вә тәртип һәм дә җырлаучының үзендә бер аерым истигъдад булуны сорый башлады. Шулай итеп, бара-тора тәсадефи бер илһамчылык бәрабәренә гамәлият туды һәм шул юлда бер йолачылык (традиция)[3] тудырылды. Ниһаять, һәр хорда башлап җырлаучы сүз вә авазларга малик һәм дә үзенең моң вә җырлары булган һөнәрле вә мөтәхассыйс[4] бер җырчы булып әверелде. Җырчының хор белән мөнәсәбәте киткән саен азайганнан-азая барды. Бәгъзән, бөтенләй киселеп тә куйды. Җырчы инде үзлегеннән үзе аерым хәлендә яки башка җырчылар белән бергә нәүбәтләшеп җырларга, ривая һәм әкиятләр сөйләргә һәм тәмам аерым хәрәкәт кылырга тотынды. Җырчылар арасында җитди яки көлкеле, ягъни уен юллы моназаралар, гәпләшүләр, такмак вә табышмак әйтешүләр башланды. Кара-каршы сөйләшү вә әйтешүләр заһир булды.

[1] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*
[2] Истигъдад – сәләт.
[3] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*
[4] Мөтәхассыйс – белгеч.

**Борынгы катнашлыкның (синкретизм) таркалуы.** Һөнәрмәнд җырчыларның килеп чыгулары, һәрнәрсәдән элек, иң борынгы катнашлыкның бүлекләргә аерылуларына сәбәп булды. Ниһаять, шул катнашлыктан аерылып, шигырьнең төрле бүлек вә нәүгъләре[1] мәйданга чыкты. Үзләренең бөтен тармаклары белән күчерекчелек, йөрәкчелек[2], драма кебиләр зоһур итте. Җырлар башта даимән кечерәк булдылар. Ләкин боларда хикәя вә ривая кылышу йөрәкчелек белән бергә булынды. Болар дәхи эндәш вә нидаларда яки җырларның кушымта бүлемендә ифадә ителделәр, риваяне акырынайту, кичектерү яки аны ашыктыруда яки әһәмиятле вә тәкълидле тәфсыйлат белән элгәреге халәткә яңадан кайтып төшүдә үзләренең әһәмиятләрен арттыру, җыр вә мисрагъларны тәкрарлау кеби хәлләрдә йөрәкчелек (лирик) аңлатылды.

**Күчерекчелекнең аерылышы.** Һәм җырлаучының үзенә, һәм тыңлаучыларга якын торган вакыйгаларны вә алардагы шәхесләрне мактаучы җырларда йөрәкчелек – бик табигый бер нәрсә иде. Ләкин бу вакыйгалар мазыйга[3] кичкән саен, үзләрендәге йөрәкчелек (лиризм[4]) рухы кими барды. Ниһаять, бу хосусият бөтенләй югалып, безнең хәтерләрдә фәкать гомуми, ачык һәм схемалы өлешләре генә сакланып калды. Бу да җырның бөтен хиссият дулкыннарын ифадәсеннән[5] катгый нәзар[6] илә фәкать бер җыр булу сыйфаты белән гомумән халыкка охшавына карап була килде. Шулай итеп, җырлардагы инде еракта калган вә яшь буыннарга ят булган мактаулы каһарманнарның, вакыйгаларның тик иң тәүсыйфи[7] сызыклары гына истә сакланып калды. Халыкның яшь буыннарга вакыйгаларны вә мәгънәви байлыкларны күчереш эшләрендәге механики хезмәтләре халык хәтеренең шундый бер гомумилеген, шундый бер типлы һәм дә әмәлләндерүче гамәлияттән тәрәккый иттерде. Моннан да менә шушы хәлләр туды. Иң борынгы халыклардагы ыруг һәм оймак (кабилә) сугышлары җырларның нинди дә булса берәр алдынгы шәхес яки мәшһүр бер вакыйга тирәсендә җыйналып бер-

[1] Нәүгъләре – төрләре.
[2] Ривая бәрабәренә – «кучерекчелек» вә «лирик» урынына да «йөрәкчелек» атагы алына. *(Авт. иск.)*
[3] Мазыйга – үткәнгә.
[4] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*
[5] Ифадәсеннән – аңлатуыннан.
[6] Нәзар – караш.
[7] Тәүсыйфи – *биредә:* төп.

ләшүләрен лязем[1] иттеләр, бер түгәрәккә туплану халәтен мәйданга китерделәр, циклизация[2] ясадылар. Бу да шул рәвешчә булды: нинди дә булса берәр төрле вакыйга яки нинди дә булса берәр шәхес, үзенең аерымрак берәр хосусиятләре сәбәпле, җырчыларның аеруча дикъкатьләрен үзенә карата алды. Башка вакыйгаларны яки бүтән исемнәрне үз тирәләренә туплап, төркемнәр ясаганнары хәлдә, болар җырланган мәүзугның мәркәзе иттереп үзләрен куйдырта алдылар, шулай итеп, аерым-аерым җырлардан, ниһаять, бер туплану (цикл[3]) хасил булды. Мәсәлән, борынгы юнаннарның Троя сугышы вакыйгалары тирәсендә җыйналып тупланган киң үлчәүдәге күчерекчелек тупланмалары (эпические циклы[4]) шул җөмләдәндер.

Җырларның мөндәриҗә[5] һәм өслүбләрендә йолачылыкның зоһуры[6] киткән саен һөнәрмәндлекләрен арттыра барган җырчылар сыйныфында үзенә тагын да яхшырак вә нык таяныч тапты вә, ниһаять, җырдан күчерек (ривая) өлешенең үзенә аерым бер шигырь төре рәвешендә аерылып килеп чыгуына сәбәп булды.

Юнаннарның бөек шагыйрьләре Гомер тарафыннан мәйданга китерелгән «Илиада» белән «Одиссей» иң беренче мәйданга килгән кечерәк шигырьләр иде.

**Җырчыларның рольләре, халык җырчылары вә гаскәри җырчылар.** Җырчылар, бара торгач үзләренең истигъдадлары[7] белән башкалардан аерымлык, артыклык казанулары аркасында, үзләренең ыруг вә оймаклары арасында вә аларның түгәрәк вә тупланыкларында киткән саен һаман зур-зур рольләр күрсәтә бардылар. Алар, үткәндәге вакыйгалар вә каһарманнарны гүзәл вә шигъри бер юл белән искәрүләре аркасында, халыкка сугышларда рух бирделәр. Батырлыкны вә өстенлекне мактасалар, куркаклыкны вә көчсезлекне дә бу җырчылар нык яманладылар, шуны халыкка начар күрсәттеләр. Боларның бу төрле тавышларына вә мондый хөкемнәренә дә халык тарафыннан нык колак салынды. Әмма сугышчылар сыйныфы мәйданга китерелеп, сугышчылык хакимияте торгызылгач һәм гаскәри фиркаләр тудырылып, даими гаскәри

[1] Лязем – тиеш.
[2] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*
[3] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*
[4] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*
[5] Мөндәриҗә – эчтәлек.
[6] Зоһуры – төсе, сыйфаты.
[7] Истигъдадлары – сәләтләре, осталыклары.

башлыклар да заһир булгач, ыруг вә оймак җырчылары белән бергә үк гаскәри җырчылар да мәйданга чыгалар. Бу соңгылар исә бигрәк тә сугыш вә сугышчылык җырларында тәхәссыс казаналар[1]. Сугыш каһарманнары хакындагы мәдхия вә мәрсияләр дә аерым бер имтияз күрсәтәләр[2].

Менә бу җырчылар тарафыннан мәйданга китерелгән шундый җырлар тарихи күчерекләрнең башлангычларын, төп маяларын тәшкил иттеләр.

Җырчылар җырларның мөндәриҗәләрен эшләгән кеби, җырның өслүбләрен, телләрен, төзелеш вә ясалышларын яхшыландыру вә карарлаштыруда, төпләндерүдә дә бөек тәэсирләр күрсәттеләр. Һәм мөндәриҗәгә, һәм дә тел вә өслүбкә шигърият вә гүзәллекләр куштылар. Ниһаять, чын шигъри өслүбләрнең тууларына сәбәп булдылар.

Үз эшендә тәхәссыс иткән[3] җырчылар-шагыйрьләр инде, җырларның әсасларын[4], вакыйга һәм ул вакыйгага катнашкан шәхесләрнең тәүсыйфи сызыкларын, җырларның гомуми вә уртак якларын хәтердә тоткан хәлдә, башка якларын үзләре тарафыннан шигъри хосусиятләр белән һаман тутыра, киңәйтә вә төгәлләндерә бардылар, җырларның хосуси вә икенче дәрәҗәдәге яклары онытылганнан-онытыла барса да, әсаслары вә гомуми сызыклары нык сакланып калды.

Шушы рәвешчә бара торгач, үзенең мөндәриҗә һәм шәкел вә өслүб хосусиятләре белән бергә нәгыз[5] бер күчерекләр (риваяләр) ясала башлады. Мондый күчерекләрне тудыручы вә саклаучылар да ыруг вә оймак җырчылары, гаскәри җырчылар, кенәз, король, хан вә сарай шагыйрьләре булды.

Борынгы юнаннарның рапсод[6] – гизүче җырчы, кельт вә Скандинавия халкының бард[7] – сугыш җырчысы, гарәпләрнең мәддах – мактаучы, төркләрнең дә оланчы, акын, җырчы дип аталган җыр һөнәрмәндләре – шундый җырчылардан иделәр. Халык җырчылары

[1] Тәхәссыс казаналар – билгеле булалар, исем алалар.
[2] Имтияз күрсәтәләр – өстен торалар.
[3] Тәхәссыс иткән – яхшы белгән.
[4] Әсасларын – нигезләрен.
[5] Нәгыз – яхшы.
[6] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*
[7] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*

катарына[1] төрк-татарларның XIX гасырда вә XX гасыр башларында урамнарда мөнәҗәт әйтеп, дини рухта төрле бәетләр укып йөрүче бәетчеләрне кертергә мөмкин.

Юнаннардан Гомер исә үзе үк гизүче халык җырчысы иде.

**Хөкүмәт вә патшалык тудырылгач, җырчылар.** Аерым ыруглар, аерым оймаклар арасында якынлашу мөнәсәбәтләре үсә башлый. Нәсел вә токым, берлек һәм бер үк телдә сөйләшүчелек вә икътисади мәнфәгать берлек тупрагында (зәминендә) берләшүләр торгызыла. Ниһаять ыруг вә оймакларның бер-берсенә икътисади мөнәсәбәтләреннән патшалык, ханлык вә солтанлыклар тудырыла. Менә шуннан соң инде бер урында гына торып яшәүче җырчылар үзләренә тагын да киңрәк мәйдан, иркенлек вә ireклек эсти һәм эзли башлыйлар. Ахырда, шуның нәтиҗәсе булып, «сәях җырчылар – сәяхәтче мәддахләр» мәйданга килә. Сәях җырчылар эченнән берәрсе бик данлыклы вә куәтле булса, аны шул нәселдән булган кенәз вә корольләр, хан вә солтаннар, халык эченнән тартып алып, үзләренә чакыралар. Төрле бүләк-тартыклар белән, алардан үзләрен мактатып, һәртөрле шигырьләр сөйләтәләр. Шулай итеп, болар җыр вә шигырьләр аркылы исемнәрен мәңгелек яшәтү чараларын күрәләр.

Менә мондый сәях җырчылар-мәддахләр ислам хәлифәләре вә төрек әмирләре арасында да күп булды. Фирдәвес Мәхмүд Газнәвинең[2] мактаучысы булган кеби, күп гарәп шагыйрьләре дә шулай иттеләр. Төркестанлылардан Мөхәммәд Салих[3] вә кыйсмән[4] Нәваи[5] һәм шул җөмләдәндер. Госманлы төрекләрнең элгәреге шагыйрьләре дә шундый шагыйрьләрдән иде.

Шуның белән бергә сәяхәт, мәмләкәттән мәмләкәткә йөрү җырчы вә шагыйрьләрнең карашларын киңәйтте. Аларны җирле тар караштан, ыруг вә оймак мәнфәгатьләреннән алып, төрле яңа мәүзуглар[6] белән баетты. Бергә тырышып эшләү һәм башкалар

[1] Катарына – рәтенә.

[2] Мәхмүд Газнәви (971–1030) – 998 елдан төрек әмире, Газнәвиләр дәүләте патшасы.

[3] Мөхәммәд Салих (1455–1534/1535) – Урта Азия шагыйре, дәүләт эшлеклесе һәм Шәйбанилар дәүләте тарихчысы. Чыгтай телендә язылган һәм 9000 гә якын тезмәдән гыйбарәт «Шәйбанинамә» героик поэмасында 1499–1506 еллардагы Урта Азиядә тарихи вакыйгалар турында бәян итә.

[4] Кыйсмән – өлешчә.

[5] Галишер Нәваи (1441–1501) – Урта Азия шагыйре, фикер иясе, дәүләт эшлеклесе.

[6] Мәүзуг – тема.

белән ярышу аркасында җырчылык вә шигырь техникасы тәрәккый итте. Җырчы вә шагыйрьләргә күрсәтелгән аерым ихтирамнар, бөек бүләкләр, ниһаять, җырчылар, шагыйрьләр арасында югары нәселдән булган кешеләр дә булырга тиешле икән, дигән фикергә китерде.

**Шаян, көлдергеч җырчылар вә бәетчеләр.** Үзләренә хөрмәт казанган һөнәрмәнд җырчылар белән бергә үк һәм Яурупада һәм Шәрык халкында көлдергеч җырчылар, мәзәкчеләр вә кызык кына такмакчылар да булып үтте. Яурупада урта гасырның трубадур дип аталган һөнәрмәнд җырчылары (бигрәк тә җәнүби[1] Франциядә) белән миннезингер[2]ыннан (XII–XIII гасырның немец җырчылары) башка, тагы Яурупаның һәр урынында көлдергеч-такмакчы сәрсәри[3] җырчылар да бар иде, болар тагын да түбәнрәк тип кешеләрдән иделәр. Борынгы юнаннар да вә Бизанес мәмләкәтләрендә мондый җырчылардан мим[4] (тәкълидче) дип аталган җырчылар, румаларда гистрион[5] (шаян көлдерүче) исемен алучылар – әнә шундый җырчылардан иде. Урта гасырда Яурупадагы жонглер[6] – думбралы җырчылар дип аталган такмакчылар да борынгы юнан вә румаларның мирасы иделәр, Урта гасыр боларның һөнәрләрен тәрәккый иттерергә вә ныгытуга ярдәм итте. Германиянең шпильман[7] – уйнаклы ирләр шундый сәрсәри җырчылардан булып, болар хәтта XI гасырдан да элек Русиягә руслар арасына да килгәннәр. Бизанеслар, ягъни константиниялеләрнең һәм дә җәнүби эслауларның[8] шундый җырчыларыннан скоморох[9]лары булган. Болар руслар арасында үзләренә бик яхшы туфрак тапканнар.

Шәрык халыкларында исә, хосусан без төрк-татарларда, мондый сәрсәри-шаян такмакчылар, думбрачы җырчылар өчен өй беренә кереп, мөнәҗәт вә такмак әйтүчеләрне, бәетчеләрне мисал итеп күрсәтергә мөмкин. XX гасырдан соң болар азайганнан-азаю юлын тоттылар.

---

[1] Җәнүби – көньяк.
[2] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*
[3] Сәрсәри – шаян.
[4] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*
[5] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*
[6] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*
[7] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*
[8] Эслауларның – славяннарның.
[9] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*

Заманнар үтү белән вә бигрәк тә язу сәнгате пәйда булу аркасында мәдәниятнең гомуми күтәрелеше һәм җәмәгатьнең сыйныфларга аерылышулары сәбәпле, һәр милләттә җырчыларны шаян такмакчылардан, сәрсәри мәзәкчеләрдән аера торган аермалар киткән саен зурайганнан-зурая барды. Ниһаять, җырчылар тәдриҗән[1] гади җырчылыктан язучы-шагыйрь булып әверелү юлына керделәр. Ахырында үзләренә, чыннан да, аерым бер шагыйрьлек сыйфатын вә кыяфәтен казандылар. Киткән саен болар үзләрен тәрбия иткән халык шигыреннән ераклаша, күпчелекнең, гаммәнең иҗатыннан үзлек иҗатына таба омтыла бардылар. Шулай итеп, ниһаять, гасырларча җыйналып килгән халык мәгънәвиятенең байлыгын, күчерек вә йөрекчелек җырларын саклап вә яшь буыннарга күчереп килүчеләр әлеге сәрсәри-такмакчы җырчылар булып калды.

Такмакчы-сәрсәри җырчылар үз халыкларыннан башка халыклар арасында да йөрделәр. Мондый җырчыларның төп сызыклары шул булды: болар үзләренең бөтен тыңлаучыларына ярарга тырыштылар. Җыр вә такмакларын да төрле тыңлаучыларның һәммәсенә дә төрле юл белән шәп вә кызыклы иттереп күрсәтү өчен тиешле итенеш вә кыланышларны да үтәделәр.

**Халык күчерегенең техникасы.** Күчерек (ривая) техникасы иң элек сәях вә сәрсәри җырчылар түгәрәгендә эшләнде. Шул игътибар белән күчерекләр өчен «кабатлану, тәкрарлану» дигән нәрсә табигый бер нәрсә иде. Бу – бөтен кавемнең халык әдәбиятында иң мөһим бер хосусияттер. Бигрәк тә бу хосусият шул рәвешчә була: алдагы җырларның баш мисраглары элгәреге җырның соңгы мисрагын кайтарып әйтүдән башлана яки бөтен бер мәнзумә[2] беткәнче анда бер төрле мисраг һаман тәкрарлана бара.

Мондый тәкрарларга сәбәп, бер яктан, тыңлаучыларның тәэсирләрен[3] көчәйтү һәм аларның дикъкатьләрен кирәкле ноктага нык тарту булса, икенче яктан да моның бөек сәбәбе борынгы җырларның хор белән җырлануы булды. Бу да музыка, бию һәм төрле хәрәкәтләр белән бергә эшләнде (борынгыда бөтен җырлар: эш җырлары, табынык җырлары, игенчелек җырлары, бәйрәм вә туй җырлары, каһарманлык җырлары яки тарихи җырлар, булгын

[1] Тәдриҗән – акрынлап.
[2] Мәнзумә – тезмә.
[3] Тәэсирләрен – сиземләүләрен.

(вакыйга) җырлары – бытовые песни[1], уен җырлары вә башкалар булсын – һәммәсе хор белән җырланалар).

**Йөрәкчелек** (лирика[2]). Күчерекчелек кеби йөрәкчелек тә яңадан-яңа тормыш хәлләренең, иҗтимагый вә икътисади тереклек кирәкләренең көчләве белән хор катнашлыгыннан (хоровой синкретизм)[3] аерылып чыкты. Иң элек күчерекчелек (эпос[4]) зоһур итеп[5], йөрәкчелек шуннан соң туды. Күчерекчелекнең катнашлыктан аерылып чыгышы үзенә башка бертөрле шигырь техникасының тууына сәбәп булды. Йөрәкчелек туганнан соң, ул бәгъзән[6] күчерекчелек өчен корылган-төзелгән васиталардан[7] файдаланган кеби, бәгъзәндә йөрәкчелек үзе яңа техника юлларын ачты.

Йөрәкчелекнең тәрәккыйсе үзенә аерым бер юл белән булды. Йөрәкчелек – гадәтән күчерекчелекнең киресе булып, үзлек шигыре димәктер. Күчерекчелек исә тышкы галәмгә кайтмалы булып, гомуми вә матдидер. Боларның һәр икесенең соңгы һәм саф хәлләренә караганда, болар арасындагы аерма вә башкалык билгеле бер үлчәүдә тугрыдыр. Соңгы алган рәвешләре вә хәзерге заманыбыздагы хәлләре игътибары белән болар бер-берсеннән тәмам аерылалар. Ләкин күчерекчелекнең иң элгәреге рәвеше даимән өзлекле (субъективный[8]) булды. Бу хәл күчерекчелекне йөрәкчелеккә якынайтадыр.

Фәкать шунысы бар: күчерекчелектәге үзлек – шәхси түгел, бәлки төркемле вә һәйәтле-коллективлы бер үзлек иде. Иң элгәреге халык йөрәкчелекләре күчерекләр дәрәҗәсендә үк һәйәтле, бергәлекле булды. Ул чакта әле шәхесләр гаммәдән, җыеннан аерылмаган иде. Ул заманнарда шәхесләр өчен бары уртак тойгылар, гомуми хисләр генә бар иде. Сугыш җырлары бөтен хисләрне, нәрсәләрне үз эченә алырга, эләктерергә мөмкин иде. Чөнки болар уртак мәнфәгатьләргә вә күпнең, җыенның һәвәсләренә җавап бирә иде. Болар сугышчылар мохитендә тудырылды. Әмма хатын вә кызларның җырлары, табигый, башка бертөрле хис вә мәнфәгатьләргә, икенче

[1] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*
[2] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*
[3] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*
[4] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*
[5] Зоһур итеп – мәйданга килеп.
[6] Бәгъзән – кайвакыт.
[7] Васиталардан – әмәл-чаралардан.
[8] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*

бер чикле мохит әгъзалары җыенының һәвәсләренә җавап бирә иде. Берләшмә (җәмгыять) никадәр күп бүлекләргә аерылса, шул тикле дә йөрәкчелекнең төрләре күбәйде вә күбәядер. Шуның өстенә шулкадәр дә аның һәйәтчелек, күмәкчелек хосусиятләре кочәядер. Ниһаять, бу һәйәт вә күмәктән аерылышлар саф үземле йөрәкчелекләрне (индивидуальная лирикаsuccessfully[1]) тудырды.

**Йөрәкчелек һәм дөньяга борынгы караш.** Йөрәкчелек, ягъни йөрәк әсәрләренең тәрәккыйсе, рәвеш вә мөндәриҗәләре һәр яктан дөнья вә тормыш хакындагы иң борынгы караш белән тыгыз бер багланыш үзәрендә[2] булынды. Бу карашлар да инаныш вә йолалар, гореф-гадәтләр аркылы ифадә ителделәр[3].

Гомумән халык шигыренең, хосусан халык йөрәкчелек җырларының төп хосусиятләреннән берсе – кешенең хис вә фикерләрен, хәрәкәтләрен, эшләрен тышкы дөньядагы төрле матди нәрсәләр, төрле матди күренекләр (явление[4]) белән чагыштыру, табигать белән шуларны даимән якынлаштыру, яраштыру, бәрабәрләштерүдән гыйбарәт. Менә шушы хәл яки шушы шигъри бәрабәрчелек-яраштыру (гарәплеләрчә әйтсәк, поэтический параллелизм[5]), һич шөбһәсез, дөньяга иң борынгы карашның нәтиҗәсе булып туды. Бу шушы караш балчыгында туып үсте. Бу караш та, югарыда бәян итеп үткәнебезчә, бөтен табигатьне җанлы иттереп вә җан белән тулган бер рәвештә төшенүдән, бөтен табигатьтә вә бөтен матди нәрсәләрдә кешелек рухи хәлләренең бөтен сызыкларын күрүдән, аларга шуларны япсарудан[6] хасил кешедәге аң, истигъдад, уйлау-төшенү, хис кылу һәм хәрәкәтләнү кеби эшләрне бөтен табигать белән уртаклашудан гыйбарәт иде.

Йөрәкчелек шигырьләрендә вә гомумән халык йөрәкчелек җырларында әнә шулар бөтенесе белән төрелеп салынды, ингыйкяс итте[7].

**Халык шигъриятенең өч төрле юлы.** Тарихи тикшерелгәндә, халык шигырендә өч төрле юлдан үтүне күрәбез: 1) халык

[1] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*
[2] Багланыш үзәрендә – багланышта.
[3] Ифадә ителделәр – аңлатылдылар.
[4] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*
[5] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*
[6] Япсарудан – *биредә:* күчерүдән.
[7] Ингыйкяс итте – чагылды.

рәмезчелеге (символика[1]) белән бергә бәрабәрчелек, 2) охшатыш, 3) сәлби[2] чагыштырыш.

Бәрабәрчелек – эчке дөньяны, аның бөтен рухи хәлләрен вә төрле мөнәсәбәтләрен аңлау һәм аңлату иң борынгы шигырьләрдә гадәтән бәрабәрчелек юлыннан барды. Тойгы дулкыннары, рухи хәрәкәтләр шигъриятсез бер рәвештә тышкы дөньядагы нинди дә булса бер хадисәгә, зоһуратка да охшату юлы белән аңлашылды.

Халык шигыре бәрабәрчелегенең иң гади төре табигать һәм кеше тереклегеннән шундый хадисәләр[н]е (явление[3]) бер-берсе белән чагыштыру-яраштыру булды. Хәтта үзләренең хакыйкый мөндәриҗәләре игътибары белән бер-берсеннән аерымачык аерылып торганнары хәлдә, янә болар гүя бер үк нәрсәнең кабатлануы кебек уйланды, болар бер-берсенә тәмам аһәңдәш нәрсә кебек аңлашылды. Гәрчә кайсыбер яктан бер-берсенә охшаган булсалар да, төбендә-маһиятендә[4] төрлечә вә бер-берсенә башка булган хәл вә хадисәләрне дә кеше бик тиз бер-берсенә якынлаштырды, чагыштырды.

Моңа мисаллар:

*Йөгереп чыктым урамга,*
*Тәгәрәп килә пар алма.*
*Пар алмадай пар китереп,*
*Кавыштырсын бер Алла.*

*Алма агачының алына,*
*Былбыл кунган талына.*
*Җегете алсын, кызы барсын*
*Үзе сөйгән ярына.*

*Тау башында зәңгәр чәчәк,*
*Ничек үскән су тими?*
*Кашы нәзек, буе зифа,*
*Ничек үскән күз тими.*

*Кара урманның артында*
*Карчыга йонын туздыра.*
*Безнең кебек ятим бала*
*Җылап гомерен уздыра.*

[1] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*
[2] Сәлби – кире.
[3] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*
[4] Маһиятендә – сыйфаты, үзлеге белән.

*Ике каен янәшә,*
*Яфраклары шаулаша.*
*Ике туган бергә килсә,*
*Сандугачтай сайраша.*

*Биек кенә тауның ай башында*
*Кәкре-бөкре үскән көнбагыш.*
*Эчем дә тышым сары сагыш*
*Кемгә генә сөйлим мин байгыш?*

*Арсландай киек һич кайгырмас,*
*Каршысында аның тау булса.*
*Җегет булган кеше һич кайгырмас,*
*Газиз башы аның сау булса.*

*Бодай гына сәчтем, әй, уңмады,*
*Буразнасы аның тулмады.*
*Беркемгә дә генә үпкәләмим,*
*Үз бәхетем минем булмады*[1].

Менә шушы рәвештәге бәрабәрчелектә, гүя тик янынннан үтеп киткәндә кагылып китү кабиленнән генә, ике төрле хәл бер-берсе белән кара-каршы куелып, чагыштырылып үтелә, бу ике хәлнең дә берсе – эзләп табыла торган, икенчесе дә шуны изах кыла торган[2] була. Боларның элгәрегесендә бигрәк кешегә тәгаллекъ иткән[3] нәрсәләр алына һәм боларда авырлык үзәге (мәркәзи сикъләт – центр тяжести[4]) бигрәк охшау була. Болар, бара торгач, тагын да яхшырак, тагын да тирәнрәк, киңрәк рәвештә эшләнергә мөмкин. Бу да нәрсәләр, эшләр, сыйфат вә хосусиятләр хакындагы тәсаувырларның ишле вә багланышлы булышларына нигезләнәдер. Менә шулардан, ниһаять, тагын да катлаулырак, читенрәк бәрабәрчелекләр мәйданга чыккан.

---

[1] Русчада болай:
*Отломилась веточка*
*От садовой от, яблоньки,*
*Откатилось яблочко,*
*От'езжает сын от матери,*
*Ну чужу дальню сторону.*
Вә:
*Не видать месяца из-за облаков*
*Не знать князя из-за бояров. (Авт. иск.)*

[2] Изах кыла торган – аңлата торган.

[3] Тәгаллекъ иткән – бәйләнешле.

[4] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*

Мисаллар:

*«Айхайла» дигән ай тавышка*
*Төлке-карсак кача камышка.*
*Үлмәсә, җегет, үлми икән,*
*Эчкенәе тулы сагышка.*

* * *

*Тышка лай чыгып карасам,*
*Өер җылкы килә көтүсез.*
*Кеше генә белми, әй, хәлемне,*
*Эчкенәем яна төтенсез.*

*Бара (дагынай) идем, ай, юл белән,*
*Юлгынаем керде кул белән*[1]*.*
*Акылсыз (дай) бала түгел идем,*
*Акылларым бетте уй белән.*

* * *

*Аккош атасым килә,*
*Атсам, аласым килә.*
*Илем ямьле, суым тәмле,*
*Илемә кайтасым килә.*

* * *

*Минем сөеп җиккән атым*
*Кара белән тимер күк.*
*Сагынганда айга карыйм*
*Ул да ялгыз минем күк.*

* * *

*Сикереп төштем, су эчтем.*
*Нигә төштем, ник эчтем?*
*Бу хәсрәтләрне күргәнче*
*Нигә тудым, ник үстем?*

* * *

*Җитен күлмәкне җил ала,*
*Илтеп дәрьяга сала.*
*Безнең болай утырулар*
*Сагынып сөйләргә кала.*

[1] Кул дип ике тау арасындагы тауга таба күтәрелеп, сузылып киткән чокыр җирләргә әйтелә. Эченнән юл киткән була. *(Авт. иск.)*

*(«Акылың булса, сөйләп кара*
*Бу дөньяда кем кала», дип әйтү дә бар).*

* * *

*Суда балык күп булыр,*
*Чуртан балык бер булыр.*
*Илдә матур күп булыр,*
*Җан сөйгәне бер булыр.*

* * *

*Сандугачка җим бирмисең,*
*Ачка үлсен дидеңме?*
*Сагынганда юк сәламең,*
*Сагынып үлсен дидеңме?!*

Табигатькә мондый якынлаштыру-яраштырулардан бәгъзеләре шул дәрәҗәдә муаффәкыятьле булып чыккан, ниһаять, болар гадәти бернәрсә хәлен алып киткәннәр. Хәтта күрәнек рәвешенә вә йолалык рәмезләре[1] җөмләсенә кереп киткәннәре дә бардыр. Мәсәлән, «бәбкәм», «күгәрчен», «карлыгач», «колын» кебиләребез дә яшь сабый баланы белдергән кебек, «дөнья тубалы» вә «пумала баш» кебиләр дә хатын-кызларны аңлата. «Былбыл», «сандугач» сүзенең җанкай-гашыйк вә мәгъшукә урынында йөртелүе дә шул җөмләдән.

Халык шигырьләренең тагын да соңгырак юлларыннан вә хосусиятләреннән берсе – охшату һәм сәлби яктан чагыштырудыр.

Охшауга мисал:

*Алмагачта ник тавыш?*
*Чут-чут сайрый былбыл кош,*
*Читлектәге кошлар кебек*
*Саргайдым мин быел кыш.*

* * *

*Ике туры ат җиктем гөл яфрагы ашатып,*
*Бик сагынсам, айга карыйм – җаныема охшатып.*
*Ак Иделкәй алкын, суы дулкын, дулкыннары килеп какмасын,*
*Бер биткәе – кояш, бер бите – ай, яман күздән Ходай сакласын.*

* * *

*Алма нурланадыр кызаргач – җегет тәүфыйк таба кыз алгач.*

[1] Рәмез – символ.

* * *

*Әй тал үсә, тал үсә – башын киссәң, тагы үсә,*
*Тутасы өчен кайгырмыйбыз – сеңелләре тагы үсә.*

* * *

*Таң алларыннан, әй, тыңласам,*
*Сандугачкай сайрый ояда,*
*Сандугачлар кебек сайрый-сайрый,*
*Гомер итсәң икән дөньяда.*

* * *

*Кара чәчеңне үреп сал – чалкан яткан җыландай,*
*Бер куеныңда йоклар идем – биләп салган угландай.*

Сәлби яктан чагыштыру хосусияте бигрәк эслау җенесенең вә шулар җөмләсеннән русларның халык җырларында күп очрый икән[1].

**Халык йөрәк шигырьләренең мөндәриҗәсе.** Халыкның иң борынгы йөрәк җырлары мөндәриҗә ягыннан ярлы һәм бертөрле булу белән аерыла. Чөнки мондый җырлар фәкать гомуми вә уртак булган һәм дә шул ук вакытта катлаусыз вә садә хисләрне генә ифадә кылалар. Шуның бәрабәренә халык йөрәкчелеге (лирикасы) үзендә халык тереклегенең бөтен катлауларын, баскычларын чагылдыра. Аучылыктан, күчмә тереклектән хайван асраучылык тереклегенә, игенчелеккә һәм дә утраклыкка күчү, гаиләсезлек һәм никахсызлык дәверләреннән соң, хатын урлап алып китү кебек хәлләр башлану, кыз сату, кыз алу, ризалык белән никах, туйлар ясап, тантаналы өйләнүләр вә башкалар – менә халык тормышындагы шушы хәлләр, шушы тәрәккый баскычлары барысы да халык йөрәкчелегендә ачык ингыйкяс кыла барган. Шушы югарыда искәрелгән борынгы гадәтләрнең күбесенең калдырган эзләрен халык җырларында, такмак вә такмазаларында очратырга мөмкин. Безнең җырларыбыздагы:

---

[1] Русчадан моңа шушы җырларны мисал итәләр:
*Ох не белые снежки забелелися,*
*Ох, забелелася да ведь у старого седая борода.*
Вә:
*Не ясен сокол тут вылетывал,*
*Не черный ворон тут выпархивал*
*Выезжает тут злой татарченок.*
(История русской словесности. В. Садовника). 1 кисәк, 22 б. *(Авт. иск.)*

*Кара урманда кар яугач,*
*Йөри алмый аучылар,*
*Күп кызларның башын ашый*
*Тәсбих тоткан яучылар, –*

кебек җырлар да бездәге кыз сату дәверләрен күз алдында җанландыра.

**Йөрәкчелек һәм мәрасимнәр.** Иң борынгы заманнарда йөрәкчелек җырлары мәрасим (обряд[1]) вә гадәтләр һәм күрәнекләр (культ[2]) белән бик нык бәйлә багланышлы булганнар. Рус әдәбият тарихын язучылар бәгъзе бер галимнәрнең шушы түбәндәге фаразияләрен күчерәләр: гомумән, бөтен халык йөрәкчелеге борын заманнарда әллә кайсы вакытларда дини яки сихерле вә тылсымлы бер мәгънәгә, шундый бер әһәмияткә малик булган[3] төрле мәрасимнәрдән, гореф-гадәтләрдән туганнардыр.

**Драмаларның туышы.** Күчерекчелек һәм йөрәкчелек шикелле драмаларда иң борынгы «катнашлык»тан (синкретизмнан)[4] туды. Моның туышы да, табигый, катнашлыкның бүлекләргә аерылышы, кисәкләргә бүленүе, таралуы заманнарында булды. Ләкин драма борынгы катнашлыктагы хәрәкәт вә эш, йөз, тән вә әгъза хәрәкәтләрен, сөйләп бирү, кара-каршы сөйләшү кебек катлаулы хосусиятләрне үзенең катнашлыктан аерылып чыгуында күчерекчелек һәм йөрәкчелекләргә караганда яхшы ук күп саклап алып кала алды.

Мәдәни һәм мәдәни түгел халыкларның һәммәсе дә драмаландырылган мәрасимнәрдә сәрсәри җырчы вә такмакчыларның кара-каршы сөйләшүләрендә, җырларында вә башка шундый хосусиятләрдә драманың башлангыч рәвешен күрсәттеләр яки күрсәтәләр.

Катнашлыктан кирәк күчерекчелек, кирәк йөрәкчелек вә кирәк драмаларның баш орлыкларын вә башлангыч рәвешләрен без төрк-татарларда, бигрәк тә казакъ-кыргызларда ачык күрә алабыз. Алардагы оланчы-акыннарның, кыз озатканда кыз белән ата-аналарның, туганнарның, якыннарның бер-берсенә әйтешкән үләннәрендә һәм боларны әйткәннәрендәге бөтен хәрәкәт вә кыланышларында без катнашлыкның бөтен тармакларын (күчерекчелек, йөрәкчелек вә драмаларны) дөрес иттереп күрә алырга мөмкин.

[1] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*
[2] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*
[3] Малик булган – ия булган.
[4] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*

Берәү үлгәндә, аның якыннары, ага-энеләре, күршеләре тарафыннан үлек тирәсенә килеп салынган нәүхәләрдә[1], «ай-вай»ларда, шунда әйтелгән матәм җырларында, тәгъзия үләннәрендә, шул заманнардагы бөтен хәрәкәтләрендә болар бигрәк тә ачык күренә.

Ләкин хәзерге заманыбыздагы мәдәни милләт драмаларын бөтен төп хосусиятләре вә чын мәгънәсе белән тудыручылар борынгы мәдәни юнаннар булды.

Драмаларның тәрәккыйсендә даими сурәттә шушы мөһим шартларны күрәбез: иң элек күчерекчелек белән йөрәкчелек, күрәнек белән массалар-хорафатлар тәрәккый итә, камилләшә, бик ашыгыч рәвештә кешеләрдә үзлек һәм дә бер милләт халкының үзүзен танучылыгы үсәргә тотына. Менә шулардан соң вә шуларның нәтиҗәсе буларак драмалар мәйданга чыга.

Юнанстанда драманың иң нык тәрәккый итеп китүен без юнаннарның иранилар белән булган сугышларыннан куәтле сурәттә хәрәкәт күрсәткән милли күтәрелештән соң булганын күрәбез. Бу хәл драмаларның башта кайсы юлда вә нинди шартлар астында тәрәккыйгә башлаганлыкларын безгә ачып бирә.

**Драма һәм күрәнек.** Инаныш, игътикад кешене төрле хәрәкәтләргә, мәрасимнәргә баглый. Бу хәрәкәт вә мәрасимнәр дә башта төрле аерым вә тәсадефи[2] хәрәкәтләрдән, тәсадефи мәрасимнәрдән гыйбарәт була. Ләкин соңыннан болар, бу хәлдән чыгып, шөгуриятле[3] һәм дә йолалыклы (традиционный)[4] бер хәлгә, билгеле вә тәртипле бер күрәнек рәвешенә киләләр. Күрәнекләрнең йолалыклануы хорның әһәмиятен арттыра, аның дәхи йолалыклы булуын эсти. Хорны даими үтәүчеләрнең, хор осталарының булынуларын таләп итә. Аның төзек вә туры рәвештә эда кылынуы[5] – иң мөһим шартларның берсе. Аны белү, аның нечкәлекләрен аңлап җиткерү һәм шуларны тәмам үтәү һәр кешегә насыйп булмый. Хорафат вә массаларны да һәркем тигез белеп бетерә алмый.

Ыруг вә оймаклар (кабиләләр) арасында туган вә төзелгән мәрасимнәрне иң башта зурлар-өлкәннәр яшьләргә күчерү хезмәтен үтәгәннәр. Соңыннан болар, һаман катлауланганнан-катлаулана, авырайганнан-авырая бару нәтиҗәсендә, һөнәрмәнд сакчыларга,

[1] Нәүхәләрдә – кычкырып елау (үлгән кеше артыннан).
[2] Тәсадефи – очраклы.
[3] Шөгуриятле – аңлы.
[4] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*
[5] Әда кылынуы – үтәлүе.

шул эшләрнең мөтәхассыйс[1] кешеләренә, ягъни кяһиннарга, руханиларга күчә. Бу соңгылар, гыйбадәтләрне бөтен әркяннәре[2] белән яхшы белү өстенә, дога вә мөнәҗәтләрне, илаһиларны, тәүбә вә истигъфар сүзләрен, гаһед[3] вә ант гыйбарәләрен дә яхшы белүчеләр булалар. Болар төрле дини рухтагы вакыйга вә хәлләрне халыкка хикәя кылалар, риваять итәләр, күчерәләр. Шулар хакында җыр вә бәетләр, касыйдәләр төзиләр: мәсәл вә хорафатларны тәфсир вә тасвир кылалар.

Борынгы йөз үзгәртеш уеннарына махсус булган төрлечә киенү һәм бизәкләнүләр, маскаланулар инде яңа бер әһәмият казаналар. Инде болар дини риваятьләрдә мәсәлләрнең каһарманнарына, аллаларга татбикъ ителә[4] башлыйлар. Болар да төрле хәрәкәтләр, көй вә мәкамнәр, такмаклы җырлар, кара-каршы сөйләшүләр, кушылма җырлар белән нәүбәтләшәләр.

**Драманың тәрәккыйсе.** Дөньяга вә хәятка яңадан-яңа карашлар тудырыла бару нәтиҗәсендә һәм төрле тәнкыйди төшенчәләрнең кысуы белән күрәнекләр үзләренең куәтләрен киметәләр, зәгыйфьләтәләр. Менә бу хәл, ниһаять, драманың алдагы яңа тәрәккыйсенә юл ача, аны башка бертөрле тәрәккый юлына төшерә, инде драмаларда дини матдәләр, хорафат өлешләре кими барып, кешеleккә вә аның эш вә хәрәкәтләренә юл куюга мәҗбүр булалар. Инде аллалар, мәгъбудләр[5] алмашына, кеше аталган каһарманнар урын ала һәм гади кешеләргә юл куела.

Хасил драма, ниһаять, күрәнекләрдән тәмам аерылып чыга да алар белән элгәреге мөнәсәбәтләрне өзә. Күрәнек белән драманың болай бер-берсеннән аерылышып, мөнәсәбәтләре киселү – драманың гүзәл сәнгать матдәсе булып туган беренче сәгате. Ул, шуннан башлап, үзенә гүзәллекне вә гүзәл сәнгать булу сыйфатын казана башлый. Хорафатларның кешелекләндерелгән һәм кешелекле мөндәриҗәләре һаманнан катлаулы, рухи һәвәсләрне эләктерә бара. Бөек әмәлләрне вә гали әхлакый мәсьәләләрне алга куя. Эчке тартышларны, рухи көрәшләрне, язмыш вә тәкъдир, җәза, савап вә мөкяфәт[6] мәсьәләләрен үз эченә ала.

[1] Мөтәхассыйс – белгеч.
[2] Әркяннәре – нигезе.
[3] Гаһед – ант итү.
[4] Татбикъ ителә – чагыштырыла.
[5] Мәгъбүдләр – потлар.
[6] Мөкяфәт – игелек.

Менә бу агымда башлап юнан драмалары хәрәкәт күрсәтәләр. Бу хәрәкәтләрдә аларда миладтан элгәреге бөек юнан эдилларыннан Эсхил, Сафокл, Еврипид, Аристофаннар аркылы күрелә. Шулар аркасында драма юлында бөтен җиһан өчен мәңгелек иҗади үрнәкләр мәйданга китерелә. Иң чигендә шуның нәтиҗәсендә күрәнекләрнең рәвешләре тәдриҗән бозыла, җимерелә. Болар тагын да баерак фәлсәфи вә әхлакый мөндәриҗәләргә юл бирәләр. Тагын да камилрәк, тагын да тулырак булган сәхнә техникасы даирәсендә болар шуңар мәҗбүр булалар.

**Халык әдәбияты вә мәдәният.** Без никадәр иң элгәреге, иң борынгы заманнарга таба барсак, шулкадәр дә халык әдәбиятының бөтен тармакларын бергә укмашкан бер бөтен хәлендә күрәбез.

Яңа заманнарга күз салып, мәдәният баскычлары белән бирегә таба үрмәләгән саен, дәхи элгәредәге бөтен төрләрен эченә алып, барлык тармакларының бергә укмашкан бер рәвештәге халык әдәбиятының мәдәният тәэсире белән төрләргә, ботак вә тармакларга аерыла, төзелә һәм сүтелә баруын күрәбез. Тәдриҗән, халык әдәбиятының мөндәриҗәсе һәм алган рәвешләре киткән саен чишелә, аерым-аерым мөстәкыйль бүлекләргә аерыла бара.

Борынгы катнашлыклы done бербөтен тәшкил иткән халык әдәбияты мәдәният тәэсире белән һаман үзгәргәннән-үзгәрә, тармакланганнан-тармаклана һәм дә бозылганнан-бозыла барды. Шулай итеп, борынгы халык әдәбияты үзлекле, гүзәл вә әдәби иҗатлар белән һаман алмашына торды. Ләкин бу үзлекле иҗатлар, шөбһәсез, шул ук халык әдәбиятының үзеннән вә сүленнән тудылар.

Халык, ягъни авыз әдәбиятыннан шагыйрь вә әдипләр һаман үзләренә рух вә яңалык алдылар, янып торган халыкчылык үзчәнлеге белән рухлана тордылар һәм рухланалар. Галимнәр дә, тарихчылар да болардан бер халыкның тарихка кадәр булган үткәннәре, иң борынгы заманнардагы хәлләре (ягъни язу сәнгате әле булмаган бер вакытта) белән танышу юлында күп файдаланганнар һәм файдаланалар. Халык әдәбиятын тикшерү кешелек иҗатына иң элгәреге баскычларын шуларны тикшерүче галимнәргә ачып салды, әмәл вә арзуларның камилләшүләрен, гүзәл хисләрнең тәрәккый дәрәҗәләрен ачып бирде, халык рухының, халык йөрәгенең дә иң тирән нокталарын яңадан терелтте.

**Халык әдәбиятын, халык шигырьләрен тикшерү.** Кешеләрдә халыкчылык һәвәсе күтәрелү, халыкка мәхәббәт, халыкның, гаммәнең хәленә, рухы салынышына әһәмият бирүнең көчәюе кебек хәлләр даимән халык шигырьләрен тикшерү эшләренең көч алуы белән бергә була килде. Бу соңгысы никадәр көчәйсә, тегесе дә шул тикле көчәйде. Халык әдәбиятын вә халык шигырьләрен тикшерүгә нык әһәмият бирелү көнбатышта (Яурупада) XVIII–XIX гасырларда бик куәтләнеп китте. Хосусан, тарих фәненең XIX гасырдагы тәрәккыйсе төрле тарихи тикшерүләр өчен төрле ысуллар мәйданга чыгарды. Бу әлеге турыда бөек бер ярдәмче булып төште. Хәтта өметсезлеккә, канәгатьсезлеккә өстерәүче катлаулы мәдәният шигырьләреннән туеп, шушы югарыда искәрелгән гасырларда халык шигырьләренең бөтенлегендә һәм шуларның садә шигъриятендә җанга тынычлык эзләнде.

Авыз әдәбиятына, борынгы халык шигырьләренә хәтта язма вә үзлекле шәхси шигырьләрдән, язма әдәбияттан да артык кыйммәт бирелүгә, аларны болардан югары куюга маил күрсәтелде[1]. Ләкин бу рәвештә халык иҗатчылыгын гая итү[2] шундый бер юлга төшерде – аның белән бик саксыз эш итә башладылар. Төрле кешеләрнең төрле зәвыкларына язу өчен, халык шигырьләре эченә аерым шәхесләр тарафыннан әллә нинди кушымталар, шәрехләр, тәфсирләр ялганды, төрле үзгәрешләргә мәхкүм ителде[3]. Аларны тәмам үзе дигәнчә яңадан эшләү, төзәтү, башкарту кебек хәлләр башланды.

Менә бу соңгы хәлләр икенче яктан халык шигырьләрен, халык әдәбиятын тагын да чынлабрак, тагын да тирәнрәк уйлап тикшерергә зәмин[4] хәзерләде. Халык шигырьләрен тикшерүнең көчәюе нисбәтендә, халык шигыренең үзенә әдип вә шагыйрьләрне вә бөтен халыкны тарту куәте дә үсте. Халык шигырьләренең үзләренә махсус булган гүзәллеккә ригая[5] һәм дә мәфтүнлек[6] артты. Менә бу хәл иң чигендә иң кирәкле бер нәтиҗәгә китерде: халык шигырьләре вә хатирәләре белән бик саклык вә хөрмәт үзәрендә мөгамәлә кылу башланды.

[1] Маил күрсәтелде – тартылды.
[2] Гая итү – *бирелдә:* файдалану.
[3] Мәхкүм ителде – *бирелдә:* дучар булды.
[4] Зәмин – җирлек, нигез.
[5] Ригая – игътибар.
[6] Мәфтүнлек – үз-үзенә соклану.

Татарлар эченнән халык әдәбиятына иң башлап әһәмият бирүче һәм шуларны җыйнаучы кеше – Каюм Насыйри булды. Аннан соң Хуҗа Бәдигый бу юлда бераз хезмәт салды. Бу юлда әдипләребездән Фазыл Туйкәнең[1] «Җырлар әхтәрисе»ннән башка тагы халык әдәбиятыбызның бөтен төрләрен җыйнаган зур хезмәте бар иде. Басарга хәзерләнгән иде. Ләкин әле бездә халык шигырьләре яхшылап тикшерелеп, катгый бер юлга куелмаган, төзелмәгәндер. Төзеләсе, эшләнәсе бар.

**Хорафат мәктәбе.** Яурупа халыкларының хорафат вә әсатыйрләрне[2] риваять кылышларында булган бертөрлелек, бер-беренә якынлык – аларда күптән сизелгән бер нәрсә. Тел гыйлеме дә бу халыкларның телләре бер-беренә ыругдаш булуларын карарлаштырды. XIX гасырның элгәреге яртысында бу зәминдә халык шигырьләрен тикшерү, шәрех вә тәфсир итү башланып, «хорафат мәктәбе» (мифологическая школа)[3] дип атадыклары әдәби мәктәп тәэсис ителә[4] вә хөкем сөрә. Халык әдәбияты, халык әкиятләре җыйнала. Бу мәктәп һиндү-җәрмән халыкларының авыз әдәбиятларындагы күптөрле мөндәриҗәләрне берникадәр хорафи әсасларга кайтарып калдыра. Бу әсасларның бер-берсе белән якынлыклары вә бу халыкларның да бер-берсе белән ыругдаш-кардәш булулары хөкемен чыгара. Ләкин бу мәктәп бөтен җир йөзендәге халыкларның риваять вә хорафатларында бер-берсенә якынлык, охшаш булуын хәтердән чыгарып эш күрә.

**Икътибас нәзариясе (заимствование[5]).** Бу нәзарияне коручы немец галимнәреннән Бенфей[6] булып, аныңча вә аңа иярүчеләр фикеренчә, һәр халыкның әкият вә хорафатлары бер-берсеннән икътибас кылынган[7], берсе икенчесеннән алынган. Бу кеше – Һиндстан әкиятләрен җыйнап, шуларны изах итүче[8] бер адәм. Бу кеше һәм аның иярченнәре тарафыннан чагыштырылып каравы нәтиҗәсендә, Яурупа әкиятләре белән азиялеләрнеке арасында әсасларда гына

[1] Фазыл Кәрим улы Туйкин (1887–1938) – язучы, фольклорчы. «Җырлар әхтәрисе» китабы 1912 елда дөнья күрә.

[2] Әсатыйрләр – мифик әкиятләр, мәсәлләр, риваятьләр.

[3] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*

[4] Тәэсис ителә – оеша, төзелә.

[5] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*

[6] Теодор Бенфей (1809–1881) – немец фәлсәфәчесе, санскритолог.

[7] Икътибас кылынган – файдаланылган.

[8] Изах итүче – аңлатучы.

түгел, хәтта вак нокталарына кадәр бер-берсенә охшаганлыклары күрелгән.

Бу әкиятләрдән күпләре һинду-җәрмән халыкларының борынгы бабаларының мәдәниятенә мәнсүб булудан[1], бигрәк тагын да соңрак һәм катлаулырак мәдәнияткә баглы булуының, шөбһәсез, бер нәрсә икәнлеген бәян итәдер. Гареб халыклары белән шәрыклыларның бер-берсе белән даими рәвештәге мөнәсәбәтләре аларның халык шигырьләренә дә тәэсирсез калмаган, диләр. Азиядән Яурупага күп хорафи риваятьләр вә әкиятләр килде вә боларны да Шәрыкның күчмә халыклары алып килделәр, диләр. Шуннан соң бу әкият вә хорафатларның яңа җирдә үзләренә бер зәмин тапканлыкларын бәян кылалар.

Боларча мондый бәйнәлмиләл әдәби вә шигъри катнашлыкка, бердән, әһле салиб сугышлары[2] сәбәп булган булса, икенчедән, бу тугрыда Рум (Византия) императорлыгының да зур роль уйнаган булуында шөбһә юк. Бу императорлыкның күп гасырлар буенча Гареб белән Шәрыкне бер-берсенә баглап торучы булганлыгы да, әлбәттә, бу фикергә куәт бирә, диләр.

Димәк ки, әкиятләр, мәсәлләр, кирәк авыздан, кирәк китаплар аркылы, шул рәвешчә җир йөзенең бер ягыннан икенче ягына күчкән һәм үзләренең иң элгәреге аналарын югалткан, кайда туганлыклары онытылып, бәйнәлмиләлчелек сурәтен алып киткән булалар.

Менә Бенфей нәзариясенә мәнсүб кешеләрнең фикерләрен хөласа кылганда[3], шуннан гыйбарәт булып кала.

**Үз-үзеннән туу нәзариясе (саморождение[4]).** Бу нәзария – икътибас нәзариясенә каршы булган бер нәзария. Моныңча, әкият вә мәсәллар, гомумән, халык яки авыз әдәбиятлары алай бер халыкның икенчесеннән икътибас белән генә тудырылмаганнар. Бу рәвешчә, халыкларның вә төрле ыругларның мөстәкыйль тудырышларын юкка чыгарып булмый. Бәлки төрле халыклардагы бер-берсенә охшаган әкият вә мәсәлләр шул ук халыкларның үз иҗатлары булу бик мөмкин. Һәр халык мәдәни тәрәккый юлында бер үк төрле баскычларны үтеп килергә мәҗбүр булган. Фикер вә аңның тәрәккыйсендә бер халык кайсы баскычта булганда нинди әкият, кыйсса

[1] Мәнсүб булудан – караганлыктан.
[2] Әһле салиб сугышлары – тәре сугышлары.
[3] Хөласа кылганда – нәтиҗә ясаганда.
[4] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*

вә мәсәлләрне үз хыялыннан тудырган булса, башкалары да, шул ук баскычта торганда, шуларны үзеннән-үзе һәм тик үз хыялыннан тудыруы табигыйдер.

Моның өчен дә Төньяк Себер халыклары белән Урта һәм Көньяк (төшлек) Африка зәнҗиләрен, Австралия вәхшиләрен мисал вә дәлил итәләр. Бу ыруглардан бәгъзеләр яурупалылар белән бер вакытта да катышмаган һәм аларның тәэсирләре астында калмаганнар. Шулай булганы хәлдә, боларда халык шигырьләрендә шундый мәүзуглар, мәсьәләләр, шундый рәвешләр-сурәтләр табылган ки, болар Яурупа вә Азиянең иске мәдәни халыкларының халык хыялыннан туган иҗатларына бик охшый һәм тәмам шуларны хәтерләтә.

Менә бу вакыйга нәрсәне күрсәтә? Бу әкиятләрне, хорафатларны тудыручы гамилләр[1], һәртөрле хорафат вә шигъри рәвешләр төрле халыкта икенче бер халык тарафыннан тәэсир күрсәтелмәстән үк үз-үзеннән туган икәнлекләрен күрсәтә. Болар – һәр халыкның иҗтимагый, икътисади тормышы буенча үзенең дини игътикадының[2] нәтиҗәсе. Болар һәр халыкның кеше дигән мәхлук тугрысында үзләрен әйләндереп алган бөтен табигать галәме хакындагы тәсаувырларыннан, халыкның әхлакый аңнарыннан вә үзләренә махсус тормыш рәвешләреннән табигый уларак килеп чыккан нәрсәләр.

Бөтен халыкның тәкърибән[3] бертөрле үк мәдәни тәрәккый баскычларын үткәргән вә үткәрә килгән булуларын искә алганда, шигъри иҗат эшләрендә дә боларның бер-берсенә охшап барулары – бик табигый бер хәл.

Мәдәни тәрәккый баскычларының һәркайсын басып үткәндә дә, шул ук баскычны үтүче һәр халыкның әхвале рухиясе[4] күп әсаси нокталарында бер-беренең гайне[5] булуы да – табигый бер канун.

Бу нәзарияне коручылар – инглиз галимнәреннән Тайлор[6] белән Эндрю Лэнгдер[7].

---

[1] Гамилләр – сәбәпләр.

[2] Игътикадының – ышанычының.

[3] Тәкърибән – якынча.

[4] Әхвале рухиясе – рухи хале, халәте.

[5] Гайне – үзе кебек булуы, үзенә охшаган.

[6] Сүз этнография, антропология фәненә нигез салучыларның берсе Тайлор Эдуард Бернетт (1832–1917) хакында бара булса кирәк.

[7] Эндрю Лэнг (1844–1912) – язучы, тәрҗемәче, тарихчы һәм этнограф.

**Хорафатларыбыз.** Борынгы җыр, дастан вә әкиятләребезне тикшергәндә, шуларны дөрес вә тулы аңлауга һәм рухларына тәмам төшенүгә ярдәм итсен өчен, бу урында борынгы хорафат вә әсатыйрләребез[1] тугрысында беркадәр мәгълүмат бирелеп үтүне тиеш таптык.

Борынгы төркләрнең диннәре, игътикад вә әсатыйрләре турысында дөрес бер аң вә тәсаувыр казану өчен хәзерге көндә Алтай таулары тирәсендә яшәүче төркләрне мисал итеп алалар. Болар әле һаман «шаман» дип аталган дини кагыйдәләр астында яшиләр. Радлов[2] кеби мөстәшрикъләр дә, «шаман» мәзһәбе турысында төркләргә күрше булган (магуллар кеби) кавемнәрдә сакланып килгән әййин[3] вә игътикадларны һәр яктан тикшергәндә дә, бөтен борынгы төркләрнең инанышларыннан гыйбарәт булуын сөйлиләр.

Төркләр җир, агач, мәгъдән, ут һәм суларга хөрмәт күрсәтә һәм шушы биш нәрсәнең биш затта күренүенә инана вә аларны кодсиятле[4] саный торган булганнар. Бу биш заттан үзәктә – «Кин хан» (Сары хан), көн туышта – «Күк хан», көнлектә – «Кызыл хан», көнбатышта – «Ак хан», төньякта «Кара хан» булганнар. Фәкать соңыннан бу мәзһәб ике асылга кайтып калган ки, бу да «күк» белән «җир»дән гыйбарәт булып, «Тәңре» («Тәкре, Тәңре, Такре») рәвешен алганнар. Мюних-нүләрнең каһаннары да хөкемдарларының «күк хөкемдары» дигән кеби вә шул ук мәгънәдәге «Тәңре кот» дип аталыр вә танылыр иде. Халыкның игътикадынча, җир йөзе җеннәр, пәриләр, гыйфритләр белән тулы дип уйланылган. Тәңре, ягъни күккә корбан чалу, мөнәҗәтләр кылу кеби хәлләр Алтай җирләрендәге төрк кабиләләрендә хәзерендә дә бардыр. Алтай потпәрәстләреннән телеутларның догасы болай икән:

*«Әй күк тәңресе Әбйашә, йире яшелдер, агачлары яшәрдер. Рызыклар бирерсең! Тәңре, өйгә бер башлык бир, халыкны яратучы, түрә тәңресе, я Раббе, кабул вә гыйнаять»* (Радлов, Төрк тарихы, җилд. 1–228).

Борынгы төркләрдә мәзһәб башлыклары гаибтән хәбәр бирү көченә малик булганнар. Төркләр каршында галәм берничә катлаулардан оешкан. Югарыдагы унҗиде катлау күк – нур галәмен, түбән-

[1] Әсатыйр – борынгылар турында мифик әкиятләр, мәсәл-легендалар.
[2] Василий Васильевич Радлов (1837–1918) – күренекле шәрыкшинас-тюрколог, этнограф, археолог һәм педагог.
[3] Әййин – гадәт.
[4] Кодсиятле – изге.

дә җиде яки тугыз катлау дәхи тәмугларны, караңгылык дөньясын тәшкил итеп, боларның икесе арасында да кешеләргә махсус булган җир өсте тора. Шул ике галәм моңа нөфүз[1] йөртә. Алтай төркләре күкне, җирне һәм бөтен нәрсәләрне вә кешеләрне яратучыга «Тәңре карахан» дип атыйлар.

Мәрхүм төрек галимнәреннән Әхмәт Мидхәт[2] тарихында бу хакта шул түбәндәге белекләрне сыгып ала алабыз:

Төрк-татар шаманистлары җир шарын гәүдәле (мөтәшәхыс) бер зат санап, аңа да бер рух иснад итеп[3], шуңа коллык иткәннәр. Шулай ук җир йөзенең һәр кисәген вә һәр тапкырын рухи бер мәгъбүд[4] санаганнар да. Һәрберсенең рухына табынганнар. Хәтта бу рухларның да үз ата-бабаларының рухы булуын уйлаганнар. Болар ата-бабаларының рухларына да табынганнар, үзләре яшәгән җирнең рухы ата-бабаларының рухларыннан берсе дип ышанылган. Иң бөек күктә «Тәңәрә кан»[5] (Күк алласы – бөек Алла) торып, бөтен кяинатне[6] ул идарә итә дип игътикад ителгән. (Тәңәрә – тәңре, туры, тары – барысы да төркчә «Аллаһ» мәгънәсендәдерләр.)

Җиденче кат күктә – аналык сыйфаты белән кояш вә алтынчы кат күктә дә аталык сыйфаты белән ай торадыр. Өченче кат күктә җиде бүлек Кодә, ягъни урынлашучы илаһ булып, «кодә» сүзенең – «бөек» мәгънәсендә икәнен һәм «кодәман» дигән тәгъбир «бөек адәм» мәгънәсен аңлатканлыгын төшенсәк, бу җиде аллаһның башлыклар хөкемендә булганлыклары аңлашылыр. Бабаларның рухлары туры бу аллаларның каршына китәрләр, һәм болар терек булган кешеләр белән аллалар арасында урталык (васита) булалар.

[1] Нөфүз – өстен, игътибарлы.

[2] Әхмәд Мидхәт (1844–1912) – төрек журналисты, язучы, тәрҗемәче.

[3] Иснад итеп – биреп.

[4] Мәгъбүд – пот.

[5] «Тәңре» сүзенең асылы һәм төп мәгънәсе хакында Әхмәт Мидхәт мондый тәхкыйкатьне язадыр. «Тәңәрә» сүзе төрк телендә Аллаһ мәгънәсендәге «Тәңре» булып, «кан», дәхи «хан» булуын карасак, «Тәңәрә хан» тәркибе «хәзрәте Аллаһ» мәгънәсен эченә аладыр. «Кәра» исә «күк» (сәма) димәктер. Бу сүзнең әйтелеше төрле урында төрлечәдер, кайсыбер җирләрдә – «тәңре» вә бәгъзе җирләрдә «туры вә тары» дип тә әйтеләдер ки, һәммәсенең мәгънәсе «күк Алласы» (илаһи сәмәи) димәктер, «тәң» сүзе дә «күк» мәгънәсендә дә, «Аллаһ» мәгънәсендә дә кулланыла. «Кәрә» янә шулай. Әмма «тәң кәра» диелгәндә, берсе – «Аллаһ», икенчесе дә «күк» мәгънәсен аңдырыр. Шул хәлдә кыскартып, җиңеләйтеп, «тәңре» диелер ки, тәмамы белән «күкнең раббысы» димәк буладыр («Дарелфөнүн мәҗмугасе»). *(Авт. иск.)*

[6] Кяинатне – галәмне.

Җир янә тугыз катлаудан гыйбарәт булып, боларның һәрберсендә явыз гамәлләрнең гамиле[1] булган берәр кодрәт хөкем сөрер. Боларның да рәисе – Әрлек хан исемендә мөдһиш[2] бер зөбани. Бу Әрлек хан – кешеләр нәүгының[3] иң бөек дошманы, бу магулларны шулкадәр куркыткан, хәтта аның ачуын бастыру өчен корбаннар чалырга мәҗбүр булганнар. Корбаннар да хайваннарның иң әгъласы[4] булган ат җенесеннән сайланган.

Корбан чалу рәсми беткәннән соң, корбанның рухы күккә ничек чыгуын һәм аллалардан теләнгән нәрсәләрне аларның ничек кабул һәм вәгъдә кылуларын шаман булган кеше, гүя үз күзе белән күреп торган кеби иттереп, халыкка хикәя кыла. Бу хикәяне дә театр вә сәхнә тамашасында драма уйнаган уенчының итенеш-кыланышлары, хәрәкәтләре рәвешендә бер такым үзенә махсус вазгыятьләр белән күчерә. Моны шулкадәр ялкынлы бер халәт үзәрендә сөйли, хәтта берзаман үзе дә, кабзыятьләнеп китеп[5], тәмам үзен-үзе оныта, үзен үзе һич белмәс бер хәлгә киләдер.

Бәгъзе бер начар-явыз адәмнәр үлгәннән соң, аларның өйләре пычранган саналып, моның өчен шаман иң элек үлекнең рухын җир катлавына иңдерә һәм анда аны мәңгелек урынына җирләштергәннән соң, догалар укып, аның пычраклыгын (хәсислеген) китәрә.

Шаман бу турыда нәрсә эшләнгән булса, аларның һәммәсен җәмәгатькә бөтен ганганәсе белән аңлатадыр. Кирәк күккә чыкканда, кирәк җир астына иңгәндә күргәннәрен, гаҗәеп вә гараиб[6] белән тулган бер өлкәне сәяхәт иткән бер җиһан гизүче рәвешендә бәян кыла, һәм ул бу вакытта бөтенләй үз-үзеннән югалыр бер хәлгә килә.

Аларның бу хәлләрен күргәч, шаманнарның диннәрен һәм иҗтимагый хәлләрен тикшереп, төпле мәгълүмат җыйнаучы Радлов үзен гүя ундүртенче миладның мәшһүр әдипләреннән Дантеның «Илаһи комедия»сен укыган шикелле зан иткән[7]. Бу әсәрдә шагыйрьнең христианлык җәннәтен, әгърафын[8], тәмугын тәгъриф

[1] Гамиле – сәбәбе.
[2] Мөдһиш – куркыныч.
[3] Нәүгының – төркеменең.
[4] Әгъласы – яхшысы.
[5] Кабзыятьләнеп китеп – каушап, куркып.
[6] Гараиб – ишетелмәгән, күрелмәгән вакыйгалар.
[7] Зан иткән – тойган.
[8] Әгъраф – җәннәт белән җәһәннәм арасындагы урын.

кылганы[1] рәвешендә, шаман да гүяки ул комедияне укып бара дип уйлатырлык бер сурәттә камил осталык белән шагыйранә вә сәнәгатькәранә бер тарызда җир һәм күкнең катлауларын – оҗмах вә тәмугларын тасвир кылып бирә икән.

Әхмәд Мидхәтнең: «Фин һәм төрк-татар ыругының иң күбесендә дикъкатьне үзенә тартырлык бер шагыйрьлек хисе бар. Аларның сугыш вә орышлары сугышчанлык хаслэтләре[2] хакындагы борынгы касыйдәләре тикшерелә торган нәрсәләрдер», – дигәне кебек, татарларның әнә шул югарыдагы хорафатларның нәтиҗәсе булган әфсанә[3], җыр вә әкиятләре, тикшерелеп, әлбәттә, мәйданга чыгарылырга тиешледер. Боларны эченә алган җыр вә әкиятләребез юк хөкемендәдер. Тарихыбызның шомлы катлаулары шушы шигъри әсәрләребезне үзенең астына алып тәләф иткән[4], югалткандыр.

## Бездә җырлар

*«Халык җырлары – халкымыз [күңеленең] һич тә тутыкмас вә күгәрмәс саф вә рушан бер көзгеседер, бу бертөрле сихерле көзгеседер»*
(Тукай).

Җырлар, гомумән, бөтен халыкның авыз әдәбиятында мөһим урын тоталар. Һәр милләт гаммәсенең эчке йөзен күрсәтүдә җырлар якты көзге булалар. Анда гаммәнең бөтен эчке дөньясы чагыла, төшерелгән була. Аның төрле баскычлы барлык хыяллары, төрле катлаулы, төрле буынлы тойгылары, төрле бормалы тәэссерләре[5] төшерелгән яки төрелеп салынган була. Бер халыкның рухи халәтен иң эчке катына кереп карый алу өчен иң яхшы, иң дөрес чара – халык җырларыннан башка нәрсә түгел. Һәр милләт гаммәсенең йөрәгендәге шигъри истигъдадның дөрес тылмачы (тәрҗеманы) – җыр, ул аның, чыннан да, шигърият мизаны.

Һәр халык гаммәсе өчен иң кадерле әдәбият та – җырлардыр. Ул үзенең табигыйлеге, садәлеге, аһәңле вә җиңел аңланышлы булуы белән халыкка якын тора. Анда халыкның уртак әдәби зәвыгы аңкып тора. Әнә шул табигый булган уртак зәвык, халыкка уртак

[1] Тәгъриф кылганы – танытканы.
[2] Хасләтләре – үзлекләре.
[3] Әфсанә – әкият, фантастик хикәя, мифик мәсәл.
[4] Тәләф иткән – бозган, бетергән.
[5] Тәэссерләре – *биредә:* күзаллаулары.

җан азыгы булып, бер милләт гаммәсенең бөтенесен уртак вә тигез ризыкландыра, һәрбер фәрденә[1] тигез тәм тарата.

Дөнья һәм тереклек белән бер халык гаммәсенең мөнәсәбәтен ачык күрәсе килгән кеше аның җырларына карасын! Дөньяга караш, инаныш, тереклек көрәшендәге төрле булгыннар (вакыйгалар), ишетелгән-күргәннәр, халыкның бөтен кылыгы[2]-әхлакы, язмышка карашы, фикер, тойгы вә хыялларының эшчәнлеге һәм боларның үзара ничек багланышлары төшенчәләренең куәт вә табигыйлеге, башка халыклар белән мөнәсәбәте, бергәлек мәсьәләләрен (иҗтимагый мәсьәләләрне) ничек вә кайсы юлдан чишәргә, өзәргә теләве – һәммәсе халык җырларында чагылган, яшьнәгән була.

**Җырларның тышкы яклары.** Җырларның тышкы ягы, тышкы төзелеше болай: гомумән, җырлар дүрт мисрагълы булалар. Кафияләр икенче мисрагы белән дүртенче мисрагъларда нык күзәтелә. Күп җырлар шулай. Тик кайсыберләрендә генә дүрт мисрагъның дүртесендә дә кафия булса да, болар – сирәк һәм иттифакый бер нәрсә. Җырларның күбесендә элекке мисрагълар бер я ике җөмләдән генә тора. Кайчакта үзләренә бөтен бер җөмлә ясый алмыйлар. Болай булганда, элекке мисрагълар соңгы мисрагълардагы җөмләләрнең кисәкләре булып тагылалар.

Туранилар вә хосусан төрк-татарларның җырларында төп әйтелергә теләнгән уй, тойгы соңгы ике мисрагъта була, элекке ике мисрагъ та исә шул төп уйга багланышлы мәгънәләрне аңдыра, төп уйны, әйтелергә теләнгән тойгы вә хыялларны ачу, аларга ничек тә булса берәр төрле юл белән тасвирыйлык вә аһәң бирү хезмәтен үтиләр. «Күп татар җырларында элекке мисрагълар – мәгънәсез сүзләр, аларның күп вакытта әһәмиятләре дә булмый, аларның соңгы төп мисрагълар белән мөнәсәбәтләре мәгънә ягыннан булмыйча, тик скрипка уйный башлаганда бер кабат кылларны тартыпکую шикелле генә бер нәрсә ул», – дигән кеби төшенчәләр – ялгыш фикерләр алар. Болар – төрк-татарларның җырларын тарихы белән яхшылап тикшерә алмаудан туган ялгышлыклар.

Тукай мәрхүм дә шушы ялгыш фикерне сөйләп китте. Тарихчы Зәки Вәлиди, дөрес юлны тотып, Тукай төшенчәсен нык кына иттереп кире бәрде.

[1] Фәрденә – затка.
[2] Кылыгы – холкы.

Шунысын онытмаска кирәк: халыкта җыр – башта чыгарылганда тик кенә чыгарылган бер нәрсә түгел ул. Аның чыгарылуына ничек тә булса берәр төрле мөһим сәбәп булган, я берәр кайгылы яки шатлыклы хәл, вакыйга, сизгер һәм җанлы йөрәкләрне хәрәкәткә китергәндә, җырлар шуларның җимеше булып туган. Кайгылы яки шатлыклы вакыйга вә хәлләргә очраган чакларда яисә берәр моңлының боеккан, моңланган чакларында моңланучы белән җырчы нинди урында, нинди бер күренеш эчендә, нинди бер эш вә кылыныш өстендә булган булса, ул җырлап җибәргән чагында, әлбәттә, фикер вә тойгыларын шундый хәлләргә ничек тә үзенчә бер яктан багланышлы иткән яхуд, үзе теләп багланышлы итмәсә дә, әхвәленең, вакыйгаларның, тирә-юнендәге күренешләрнең тәэсире белән ул шулай булып чыккан. Әгәр дә һәр борынгы җырны чыгаручының үзеннән сорап алу мөмкин булса иде, җырны чыгаручы, мотлакан, аның элекке ике мисрагының бик мәгънәле бер ялгау икәнен, соңгы ике мисрагъка асыл тасвирыйлык вә аһәң бирүче дә шул элекке мисрагълар булганын бик ачык иттереп ярып салган булыр иде.

Тукайның элекке ике мисрагы белән соңгы ике мисрагы арасында мөнәсәбәт булмауга һәм гаммәнең ул сүзләрне җырга да санамавына, бәлки аның ялгыз тыңлаучыга үзеннән бер нәрсә көттергәнлегенә мисал итеп китергән:

*Сандугачлар су ташый,*  
*Кайда икән су башы?*  
*Безнең җанкай ялгыз башы,*  
*Хозыр булсын юлдашы!* –

дигән җырның үзен алыйк. Менә мондагы элекке мисрагъ тик скрипка кылын тартып җибәрү кабиленнән генә китерелгән бер нәрсә түгел. Болар бик тирән бер мәгънә белән китерелгән: соңгы ике төп мәкъсудны[1] әйтүче мисрагълардагы мәгънәгә тасвирыйлык, шигърият бирү өчен китерелгәннәр. Димәк, мәгънә ягыннан аларның соңгы мисрагълар белән багланышы юк кына түгел, бәлки гаять көчле. Менә шул рәвешчә көчле:

Бердән, бу җырны башлап җырлаучы – һәрхәлдә, матур табигать эчендә сандугач сайравы, аның бер талдан икенче талга очып-кунып йөрүе тәэсире астында калган бер кеше. Табигатьнең күренеш вә моңнарыннан илһам белән җырланган бу җырны әллә нинди ма-

[1] Мәкъсудны – теләкне.

шиналар, колачалар шатырдаган, дөбердәгән бер завод яки бер фабрик эчендә булынган хәлдә җырланган бер җыр дип берәү дә әйтмәс һәм бу җыр шатыр-шотыр, дөбер-дабыр килеп шаулап торган шәһәр халыкларының йөрәгеннән чыккан бер җыр түгеллегенә дә берәүнең дә шөбһәсе калмас. Бу җыр – табигать эчендә, табигатьнең матур күренешләре кочагында тирбәлүче яки киң сахраларда, бүз кырлар (степь) уртасында илһамланучы бер гами җырчы авызыннан чәчрәгән тибрәткеч бер тойгы чаткысыдыр. Җырның элекке мисрагында «су башы» сүзенә аеруча дикъкать итеп үтик. Төрк-татарлар, хосусан татарлар һәм башкортларда, егетнең җанашы яшь килен булып, йортка төшкәч, «су юлы башлату» дигән тарихи баш ягы әллә кайларда, ерак заманнарда калган мөһим бер гадәт бар. Җырның әнә шуның белән мөнәсәбәте бар. Су юлы башлату ул яшь киленгә тереклек ишеге ачу, аны тереклек юлына кертеп җибәрү дигән сүз була. Яшь киленгә су юлы башлатмастан элек, аңа һичбер эш кушылмый һәм ул үзе дә анынча һичнәрсә эшләми. Әмма су юлы башлаткач инде, ул җанкаеның, иренең йортындагы эшләргә әкренләп тотынып китә. Су юлы башлатканда, киленнең тирә-ягын, алдын вә артын кызлар, җиңгәйләр чолгап алган була. (Башкортларда бәгъзе бер урыннарда суга «көмеш акча» дип аталган кечкенә һәм юка гына көмеш тәңкә төшерү дә була. Бу инде – яшь киленнең чире су белән агып китсен өчен үзенчә бер ырым. Типтәрләрдә исә тәңкәне суга кырып салалар.)

Әнә шулай булгач, җырда «Кайда икән су башы?» дип сорау бирү, бу җырны егет һәм кызның кайсысы гына җырласа да, бик мәгънәле, бик урынлы булып чыга. Егет белән кызның һәр икесенә дә бу – бик мөнәсәбәтле бер нәрсә. «Сандугачкай су ташый» мисрагы исә җырчының сандугач белән җанкае арасында охшаш табуының яки, үзе дә сизмәстән, йөрәгенең тәэсире белән җанкаен сандугачка охшатуның нәтиҗәсе икәнен кем инкяр итәр? Менә монда нечкә бер шигърият юкмы? Сандугачның су ташып-ташымавыннан катгый нәзар илә, аны хыялда су ташучы иттереп җанландырып та, үзенең (җырлаучы – кыз булса) яки җанкаеның (җырлаучы – егет булса) сыгылмалы көянтәләрен иңбашына салган хәлендә тәңкә вә чулпыларын шылтыратып су ташуларын күз алдына китерү – авыл егетләре өчен моңанчы татлы бер шигърият, тәмле бер тасвир вә тәсаувыр түгелме иде? Әнә шушы тасвир вә тәсаувырлар шушы хыялый күренешләрдән соң: *Безнең җанкай ялгыз башы, Хозыр*

*булсын юлдашы*, – дип кую бик табигый бер нәрсә булу өстенә, теге югарыгы ике мисрагъ белән мәгънә ягыннан да гаять тыгыз бабланган бер төп уй булып кала.

Менә татар җырларының шул рәвешчә тышкы караштa элекке мисрагълары соңгылар белән мәгънәдә мөнәсәбәтсез булып күренгәннәре вә шуңа ачык мисал итеп китерелгәннәре дә, җырның эченә вә шуны җырлаучының да йөрәгенә керебрәк, җырны тудырган сәбәпләр белән дә исәпләшебрәк тикшереп карганда, бик мәгънәле һәм бик мөнәсәбәтле булып чыгалар. Әнә инде соңрак яңарак җырларда бер дә мөнәсәбәтсезләре дә булсын. Ләкин боларга аз очрарга мөмкин. Аңа дөрес бер җыр иттереп, татарларның тарихи әдәби зәвыгы тудырган бер нәрсә иттереп карый алмыйбыз. Моңа һәрхәлдә заманның үтүе белән җырлар хакында туган бер сансызлык һәм элекке әдәби зәвыкның тупаслануы, керләнүе, караңгылануы, гадиләшүе дип кенә карарга кирәк. Шуның өчен, төрк-татар җырлары турысында тарихи дөрес бер хөкем чыгару өчен, мисалга фәхешханәләрдә яки башка бер шарлатанлык урыннарында кызма баш белән чыгарылган яңа вә бозык табигатьле җырларны түгел, аек баш, саф вә пакь йөрәк белән, чыннан да, шигъри бер селкенүнең, төшенчәле бер сызланманың нәтиҗәсе булган борынгырак җырларны алырга кирәк.

*Минем сөеп җиккән атым –*
*Кара белән тимер күк,*
*Сагынганда айга карыйм,*
*Ай да ялгыз минем күк, –*

дигән җырда Тукай элекке ике юлның соңгы мисрагына бик ябышып җитмәвен әйтсә дә, алай түгел, бәлки, киресенчә. Бердән – бу җырны һичвакыт кызлар җырламыйлар. Бу – фәкать иркәкләр, егетләр җырлый торган бер җыр. Шуның өчен җырчының сөеп җиккән аты кара белән тимер күк булуы һәм җырның башында ат китерелү – бик табигый вә тасвирый халәт. Сөеп җиккән аты аның ишле булып, берсе – кара, берсе дә тимер күк төсле. Бу ике төсне җырчы икесен дә сөя. Бигрәк тә егетнең җиккән аты ишле булуына аеруча дикъкать итегез. Әнә шушы пар аты кебек егет тә җанкае белән пар-ишле булачаклар. Ләкин ул янында юк. Атлар пар-ишле булса да, егет ялгыз. Әнә шушы ишле атларына утырып йөргән чагында, җанкаен сагынганда, ачык-ярык кичәдә җемелдәп торучы матур-тартымлы (җазибәле) күккә караса, анда айның да ялгызлыгын күреп, үзенә бераз юаныч таба. Ялгызларның үзен генә түгел, бәлки бу турыда

аның иптәшләре, тыңдәшләре дә барлыгын белеп, йөрәк янганын бераз басып куя.

Сүзнең кыскасы, җырларның төп хосусияте шунда: татарларның вә бөтен төрк халыкларының җырлары дүрт мисрагълы булып, элекке ике мисрагъларында табигать, агач, тау, таш, кош-корт, йорт-җир һәм башка терлекләр (хайваннар), кардәш-ыруг, гаилә тасвирга алына да, соңгы ике мисрагъ та шуңа багланып, асыл әйтелергә теләгән уй вә тойгы тасвир кылынадыр.

Туран халкының үзенә табына торган иң якын күргән мөкаддәс нәрсәсе вә тәңресе – табигать һәм аның эчендәге табигый көчләр иде. Матдә, табигать – аларның сыена торган нәрсәсе иде. Туранлылар һәрнәрсәдән артык матдә вә табигатьне сөйлиләр. Аларның шигырь вә илһамнары да шул ук табигать хәзинәсеннән куела иде. Шуның өчен дә аларның әдәбиятында, җырларында, шигырьләрендә иң элек табигатькә урын бирелә, табигатьне тасвирдан башланып кителә, табигатькә багланмаган җыр татарларда, булса да, сирәк булыр.

Ихтимал ки, башка милләтләргә татарларның җырларында элекке мисрагъларының җир, күк, агач, таш, тимер, кояш вә терлекләрне дә тасвир итү ят тоела торгандыр. Ләкин татарларның мәдәният, тереклек, шигырь вә әдәбият тарихлары, табигать вә әхлаклары белән таныш булганнар моннан гаҗәпсенмәсләр, бәлки шуны табигый санарлар.

Мондый хосусият рус җырларында да юк түгел.

Татар җырларының болай элекке ике мисрагълары соңгы мисрагълар белән мөнәсәбәтле тасвирларны эченә алган ят җөмләләрдән гыйбарәт булуы – татарларга төбәлгән кыйммәтле бер әдәби сәнгать. Дөрес, әйтергә теләнгән төп уй вә тойгы, хасил төп мәгънә соңгы ике мисрагъта була. Мәгәр шунысы: төп уйны эченә алган соңгы мисрагъларның үзләре генә җырлангандагы тәэсир белән элекке мисрагъларны кушып җырлаганда хасил ителгән тәэсир, алынган тәэссер бер булмый. Төгәл җырланганда, төп мәгънәнең ачылуы да бөтенләй башкача була. Элекке мисрагълардан башка, ни өчендер, татарның әдәби зәвыгы канәгатьләнә алмый, җырның әдәби кыйммәтен ким иттереп таба һәм аннан тегеләй җырлануга караганда аз әсәрләнә.

Тарихчы Зәки Вәлиди Тукайның «Безнең җырлар житлексез» дигән сүзен кире бәргәннән соң: «Безнең җырларыбыз житлеккәннең

соңыннан зәвалга[1] йөз тоткан. Аңа Азиянең бөтен нисфе шималесе[2] шәһадәт бирә», дидер.

Чыннан да, борынгы татар җырларында элекке тасвирый мисрагълар белән соңгы төп уйны эченә алган мисрагълар арасындагы мөнәсәбәт нык сакланып, шул сәбәпле алар җитлегеп, пешеп, чын шигырь булып чыгалар иде. Әмма соңгы яңа заман җырларында җырларның бу ике бүлеге арасындагы мөнәсәбәт күп вакыт нык игътибарга алынмас булып китте. Тукай әйткәндәй, элекке мисрагъларга тик музыка кылын чиертеп, тартып кую кеби бер нәрсә дәрәҗәсенә төште. Ләкин бу – татар гаммәсенең әдәби зәвыгының тәрәккыйсе түгел, түбән китүе, аның җырларындагы элекке әдәби кыйммәт вә зиннәтнең югалырга йөз тотуыдыр. Моңа да, әлбәттә, күп тарихи сәбәпләр булгандыр. Моның өчен мәдәният һәм мәдәни тереклекнең айлап кына түгел, көнләп, сәгатьләп үзгәрә баруының, элекке киң далада күк түбәсе астында тик саф һава гына сулап яшәүдән аерылып, бозык һавалы калаларда, авылларда каты низам астында багланып тереклек итүгә күчүнең дә бу турыда беркадәр тәэсире булмый калмагандыр. Ләкин без мәдәният вә мәдәни тереклекнең үзгәрә баруы борынгы җырлардагы элекке хосусиятнең югала баруыны мотлак лязем итә торган, татарның элекке әдәби зәвыгына, әдәби сәнәгатенә зарбә[3] ясый торган бер нәрсә итеп карый алмыйбыз. Моны без чын бер татар әдәбият тарихының юклыктан, заман татар яшьләре гаммәсенең үзенең әдәбият тарихыннан хәбәрдар була алмыйча килүеннән күрергә мөмкин.

Татарларның мөхәммәдилекне кабул итү илә дин һәм гарәплек тәэсире астында богауланып калулары да аларның җырларына тәэсир итмәде түгел. Татарның элекке табигый, кискен хыялының киң, җиңел, җитез канатының көченә дин исеменнән руханилар, имам вә мөэзиннәр, остазбикәләр каты зарбә ясадылар. Гөнаһ, тәмуг, гөрзи, сакчы фәрештә, Мөнкәр-Нәкир, тагы әллә кемнәр, әллә нинди нәрсәләр белән гаммәсенең котын алып, аны борынгы чын шагыйрьлегеннән, чын вә табигый әдәби зәвыгыннан, әдәби кабилиятеннән тәмам аера яздылар. Дөньяда бөеренә таянып, күкрәген киереп, тәмам эрелек белән бөтен табигатен, һавасын, суларын, тауларын, урманнарын яңгыратып, тәмам үз хыялының ирегенчә җыр-

[1] Зәвалга – бетүгә.
[2] Нисфе шималесе – ярты төньягы.
[3] Зарбә – зыян, зарар.

лап җибәрә торган татар гаммәсенең истигъдадын дөньяда чагында ук кабер эченә илтеп тыктылар. Ул, шулай итеп, иясе җир өстендә, киң табигать мәйданында йөрегән хәлдә, җир астында, кабер эчендә иясен көтеп ыңгырашып ятты. Моңанчы шуңа мәҗбүр булып килде. Шуның өчен ул үзенең җырларында элекке мисрагълар белән соңгы мисрагъларның тыгыз мөнәсәбәтен, асыл шигърият, асыл тасвирыйлык элекке мисрагъларда булганын үтенде. Аны тикшереп торырга да вакыт һәм имкян[1] таба алмады.

Менә мәсьәләнең иң авыр ноктасы шундадыр. Аннан соң җырларның элекке мисрагълары белән соңгы мисрагълары арасында мөнәсәбәт югалуның бер мөһим сәбәбе менә шушы: борынгы җырларны соңгы җырлаучылар күп вакытта үз кәефләренә каратып үзгәртәләр. Ягъни әйтергә теләгән бер уе, тойгысы була, ләкин шуны бәян итәчәк мисрагъларның башына кушарга, мөнәсәбәтле тасвирый мисрагъларны оештырып чыгаруга тиз генә булдыра алмый яки аңа булдыклыгы җитми. Менә шуннан тота да, мөнәсәбәтен-фәләнен карап тормастан, үзенең әйтәчәкләренә вәзенләп, борынгы җырларның мисрагъларын куша да җибәрә, менә шуннан сезгә баш мисрагълары белән соң мисрагълары мөнәсәбәтсез булган җырлар килеп туа. Мисал:

*Җитен күлмәкне җил ала,*
*Илтеп дәрьяга сала.*
*Безнең болай утырулар*
*Сагынып сөйләргә кала.*

Менә бу җырны:

*Акылың булса, уйлап кара,*
*Бу дөньяда кем кала? –*

дип тә җырлыйлар.

Менә бу хәл бер җырда гына түгел, хикәя, әкият вә мәсәлләрдә дә шулайдыр.

Татар халкында җырлар исәпсез күп, безнең халык – табигате белән җырчы. Ул һәр заман җыр чыгарырга бик яраткан һәм шуңа мәел итүчән булган. Халык арасында туган аз гына бер әһәмиятле вакыйга да халык җырында тасвир ителеп, үткән яки һәрбер аз гына әһәмиятле бер вакыйга өчен дә халык җыр чыгарып, аны

[1] Имкян – мөмкинлек.

әдәбиятына керткән була. Тагын икенче төрле әйткәндә, аның турысында ничек тә бер бәет чыгарылган була:

*Тау башында тимер бүкән,*
*Типкәләмә, Гайнетдин!*
*Без чыгарган бәет түгел,*
*Үпкәләмә, Гайнетдин!*

Шундый җырлардан бер кисәктер «Гайшә кыз бәете», «Ашказар» җырлары, мәдрәсәдә укыган «Җиде кыз» бәетләре вә башкалар янә шул җөмләдәндер.

Бездә кара-каршы әйтешеп җырлау булса да, бу – казакълардагы шикелле уңышлы булып чыга алмый. Бу турыда казакълар, чыннан да, бер искитмәлек күрсәтәләр. Монда инде татарларның казакълардан күп артталыгы ачык күреләә.

Халыкның табигый җырларына ияреп-тәкълид итеп, «ясалма» (сонгый) җырлар да тудырыла:

*Каләш-шәйхе фишшифа дип*
*Укыганың мантыйкмы?*
*Ма вәҗәдтү, валлаһи*
*Синнән бүтән артыкны,*

кеби мәдрәсә шәкертләренең җырлары – шундый җырлардандыр.

Рус шагыйрьләреннән Пушкин белән Гальцевның шундый ясалма шигырьләре булса да, бөтенләй тәкълид түгел. Шулай ук безнең шагыйрьләрдән Тукайның «Милли моңнар»ын, Укмасыйның[1] «Килен»ен халык җырларына иртелеп язылган җырлар диелсә дә, (моны Тукай мәрхүм әйтте) бу дөрес түгел, чөнки монда элекке мисрагълар, халык җырындагы кеби, соңгы мисрагъларны тирән бер киная яки истигарә[2] юллы тасвир итмиләр, болар ялгыз халык җырларының көенә генә тәкълид белән язылганнар. Ялгыз шул кадәр.

* * *

Халык җырларыннан тагын сезгә ике бик мөһим җыр күчереп үтим:

*Ак келәтнең тәрәзәсе – сиксән сигез өлгеле.*
*Начар кызларга бәйләнсәң – хур буласың билгеле.*

[1] Миргазиз Каюм улы Укмасый (Зәбиров; 1884–1948) – драматург, шагыйрь, дин әһеле.

[2] Истигарә – метафора.

*Йөрмә монда, кайт илеңә,*
*Илеңдә иген игәрсең.*
*Стаканыңны ат итеп,*
*Бутылкаңны җигәрсең.*

Менә бу соңгы аракы вә сыра йортлары ачылгач җырланган соңгы заман җыры шәһәрләргә авылдан килеп, эчеп, исереп утыручы авыл яшьләренә, игенчеләргә ни рәвешчә ачы һәм бик мәгънәле кадала, алардан никадәр ачы көлә: «Инде бар, кайт. Акчаңны, бөтен нәрсәңне эчеп бетердең. Ат, арбаң да эчке юлында сатылып беткәндер инде. Зыян юк, кайгырма, стаканыңны ат итәсең дә, бутылкаңа җигеп, сабан сөрерсең!...», – ди. Ни тикле әдәби үткен вә агулы бер инә бу! Тукай да, бу җырны күчергәннән соң: «Менә монысы халыкның үткен гакыллылыгын, русча әйткәндә, остроумный[1]лыгын күрсәтә», – дип куя. Дөрес сүз.

* * *

Халык җырларына ияртелеп ясалган «ясалма җырлар»дан татарчада шуны күрсәтергә мөмкин.

*Йомры тояк тайларда,*
*Матур кызлар байларда,*
*«Әхбар» тәэмин иткән байлар*
*Йөри икән кайларда!*
*Безнең урам аркылы,*
*Ага суның салкыны,*
*Тарта Казанның яшьләрен*
*Рәмиевләр алтыны.*

* * *

Яшь татар шагыйрьләреннән Сәмәвидән[2] моның өчен ачык мисал:

*Кулларымда асыл кызыл байрак,*
*Утырганым – җилкән көймәсе,*
*Күз алдымда өлкән кызыл маяк.*
*Йолдызланган аның тирәсе.*
*Энҗе мәрҗән, гәүһәр якут катнаш*
*Таң нурыннан көмеш сибелә.*
*Аллы-гөлле байрак кызыл атлас*
*Йомшак таң җиленнән сөелә.*

[1] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*
[2] Сәмәви – шагыйрь, мөхәррир Төхфәт Гыйззәтулла улы Гыйззәтуллинның (1893–1959) әдәби псевдонимы.

Менә болар чыннан халык җырларына ияртелгәннәр. Чөнки боларда баш мисрагълар соңгы мисрагъларны ачу өчен кинаяле тасвирларны эченә алган.

* * *

Бер халык теленең сафлыгын, табигыйлеген, аһәңен, дөреслеген саклауда халык әдәбияты эченнән дә җырлар булганын аеруча әйтеп үтәргә кирәк. Тукай: «Кечкенәдән үк күңелемә урнашкан җырларны сөймәкемнән миндә туган телебезне сөю туды. Әгәр миңа җырлар ярдәм итмәсә дә, мин туган телебезне сөймәк кеби олы бер нигъмәткә малик була алыр идеммени?» – ди. Без әйтәбез: Тукай яшеннән үк[1] җырчы булуы, халык җырлары җырлап йөрүе Тукайга туган телен сөю нигъмәтен генә түгел, бәлки аннан ничә вә ничә катлаулар өстен торган татарча сөйли алу, чын татар шагыйре булып таныла алу нигъмәтен башлады. Тукай халык җырына якын тормаган, аннан илһам вә үрнәк алмаган булса, бик ихтимал ки, үзенең элекке шигырьләрендә күренгәнчә, я госманлы түгел, я гарәпчә түгел, я фарсыча түгел, шуның белән татарчага да туганлыгы булмаган татсыз бер өслүб белән суык мәгънәләр сөйләүче гади бер нәзым булып калган булыр иде. Аны шул соңыннан халык җырлары үз ягына нык тартып алды да, үзенең илһамы, үзенең саф рухы белән коендырып, Тукайны чын халык шагыйре ясады. Башка шагыйрьләребез халык җырлары илһамыннан, рухыннан ераграк торганга, заманында Тукай артына җитә алмадылар. Ләкин бергәлек үзгәреше дәверенең социалист шагыйрьләрендә халык җырларыннан илһамлану ачык күреләдер.

**Халык җырларының вәзеннәре.** Халык җырларының вәзеннәре иҗек санынча. Кафия һәр мисрагъта шарт түгел. Икенче белән дүртенче мисрагъның бер кафияле булуы гына шарт. Җырларның һәр юлы ике өзектән тора. Өзек (стопа)[2] дип тезмәнең (мәнзумә) сүз басымы үзенә төшү белән аерылган өлешенә әйтелә. Өзекнең эченә кергән иҗекләрдән берсе – басымлы, калган күрше иҗекләр басымсыз яки басымнары бик йомшак булып, бер дә сизелмәслек булалар. Өзекләр ике иҗекле дә, өч иҗекле дә булалар. Ләкин өзекләрнең иҗекләре берсе – озын, берсе яки берничәсе кыска иҗекләр булалар. Җырларның һәрбер өзегендә дүрт иҗек булса да, күбрәк соңгы мисрагъта өч иҗек кенә була. Дүрт иҗекле өзекләрнең элеккесе –

[1] Яшеннән үк – яшьтән үк.
[2] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*

озын, ягъни сузыбрак әйтелә торган, калган өчесе кыска әйтелә торган иҗекләр булалар.

Мисаллар:

آ                    آ
*Суда балык || күп булыр,*
آ                         آ
*Чуртан балык || бер булыр.*
*Илдә матур || күп булыр,*
آ                    آ
*Җан сөйгәне || бер булыр.*

Искәрмә: кайсыбер җырларда беренче һәм өченче мисрагъларның соңгы өзекләре – дүрт иҗекле, икенче һәм дүртенче мисрагъларның азаккы өзеге дә өч иҗекле була.

Мисал:

آ                    آ
*Сандугачка || җим бирмисең,*
آ                    آ
*Ачка үлсен, || дидеңме?*
آ                    آ
*Сагынганда || юк сәламең,*
آ                        آ
*Саргаеп үлсен, || дидеңме?*

Димәк, мондый җырларда беренче мисрагъ белән өченче мисрагъ – сигезәр, икенче белән дүртенче мисрагълар җидешәр иҗекле булалар.

Искәрмә: озын иҗекләр өстенә «آ» билгесе куелды.

Бездә озын көйгә җырлана торган җырлардан «Зиләйлүк» белән «Тәфтиләү» көенә салынган җырларның беренче мисрагы белән өченче мисрагы – унар, икенче белән дүртенче мисрагълары тугызар иҗекле булалар. «Ашказар» – моның киресенчә. Җырларда иҗекләр табигый үлчәүгә тулмаса, «лай», «һай», «ай», «дә», «дәй», «үк» кеби сузгычлар кушыла. Бу – бер татарларда гына түгел, таранчы[1] һәм үзбәкләрдә дә шулайдыр.

Югарыда Урал-Идел буе татарларының җырлары турысында йөртелгән төшенчәләрне башка төрки кавемнәр хакында да йөртеп була. Себер татарларында, үзбәкләрдә, кумыкларда, казакъ вә

[1] Таранчы – Россия империясе территориясендә яшәүче уйгурларның 1917 елга кадәрге атамасы.

таранчыларда, төрекмән, азәрбайҗан, госманлыларда булсын – гомумән, шулай, ягъни рухлары, мөндәриҗәләре, мисрагъларның бер-берсенә бәгланыш вә мөнәсәбәтләре игътибары белән бөтенесенең җырлары, үләннәре бертөсле, тик вәзендә генә аз-маз аермалар күрелергә мөмкин.

Себер татарларының җырларыннан мисаллар:

*Сандыгаш очат сас (саз) саен – саска петкән тал саен,*
*Санаган туган киләт тип, сафтанып күрдем ул саен.*
*Күңәнәк*[1] *очат күл саен – күлгә петкән тал саен,*
*Күргән туган киләт тип – күрергә чыктым юл саен.*

* * *

*Тоболдың*[2] *юлы тулгыш юл – тузудыр (тузадыр) комыт колагы,*
*Тобол барган пай улым*[3] *– комыт йөгүнәт*[4] *майлары.*

* * *

*Өркет*[5] *юлы өч айлыш – өзеләт комыт колагы,*
*Өркет барган пай улым – өзеләт йөрәк майлары.*

* * *

*Ярга пүткән*[6] *каеңның – күлүткүзе (күләткә)*[7] *суда турат,*
*Аданың*[8] *улу булужы – сөнүзе пидә торат.*

* * *

Үзбәк җырларыннан:

*Моннан бардым ул йөзгә – атым тайгалды мүзгә*[9]*.*
*Таелгалы мүз яхшы – уйнашкалы кыз яхшы!*

* * *

*Күрмәен бастым тәкәнне (тәкәнәк)*[10] *– тартадыр мән җәбрине*[11]*,*
*Күрсәм ирде, басмас ирдем – тартмас ирдем дәрдене*[12]*.*

---

[1] Күбәләк. Котыт – камыттыр. Сас – саздыр. *(Авт. иск.)*
[2] Тобол – Тобольск.
[3] Пай улым – ир балам.
[4] Йөгүнәт – *биредә:* бетерә.
[5] Өркет – Иркутск.
[6] Пүткән – үскән.
[7] Күләткә – күләгә.
[8] Адаң – анаң.
[9] Тайгалды мүздә – бозда тайды.
[10] Тәкәнәк – тигәнәк.
[11] Тартадыр мән җәбрине – мине ирексезләп тартадыр.
[12] Тартмас ирдем дәрдене – бу кайгыга тарымас идем.

* * *

*Гөлене өзәйдисәм – тикәне барга охшайдыр;*
*Яр белән ятай дисәм – баласы барга охшайдыр.*

* * *

*Калдыргач (карлыгач) кара булыр, канаты ала булыр;*
*Яшьлектә биргән күңел аерылмас бәла булыр.*
*Бидә (клевер, печән) бирсәң, тайга бир, кәсер-кәсер чәйнәсен;*
*Кызны бирсәң, яшькә бир, гыйшкы белән уйнасын.*
*Ул күчәдә*[1] *сән булсаң, бу күчәдә мән булсам;*
*Багның гөле сән булсаң, унык*[2] *бәрке (япрак) мән булсам.*
*Ишегеңдә җөп тирәк, җөп тирәккә су сирәк;*
*Кайлыгы (хатыны) юк йигеткә кырчылама*[3] *кыз кирәк (кырчып торган).*
*Чумчыклар чыркылайды*[4] *– шам булганга охшайды.*
*Йөрәкләр җыглайды – яр килгәнгә охшайды.*

* * *

*Гөлләр эчендә бер гөле бар – кайрыладыр.*
*Бездән нә гөнаһ үтте, кем яр аерыладыр.*
*Сәни – монда, мәни унда яратты;*
*Уртамызда акар дәрья яратты;*
*Акар дәрья икән акты да китте...*
*Би вафа*[5] *яр икән, ташлады китте...*

Күрәсез, үзбәк җырлары да күп яктан нәкъ татар җырлары шикелле, үзбәкләрдә «үлән», «ашула», «кушук» дип аталган өч төрле җырлар бар. Үләннәрнең соңнары, гомумән, гадәттә, «яр-яр» белән бетә. «Ашула» дип аталган җырларның күпләре озын була һәм күбрәк ике кеше белән әйтелә. «Кошык» дигән җырлары исә күп кеше тарафыннан җырлана, ягъни бусы «хор» димәктер.

Таранчы (уйгур) җырларыннан мисаллар:

*Кузукдиги тасмамны – путтам чыгыда бетимән;*
*Ишекләр тарахлыса – ярым чыгыда бетимән.*

[1] Күчәдә – урамда, авылда.
[2] Уның – аның.
[3] «Үткен, эшлекле» мәгънәсендә.
[4] Чумчыклар чыркылайды – чыпчыклар чыркылдый.
[5] Би вафа – вәгъдәсез.

Мәгънәсе: Казыкта асулы торган тасмамны путам, ягъни билбау дип уйлаганмын. Ишекләр шатырдаса, ягъни аяк тавышы килсә, ярымсөеклем дип уйлаганмын. (Ләкин киресенчә булып чыкты, яңлышканмын, димәктер.)

*Каш атарым килиде, керпек атарым килиде;*
*Билга алма чүгеп, яганчы ярым килиде.*
(Бу җырны кызлар җырлый.)

Мәгънәсе:

Каш сикертүчем килә, керпек атучым килә;
Биленә алма тагып, ялганчы ярым килә.

*Сула шакрап акса, «түгмәннең нуры» дәймән;*
*Яр өчен йисәм таяк, үземнең шуры дәймән.*

Мәгънәсе: Сулар шалтырап акса, тегермәннең улагы, димен. Сөеклем өчен таяк җыйсам – кыйналсам, аны үземнең шомлыгымнан дип беләмен. (Таранчыларда күплек галәмәте булган *-ләр, -лар*ның *«р»*сы әйтелми кала. Түгмән – тегермән, нуры – улак, тегермән улагы; шуры – шомлык, гөнаһ шомлыгыдыр).

*Гөлмеде, гонҗәмеде, ярым, синең башыңдике?*
*Кичиләб туналмыдым, кемләр иде әйде кашыңдике?*
(Туналмыдым – таный алмадым димәктер.)

Мәгънәсе:

Гөл идеме, гонҗә[1] идеме, ярым, синең башыңдагы?
Кичәгенәк таный алмадым, кемнәр иде кашыңдагы[2]?

Таранчыларда һәрбер эш вә хәлнең, вакыйгаларның үзенә махсус җыр вә көйләре була икән. Мәсәлән, иген эшләрен эшләгәндә үзенә хас көй вә җырлары булган кеби, сәфәрдә чакта, туй һәм уен мәҗлесләрендә, сугышларда янә үзләренә махсус көй вә җырлары буладыр.

Иген эшләре вакытында (урак урганда) менә шундый җырлар җырлана икән:

*Омыңызны мән удым,*
*Унчыңызны сайламай;*
*Йиңездә яр тоттым,*
*Утыңызга пайламай.*

[1] Гонҗә – яңа ачылып килгән чәчәк.
[2] Кашыңдагы – яныңдагы.

Мәгънәсе:

Алыныгызны[1] мин урдым,
Учмаңызны[2] сайламай.
Яныгызда яр тоттым,
Утыгызга чыдамай[3].

*Искәртмә:* бу җырны җырлаганда, ахырына беренче мисрагъда[4] – «ай-йәй...», «икенче мисрагъда – «ва-йәй...», өченче мисрагъда – «әй...», дүртенчесендә «әй...» кушыладыр һәм бу кушымчалар сузылып әйтеләләр.

## Саф халык теле вә борынгы халык әдәбиятыбыз турысында гомуми төшенчәләр

Безнең иң борынгы саф тел вә саф халык әдәбиятыбызны, бердән, ислам дине, гарәп вә иран тәэсирләре имгәткән булса, Казан руслар тарафыннан алынганнан соңгы караңгы вә шомлы дәверебез дә аның харап булуына сәбәп булды. Казан алынмастан элгәреге, ягъни XIII вә XIV гасырлардагы халык әдәбиятыбызның һәм аннан да борынгы вә мөхәммәдилекне[5] кабул итмәстән әүвәлге җыр вә экиятләребезнең, мәсәл вә әфсанәләребезнең[6] хәзерендә арабызда калдыклары бик аз, бәлки юк хөкемендә. Боларның күбесе – тарихи вакыйгалар, орышлар-сугышлар, ватылыш вә җимерелешләр сәбәпле югалган, тузылган, чәчелгән, юк булганнар яки борынгы халкыбыз, карт вә карчыкларыбызның үзләре белән бергә җир астына сәфәр иткән, югалган, күмелгәннәрдер. Арабыздан чыгып та, Каюм Насыйриебызга кадәр аларны эзләү, табу, сафлау дәртенә төшүчеләребез булмаган; моның имкяне[7] дә табылмаган.

Хәзерендә боларның да беркадәресен һәм телебезнең дә бераз сафлыгын тик типтәрләр белән башкортлар арасында сакланып калганын күрсәк тә, болар тагын безне канәгатьләндерерлек түгел. Асыл Казан тирәсендәге татар вә мишәрләр исә төрле тәэсирләр астында һәм телләренең, һәм халык әдәбиятының сафлыгын тагын да ныграк югалтканнар. Руслык тәэсире дә боларга ныграк тукылган.

[1] Алын – эшкәртеләсе басуның бер башыннан икенчесенә кадәр бер кеше алып барырга тиешле кишәрлек.
[2] Учмаңызны – көлтәгезне.
[3] Бу җырларны җыйнауда Ташкенттагы Татар белем йортындагы шәкертләрем вә хосусан Габделхәй Мөхәммәдинең ярдәме катнашты. *(Авт. иск.)*
[4] Мисрагъда – юлда.
[5] Мөхәммәдилекне – ислам динен.
[6] Әфсанә – экият, фантастик хикәя, мифик мәсәл.
[7] Имкяне – мөмкинлеге.

Николай вә аның элгәреге юлбашчылары заманында, каты истибдад[1] дәверләрендә, җырларыбыз, бозык йортларда, фәхеш вә исереклек мәҗлесләрендә генә җырлана торган бер нәрсә булып калып, рух вә мәгънәләрен, телләрен, өслүб вә тасвирларын тәмам югалта язганнар.

Җөмләдән, каһарман җырлары, батырлар хакындагы әкият вә мәсәлләребезнең һәммәсе диярлек тарихның шомлы пәрдәләре астында ябылып калып тәләф булганнар[2].

Дөрес, борынгы телебез вә халык өслүбенең үрнәкләре һәм халык әдәбиятыбыз турысында Радлов вә Катанов[3] кеби мөстәшрикъләр[4], күп көчләр сарыф итеп, зур хезмәтләр куйдылар. Ләкин боларның тапкан нәрсәләре дә әле моңанча үз тел галимнәребез, әдәбиятчы һәм тарихчыларыбыз тарафыннан ныклап тикшерелеп, шулар халкыбызга, аның рух вә табигыятенә, борынгы әхвале рухиясенә[5] нечкәләп, яңадан татбикъ кылып[6] каралмаган вә дөреслекләре дә үз тәхкыйкләребез[7] белән ныгытылмагандыр. Яки тагын дөрес әйтсәк, без әле шушы мөстәшрикъләрнең тәхкыйкатларыннан да тәмам файдалана алмый торабыз.

---

Хәзерендә без чын борынгы саф телебезне, саф, табигый вә тирән халык әдәбиятыбызны, булса-булса, ялгыз казакълар арасыннан, Алтай таулары астыннан һәм Себер төрк кавемнәре вә Себер татарлары арасыннан эзли алабыз.

Чын гыйлем намына[8] ачык әйтергә кирәк: хәзерендә иң саф, иң бай, иң табигый вә бозылмыйча, элгәреге халәтендә сакланып калган бер тел булса, ул да казакъ теле вә казакъларның халык әдәбияты булды.

Төркестанлыларда – үзбәк вә төрекмәннәрдә дә без халык теле вә халык әдәбиятының дин, гарәплек вә иранилык тәэсире астында элгәреге сафлык вә байлыгын күп югалткан икәнен күрәбез.

---

[1] Истибдад – деспотизм.
[2] Тәләф булганнар – юкка чыкканнар.
[3] Николай Федорович Катанов (1862–1922) – тюрколог, этнограф, фольклорчы.
[4] Мөстәшрикъләр – Көнчыгышны өйрәнүчеләр.
[5] Әхвале рухиясенә – рухи халәтенә.
[6] Татбикъ кылып – яраклаштырып.
[7] Тәхкыйкләребез – тикшерүләребез.
[8] Намына – хакына.

Тел вә әдәбиятта киңлек, байлык һәм боларның сафлыгы вә фәсахәте[1] ягыннан караганда, Казан теле барысыннан өстен тора. Әйтергә мөмкиндер ки, бу турыда безнең гарәп әдәбиятындагы «җаһилият дәвере»[2] рәвешендәге җаһилият заманнарыбызның чишмәләре казакъларда нык сакланып киләдер. Әлбәттә, мәдәният тәэсире һәм күчмә хәяттан чыгу боларның да телләренә күп тәэсир кылачак, элгәреге халәтенә бераз башкалык бирәчәк. Ләкин, һәрхәлдә, боларның тел вә әдәбиятлары, бу тугрыда нишләсә дә, безнеке халәтенә төшмәячәк.

Мәшһүр Радлов та үзенең «Образцы народной литературы тюркских племен»[3] дигән әсәрендә[4] казакълар тугрысында дөрес төшенчәләр йөретә вә әйтәдер: «Без бу ыруглар хакында элек сүзне кыргызлардан башлыйбыз ки, болар үзләренең яшәгән урыннары һәм иҗтимагый вә фикри шараитлары[5] белән башка төркләргә якынлыкларыннан бигрәк мөхәммәди булмаган (мөселман түгел) төркләргә якын торалар».

«Төньяк Алтайдан Урал елгасына кадәр, Омскидан Зәрафшан[6] сахрасының төньяк чикләренә тикле булган җирләрдә бер үк төрле ыругның вә бәлки, әйтергә мөмкин ки, бер үк халыкның әгъзалары яшиләр. Бу халыклар да үзләренә «казакъ» дип, руслар һәм башка көнбатыш халыклары да боларга, яңлыш уларак, «кыргыз» намын[7] яхуд[8] «кыргыз-качак» исемен бирделәр. Кыргызларның төп кайсы нәселдән, кайсы нәсәптән икәнлекләре хакында безнең өчен белекләр[9] бик аз. Боларның нәсәбе исемнәре безгә таныклык бирәдер

[1] Фәсахәте – матурлыгы.

[2] Сүз ислам дине таралганчыга кадәр V–VI гасырларда формалашкан гарәп әдәбияты турында бара.

[3] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*

[4] Аның бу әсәре берничә зур-зур җилдләрдән гыйбарәт булып, беренче вә икенче җилдләре көньяк (җәнүби) себер төркләренең фикри әсәрләренә (мәкаль, мәсәл вә хикәяләренә) гаидтер (*кагылышлы*). Ягъни бу ике җилдне Радлов әле һаман борынгы шаман динен тотып килүче вә ислам тәэсиренә бирелүче төрк ыругларына багышлаган. Өченче җилде исә Алтайның төньягында яшәп тә, хәзерендә ислам динендә булган төрк кавемнәренә хасланып, шулар эченнән дә казакълардан башлангандыр. Бу җилдтә элек аларның фикри хәлләре, халәте рухияләре, тереклек рәвешләре, иҗтимагый тереклек ысуллары тикшерелгән һәм казакъ халык әдәбиятыннан күп үрнәкләр җыйналган. *(Авт. иск.)*

[5] Шараитлары – шартлары.

[6] Зәрәфшан – Үзбәкстандагы түбәнлек.

[7] Намын – атамасын.

[8] Яхуд – яки.

[9] Белекләр – мәгълүматлар, белешмәләр.

ки, кыргызлар да төрле халыклардан хасил булганар. Моны да, мәсәлән, ыругларның «кыпчак», «аргун», «найман» (бу соңгысы, һич шөбһәсез, монгол нәсәбеннәндер) дип аталулары күрсәтәдер. Ләкин бу төрле-төрле гонсырлар[1], аңлашылуына күрә, үзара бик күптән бер-берсе белән катнашып киткәннәр».

Радловның бу сүзләре, бу тәхкыйкатлары[2] да безнең югарыдагы сүзләребезгә нык шаһит була алалар.

Радлов янә, югарыдагы сүзләренә өстәп, шуларны әйтәдер:

«Кыргызлар, казакълар һәм әхлак вә табигатьләре, һәм дә телләре ягыннан бербөтен халык булуларын күрсәтәләр».

«Гәрчә болар күптән бирле ислам диненә иярүчеләр булып килсәләр дә, боларга мөхәммәдилек мәдәниятенең төп галәмәтләре, сыйфатлары күп урынлаша алмады, ягъни укымышлылар (галимнәр) яки руханилар катлавының тәэсире белән өлүһият[3] вә кодсияткә[4] таба гайре табигый омтылу боларда күрелмәде».

«Ислам динен казакъларның болай тыштан гына тотулары өчен без тагы шушы яктан бурычлыбыз ки, кыргыз теле исламның таратучы, җимерүче тәэсиреннән зарарланмыйча бөтен калды һәм үзенең элгәреге саф төрклек табигатен саклады».

«Дөрес, бу телгә дә чит сүзләр керде, ләкин казакълар башка мөхәммәди төркләргә булган дәрәҗәдә ул сүзләрнең үзлеген – истикъляльятен[5] сакламадылар. Бәлки казакъ теленең үз авазлары канунына ул сүзләрне буйсындырдылар, һәм шулай итеп ул сүзләр халыкның тәмам үз малы булып әверелделәр».

«Казакълар башка үзләренең нәселдәшләреннән бигрәк тә ифадәдә[6] җитезлекләре һәм матур сүзләре белән аерылалар».

Туры[7]! Бер яктан, хәзерге көндәдге вакыйгый хәлне вә казакъларның үзләрен турыдан-туры күз алдына китергәндә, икенче яктан, дәхи Радловның сүзләренә игътибар ителгәндә, саф халык теле вә саф халык әдәбиятыбызның чын төсләре казакъларда булуына шик калмаячак.

---

[1] Гонсырлар – элементлар, өлешләр.
[2] Тәхкыйкатлары – тикшерүләре, нәтиҗәләре.
[3] Өлүһият – тәңрелек, аллалык.
[4] Кодсияткә – изгелеккә, Алла белән бәйлелеккә.
[5] Истикъляльятен – бәйсезлеген.
[6] Ифадәдә – аңлатып бирүдә.
[7] Туры – «төгәлрәге» мәгънәсендә.

Төрле үсемлекләрнең нәгыз[1] борынгы үз телебездәге исемнәре дисезме, саф җиңел һәм катлаусыз-тәкәллефсез, ачык вә аһәңле тасвирлар дисезме, батырлар, борынгы каһарманнар хакындагы табигый тасвирлы дастаннарны сорыйсызмы, тирән мәгънәле халык мәкальләре, табышмаклар, җырлар һәм такмаклар кирәкме – хасил, борынгы халык әдәбиятының һәрбер төреннән һәрнәрсәне ялгыз хәзерге казакъ әдәбиятыннан гына тапмак мөмкин. Казакъларның яшь язма әдәбиятларының атасы Абай[2] белән шул әдәбиятның иң якты бер йолдызы булган көчле шагыйрь Мәгъҗанның[3] тел, өслүб, тасвирларын бу урында мисал итә алабыз. Болар безгә казакъ язма әдәбиятының да бу яктан нинди нигезгә корылып киткәнен күрсәтә алалар.

Радловның «халыкчылык рухын китап телендәге җырлар, китап сүзләре кысрыклыйлар» дигәне кеби, гәрчә казакъларның арасына күп таралган «Сәйфелмөлек»[4], «Сахибҗәмал», «Ахырзаман»[5], «Чәһаръяр»[6], «Бүз егет»[7], «Сәетбаттал»[8], «Гали»,

[1] Нәгыз – асыл.

[2] Абай Конанбаев (1845–1904) – мәгърифәтче шагыйрь, казакъ язма әдәбиятына нигез салучы. Шәрык дин галимнәре тәфсиреннән файдаланып, мантыйк һәм мөселман фикъһ нигезләрен, әт-Табари, Рабгузи, Рәшид әд-Дин, татар тарихчысы Ш. Мәрҗани һ. б. ларның тарихи хезмәтләрен өйрәнә. Лирик һәм сатирик шигырьләр, «Мәсгуд» (1887), «Әзим кыйссасы» (1901), «Искәндәр» (1901) поэмалары авторы.

[3] Мәгъҗан Җомабай (1893–1938) – казакъ шагыйре, публицист, яңа казакъ әдәбиятына нигез салучыларның берсе.

[4] «Кыйссаи Сәйфелмөлек» – XV гасыр ахыры – XVI гасыр башында яшәгән шагыйрь Мәҗлиси әсәре. Тумышы белән Харәземнән, аннан Бохарага күчкән, Гобәйдулла хан һәм аның улы Габделгазиз ханнар сараенда хезмәт иткән дип фаразлана.

[5] «Ахырзаман китабы» – дини-дидактик рухтагы әсәр. «Тәкый гаҗәб китабы» исеме белән дә мәгълүм. Сөләйман Бакыргани язган дип санала. Китап Урта гасырлар суфичылык әдәбияты традицияләрендә, башлыча, Әхмәд Ясәви хикмәтләре тәэсирендә язылган. Әсәрдә Ахырзаман көне (Кыямәт), бакый дөньядагы тормыш тасвирлана.

[6] Әбу Талибның улы Гали батырга багышланган, Урта гасырларда иҗат ителгән төрки дини-дидактик дастан турында сүз бара.

[7] «Бүз егет» – фарсы телендә мәхәббәткә багышлап язылган ярымфантастик хикәя сюжетына ияреп, 1842 елда Баһави тарафыннан Уфа шәһәрендә иҗат ителгән лиро-эпик әсәр. «Бүз егет»нең кульязма варианты иске татар телендә язылган. Стиленең халык җырлары традицияләренә якын булуы әсәрнең күп кенә төрки халыклар – татарлар, казакълар, башкортлар, нугайлар, кумыклар арасында (шагыйрь чичәннәр башкаруында) киң таралуына сәбәп була.

[8] «Кыйссаи Сәетбаттал газый» («Сәетбаттал каһарман турында кыйсса») – героик дастан, урта гасырлар госманлы төрк әдәбияты ядкәре. Татарлар арасында XVII йөзгә кадәр киң таралган була. Дастанның иң борынгы татарча нөсхәсе 1709 елга карый. XIX йөздән алып берничә тапкыр нәшер ителә. Сәетбаттал каһарманлыгы темасы татар әдәбиятында да эшкәртелә. Әсәрнең «Сәетбаттал китабы», «Мәнакыйбе Сәетбаттал газый», «Сирәте Сәетбаттал газый» кебек охшаш исемле күптөрле татар вариантлары да бар.

«Җөмҗөмә»[1] кеби китаплар казакъ дини галимнәре вә мөлдәкәләр[2] аркылы үзләренең тәэсирләрен төрле яктан нык күрсәткән булсалар да, казакълар аларның теленә вә өслүбенә бездәге дәрәҗәсендә мәгълүб булмадылар[3]. Моңа югарыдагы ике өлкән казакъ шагыйре вә, гомумән, хәзерге көндәге бөтен казакъ язма әдәбияты шаһит.

Дөрес, мондый әсәрләр казакъларга дини рухны нык тараттылар. Радлов гыйбарәсе белән әйтсәк, ««Җөмҗөмә»нең бер җыры шигыре казакълар арасында исламны ныгытуга сахраларда йөрүче йөз мулладан артык тәэсир иткәндер» дияргә мөмкин булса да, тел вә өслүбтә, һәрхәлдә, казакълар гарәп тәэсиренә бик аз җиңелделәр. Гәрчә Радлов: «Кыргызларда вәзен кагыйдәләренә килгәндә, боларда Иран шигыренең тәэсире ачык күрелә», – дисә дә, без моңар кушыла алмыйбыз. Аларда бу тәэсирне без күрә алмыйбыз.

Бу урында аеруча әйтеп үтәргә тиешле бер нәрсә булса, ул да җырларның борынгы катнашлык (синкретизм[4])ына ачык вә тулы мисаллар казакъларда табылудыр. Болар өчен мисалларны без татарчадан таба алмыйбыз яки бик аз таба алабыз. Үзбәк һәм комыкларда да моңар мисаллар табылса да, казакълар дәрәҗәсендә түгел. Илһами җырлар өчен инде бердәнбер чишмә казакълар булыр.

Илһами җырлар һәм кара-каршы әйтешеп җырлар якын бер заманда башкортларда да булган, ләкин инде бу аларда беткән диярга ярый.

Башкортларның кызны кияү йортына озатканда кияүгә каршы җиңгиләрнең мәзәхләп[5] җырлаулары вә кияүнең дә шуларга каршы шул ук җыр белән җавап кайтарулары әле дә булса бәгъзе урыннарда бар. Шундый хәлне Златоуст өязендә моннан ун еллар гына элек булганын күреп һәм шунда катнашып, җырлашып йөргән Мөхтәрәмә ханым Хәлилулла кызы риваять итәдер. Шул ук җиңгиләр тарафыннан (яки кыз үткенрәк булса – үзе), кыз исеменнән атасына

[1] «Җөмҗөмә дастаны» – XIV гасыр төрки-татар язма истәлеге. Авторы – Хисам Кятиб. Ф. Гаттарның шул ук исемдәге фарсы телендә язылган әсәренә нәзыйрә дип фаразлана. Әсәрнең 30 га якын кульязма нөсхәсе бар, алар Казан, Санкт-Петербург, Ташкент, Париж архивлары һәм китапханәләрендә саклана. 1872 елдан алып «Җөмҗөмә солтан» Казанда берничә тапкыр басылып чыга. 1881 елда М. Юмачиков әсәрне татарча варианттан казакъ теленә тәрҗемә итә (барлыгы 10 басмасы чыга).

[2] Мөлдәкәләр – муллалары.

[3] Мәгълүб булмадылар – җиңелмәделәр.

[4] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*

[5] Мәзәхләп – мәзәкләп.

барып, җыр белән «семдәү» яки «сеңдәү», ягъни саубуллашу әйтелә икән. Болай әйтешкән вакытларда кызлар һәм җиңгиләр, барысы берлектә бер кызыл чаршау астына кереп, шуңар төренгән хәлдә киләләр, имеш[1].

Шундый әйтешләрдән бәгъзе мисаллар:

Кияүне тиргәп:

*Анауда таудың кыегы,*
*Монауда таудың кыегы;*
*Шундала туган кияүдең*
*Эт койрыгындай мыегы!*
*Анауда тауның күрке бар,*
*Монауда тауның күрке бар;*
*Шундала туган кияүдең*
*Эт тиреһендән теккән бүрке бар!*

*Һавала торган һыерымның*
*Имсәкенәге көпшәктәй;*
*Шундала туган кияүдең*
*Авызы нигә көршәкдәй[2]!*
*Өстеңә кигән киемең*
*Кытат[3] инеме[4] – кыптырдай;*
*Шундала туган кияүкәй*
*Кәзә тәкәһе күк мыкырдай...*

Кызның ата-анасына йортыннан китәр көнне әйткәннәреннән бәгъзеләре шулар:

*Әтекәемнең өендә*
*Утырганнарым түр иде;*
*Әтекәемнән киткәс тә,*
*Ишек төбе дә юк инде.*
*Әтекәемнең өендә*
*Утырганнарым бер такта;*
*Бер тактакайдарын кызганып,*
*Утыртып иде бер ятка.*
*Бурада бура аштыкыңды[5]*
*Аш итмәдегез, әткәем!*

*Бер-ике елга иш инем,*
*Иш итмәдегез, әткәем!*
*Мин ашаган кашыкты*
*Уша башына куегыз[6],*
*Уша башынан төште ниһә[7],*
*Ияһе лә юк дип алыгыз!*
*Ак сөперәккә төйгәнең*
*Ахак кына инеме, әткәем?*
*Ахакда кебек һатып идек,*
*Артык кына идемме, әткәем!*

[1] Урал башкортларының тел һәм гадәтләрен белүче Нигъмәт Хәким дә шуларны тәэкид кыладыр. *(Авт. иск.)*
[2] Көршәктәй – чүлмәктәй.
[3] Кытат – Кытайда эшләнгән тыгыз ефәк тукыма, парча.
[4] Инеме – идеме.
[5] Аштыкыңды – ашлыгыңны, икмәгеңне.
[6] Уша – пич кырыендагы киртләчтер, ягъни пич кырыена куегыз дигән сүз. *(Авт. иск.)*
[7] Төште ниһә – төшсә.

Анасына:

*Һике астындагы йомырканы*
*Ал, инәкәем, онытма!*
*Кулымда балам бар тип,*
*Бар, инәкәем, онытма!*
*Бурдатта шаршау шәүләһе*
*Биткенәеңә төшәр, әнкәем!*
*Һуга ла һалһаң – һөләкмен...*
*Кулга ла гиһәң – йөзекмен.*
*Мамыкда кебек ифәкмен,*
*Бүгенгә генә кунакмын.*

Ананың кызга каршы:

*Кулымдагы орсок башым,*
*Ай-һай да, беләк талдыра;*
*Кыз китүләре авыр икән,*
*Аһ-һай да, йөрәк яндыра!*[1]

Күрәсез, менә бу мисаллар – тормышыбыздагы тарихи ләүхәләребезне[2] күз алдыбызда җанландыра торган вә онытылып бара яткан парчалардандыр. Боларның, бәлки, тагын да бүтән, тулы вә төгәл тасвирлыраклары да бардыр.

Фәкать казакълар исә бу бабта һичкемне алларына чыгармаслык дәрәҗәдәләр. Мин үзем казакъларның кыз озаткандагы кара-каршы әйтешләрен, үзе белән бергә өлкән кыз иптәшләренең китә торган кызга һәм кызның аларга вә ата-аналарына «үләң» белән илһами әйтешүләрен тыңлап торып, тәмам хәйран калганым бар. Мондагы оста тасвир, матур вә кискен тәгъбир, тулы вә үткен мәгънәләр, үткен шигърияләр, фәсахәт вә бәләгатьләр – кешене хакыйкатән таң калдырырлык бер нәрсә.

Элгәредән һичбер хәзерләнмәстән вә һичбер уйлап тормастан, казакъ акынлары-үләңчеләренең (җырчыларының) хәтта өзексез икешәр-өчәр сәгать буена кара-каршы тәмам шигъри бер тарызда[3] «үләң» әйтешкәннәрен казакълар арасында булган һәркем һәм казакълардан күпләр сөйлиләр.

[1] Башкортларның илһами җырлары турысындагы мәгълүматлар Мөхтәрәмә ханым Хәлилулла кызыннан алындылар. Аның җырлап күрсәтүенчә, югарыдагы җырның үзенә махсус бик моңлы бер көе дә бар. Башкаларның һәм шулай икән. *(Авт. иск.)*

[2] Ләүхәләребезне – картиналарыбызны.

[3] Тарызда – формада.

# ИКЕНЧЕ БАБ

## ЯЗУЛАР-ӘЛИФБАЛАР ҺӘМ АЛАРНЫҢ ТАРИХИ ҮСҮЛӘРЕ

**Язуның файдасы вә хезмәте.** Кеше кулы, кешеләр җәмгыяте тудырган иң кыйммәтле нәрсәләрнең берсе вә бәлки беренчесе язу-әлифба булды. Бу – мәдәниятнең зур бер нәтиҗәсе.

Язуның файдасын, аның чиксез зур хезмәтен кешелек тарихы үзенең тәрәккый дәверләренең һәркайсында ачык күрсәтә килә. Аның файдасын вә хезмәтен без менә шушы яклардан да күрә алабыз:

1) Үзенең фикер, аң вә тәҗрибәләрен, белемнәрен башкаларга киң, тулы кылып, ачык һәм туры рәвештә аңлата алуның көчле бер коралы кешенең язуы булды. Бу турыда кешенең беренче коралы тел – сүз иде. Язу шуның икенчесе булып табылды.

Тән вә әгъза хәрәкәтләре кебек, тел һәм язудан башка да кешеләрнең бер-беренә фикер вә тойгыларын аңлатышуның юллары, чаралары бар иде һәм бардыр. Ләкин болар бик зәгыйфь, бик кимчелекле чаралар иде. Болар белән бик аз нәрсәләр генә аңлатыла алды. Болар да томанлы бер рәвештә тик бер ишарә юллы гына була иде, һәм бу юл белән әле дә шулай гына аңлатыладыр.

2) Язу кешелек дөньясында фикри тәрәккыйгә киң юл ачты. Кешелек дөньясында чын фикри хәрәкәт вә мәдәни тәрәккый язу белән бергә башланды. Фикри тәрәккыйне көчәйтеп, киңәйтеп җибәрүдә дә ул иң беренче зур адым булды.

3) Язу үзенең тудырылган чагыннан башлап шул хәзерге заманыбызгача кешелек мәдәниятен алга хәрәкәт иттерүче иң көчле бер гамил[1] булып килде һәм ул һаман шулай булып килә дә.

Язуның бу юлдагы хезмәт вә тәэсире – хәзерге заманыбызда һәркаюбызның күз алдында ачык күренеп торган бер нәрсә. Бер халыкта язусызлык, сәвадсызлык[2] кими барган саен, без аның матди һәм мәгънәви мәдәниятендә һаман алга китә барганын күрәбез. Язусыз, сәвадсыз яки үзендә язу, сәвад гомумиләшмәгән бер халыкта

[1] Гамил – чара.
[2] Сәвадсызлык – укый-яза белмәү.

фикри хәрәкәт вә мәдәни күтәрелүнең бик зәгыйфь, бик әкрен барганлыгы – янә күз алдыбыздагы вакыйгый бер хәл. Моның өчен, статистикаларга карап, хәзерге гарәп белән Шәрык арасында бер тиңләштерү мәсьәләне ачып бирүгә җитә. Хәзерге көндә мәдәният чишмәсе булып танылган гарәп мәмләкәтләренең үз арасында бу турыдагы статистика мәгълүматларын да шуңа китереп кушсак, мәсьәлә тагын да яхшы ачылыр.

Менә бу хәлләр безгә фикри вә мәдәни хәрәкәттә, мәдәни тәрәккыйдә язу-сәвад дигән нәрсәнең күпме тәэсире вә хезмәте булганын тәмам ачып бирә ала.

4) Язу кешеләрнең аң вә фикерләрен, дөнья вә тормышка карашларын, дөнья вә тормышны аңлашларын, белем вә тәҗрибәләрен – хасил[1], бөтен фикри вә мәдәни байлыкларны, мәдәни мирасларны югалтмыйча бергә җыеп саклап килде, шуларны соң заманнарга, яшь буыннарга һаман саклап калдыра барды. Шуның белән соңгы яшь буыннарга фикри, мәдәни тәрәккый хәрәкәтләре һаман җиңелләшә килде, һәм бу һаман шулай булып бара вә барачактыр.

Тел белән әйтелгән нәрсәләр, сүзләр үзләре шул язу аркасында гына соң заманнарга, яшь буыннарга төгәл сакланып килә алганлыктан, бу турыда язу дигән нәрсәнең бу яктан телдән дә өстен торганлыгын аңлау янә кыен булмас.

Язуның менә шушы фикри-мәдәни байлыкны соң заманнарга саклап калдыра бару хосусияте – аның үзенә генә хас булган иң зур бер хосусиятедер. Бу яктан караганда, язу дигәнебез бөтен кешелек дөньясының матди вә мәгънәви бөтен мәдәни байлыгын, мәдәни мирасын үзе аркылы югалтмастан саклап килә торган ышанычлы киң бер хәзинә булганын күрәбез.

5) Язу – кешеләрнең, кешелек җәмгыятьләренең үзара мәдәни яктан якынлашып берләшүләре, фикри-мәдәни байлыкларны уртаклашулары өчен дә көчле бер васита[2]. Кешелек дөньясындагы һәрбер яңа игътираглар[3], һәрбер яңа кәшеф ителгән[4] нәрсәләр, һәрбер яңа фикер, яңа төшенчәләр, алар кайдан гына туган, кайдан гына мәйданга чыгарылган булмасыннар, язу аркасында һаман ке-

---

[1] Хасил – нәтиҗә.
[2] Васита – чара.
[3] Игътираглар – уйлап табылган әйберләр.
[4] Кәшеф ителгән – ачылган, уйлап табылган.

шелекнең уртак малы булып, җир йөзенең һәммә ягына тарала баралар. Язу аркасында һәрбер уку-язу белгән, әлифбасы, әдәбияты булган халык шулардан файдалана, шуларны үз тормышына кертә һәм шулар аркылы үзен матди вә мәгънәви яктан һаман тәрәккый иттерә кilә.

Менә шушы яктан язуда бөтен кешелек җәмгыятьләрен оештыручылык, тәкшил итүчелек хосусияте бар. Ягъни язу бөтен кешеләрне, бөтен кешелек җәмгыятьләрен, төрле мәмләкәт вә хөкүмәтләрне, төрле милләт вә кавемнәрне матди вә рухи яктан бер-берсе белән якынлаштырып, аларны берләштерә, берсен икенчесе белән баглый һәм шуның белән бергә берсен икенчесе яхшы аңлый алуга да көчле бер васита була.

Язуның бу хезмәте бер заман вә бер гасырга гына да гаид[1] түгел, аның бу хезмәте үткән заманнарны, борынгы гасырларны да үз эченә ала. Ул кешелек дөньясындагы әллә кайда озакта калган һәм дә тарихның иң караңгы катлаулары эчендә күмелеп яткан карт буыннарны, иң ерак иске заманнарны, иске гасырларны, аларның борынгы фикри-мәдәни байлыкларын да яңаларына китереп тага. Шуларны бер-берсе белән кушып баглап, бөтен бер фикри-мәдәни тәрәккый тезмәсен тудыра.

Язу аркасында без хәзерге вакытта, шушы гасырыбызда яшәгән һәртөрле халыкның тормышында нинди хәлләр, нинди эшләр, нинди тартыш вә көрәшләр, нинди үзгәрешләр булып торганын беләбез. Бу – мәгълүм. Шуның белән бергә без, үзләренең калдырган һәртөрле язулары аркылы, иң ерак, иң караңгы, иң карт, иң борынгы гасырларда нинди халыклар яшәп киткәнлекләрен, аларның ничек яшәгәнлекләрен, уйларын, белемнәрен, дөньяга карашларын, нәрсәләргә ышанган, ниләр эшләгән һәм нинди хәлләрне башларыннан кичергән икәнлекләрен янә бик яхшы тикшерә, белә алабыз. Шуның аркасында хәзерге мәдәни төзелеш, мәдәни тәрәккый эшләребездә үзебезне төрле хаталарга төшүдән саклый алуны тәэмин иткән булабыз. Тагын шуның аркасында кешелек җәмгыяте вә аның мәдәниятенең төзелеш вә тәрәккый кануннарын туры аңлый алабыз.

Боларның һәммәсе безгә кешелек мәдәниятен зур вә киң «бөтен» итеп тануга, иске мәдәниятләр белән яңа мәдәниятләрнең кыйммәт

[1] Гаид – караган, бәйле.

вә әһәмиятләрен, мөнәсәбәтләрен, аермаларын ачык төшенә алуга да имкян бирә.

Язуның хәзергене иске вә борынгы белән баглавының төп мәгънәсе дә шунда.

Кыскасы, язу дигәнебез, бөтен иске вә яңа гасырларның бөтен мәдәният әсәрләрен, мәдәният нәтиҗәләрен бергә җыеп, бергә баглап, бөтен бер кешелек мәдәниятенең системын тудыруга сәбәп һәм васита[1] булып килә. Шуның аркасында без җир йөзендәге бөтен кешелек мәдәниятенең бөтен вә төгәл бер сурәтен, гәүдәсен күз алдыбызга китереп бастыра алабыз.

6) Язу – кеше хәтеренең иң көчле бер ярдәмчесе.

Хәзерге чиксез киң бер мәдәният гасырында без ялгыз хәтер көчебез белән генә бернәрсә дә эшли алмас идек. Булса да, бик аз гына нәрсәләрне саклап бара алган булыр идек. Хәзерге заманның фәннәрен, сәнгать вә әдәбиятларын, иҗтимагый вә сәяси хәлләрен, эшләп чыгаручылык вә сәүдә мөнәсәбәтләрен вә башка шундый хәлләрне бер уйлап карасак, без монда тәмам ис китеп, аптырап торырлык нәрсәләр күрәбез. Болар бит саннан ашкан чиксез тәҗрибәләр, хәтта үзләренең бөтенләй үлчәүләрен югалткан чиксез бер белем диңгезләреннән гыйбарәт булган нәрсәләр. Шуның өстенә тагын болар хәзерендә үзләрен иң ачык һәм иң туры вә тулы бер рәвештә аңлатылуларын таләп итәләр.

Менә шуларны нинди бер адәмнең хәтере күтәрә алу ихтималы бар? Әлбәттә, юк. Бөтенләй һәммәсен үзендә саклап, һичбер үзгәртмичә, яңлыштырмыйча шуларны үзендә урынлаштырып, югалтмыйча тота алу – бу адәм хәтере булдыра ала торган бер нәрсә түгел.

Менә шунда инде кешенең хәтеренә көчле бер ярдәмче булып язу килә. Язу кешеләргә шушы чиксез күп, чиксез зур фикри-мәдәни байлыкларны, шушы гаять күп тармаклы мәдәни мирасларны саклый бара. Шуның өстенә ул шул ук вакытта аларны яхшылап тикшерергә, аларны төрле яктан аралап карарга да күп имкян бирә. Ягъни кеше язу аркасында шушы чиксез бер мәдәни байлык эченнән хәзерге вакыты өчен үзенә кирәк булганнарны алып табып, шуларны үзенә сайлап ала ала.

Шуның өчен дә без, халыкларның мәдәни тарихларын тикшергәндә, менә нәрсәне күрәбез: һәр халыкның мәдәни күтәрелеше, мәдәни тәрәккыйсе аның язуының тәрәккыйсе белән әһәмиятле

[1] Васита – арадашлык.

бер дәрәҗәдә бергә багланып килә. Кайсыбер халыкның язу системы тагын да тәрәккый иткән, тагын да камилләшкән булса, аның үзе дә шулкадәр артык мәдәниятләшкән, фикри-мәдәни тәрәккый дә шулкадәр югары күтәрелгән була. Шулай ук, киресенчә, бер халык никадәр аз мәдәниятле яки мәдәнияттән түбән булса, аның язу системы да шулкадәр түбән бер дәрәҗәдә тора.

Һәр заманда, һәркайда язуга ия булган халыклар язуга ия булмаган халыкларга караганда бик тизлек белән үзләренең зур вә киң бер мәдәни югарылыкларын күрсәтә килгәннәр. Язулы халыкларның язусыз халыкларны үзләренә буйсындырып, кол итеп килүләре дә – тарихта ачык бер факт.

Хәзерге гасырыбызда язусыз, әлифбасыз, әдәбиятсыз мәдәният дигән нәрсәне хәтта уйлый да алмыйбыз. Болар, ягъни язу белән мәдәният бер-берсенә шулкадәр нык багланып йөриләр. Язусыз, әдәбиятсыз халык хәзердә мәдәни бер халык дип саналмый да. Хәзердә бер халыкның мәдәнилеге, аның фикри-мәдәни тәрәккыйсе бармы-юкмы икәнлеге иң элгәре аның язуы, әдәбияты белән үлчәнә.

Язуның югарыда алты маддәгә аерылып бәян ителгән шушы хосусиятләре аның кешелек дөньясында нинди зур бер роль уйнап килгәнлеген, киләчәктә янә ул үзенең шушы роль вә хезмәтен тагын да зурайта вә киңәйтә барачагын безгә яхшы ук ачып биргән булса кирәк.

Инде аның тарихи ягына күчәбез. Соң, бу кадәр зур файдалы, бу кадәр кыйммәтле бер мәдәният коралы яки васитасы ничек итеп табылган? Аны башта кемнәр башлап чыгарган? Хәзерге шушы камилләшкән бер хәленә җиткәнче, ул нинди бер дәверләре, нинди бер тәрәккый баскычларын үткәрә килгән? Хәзерге гарәп һәм Шәрык язуларының төп анасы, төп тамырлары кайда? Кемнәр, кайсы мәдәни халыклар ул тамырлардан үзләренең язуларын үстереп алып киткәннәр?

Инде менә шуларны бер тикшереп күрик.

**Кешелек дөньясында язусызлык дәвере.** Кешелек дөньясы әллә ничә меңьеллык озак бер язусызлык дәверен үткәргән. Хәзерге заманыбызда язуга ия булган халык вә кавемнәрнең һәммәсе шушы куркыныч, караңгы дәверләрне башларыннан кичергәннәр. Хасил, бөтен җир йөзендә язу дигән нәрсәнең, язу сәнгатенең нәрсәдән гыйбарәт булганын һичкем белмәгән бик озак заманнар булып үткән.

Язуның нәрсәдән гыйбарәт икәнен һич белмәгән шундый халыклар хәзерге шушы искиткеч бер мәдәният заманында да җир йөзендә бар әле. Урта Африкадагы вәхшиләр – зәнҗиләр, америкалы һиндиләр, австралиялеләр – шундый халыклардандыр. Болар арасында бәгъзеләре язу дигәннең ни икәнен дә белмиләр. Язуны күргәннәре, аның турысында аз-маз ишеткән-белгәннәре дә язуны әллә нинди бер тылсым, әллә нинди бер сихер вә могҗиза дип таныйлар һәм аннан куркалар, шомланалар. Хәтта менә нинди бер вакыйга булган: бер заманны Африкада бер зәнҗи кич белән бер немец офицерының фатирына барып керә. Кергәч тә, ул өстәл өстендә бер китап ятканын күрә. Ниһаять, шуны күрү белән, зәнҗи, уйлаган эшен башкара алмыйча, китаптан куркып, кире борылып чыгып китә. Ул китапны, үзенең угрылыгын күреп, үзен тоттырыр дип уйлаган була.

Бу турыда тагын менә шундый бер кызык вакыйга була: җәнүби[1] америкалы бер һиндинең хуҗасы үзенең бер дустына әлеге колы һинди аркылы бер кәрзинкә җимеш һәм шуның белән бергә бер хат биреп җибәрә. Һинди, юлда барганда, әлеге җимешләрне бераз ашап ала. Һинди, җимешләрне тиешле кешесенә илтеп, каршысына җавап хаты алып килә. Хатта кәрзинкәдә җимешләрнең кимегәнлеге әйтелгән була. Хуҗасы, моннан һиндинең җимешләрне ашаганын белеп, моның өчен аны каты орыша. Һинди исә үзенең җимешләрне ашаганлыгын шушы үзе белән бергә хуҗасына алып килгән кәгазь әйткән икән дип уйлый. Икенче шундый бер йомыш белән барганда инде, һинди, кәгазьне яшереп, бер җиргә күмеп куярга карар бирә. Һинди бервакыт тагын шундый бер йомыш белән җибәрелә. Хәзер инде һинди бу юлы алданмаска уйлый. Иң элгәре кулына бирелгән кәгазьне – язуны – зур бер таш белән бастырып, аны таш астына яшереп куя. Шуның белән һинди үзенең җимешләрне ашавын кәгазь инде күрмәс дип ышанган була. Җимешләр тагын бераз ашалалар. Һинди хуҗасына тагын җавап хаты алып кайта. Хуҗасы хат аркылы һиндинең тагын җимешкә хыянәт иткәнен белеп, бу юлы инде һинди хуҗасыннан таяк җыя. Менә шунда инде һинди, бу эшкә берни дип тә мәгънә бирә алмыйча, моңа тәмам шашып, аптырап кала. Шулай да, каты таяк җыйганнан соң, һинди язуның нәрсә икәнен аңларга бераз якынлашкан була.

Шуның өстенә, сәяхәтчеләрнең сүзләренә караганда, Урта Африканың вәхши адәмнәре бер-берсеннән ерак булган кешеләрнең

[1] Җәнүби – көньяк.

язу, ягъни төрле сызыклар белән чуарланган бер кәгазь аркылы берберләренә фикерләрен аңлатышуларын күргән һәм шуны белгән чакларында тәмам аптырашта калалар икән. Мондый чуарланган кәгазь әле аларны гаҗәпсендереп кенә калдырмый, бәлки шуның белән бергә аларда әллә нинди бер курку да тудыра; алар шул кәгазьнең эчендә табигатьтән өстен әллә нинди бер яшерен көч, әллә нинди бер рух та бар дип белә һәм ул рух кәгазьнең иясе үзенә әйтеп торырга кушкан һәммә нәрсәләрне аңа әйтеп, хәбәр биреп тора, дип ышаналар икән.

Югарыда язылып үткән Җәнүби Америкадагы вакыйга да менә шуны тасдыйк итә[1].

Менә тагын характерлы бер вакыйга: Шимали[2] Америка вәхшиләре беренче мәртәбә яурупалылар тарафыннан китерелгән язуны күреп, шуның мәгънәсен аңлаганнан соң, шушы язуның кәгазен «сөйләүче» дип атаганнар, кәгазьгә җанлы бер нәрсәгә караган кебек караганнар. Аны ишетә, күрә, сөйли дип белгәннәр. Кәгазьдән берәр нәрсә ишетү, аның сүзләрен үз колаклары белән тыңлау өчен, кайдандыр язылган бер кәгазь кисәкләрен табып алып, шуларны колакларына куйганнар, шул кәгазь кисәкләреннән үзләренә берәр нәрсә сөйләүне сораганнар. Фәкать күп вакытлардан соң кәгазьне сөйләтү өчен аны кулга төшерү белән генә булмый, бәлки моның тагын нindидер башка бер сере булып, моның өчен шуны белергә кирәк икәненә ышанганнар.

Язу явыз рухларның явызлыгыннан саклый дип, муеннарына яки берәр әгъзаларына язулы, сурәтле кәгазьләрне «бөти» (тумар) итеп тагып йөрүчеләр дә юк түгел. Без дә әле күптән түгел генә каты хөкем сөреп килгән «бөти тагу» (түбәтәй эченә яки култык астына), тарелкага «бүсер» сурәтләре яздырып, шуларны чайкап эчү кебек гадәтләр дә шундый дәвердән калган мираслар булган булса кирәк.

**Язу кайчан һәм ничек туды.** Язуның башлануы һәм аның җир йөзендә беренче мәртәбә күрелүе тарихтан элек булган бик ерак вә томанлы бер заманнарга барып терәлә. Шуның белән бергә язу кинәттән һәм бердән уйланып чыгарылган бер нәрсә дә түгел. Ул бик озак заманнар буенча сузылып килгән күп ачы тормыш тәҗрибәләренең нәтиҗәсе булып, бик әкренлек белән генә туган һәм бик әкренлек белән генә тәрәккый итә килгән.

[1] Тасдыйк итә – раслый.
[2] Шимали – төньяк.

Язуны бер генә кеше уйлап чыгармаган. Ул бер генә кешенең шәхси, хосусый бер иҗаты түгел. Ул – бөтен кешелек җәмгыятьләренең коллективлы бер хезмәт нәтиҗәсе. Моның өчен кешеләр бик күп, бик кыен бер коллективлы хезмәтләр куйганнар. Язуның башлануы шулай булган шикелле, аның соңгы тәрәккый дәверләре дә шундый коллективлы бер хезмәт юлы белән барган.

**Язуның тууына нәрсәләр сәбәп булды.** Язуның тууында менә шундый сәбәпләр булган дип уйлана:

1) Хәтер эшләрен җиңеләйтү өчен, аңа ярдәмчеләр эзләү, хәтерләткечләр табу.

2) Иҗтимагый мөнәсәбәтләрне җиңеләйтү.

3) Үзеңнән озакта, еракта булган кешеләргә белгән, күргәннәреңне, фикерләреңне аңлатырга һәм шуларны үзеңнән соңгыларга саклап калдыра барырга теләү.

4) Үзенең рәхәте, кызыгы-ләззәте өчен яки шулар белән башка нәрсәләрне бизәкләү, матурлау өчен кешедә һәрвакыт чолгап, әйләндереп алган нәрсәләрнең рәсемнәрен төшерергә, шуларның сурәтләрен алуга җилкенеп торучылык табигате.

Кешелек дөньясында тереклек, тормыш башта бик катлаусыз, бик тар вә гади бер рәвештә булган, үзе аркылы алынган тәҗрибә вә белемнәр бик аз булганнар, андый бер тормыш эчендә күргән, белгәннәрне һәм ул тормыш аркылы алынган тәҗрибә вә белемнәрне онытмыйча саклый бару да артык кыен бер эш булмаган. Боларны ялгыз хәтер көче белән генә дә саклап бара алырга мөмкинлек табылган.

Ләкин кешелек тормышы мондый тар, мондый җиңел бер рәвештә генә тукталып кала алмаган. Ул, киткән саен, һаман катлауланганнан-катлаулана, авырайганнан-авырая барган. Бара торгач, ахыр чиктә, белгән вә күргәннәрне, тормыштан алынган белем вә тәҗрибәләрне, хасил, хәтердә тотарга тиешле булган барлык нәрсәләрне ялгыз хәтер көче белән саклап тота алу мөмкин булмый башлаган. Моның өчен башка бер төрле юллар, башка бер төрле чаралар, ярдәмчеләр кирәк булган. Бу турыда хәтергә ярдәм итү өчен искәрткечләр, хәтерләткечләр табарга ихтыяҗ төшкән.

Моны ачык аңлау өчен алыйк, мәсәлән, кешелек җәмгыятьләренең төрле дәвер вә төрле баскычтагы тормышларын.

1. Башлыйк вәхши бер аучылык тормышыннан. Менә аның һәм дә андый бер кәсеп белән яшәүче бер кечкенә җәмгыятьнең

тереклек юлы – бик тар, бик җиңел вә гади бер нәрсә. Мондый бер тормыш үзе өчен күп нәрсәләр булуны, күп тәҗрибәләр җыйнауны таләп итми.

Әмма инде күчмә тереклек белән яшәүче чарвачылар (хайван асраучылык белән яшәүчеләр) тормышын алсак, бу тормышның инде вәхшиләрнекенә караганда күп кыйналышканын, күп катлауланганын күрәбез. Бу баскычтан күчеп, игенчелек белән яшәү баскычына җиткәч, монда тереклек тагын да читенләшә, чарвачыларныкына караганда күп катлауланып өлгергән була. Моннан да күтәрелеп, шәһәр тормышына килсәк, менә монда инде иҗтимагый, икътисади вә мәдәни тормыш игенчелек белән яшәүгә караганда әллә никадәр мәртәбәләр артык бер рәвештә катлауланган, авырайган була. Бара торгач, авыл тереклеге белән шәһәр тереклеге арасында бик күп аерма булып китә. Шәһәрдә һөнәр, шәһәрдә төрле сәнәгать, шәһәрдә һәртөрле иҗтимагый эшләр, һәртөрле эшләп чыгаручылык хезмәтләре вә мөнәсәбәтләре шәһәрне авылдан бөтенләй аерып ташлый. Бу бик табигый дә. Чөнки кайда кеше күп булса, шунда тереклек юлларының катлаулануы – зарури бер нәрсә.

Шул рәвешчә ничә мең еллар үтеп китә. Кешелек дөньясында һәрбер кешенең шәхси тереклеге дә, бөтен бер кешелек берләшмәсенең бергәлек тормышы да киткән саен һаман катлауланганнан-катлаулана, кыенлаша бара. Күргән-белгәннәрне, белем вә тәҗрибәләрне хәтер көче белән генә саклап булмый башлый. Хәтернең бу турыда көче җитмәгәнлеге күренә.

Ниһаять, кешелек дөньясы хәтер эшләрене җиңеләйтүнең чараларын эзли башлый. Төрле искәрткеч-хәтерләткечләр табып чыгара.

Мондый чараларның яки мондый хәтерләткечләрнең дә беренчесе төрле каһарманнар исеменә ясалган төрле һәйкәлләр, текелмәләр була. Бу һәйкәлләр, билгеле, башта ялгыз гади бер таш яки туфрак вә балчык өемнәреннән генә гыйбарәт булып, хәзерге заманда камилләшкән бер рәвешләрене алар күп заманнар буенча сузылып килгән тәрәккыйләре нәтиҗәсендә генә казана алалар.

Менә бу дәвер язу сәнгатен табу юлында, бәлки, иң беренче баш адым булгандыр.

2–3. Кешеләр үзләренең мәдәни тормыш кичерә башлаган дәверләренең иң баш ягында бер-берсеннән аерым вә тәмам мөстәкыйль булган вак-вак бер төркемнәрдән гыйбарәт булганнар. Иҗтимагый

тормыш әле төзелмәгән, тәшкил ителмәгән булган. Эшләп чыгаручылык мөнәсәбәтләре дә иң башлангыч бер тәрәккый баскычында торган.

Менә шуның өчен дә ул вакытларда язуның кирәклеге һич сизелмәгән дә, чөнки азсанлы булган шушы кешелек төркемнәре әгъзаларының үз араларында бер-берсе белән аңлашу, фикер алышулары өчен тел-сүздән башка бер васита – язуга ихтыяҗ һич күрелмәгән. Һәртөрле иҗтимагый мөнәсәбәт шуның белән үтәлә алган. Башка төркемнәр белән һичбер төрле иҗтимагый мөнәсәбәт булмаган. Алар белән һичбер төрле иҗтимагый эш итәргә туры килмәгән. Вә гомумән, ул кешелек төркемнәреннән иҗтимагый һәвәс[1], иҗтимагый мәнфәгать дигән нәрсәнең юклыгы, аларга язусыз да яши алырга тәмам имкян биргән.

Әмма инде бара торгач, хәлләр, әлбәттә, үзгәргән. Кешеләр инде бергә оешып яшәргә, иҗтимагый тормышны киңәйтергә мәҗбүр булганнар. Шуның файдасын да яхшы аңлый башлаганнар. Шуның нәтиҗәсендә аерым вак төркемнәр, бер-берсе белән кушылып, тагын да зуррак төркемнәргә әйләнә барганнар. Зур гына бер җәмгыять хәлендә оеша башлау юлына кергәннәр. Аерым төркемнәр, аерым вак ыруглар арасында бер-берсе белән бәйләнеш вә төрле иҗтимагый мөнәсәбәтләр хасил булган. Үзләрен дошманнарыннан саклау, уртак көч белән нәрсә эшләп чыгару, сәүдә мөнәсәбәтләре вә гаиләви хәлләр кебек төрле иҗтимагый мәнфәгатьләр туган.

Менә шушы вакытларда озак мәсафәдәгеләр[2], ягъни үзләреннән еракта булган кешеләр вә төрле халыклар белән фикер алышу, аңлашуның һәм арадагы мөнәсәбәтләрне җиңеләйтүнең берәр төрле юлын, чарасын табуны кирәксенү туган.

Шуның өстенә белгән-күргәннәрне, тормыш юлында хасил ителгән тәҗрибәләрне югалтмыйча саклап бара һәм шуларны яшь буыннарга күчерү һәвәсе дә кузгала башлаган.

Ахырда, шулай итеп, менә шушы кирәксенү, шушы һәвәс вә сизенү нәтиҗәсендә язу сәнгатен тудыру юлында төрле хәрәкәтләр башланып китkән.

4. Язуның тудырылуы турысында дүртенче сәбәпне менә болай изах итә[3] алабыз: кешенең табигатендә шундый бер төп хосусият

[1] Һәвәс – омтылыш.
[2] Мәсафәдәгеләр – ераклыктагылар.
[3] Изах итә – аңлата.

бар. Ул я үзенә эшсезлектән килгән бер эч пошуны югалту яки шуннан үзенә бер кызык, бер ләззәт вә рәхәт табу яисә үзләре белән төрле нәрсәләрне матурлау вә бизәү өчен даимән үзенең тирәсендә булган һәм үзен чолгап алган матди нәрсәләрнең рәсемнәрен, сурәтләрен төшерергә җилкенеп, шуңа кызыксынып тора.

Кешенең табигатендәге менә шушы хосусият иң борынгы адәмнәрне дә үз юлы белән хәрәкәт иттереп җибәргән. Алар шуның сәбәпле төрле нәрсәләрнең рәсемнәрен, сурәтләрен ясый башлаганнар.

Рәсемнәр, сурәтләр ясау исә чын язуга якынлашуның иң зур бер адымы булган (моны түбәндә янә ачыграк, киңрәк аңлаячакбыз).

## Язуның дәверләре һәм үткәргән баскычлары

Язу тудыру юлында төрле дәверләр кичерелгән, төрле баскычлар үтелгән. Бу дәвер вә баскычларны без иң элгәре икегә аерып тикшерә алабыз: 1) чын язу тудыруга хәзерлек баскычы – әйберләр аркылы фикер аңлатышу дәвере; 2) чын язу тудыру юлына күчү дәвере. Беренче дәвер әйбер язуы – предметное письмо[1] дәвере дип аталып, икенче дәвер сызык язуы дәвере дип атала. Сызык язуы үзе дүрт баскычка бүленә: 1) рәсем язуы (живописное письмо[2]), 2) сурәтле-фикерле иероглиф[3] язуы (фигурально-иероглифическое письмо[4]), 3) чөй язуы (клинопись[5]), 4) әлифба язуы (алфавитное письмо[6]).

**Әйбер язуы.** Кешеләр онытмаска тиешле нәрсәләрне истә саклау турысында хәтергә ярдәм күрсәтү өчен төрле әйберләрдән файдаланалар. Әйберләр алар өчен иң яхшы бер хәтерләткеч булганнар. Үзләренең уй-фикерләрен үзләреннән башкаларга, озакларга ирештерү өчен дә алар әйберләрне васита иткәннәр. Фикерләрен төрле әйберләр аркылы аңлатырга теләгән һәм аңлатканнар.

Шундый язуларның хәзерге вәхши халыкларда берничә төрлесе бар.

---

[1] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*
[2] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*
[3] Чыганакта бу сүз «һияроглиф» вариантында бирелгән. Текстны уку өчен җиңеләйтү максатыннан, биредә һәм алга таба «иероглиф» дип бирү уңышлырак булыр дип табылды.
[4] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*
[5] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*
[6] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*

Шулар эченнән бөтен бер системалысы «төен язуы» (квипос[1])тыр. (Таблицадан кара. 3 нче рәсем). Бу систем язуны иң борынгы бер заманнарда иранлылар, кытайлар һәм перулылар – ацтеклар (ацтеки[2]), ягъни Америкада Перу вә Мексиканың иң борынгы халыклары кулланганнар. Бу язуның иң күп тәрәккый итүе дә ацтекларда булган.

Бу язу шуннан гыйбарәт: таяк яки дилбегә шикелле өфкый[3] бер җеп, менә шуңа әллә никадәр текә (гомуди) җепләр тагылган. Болар үзләре һәртөрле рәвештә төрле озынлыкталар һәм төрлечә төенләнеп, үрелеп беткәннәр.

Ацтеклар бу төен язу белән ялгыз нәрсәләрнең саннарын истә тоту өчен генә файдаланмаганнар, бәлки алар аркылы һәртөрле мәгълүматны, солых шартларын да теркәп куйганнар. Бу гына түгел әле, хәтта шуның аркылы бөтен бер тарихи вакыйгаларны, Мексика патшаларының кылган эшләрене вә шулар турындагы төрле риваятьләрне, хәбәрләрне аңлатканнар. Шулар өстенә бу язу аркылы һәртөрле хөкүмәт боерыкларын вә хәтта үзләренең җырларыны аңлаткан икәнлекләре дә уйлана. Бигрәк тә сәяхәтче Чуди[4] шулай фараз итәдер.



1 нче шәкел. *Төен язу*[5]

Фәкать бер вакыйганы теркәү өчен булганда, бу төен язуының җөйләре, төеннәре төрле төскә, төрле буяуларга буяла торган булган. Һәрбер төс үзенә махсус мәгънәне аңлаткан. Мәсәлән, кара төстәге җеп – гадәттә, үлемне, бәхетсезлекне; кызыл төстәгесе – сугышны, гаскәрләрне; ак төстәгеләре – солыхны, татулашу, дуслашу һәм килешүне яки көмешне; сары төстә булганнары – алтынны, күк төслеләре икмәкне вә

[1] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*
[2] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*
[3] Өфкый – горизонталь.
[4] Иоганн Якоб фон Чуди (1818–1889) – швейцарияле натуралист һәм сәяхәтче. 1838–1843 елларда Перуга сәяхәт кыла. 1857–1859 еллар арасында Бразилия һәм Көньяк Американың башка илләрендә була.
[5] Бу һәм алдагы битләрдә бирелгән рәсемнәр Г. Сәгъдинең 1926 елда нәшер ителгән оригинал басмасыннан алынды.

илх[1] аңлаталар. Төеннәр, янә үзләренең урыннарына карап, төрле мәгънәләргә малик[2] булганнар. Мәсәлән, төеннәр җепләрнең никадәр югары бер урынында булсалар, бу әлеге җепләр аркылы аңлатылган вакыйганың тагын да җитди һәм аның тагын да мөһим икәнлегенә галәмәт булган.

Әгәр дә бу язуда җепләр буялган булмасалар, алар күп вакытта саннарны, хисап эшләрен теркәү өчен кулланылганнар. Мәсәлән, бер катлы җеп – гадәттә, 10 ны, ике катлы җеп – 100 не, өч катлысы – 1000 не аңлаткан. Бер катарда[1] торган бер катлы җепләр ничәү булса, алар шулкадәр дә унны, бер катардан бердән артык торган ике катлылары тагын шулкадәр унны белдергәннәр вә илх.

Ләкин перулыларда бу төен язуларын уку өчен махсус укымышлы бер сыйныф булган, болар «төеннәрнең түрәләре» дип аталганнар, бу түрәләр шул ук вакытта әлеге язуларны тудыручылар һәм шуларны саклап килүчеләр булганнар.

Хәзердә дә бит бездә бәгъзе сәвадсыз кешеләрнең, хосусан хатын-кызларның, базарга чыкканда алырга тиешле нәрсәләрен яки башка бервакытта исләренә төшерү кирәк булган нәрсәләрне җиңелрәк хәтерләү өчен, яулыкларына төрле рәвештә берничә төеннәр төенләп куйганлыкларын сөйлиләр. Менә хәзерге шушы хәлләрне безгә төен язуының кардәшедер дип уйларга юл бар. Чыннан да, бәлки, ул – шул төен язуының дәвамыдыр, шуның калдыгыдыр. Бәлки, бу – язуның, чыннан да, үткәндә тарихи бер әсасы[2] булгандыр.

Әйбер язуларыннан берсе янә каек язуы (раковинное письмо[3])дыр. Бу да бер җепкә яки бер чыбыкка төрле рәвештә төрле зурлыкта вә төрле төстә булган бака кабыкларыннан тезелеп оештырылган бер язудан гыйбарәт (2 нче рәсем.)



2 нче шәкел

[1] Илх – илә ахриһи – һәм башкалар.
[2] Малик – ия.
[1] Катарда – сафта, рәттә.
[2] Әсасы – нигезе.
[3] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*

Бу язу бигрәк Шимали[1] Америка һиндиләренең бәгъзе кабиләләрендә (ирокез, алгонкин, гурон кеби кабиләләрдә) таралгандыр.

Төен язуындагы кебек монда да әлеге чыбыкка яки җепкә тезелгән кабыкларның төрле мәгънә аңлатулары аларның рәвешләренә, зурлыкларына, төсләренә һәм алган урыннарына карап йөртелгән, мәсәлән, ак төстәге кабыклар – гадәттә, солых, татулык һәм тынычлыкны; кызыл төстәгеләр – сугышны, галәбәне[2]; каралары – үлемне, бер күңелсезлекне, мәгълүбиятне[3] аңлатканнар.

Шушы кабык язуы белән дә төрле вакыйгалар аңлатылган, могаһәдәләр[4], солыхнамәләр ясалган. Бу язуны уку һәм аларны саклый бару өчен дә төен язуларыныкы кебек махсус кешеләре булган. Бәгъзе кабиләләр бу язуларны бик нык җыеп саклап барганнар. Әлеге Шимали Америка һиндиләренең кабык язулары кабиләләрнең бәгъзе бер тантаналы вакыйгаларында шушы язулар сакланган җирләреннән халыкка күрсәтелә һәм әлеге үзләрен белүче укымышлылар шуларны укып, шулар аркылы аңлатылган вакыйга вә хәлләрне халыкка сөйләп бирә торган булганнар.

Әйбер язулар катарында тагын кешеләрнең башкаларга фикер вә максатларын хайваннар, кошлар аркылы аңлатканлыкларын да әйтеп үтәргә кирәк. Мәсәлән, борынгы мәшһүр юнан тарихчысы Геродотның[5] бәянына караганда (моны Геродоттан Вуттке белән Р. Андре[6] күчерә[7]). Иран патшасы Дараның[8] таләбенә каршы шуңа җавап уларак скифлар Дарага берничә хайваннар, кошлар җибәргәннәр. Бу да шул рәвешчә була: Дара скифларның үзенә һич кичекмәстән мотлак буйсынуларын таләп итә. Скифлар шуңа каршы Дарага бер кош, тычкан, бака һәм биш данә ук җибәрләр. Дара да менә болардан шушы мәгънәне укып аңларга тиеш була: «Иранлылар, әгәр дә сез кош булып әверелеп, кошлар шикелле күккә очып менмәсәгез, әгәр

[1] Шимали – төньяк.

[2] Галәбәне – җиңүне.

[3] Мәгълүбиятне – җиңелүне.

[4] Могаһәдәләр – килешүләр.

[5] Геродот (б. э. к. 484–425) – борынгы юнан тарихчысы, б. э. к. 500–449 елларда грек-фарсы сугышлары турындагы әсәр авторы. Алга таба «Тарих» дип аталган һәм тугыз китапка бүленгән бу әсәрдә Геродот, күптөрле чыганакларга (шәхси күзәтүләре, күреп белүчеләрнең сөйләүләре, риваятьләр һәм легендалар, төрле язма чыганаклар) нигезләнеп, төрле илләрнең географик урыны, иктисади һәм сәяси тормышы үзенчәлекләре, аларда яшәүчеләрнең дине, гореф-гадәте һәм йолалары турындагы мәгълүмат бирә.

[6] Рихард Андре (1835–1912) – немец географы һәм этнографы.

[7] Карл Вейле. «От бирки до азбуки». Русча тәрҗемәсе, б. 35. *(Авт. иск.)*

[8] Дарий I – Әхәмәниләр дәүләте патшасы. Б. э. к. 22–486 елларда идарә иткән.

дә сез тычкан шикелле җир астына качып котыла алмасагыз яки сез бакалар шикелле суга, сазлыкларга яшеренмәсәгез – бу тәкъдирдә сез безнең укларыбыз тарафыннан җиңелерсез һәм үз җирегезгә борылып кайта да алмассыз».

Гобрий дигән галимнең бу язуны аңлатып бирүе менә шулайдыр[1].

Әйбер язуның тагын шундый төрлесе дә булган: борынгы юнаннар, скандинавиялеләр һәм эслаулар[2] үзләренең фикерләрен агач таякларга, такта кисәкләренә эшләнгән һәртөрле ырмаулар, киртекләр аркылы аңлатканнар.

Хәзердә дә Олы Русиядә язу белмәгән бәгъзе бер кара авылларда, вак һөнәрчеләр, тегүчеләр, осталар кешеләрдән нәрсәләрне төзәтергә, эшләп бирергә алган чакларында, әлеге нәрсәләр башкаларныкы белән яңлыштырылмасын өчен һәм ышаныч язуы итеп, кечкенә бер агач таякны ырмаулап, киртекләп, гүя бер квитанция рәвешендә шул нәрсәләрнең иясенә бирү гадәтләре булганын сөйлиләр[3]. Бу киртләчле агачларның берсе нәрсәләрнең ияләренә бирелсә, берсе дә һөнәрченең үзендә кала икән[4]. Шулай ук хәзер дә, үзләренең җирләрен башкаларныкыннан аеру өчен, ул халыкларның җирләрене чикләү-межалаулары, шунда үсеп утырган агачларны киртләчләп тамгалап куюлары да шундый язулар җөмләсеннән. Бу да хәтергә ярдәмче бер искәрткеч булып йөртелә.

Сибирия тунгуслары, ерак бер юлга киткәндә, кайсылай булса да бер якка кыйшайтып, карга бер таяк кадап китә, һәм аның кардәше, шуңар карап, бик тизлек белән һич яңлышмыйча, аның кай якка таба киткәнен әлеге таяктан укып белә икән.

Вәхшиләр, хайваннарның тәннәрен көйдереп, аларга тамга салалар яки хайваннарның колакларын кисеп тамгалыйлар. Менә бу да үзенә бертөрле хәтерләткеч, үзенә бертөрле язу булып килгән. Хәтта бу эш хәзерге мәдәни халыкларда, хосусан Русиядә авыл халыкларында да дәвам итә. Янә авылларда хәзерге заманыбызгача дәвам итеп килгән «приговорга тамга салу» яки «кул кую», ягъни кәгазьгә бармаклары белән бар кулыны төшерү юлы бар (үзбәкләрдә бигрәк тә шулай). Бу әйбер – язу катарыннан булган бернәрсә.

[1] Шул ук әсәр, шул ук бит. *(Авт. иск.)*

[2] Эслаулар – славяннар.

[3] В.А. Правдолюбов. История письма. 21 б. *(Авт. иск.)*

[4] Татар-башкортларда һәм русларда хосусан җеп буятырга биргәндә шулай итәләр. Киртелеп бирелгән агачка «җирәбә» диләр. *(Авт. иск.)*

Кешеләр бу рәвештә әйберләр аркылы ялгыз бик ачык, анык булган нәрсәләргә түгел, сыйрыф[1] нәзари аңнарны да аңлату юлына кергәннәр. Ягъни нәрсәләрне сыйрыф мәгънәви бер нәрсәгә рәмез[2] вә ишарә кылып алганнар. Суматра[3] атавындагы халыкларда хәзергә вакытка кадәр шул хәл дәвам итә. Мәсәлән, аларда бер кисәк тоз дуслык, татулык галәмәте булса, борыч та дуслык галәмәте булып йөртелә икән.

Борынгыдан сугыш коралларының сугышка, сугыш игълан итүгә галәмәт булулары да шул җөмләдәндер. Мәсәлән, борынгыда бер халыкның үзе белән сугышырга теләгән икенче бер халыкка сугыш кораллары җибәрүе аңа каршы сугыш игълан итүе дип аңлана торган булган.

Борынгы кытайлар үзләренең төен язулары дәверендә һәрвакыт төеннәрне чишү өчен билләрендә мөгездән ясалган без йөрткәннәр. Бу без, үзенең гамәли әһәмиятен югалтканнан соң, шушы безгә ия булган кешенең катлаулы, серле вә буталчык һәртөрле мәсьәләләрне хәл итә ала икәнлегенең бер галәмәте, шуның бер рәмезе рәвешендә аңлана торган булган.

Әйберы язу бөтен төрләре белән хәзер дә бик күп Африка зәнҗиләре вә Америка һиндиләре арасында кулланылудан башка тагын Азиядә – Шимали Русиядә һәм Сибириядә яшәүче лопарларда[4], тунгус һәм якутларда да кулланыладыр. Хосусан, төен язуы, ырмау һәм киртекләр кебек язулар мондый мәдәни булмаган халыкларда әле һаман үзләренең борынгы куәтендә дәвам итеп киләләр.

Әйбер язуы дәверене хәзерге бөтен мәдәни халыклар да үз заманнарында башларыннан кичереп үткәннәр, әлбәттә. Чөнки кешеләр, әйберләр аркылы эш итә торгач, әйберләргә нинди дә булса бер билгеле мәгънә бирергә, алар аркылы билгеле бер мәгънә аңларга өйрәнә башлаганнар. Бу исә аларга, саклык белемнәр һәм җыелган тәҗрибәләреннән файдаланып, язуның икенче бер тәрәккый баскычына ашуга имкян биргән. Ниһаять, кешеләр бу дәверне үткәреп, сызык дәверенә килеп ирешкәннәр, инде шушы икенче тәрәккый баскычына аяк басканнар. «Әйбер язуы» дәвере кешеләрне әнә шуңа хәзерләгән. Әйбер язуының бөтен әһәмияте дә менә шунда.

[1] Сыйрыф – тулысынча.
[2] Рәмез – билге, символ.
[3] Суматра – Малайзиядәге утрау.
[4] Лопарлар – саам халкының әүвәлге атамасы.

**Рәсем язуы.** Кешеләр, әйберләр аркылы хәтерләренә ярдәм күрсәтеп, шулар аркылы истә тота торган нәрсәләрен истә тотып һәм үзләреннән озакта булган башка кешеләргә үзләренең фикер вә теләкләрен шулар аркылы аңлата торгач, инде икенче бер юлга керәләр, матди вә фикри тәрәккый инде аларны бу юлда икенче бер тәрәккый баскычына аштыра.

Инде кешеләр үзләренең фикерләрен аңлату һәм аны саклап бару өчен, әүвәлгечә, нәрсәләрнең турыдан-туры үзләрен кулланмый башлыйлар. Бәлки аларның сурәтләрен сызгалап төшереп, нәрсәләрнең үзләре урынына шуларны куллану юлына керәләр.

Бу дәвер, ягъни рәсем язуы дәвере кешеләрнең нинди дә булса берәр төрле очлы, үткен нәрсәләр белән ташларга, агачларга, сөякләргә вә хәтта үзләренең тәннәренә төрле әйбернең сурәтләрене – рәсемнәрене төшерергә өйрәнгән заманнарыннан башланып киткән.

Рәсем язуы дигәнебез аерым-аерым фикерләрне, аңнарны, аерым-аерым җөмләләрне, гыйбарәләрне, бөтен бер хикәя вә риваятьләрне үзләренә муафикъ төрле рәсемнәр һәм әллә ничә төрле картиналар җыены аркылы аңлатудан гыйбарәт. Шуның өчен сызык язулар эчендә рәсем язуы – уку өчен иң кыен булган бер язу.

Бу язуның башланып китүе менә шулай булган: бик иске заманнардан башлап Америка, Австралия һәм Африка вәхшиләре, зиннәт, матурлык өчен, тәннәренә төрле буяулар белән бизәкләнгән төрле сын вә сурәтләр төшерә башлаганнар. Тиреләрен уеп, йөз, арка, күкрәк, кул вә аякларын шулар белән нәкышьләп, бизәп бетергәннәр. Гомумән, җир йөзендәге вәхши адәмнәрнең иң яраткан нәрсәләре – шул рәвешчә «тире уйма» (татуировка[1])[2] ясаудыр.

Хәзердә дә кайсыбер вәхшиләр, җөмләдән, мәсәлән, Америка һиндиләре бик матур итеперткычларның, кошларның, еланнарның һәм башка шундый җан ияләренең сыннарын, рәсемнәрен, тире уйма ясатып, тәннәренә эшләтәләр. Полинезия утрауларындагы вәхшиләрдә исә тире уйма дигән нәрсә хәтта искиткеч бер рәвештә тәрәккый иткән вә камилләшкәндер. Болар тире уйманы иң бала вакытларыннан башлап, шуны бөтен гомерләре буенча дәвам иттерә

[1] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*

[2] Тире уйма – татуировка ясау: тәнне яралап, тирене кисеп, шул урынга эстәгән бер нәрсәнең сурәтен, сынын буяп төшерү һәм шул рәвешчә тәнне нәкышьләү, бизәкләүдән гыйбарәт. Яра төзәлгәннән соң, әлеге бизәк кеше үлгәнче сакланадыр. *(Авт. иск.)*

баралар. Ниһаять, шуның нәтиҗәсендә бөтен тәннәре әллә ничә төрле сурәт вә бизәкләр челтәре белән капланып беткән була. Бу сурәтләр дә әллә ничә төрле буяулар белән бизәтелә. Бизәкләр янә (хосусан алдынгы халыкларында) чиктән тыш рәвештә назик, матур һәм нәфис итеп эшләнгән була.

Күп вакытларда шушы оригиналь тире уйма язуларны фәкать зиннәт, матурлык өчен генә эшләнгән нәрсәләр дип уйлаганнар. Аларны ясаудан бөтен максат ялгыз матурлану гына булган дип белгәннәр. Ләкин бу турыда мәсьәләне чынлабрак тикшереп караганнан соң, шуларны тикшерүче галимнәр тарафыннан боларның икенче төрле максатлары, икенче төрле бер мәгънәләре булганлык аңлашылды. Болар, ягъни бу тире уйма сурәтләр, галәмәтләр, матурлык өчен булу белән бергә, язу хезмәтен дә үтәгән икәнлекләре беленде. Боларның – бу бизәк вә галәмәтләрнең мәгълүм бер мөндәриҗәсе[1], аңлатырга теләгән рәмезле бер мөндәриҗәләре булган.

Җөмләдән, мәсәлән, бу тире уйма язуларда мәгълүм бер кабиләгә яки ыругка мәнсүб[2] булучылыкны (3 нче шәкел, 1 нче номер); ирнең хатынлымы, түгелме икәнен (3 нче шәкел, 2 нче номер), көчле бер рухның сурәтене һәм аның чиксез бер хакимиятенең рәмезле ишарәсене (3 нче шәкел, 3 нче номер), кяһиннарның[3] һәм мөкаддәс булган уен вә танса башлыкларының шул сыйфатларыны (3 нче шәкел, 4 нче номер), дошманнарга галәбә кылып, аларны җиңгәнлекне (3 нче шәкел, 5 нче номер) күрсәтә торган галәмәтләр шундый мөндәриҗәле галәмәтләрдәндер.



3 нче шәкел. *Австралиялеләрнең тире уймаларындагы галәмәтләр*

Болардагы бәгъзе сурәтләр иҗтимагый әхвәлне, ителгән хезмәтне, зур бер вакыйганы, сугышларны вә илх күрсәткәннәр. Хәтта үзләрендә сурәт вә галәмәтләр булган халыкларның тормышларында мөһим роль уйнаган бөтен бер вакыйга шулар аркылы тасвир ителгән.

[1] Мөндәриҗәсе – эчтәлеге.
[2] Мәнсүб – караган.
[3] Кяһиннарның – күрәзәчеләрнең.

Кыскасы, болар биографик бер документ һәм үзенең идеясе өчен махсус бер шаһәдәтнамә рәвешендә булганнар. Сер адәмнәре – кяһиннар – аның кемнәр белән эш иткәнлеген һәм үз алдында кемнәрне күреп торганлыгын аңа сөйләп торганнар.

Тире уйма – язу сәнгатенең тәрәккыйсе өчен язу тарихында мөһим бер роль уйганан. Ул, кешеләрне иң элек язу коралларына өйрәтү өстенә, аларны бигрәк тә үзләренең фикерләрене рәсем аркылы аңлата белүгә дә өйрәткән. Бу җәһәттән ул рәсем язуының беренче баскычы һәм кешенең тасвир куәтенең беренче тәҗрибәсе дип санала.

Кеше шуның аркылы әйберләрнең сурәтләрен – рәсемнәрен ясарга өйрәнә. Ахырда боларны да үзенең фикерләрен аңлату өчен бер васита итеп, аларны безнең хәзерге әлифбабыз урынына куллана башлаганнар. Үзенең бөтен бер фикерене аңлатмак өчен, шуңа муафикъ төрле рәсемнәр ясаганнар. Мәсәлән, үзен агач баскан бер адәмнең шушы хәлене аңлату кирәк була икән, моның өчен егылып яткан бер кеше һәм шуның өстенә егылган бер агач рәсемен төшергәннәр.

Бара торгач, тормышның мәҗбүр итүе белән кешеләр бу рәвештә фәкать күзгә күренеп торган конкрет нәрсәләрне генә түгел, бәлки сыйрыф гаклый[1] нәрсәләрне дә рәсемнәр аркылы аңлата башлаганнар. Мәсәлән, көч-куәт өчен – арыслан вә фил сурәте, итагатьҗанлык вә дуслык аңын бирмәк өчен дә эт сурәтен төшерү вә кебиләр шул җөмләдәндер.

Ниһаять, кешеләр «бәхет», «тормыш» дигән шикелле үзләрен аңлату иң кыен булган сыйрыф гаклый мәгънәләрне дә рәсемнәр аркылы аңлату юлын тапканнар. Тормыш үзе һәм һәртөрле тормыш мөнәсәбәтләре вә хосусан эшләп чыгаручылык мөнәсәбәтләре мондый аң вә мәгънәләрне аңлату өчен шарты булган махсус бер символ галәмәтләр эшләтеп чыгарткан. Болар башта бик кечкенә булган түгәрәктә тудырылып, шул түгәрәктәге кешеләрнең үзләренә аңлашыла торган билгеле бер мәгънәне аңлатканнар. Соңра бу галәмәтләр, баштагы әлеге тар бер түгәрәктән тышка чыгып, үзләренең шул мәгънәләрендә истигъмальләрен[2] киңәйтә һәм күпчелек малы булып әверелә башлаганнар.

4 нче шәкелдә Америка һиндиләренең картиналы язуларыннан алынган шундый символ – рәмезле мәгънәле рәсемнәр күрсәтеләдер. Монда: 1) мөгезле еланның хыялый сурәте һиндиләрдә «тормыш,

[1] Сыйрыф гаклый – тулысынча аң, акылга мөнәсәбәтле.
[2] Истигъмальләрен – куллану даирәләрен.




4 нче шәкел. *Һиндиләрнең картиналы язуларыннан берничә символ галәмәтләр*

хәят» мәгънәсен биргән, 2) «үлем» мәгънәсе нинди дә булса бер хайванның аяклары – югары, башы түбән булган хәлдә чалкан төшеп ятканын күрсәткән рәсем аркылы аңлатылган, 3) ташбака сурәте муаффәкыятьне[1] аңлаткан, 4) «җитезлек, җиңел сөяклелек» мәгънәсене куллары урынында канатлары булган бер адәм сурәте аркылы биргәннәр, 5) куллары берләштерелгән ике кеше дуслыкка ишарә булган, 6) бер-берсенә берләштерелгән ике йөрәк «мәхәббәт» мәгънәсен биргән, 7) трубкалы кеше «солых ясау, килешү, татулашу» мәгънәсен аңлаткан.

Һиндиләр менә шундый һәм шуңа охшаган сурәтләр аркылы бөтен бер вәкаигънамәләр язганнар. Мондый рәсемле картина язуның иң иске бер үрнәге Шимали Америка һиндиләреннән табылган. «Сихерче җыры» дигәннәре шундый язулардандыр (5 нче шәкел). Бу «сихерче җыры» әллә ничә төрле күп сурәтләрдән тора. Болардан һәрберсе җырның әллә ничә мәнзумә (тезмә)ләрен аңлата.




5 нче шәкел. «*Сихерчеләр җыры»ннан берничә галәмәт*

5 нче шәкелдәге беренче сурәт болай дип укылырга тиеш: «Менә мин хәзер Мәданың[2] сихри сүзләрен ишеткән (колаклардан килгән дулкынлы сызыклар), минем әйләнәмдә утыручы минем шикелле дусларым», икенче сурәт – судагы ташбака: «Бу сулар кем аркасында ага? Мәда аркасында агалар бу сулар»; өченче сурәт: «Карагыз миңа, Мәдага, минем дусларым, гади халык. Миңа сөальләр бирегез, минем дусларым»; 4: «Ә хәзер, минем сөекле дусларым, ике көн сез ураза тотарга тиешсез (корсакта ике сызык), ә дүрт көн тыныч утырырга

[1] Муаффәкыять – уңыш, уңайлык.
[2] Сихерче – кяһинның исеме. *(Авт. иск.)*

һәм урыннан кузгалмаска (аякларында дүрт сызык).

Рәсем язуы борынгы мәдәни халыклардан мисырлыларда бигрәк тәрәккый иткән булган. 6 нчы шәкел – шуларның картиналы рәсем язуларыннандыр. Моны шулай укырга кирәк: «Яшьләр һәм картлар, аңлагыз: Аллаһ җинаятьне, гөнаһны сөйми».



6 нчы шәкел. *Мисырның картина язуыннан үрнәк*

Монда 1) ир бала – моңа авызындагы бармагы күрсәтә; 2) карт – бөкрәйгән килеш таяк белән бара; 3) Алла – каракош. Бу – мисырлыларда аллалык символы; 4) дошманлык – балык. Бу – дошманлык символы; 5) җинаять, гөнаһ – бегемот (су айгыры). Бу – гөнаһ, канунсызлык символы.

Мондый картиналы рәсем язулары укырга иң кыен язулардан булган. Моны фәкать кяһиннар генә аңлый алган. Чынында болар язу булмаганнар, бәлки болар хәтер өчен мәгънә вә фикерләрнең ишарәләре, маяклары гына булганнар. Болар аркылы мәгънә, фикерләр бик кыенлык белән генә эзләнеп табылганнар.

Мондый язулар, күрелә ки, «җөмлә язуы» (письма фразами[1]) булганнар.

Моннан соң инде язу үзенең ролен тагын да арттыра барган. Рәсемнәр текстларның мөндәриҗәләренә һаман якынайганнан-якыная барган һәм аңа тагын да муафикъ була төшкәннәр. Шул рәвешчә, мәсәлән, инде нинди дә булса бер сурәт-рәсем бөтен бер мәнзүмәне яки бөтен бер җөмләне генә түгел, бәлки нинди дә булса билгеле бер аң вә тасвирны, бер сүзне аңлата башлаган.

Шулай итеп, ниһаять, җөмлә язуы яки фраза язуыннан сүзләр белән язуга күчелгән. 7 нче шәкелдә америкалы һиндиләрнең менә шундый укуга һәм



7 нче шәкел

[1] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*

аңлауга тагын да җиңелрәк булган язуларыннан сәүдә могаһәдәсе[1] күрсәтеләдер. Бу язуда инде без фикерләрнең үзара тагын да тәртипле һәм билгеле багланышлары белән тагын да ачыграк аңлатылганын күрәбез. Моның да мәгънәсе болай була: «Шуның белән таныклык бирәмен вә тәэкид итәмен[2] ки, 30 кондыз тиресе алмашына бер бизон (Америка кыр үгезе – вәхши үгез), бер кама, бер сарык алдым». Кондызга каратып куелган мылтык үтерелгән утыз кондызны яки кондыз тиресен күрсәтәләр. Уртадагы тәре сурәте дә алмашуны күрсәтә.

Менә шундый юл белән Шимали Америка һиндиләре үзләренең бөтен бер хәрби хәрәкәтләрен, сугыш сәфәрләрен дә тасвир итәләр. 8 нче шәкел шуны күрсәтәдер. Бу шәкелдә башлык (атта), барысы 51 гомуди[3] сызыклар белән биш көймә, күк гөмбәзләре астында өч кояш рәсеме (бу сугыш сәфәренең өч көнгә сузылганын күрсәтә), каракош, ташбака һәм ике хыялый хайван рәсеме: Берсе – пантера (эссе якларда була торган юлбарыска охшаган бер хайван), икенчесе мөгезле елан. Болары – сугыш сәфәрендә үзләрен химая итә[4] торган ике аллалары.

Бу рәсем язуы аркылы менә шушы мәгънә аңлатыла: бервакыт һиндиләрдән 51 кеше үзләренең башлыклары белән сугыш сәфәренә китәләр, сугыш өч көнгә сузыла һәм үзләре өчен бик уңышлы булып бетә (ташбака уңышлылыкны аңлата). Бу да, бер яктан, аларның батырлыкларыннан (каракош шуны аңлата) булса, икенче яктан да, аллаларның ярдәм вә химаяләре аркасында була (монда башлыкның атта күрсәтелүе – фәкать бер символдыр. Вәхшиләрдә кешеләргә хайваннар исеме куела. Бу хайван да башлыкның исеме булу ихтимал, яки ул шул хай-



8 нче шәкел. *Шимали Америка һиндиләренең сугыш сәфәрләрен тасвир*

[1] Могаһәдәсе – килешүе.
[2] Тәэкид итәмен – раслыйм.
[3] Гомуди – вертикаль.
[4] Химая итә – яклый.

ванның исеме белән аталган бер ыругка мәнсүбтер. Сугыш суда була. Шуның өчен башлык анда булган дип уйлап булмый).



9 нчы шәкел. *Шимали Америка һиндиләренең язуы*

Менә безгә тагын бик кызык рәсем язуы (9 нчы шәкел). Бу язу Шимали Америка һиндиләренең 1849 елда «Бөек ага»га, ягъни Шимали Америка җөмһүриятенең башлыгына бирелгән бер гаризадан гыйбарәт. Монда болар үзләрен Югары күлдән аның күршесендә булган бер күлгә күчүләренә рөхсәт ителүне сорыйлар. Моны сораучы ыругларның һәммәсе җиде: балыклар, кеше, кондыз, көнгерә, торна рәсемнәре шушы төрле ыруг вә кабиләләрне күрсәтә. Боларның һәммәсенең дә күзләре җепләр белән берләштерелгәннәр. Бу аларның шушы низаглы мәсьәләләргә карашлары һәммәсенең дә бер төсле булганын аңлата. Болар үтенечләрен һәммәсе дә бер авыздан, бер күңелдән, үзара тәмам иттифакъ белән күндерәләр. Моны янә һәммәсенең дә йөрәкләре җепләр белән бергә китереп баглануы күрсәтә. Торна ыругыннан булган башлыкларның күзе бер үк вакытта ике сызык белән ике якка каратыла: берсе – «Бөек ага»га, икенчесе дә – үзләренең сораган күлләренә.

Америкада (Мексикада) тагын шундый бик күп язулар табылган. Болар безгә Мексика балаларының ничек тәрбия ителүләре, тәрбиячеләр һәм ата-аналарның балаларына каршы булган бурычлары, вазифалары турысында мәгълүмат бирәләр. Түбән язуны күрсәткән таблицада 1–2 нче номерлы рәсемнәр шундый язулардан. Монда 2 нче рәсемдә унбер яшьтәге бер ир бала турысында сөйләнә. 11 түгәрәк шуны күрсәтә. Ике икмәк рәсеме – тәрбияне күрсәткән символ. Боларның берсендәге ун сызык – баланың 10 яшькәчә тәмам ата-ананың тәрбиясендә, шуларның тәэминатында булырга тиешлеген, тугыз сызыклысы моннан соң янә тугыз ел ата-ана балага ярдәм итеп торырга кирәклеген аңлата. 19 яшькә җиткәннән соң инде, бала ата-ана тәрбиясеннән, аларның тәэминатыннан тәмам чыга. Шул ук таблицада, шул ук 2 нче номерлы рәсемдә ата-аналарына

итагать итмәгән унбер яшьтәге балаларга җәза бирүләрнең рәвеше күрсәтелә. Ата баласын җиргә ягылган, янып торган ут өстенә тота. Янә шул ук төен язуны күрсәткән таблицада 1 нче номерлы рәсем бар. Менә монда бер яшүсмер 15 яшькә ирешкәннән соң (15 түгәрәк шуны күрсәтә), аның атасы, югары кяһингә барып күренеп (атаның барышы эзләр белән күрсәтелә), углының үзенә нинди эш вә эшчәнлекне ихтыяр иткәнлеген аңа белдерергә тиеш икәнлеге аңлатыла (күрүпкә – хакимият символы, кяһинне күрсәтә).

Вәхшиләрдә бөтен язу могаһәдә, сүз куешлар янә рәсемнәр аркылы аңлатылган. Мәсәлән, бер күл рәсеме, үзендә балыклар йөзеп тора, шуның өстенә тирәсендә кешеләр сурәте. Менә шушы пиктография, ягъни шушы рәсемнәр төркеме ике кабиләнең шул җирдә аучылык кәсебен уртак кылу могаһәдәсе булган.

Шундый ук рәсем язуларыннан 10 нчы шәкелне карагыз. Менә монда гыйльми геология (җир катлавы гыйлеме – гыйльме табәкателарз) экспедициясенең сәяхәтләреннән бер эпизод күрсәтелә. Сәяхәт үзе 1820 елда була. Экспедициянең һәйәтендә[1] алты галим, сигез хәрби сакчы, болар ике һиндине үзләренә юл күрсәтергә алганнар. Гыйльми тикшерү өчен Миссисипи елгасы тирәсенә баралар. Бара торгач, бик коры бер урманлык һәм баткаклык-сазлык бер җиргә килеп чыгалар да юл яңышдыралар. Экспедиция моннан чыгуга, котылуга һичбер юл таба алмый. Юл белмәстән чамалап алга китә бирүдән элгәре, әлеге юл күрсәтеп баручы ике һинди үзләренең шул җиргә артларыннан килеп керүче җирдәшләреннән ярдәм алу исәбе белән, бу җирдә булган әлеге вакыйга турысында бер хәбәр калдырып китәргә карар бирәләр. Бер кисәк каен агачы кабыгына шушы 10 нчы шәкелдә күрсәтелгән язуны калдырып китәләр. Моны да озын бер казыкка асып, ачык бер мәйданга куялар.



10 нчы шәкел. *Фәнни экспедицияне тасвир*

[1] Һәйәтендә – төркемендә.

Шушы язуга карап, һиндиләрнең җирдәш-ватандашлары менә шуны аңларга тиешләр: моннан ниндидер бер экспедиция үтте (моны очып баручы кошлар рәсеме күрсәтә), экспедиция һәйәте эчендә ике һинди һәм ундүрт яурупалы бар (эшләпәлеләр – яурупалылар). Экспедиция һәйәтенең башында бер геолог (уңыннан беренче, кулында чүкеч булганы) тора, аның артында бер секретарь бар (уңнан икенче, кулында бер китап булганы), соңра кораллы сигез сакчылары бар. Өч мәртәбә тукталганда, алар кош һәм ташбака ашадылар (моны өч ягылган ут – костёр күрсәтә).

Түбәндәге 11 нче шәкелгә карагыз. Аляска ярыматауларындагы эскимосларның юл журналын күрерсез. Бу язу фил сөягеннән бер таякка чокылып язылган.




11 нче шәкел. *Эскимосларның юл журналы*

Монда хикәя кылучы: 1) бер кулы белән үзенә юл күрсәтә – «мин», ди, икенче кулы белән еракны күрсәтә – «китәм», ди; 2) «көймәдә», ди (көймәнең ишкәген күтәреп тора); 3) «бер кич (күтәрелгән кулындагы бармак шуны күрсәтә) кунамын, йоклыймын», ди (башына куелган кулы шуны аңлата); 5) «тагын да арырак китәм»; 6) «үзендә кеше тормаган утрауда»; 7) «анда ике кич кунып калам»; 8) «гарпун – сөңге белән ауларммын»; 9) «тюленьне»; 10) «уктан атармын»; 11) «икенче бер кеше белән көймәдә кайтырмын» (кирегә караган ике ишкәк күрсәтә); 12) «үз йортыма – чатырга кайтып килеп керермен».

Эскимосларның 12 нче шәкелдә күрсәтелгән «авырудан имнәр» язулары да – шул ук әйбер язуы яки рәвеш язуның бер төрлеседер. Беринг утравының икенче тарафында яшәүче чукчалар язуы да шуңа охшаш.



12 нче шәкел. *Шаманның җен-пәриләрне куганын тасвир*

Бу язу шаманның җен-пәриләрне куганын күрсәтә. Монда шаманның агачлардан корылган җәйге өе (ا), шаман үзенә буйсынучы җен-пәринең (ب) койрыгыннан тоткан; авырулардан явыз рухларны куып җибәрү өчен шуннан файдаланмак була. Шаман (ج), биеп, ике авырудан явыз рухларны (د) каулый. Шаман тарафыннан куылып, авыруларның тәннәрен ташлап киткәннән соң, әлеге ике явыз рухның хәле (ه).

Яна һәм Анадырь[1] арасындагы тундраларда яшәүче бер юкагирка кызының хаты (13 нче шәкел) тагын да кызыграк. Бу хат пычак белән бер каен кабыгы кисәгенә язылган. Үзе хатынлы бер руска адрес кылына. Юкагирка шуңа гашыйк булган була. Юкагирка кызлар, үзләренең гадәтләре буенча, мәхәббәт турысында ирләргә бер сүз дә әйтергә хаклы түгел. Менә шуның өчен дә алар үзләренең кәеф вә тойгыларын кирәкле бер вакытта үзенә бертөрле рәвеш язу белән аңлату сәнгатен тудырганнар.



13 нче шәкел. *Юкагирканың хаты*

Бу язуның мөндәриҗәсе шуңа кайтып кала: «Рус кешесе, син миннән еракка – үз өеңә китәсең. Син башка бер хатынны сөясең, шуның өчен син мине сөя алмыйсың; сезнең балаларыгыз булыр, син дә бәхетле булырсың; мин исә монда ялгыз калып, фәкать сине генә сөеп яшәрмен; мәңге синең турында гына уйлар һәм кайгырырмын. Хәтта мине сөя торган бер ир табылганда да, мин шулай булырмын».

Бу рәвештә рәсемнәр төркеменнән гыйбарәт булган язуга «пиктография» яки «пиктографик язу» дип тә әйтәләр.

**Сурәт-иероглиф язуы.** Без югарыда һиндиләрнең «тормыш-хәят» дигән аңны[2] – мөгезле елан сурәте белән, «үлем» дигән мәгънәне – аяклары югары күтәрелеп яткан хайван сурәте аркылы, «җитез, елдам» мәгънәсен дә куллары урынында канаты булган бер кеше сурәте аркылы аңлаткан икәнлекләрен күргән идек. Кешеләр,

[1] Себердәге елга исеме.

[2] Аңны – мәгънәне.

тәрәккый итә торгач, менә шул рәвештә сурәт язу баскычына да килделәр. Рәсем язуы ахырда шуңа әйләнеп китте. Борынгы мисырлылар да, башта рәсемнән башлап, ахырда иероглиф дигән язуларын тудырдылар. 14 нче шәкелдә шуның галәмәтләре күрсәтеләдер.




14 нче шәкел. *Мисырның сурәт язуыннан берничә галәмәтләр*

Кытай язуы исә хәзердә дә шушы сурәт язуы әсасында. Мисырлыларның – сурәт язуларыннан элек булган һәм шуның үзеннән сурәт язулары хасил булган рәсем язулары 15 нче шәкелдә күрсәтелә. Бу язу миладтан элек дүртенче мең елның соңгы гасырына гаид[1]. Бу рәсем ләүхәсенең[2] уртасында патша. Уң кулы белән дошманга үлем зарбәсе[3] бирү өчен гөрзи күтәргән. Рәттән уң якта лачын. Бу – патшаның көченә, хакимиятенә галәмәт, шуның эмблема[4]сы, шуның символы. Аның басып торган шәкеле – мәмләкәтнең бер өлеше. Лачын куй башының авызыннан үткәрелгән җепне тотып тора. Моның янында ук алты данә лотос (эссе яклардагы су үсемлеге һәм Америкадагы хыялый бер үсемлек) яфрагы. Уңда янә, түбәндә, атып



15 нче шәкел. *Борынгы мисырлылардан Нармер патшаның палитрасындагы (рәсем ләүхәсендәге) рәсем язуы*

[1] Гаид – карый.
[2] Ләүхәсенең – күренешенең, картинасының.
[3] Зарбәсе – сугуы, зыяны.
[4] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*

бәрә торган сөңгеле сугыш коралы – гарпун һәм эчендә дулкынлы сызыклар булган дүртпочмак. Бу да күлне аңлатырга тиеш. Гарпун мисырлыларда «ва» дип аталган. Шуның өчен монда ул рәсем «Ва» исемендәге мәмләкәтне аңлата. Лотосында алты данә чәчәк төенчелегенең һәркайсы 1000 саны күрсәтә. Бу да Мисыр сазлыкларында лотосның меңләп табылуыннан булса кирәк. Г. Штейндорфның[1] аңлатуынча, бу рәсем язуы ләүхәсе бөтене белән Мисыр патшасының бер күл янындагы «Ва» мәмләкәтен фәтех итеп[2] үзенә буйсындырганлыгын һәм алардан алты мең әсир алганлыгын тасвир итә.

Сурәт язуының иң нык тәрәккыйсе Мисырда булды. Ул да, югарыдагыча, рәсем язуыннан тудырылды. Мисырлылар шуннан туган сурәт язуларын, тагын әллә ничә гасырлар буенча тәрәккый иттерә-иттерә, хәтта тагын тәмам безнең хәзер кулланганыбыз әлифба язуыбызга якынлаштыра язып куйганнар.

Мисырлылар безгә шушы соңгы язулары белән бик күп микъдарда кыйммәтле тарих-хатирәләр калдырдылар. Бу хатирәләр, бу язуларның безгә килеп ирешкән иң борынгы рәвешләре миладтан өч мең ярым еллар элек булган бер заманга кайтып кала. Иң соңгылары да миладның XV гасыр хатирәләреннәндер[3]. Шул хатирәләр берсе биш меңьеллык бер заманның хатирәләре димәк буладыр.

Мисырлылар язуга иң элек, һиндиләр кебек үк, үзләренең фикерләрен аңлатмак өчен төрле әйберләрнең рәсемнәрен төшерүдән башлаганнар. Шуның белән бергә һәрбер әйбер боларда билгеле бер аңга муафикъ булган. Иң башта сурәтләр туры мәгънәне аңлатканнар. Мәсәлән, арыслан, каракош сурәтләре аларның турыдан-туры үзләрен, кул учы да турыдан-туры учны аңлаткан, вә башка сурәтләр янә шулай (14 нче шәкел).

Ләкин әйберләрнең бу рәвештә сурәтләрен төшереп, турыдан-туры шуларның үзләрен аңлату мөмкин булса да, «көн», «гыйбадәт», «көч», «үлем», «сусау», «байлык», «салым түләү», «ачму» кебек сүзләрне һәм шундый гаклый нәрсәләрнең рәсемнәрен төшереп, аларны турыдан-туры аңлату мөмкин түгел, бәлки боларны рәсемнәр аркылы хәтерләргә генә мөмкин иде. Мисырның фикри

[1] Георг Штейндорф (1861–1951) – Мисырны өйрәнүче немец галиме.

[2] Фәтех итеп – яулап алып.

[3] Карл Вейле. От бирки до азбуки. Профессор Д.Н. Анучин тәхрире астында русча тәрҗемәсе, б. 77–78 һәм «История письма» (Правдолюбов), б. 35. *(Авт. иск.)*

тәрәккыйсе менә шушы имкянне дә күрде. Инде: «көн» мәгънәсен – кояшны күрсәткән бер түгәрәк белән, «гыйбадәт»не – кулларын күккә күтәргән кеше рәсеме белән, «йөрү» мәгънәсен дә – йөреп торган ике аяк рәсеме аркылы, «салым түләү» мәгънәсен – икмәк тотып торган ике кул, «алла» һәм «патша» мәгънәсен дә лачын сурәте аркылы аңлата башлаганнар. Җиргә яткан бер кеше рәсеме – «төшү» мәгънәсен, рәвешендәге астына күп нокталар куелган сызыклар – «үсмер җир» (мөнбит[1]) мәгънәсен, пычкы рәвешендәге тешле бер галәмәт дә – «үсемсез җир» (гайре мөнбит) мәгънәсен, өй сурәте – «чыгу, өйдән чыгу», канатлы кояш түгәрәге рәсеме «изгелекнең явызлыкны җиңүе» мәгънәсен аңлатулары вә башкалар янә шул җөмләдәндер.

Бу рәсемнәр дә – әлбәттә, шарты вә игътибары булган нәрсәләр. Ягъни билгеле аң вә бер мәгънәне, билгеле бер тойгыларны аңлату өчен, болар сүз куешлы булганнар, шуның өчен араларында мондый язу кулланылган халыклар андый рәсемнәрнең нәрсә аңлатканнарын яхшы төшенгәннәр.

Хасил, шул рәвешчә сурәтләр инде әүвәлгечә нәрсәләрнең турыдан-туры үзләрен генә түгел, бәлки шуларга мөнәсәбәтле мәгълүм бер тасвир вә тойгы кебек гакылый вә мәгънәви нәрсәләрне дә аңлата башлаганнар, ягъни сурәтләр тугры мәгънәләрендә түгел, бәлки күчерелгән мәгънәдә, киная рәвешендә кулланылып, билгеле мәгънәдә аңның символы булып йөртелә башлаганнар (16 нчы шәкел). Шулай итеп, инде «мәгънә рәвеш язу», ягъни идеографик юлына керелгән. Мондый символ рәсемнәр тәдриҗән[2] реалистик (реалистический[3]) рәсемнәрнең киметелә баруына да сәбәп булган. 16 нчы шәкелдә: 1) Бөтен урынына



16 нчы шәкел. *Мисырның символ сурәт язуы галәмәтләреннән*

[1] Мөнбит – уңдырышлы, мул уңыш бирүче.
[2] Тәдриҗән – акрынлап.
[3] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*

кисәкнең рәсеме төшерелгән. Мәсәлән, «бәрелешү» аңы берсендә – калкан, берсендә сөңге булган ике кул рәсеме белән бирелгән, әһрам[1] сурәте дә Мисырның үзен аңлаткан. 2) Сәбәп нәтиҗә урынында сурәтләнгән. Мәсәлән, «көн» яки «көндез» мәгънәсе кояш сурәте белән аңлатылган. «Төн» дигән аң яки мәгънә йолдызлар аркылы сурәтләнгәннәр. «Үлем» мумия сурәте белән аңлатылган. 3) Үзен сурәтләндерү тиеш булган бер аң яки мәгънә белән нинди дә булса бер мөнәсәбәте, бер бәгланышы булган нәрсәнең сурәте төшерелгән. Мәсәлән, колга (мачта)да җилкән көймәсенең сурәте җилне белдергән, ике күз сурәте «карау» мәгънәсен аңлаткан. 4) Бик томанлы сурәтләрнең рәсемнәре, үзләре аркылы аңлатылган аң вә мәгънәләргә мөнәсәбәтләре шартлы булган нәрсәләрнең рәсемнәре шулар җөмләсеннәндер. Мәсәлән, бал корты сурәтләре патшаны аңлаткан кеби. Мисырлылар карашында гүя бал корты хәяты тугры һәм монархик бер канунга каратылган. Аның аркылы «патша» аңын сурәтләндерү дә шуның өчен. Шуның белән бергә патша һәм бал корты мәгънәсендәге сүзләр мисырлыларда бер үк төрле авазлар белән әйтелгәндер. Төя[2] кошы каурыйсы-кыягы «гадәләт» вә «тугрылык»ны аңлаткан, чөнки мисырлылар бу кошның каурыйлары һәммәсе дә бер төрле була дип уйлаганнар. Нил казы «угыл» мәгънәсен алган, аның сурәте шул мәгънәне аңлаткан. Бу кошта алар артык бер угыллык хосусиятен күргәннәр. Хөрмә агачының ботагы «ел»ны аңлаткан, чөнки мисырлылар хөрмә агачын ай саен бер ботактан, ел саен унике ботак чыгара дип уйлаганнар.

Сурәт язуының менә шушы рәвеше «сүзләр язу» (письмо словами[3]) дип тә йөртелә. Чөнки монда нинди дә булса бертөрле сурәт белән бөтен бер сүз аңлатылган.

Мисырлыларда бу язу аларның тарихы хәятларының иң соңына кадәр дәвам иткән.

Шушы сурәт язуы (фигураль[ное] письмо[4]) белән бергә иң борынгы заманнарда Мисырда тагын бертөрле язу тудырылып тәрәккый иткән. Мисырга килеп, диварларда шул язуны күргәннән соң юнанлылар аны «иероглиф» язуы дип атаганнар («кяһиннар язуы – мөкаддәс язу» дигән мәгънәдә). Иероглиф язуы – кяһиннар тарафын-

[1] Әһрам – пирамида.
[2] Төя – тәвә.
[3] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*
[4] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*

нан дини максатлар өчен эшләнеп чыгарылган бер язу. Бу язуның галәмәтләре дә махсус бер кораллар белән ташка, агачка вә башка бер нәрсәләргә уелып ясалганнар. Моның исеменең дә шуның белән мөнәсәбәте бар (Герос[1] – кяһин, глифи[2] дә «кисү» мәгънәсендәдер)[3].

Иероглиф язуы тугрыдан-тугры сурәт язуыннан тәрәккый иткән бер язу булган. Боларның аермасы шунда: сурәт язуы бөтен сүзләрдән гыйбарәт булса, иероглиф язуы үзенең әсасы итеп иҗекләрне алган. Ягъни сурәт язуында рәсемнәр – сурәтләр бөтен сүзләрне аңлатсалар, иероглиф язуында болар фәкать иҗекләрне генә аңлата торган булганнар. Ягъни сурәтләр сүзләрнең иҗекләренә генә галәмәт ителгән.

Моның да бер сәбәбе – сурәт язуы системы аркылы хас исемнәрне[4], кеше исемнәрен аңлата алу мөмкин булмаганлыгыдыр. Шуның өчен Мисыр язучылары, хас исемнәрне иҗекләргә аерып, шуларның һәрбер иҗеге махсус бер галәмәт белән күрсәтелә башлаган. Шулай итеп, ахырда иҗек язуы юлы (силлабическое письмо[5]) мәйданга чыккан. Мәсәлән, «пр» иҗеге, ягъни тавышсыз «п» белән «р» авазының бергә кушылып тоташуы кай урында гына очраса да (чөнки мисырлыларда сузынкы авазлар язуда күрсәтелмәгәннәр), бу иҗек «өй» сурәтенең кыскартылган бер рәсеме белән язылган – ◇, чөнки мисырлылар «пр» дип өйгә әйткәннәр. Шул ук иероглиф сурәтләрдә «чыгу» дигән фигыль урынында йөртелгән.

Менә бу инде язу тарихында иң зур бер тәрәккый адымы санала. Кешелек дөньясы шуның белән хәзерге көндәге язуыбызны тудыруның да юлына төшкән була.

Димәк, бу тәрәккый баскычына җиткәндә, инде кешеләр телнең сүздән дә ваграк гонсырлары булганын аңлый башлаганнар. Ягъни телнең – сүзләрдән, сүзләрнең иҗекләрдән гыйбарәт икәнлеге беленгән. Ничә гасырлардан бирле үзләренең җайлы сөйләшү телләрендәге сүзләрне, аларның аваз бүлемнәрен үз колаклары белән ишетеп килеп, шуларны аера белүгә мәләкәләнүләре[6] аларны ахырда шул нәтиҗәгә ирештергән.

Шулай итеп, бер яктан сүзләрнең иҗекләрдән гыйбарәт булуын аңлау, икенче яктан да, сурәт язуының кыенлыгыннан котылу

---

[1] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*
[2] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*
[3] В.А. Правдолюбов. История письма. *(Авт. иск.)*
[4] Хас исемнәрне – ялгызлык исемнәрне.
[5] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*
[6] Мәләкәләнүләре – өйрәнүләре.

ихтыяҗы мисырлыларны язу бабында әлегедәй башка бер юлга кергезгән. Ниһаять, алар инде сурәт язуларының рәсемнәре эченнән иң гади һәм үзләрен төшерер өчен иң җиңел булганнарын – барысы биш йөз чамасы рәсемнәрне сайлап алганнар да, шуларга иҗек мәгънәсен биргәннәр. Ягъни шулар белән үзләренең иҗекләрен яза башлаганнар. Һәрбер сурәт инде сүзнең иҗегенә галәмәт ителгән.

Бара торгач, мисырлыларда сүзләрнең иҗекләре генә түгел, авазлары да аерыла башлаган. Инде сурәтләр, рәсемнәр иҗекләрдән күчеп, сүзләрнең аерым авазларына галәмәт ителгәннәр. Ягъни бер сүз нинди язу белән башланган булса, шул сүзне белдерә торган сурәт әлеге авазның галәмәте ителү юлына төшелгән. Фәкать мисырлыларда тавышлы авазлар башта язуда һич игътибарга алынмаган һәм күрсәтелмәгәннәр. Сурәтләр иҗекләрдә ялгыз тавышсыз авазларга гына галәмәт булганнар. Язуда да тавышлы, ягъни сузыла торган авазларны кертү фәкать соңыннан башланып киткән. Бу да язуны җиңеләйтү юлында бер адым булган. Аерым авазларга бер галәмәт алу иң элек авазлы тавышлардан башланган. Мәсәлән, сузынкы, ягъни тавышлы аваз булган нечкә «ү»не аңлату өчен – куян сурәте, калын «у» өчен – элмәк (петля[1]) шәкеле, «а» өчен – каракош сурәте, «и» өчен дә хөрмә агачы сурәте төшерелгән.

Сузык авазларны бу рәвештә язу белән бергә, шуның артыннан ук саңгырау, ягъни яңгырамый торган авазларны да алар шул юл белән яза башлаганнар. Мәсәлән, дүрткел рәсем – [п] авазын, арыслан сурәте – [л] авазын, корзинка сурәте дә – [к] авазын, авыз рәсеме [р] авазын белдергән. Мисырның янә шушы иероглиф язуының үрнәге 17 нче шәкелдә күрсәтелә. Менә бу ике бүлек шәкелнең берсе – Птолемей[2], икенчесе Клеопатрадыр[3].



*Птолемей* *Клеопатра*

17 нче шәкел

[1] *Кирилл хәрефләре белән бирелгән.*

[2] Птолемей I Сотер – б. э. к. 323–283/282 елларда Мисыр патшасы, Птолемейлар династиясенә нигез салучы.

[3] Клеопатра VII Филопатор (якынча б. э. к. 69–30) – Птолемейлар династиясеннән Мисырның соңгы патшасы.

Шул хәлдә мисырлыларның шушы системы белән язарга булсак, «ура» дигән сүзне безгә менә болай язарга туры килер иде: элмәк шәкеле+авыз рәсеме+каракош сурәте.

«Күк» дигән сүзне исә: корзинка рәсеме+куян рәсеме+корзинка рәсеме рәвешендә язар идек. Русча «рука»[1] дигән сүзне дә, мисырлыларча язганда, менә болай булыр иде (18 нче шәкел). Шушы иероглиф системында бөтен тавышсыз авазларны сурәтләндерә торган галәмәтләр барысы 24 чамасыдыр.



18 нче шәкел

Бара-бара бу язу янә җиңеләйтелә, ягъни инде бу сурәтләр кыскартылып, бөтен бер сурәт хәлендә аның бер кисәге яки сызыкчасы (контуры[2]) рәвешенә генә калдырыла. Мәсәлән, каракош сурәте урынына инде аның төгәл сурәте түгел, бәлки 19 нчы шәкелдәгечә аның сызыкламасы гына төшерелә башлый.



19 нчы шәкел

Мисыр язуы үзенең үзгәреш вә тәрәккый юлында, шулай итеп, өч төрле баскыч күрсәтә алды: 1) асыл иероглиф язуы (иероглифическое письмо[3]); 2) һиератик язу (гиеротическое письмо[4]); 3) демотик язу (демотическое письмо[5]).

Асыл иероглиф язуы, ягъни сыйрыф сурәт галәмәтләр бигрәк ташка язылган тарихи хатирәләр (мәсәлән, диварлар һәм кәлисә баганалары, кабер ташлары, табутлар кебек) өчен кулланганнар. Бу хатирәләрдә инде иероглифларның тышкы пиктографик рәвешләре аеруча нык сакланганнар. Моңа язуның үз техникасы да сәбәп булган. Чөнки монда язу техникасы менә болай булган: һәрбер галәмәт кискеч үткен бер нәрсә белән ташка казылып язылган. Менә шушы техника үзе генә дә бу язуның кыскартылуына имкян бирмәгән.

Әмма папирус яфрагыннан эшләнгән кәгазь кебек, язуның материаллары чыкканнан соң, язу техникасы үзгәргән. Инде папируска махсус бер каләм аркылы тушь белән яза башлаганнар. Шулай итеп, иероглиф галәмәтләр папирусларга төшерелә башлагач, табигый буларак, сурәт рәсемнәрнең кыскартылуы башланып киткән. Һәм бу

[1] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*
[2] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*
[3] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*
[4] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*
[5] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*




20 нче шәкел.
*Бу шәкел рәсем сурәт язуыннан әлифба язуына күчү баскычларын күрсәтә.*
*Сулдан беренче багана – төгәл сурәтләр рәвешендә Мисырның иероглиф язуы. Икенче багана – Мисыр иероглифының кыскартылганы. Өченче багана – шул ук Мисыр иероглифыннан кыскартылып эшләнгән язу.*
*Дүртенче багана – латин, юнан, яһүд язулары*

рәвештә боларны кәгазьгә язганда шәп-тиз яза алу мөмкин булган язуның шәп, тиз язылуы исә, әлбәттә, аның тышкы күренеше үзгәрүне лязем итүе табигый. Папируска каләм белән яза башлаганнан соң, Мисырда менә шулай булган да. Язучылар ул галәмәтләрне һаман кыскартканнан-кыскарта барганнар. Бара торгач, галәмәтләрнең фәкать бер кисәге (югарыда әйткәнчә) яки фәкать бер сызыгы гына калдырылган.

Һиератик язу нәкъ әнә шул рәвешчә язу техникасы үзгәрү аркасында туган. Һиератик язу белән эш кәгазьләре, документлар, эш хисаплары языла башлау аркасында, бу язу тагын да кыскартыла һәм җиңеләйтелә башлаган. Ниһаять, моннан демотик язу туган, хасил, асыл иероглифта бер иҗеккә һәм бер авазга нәрсәләр, хайваннар, кошларның бөтен-төгәл сурәтләре йөртелсә, һиератикта ул сурәтләрнең сызыкламасы яки бер кисәкләре



21 нче шәкел. *Һиератик язудан үрнәк*

генә йөртелү баскычына күчелгән. Әмма демотикта исә бу сурәтләр, тагын да кыскартылып, безнең хәзерге хәрефләребез рәвешенә якынлаштырылган. 22 нче шәкелдә мисырлыларның язуларындагы шушы өч төрле тәрәккый рәвешләре күрсәтелә. Иероглиф язуы бигрәк руханилар – кяһиннар язуы булып, Нил хаузасында[1] миладның беренче гасырынача кулланылган бер язу. Бу язуда бигрәк Мисыр әдәбияты һәм гыйльми хатирәләр язылган. Соңра бу язу христиан – насари мисырлылар, ягъни кыйбтилар язуы белән алмашына. Бу соңгыларның язулары исә, юнан әлифбасыннан алынып, бәгъзе Мисыр хәрефләре белән тутырылгандыр[2].

Демотик язу Мисырның иң җиңел бер гавам язуы булган. Бу язу Мисыр халкы арасында күп таралган. Шуның өчен дә моңа халык язуы мәгънәсендәге «демотик» исеме бирелгән.

Демотик язу – Мисыр язуының иң соңгы тәрәккыйсе. Бу язу инде шуннан да ары тәрәккый иттерелә алмаган. Үзенең шул тәрәккый ноктасында тәмам тукталып калган. 22 нче шәкелгә карасак, чыннан да, демотик язу безнең хәзерге хәрфи, ягъни әлифба язуыбызга тәмам якынлашкан иң гади, садә бер язу булганын күрәбез.

| иероглифлар | кыскартылган иероглифлар | демотик язу | мәгънәләре |
|---|---|---|---|
|  | | | *А* |
|  | | | *Л* |
|  | | | *К* |
|  | | | *Р* |

22 нче шәкел. *Мисыр язуының тәрәккый баскычы*

Шуның белән бергә, Мисыр язуындагы бу тәрәккый баскычлары берсе соңында икенчесе гамәлдән чыга барган язулар түгел. Ягъни иероглиф язуы чыгарылу белән әүвәлге рәсем-сурәт язуы истигъмальдә[3] калмаган кебек, демотик язу чыгарылу белән иероглиф язуы да истигъмаль ителүдән тукталмаган. Шулай ук иң соңгы тәрәккый баскычы булган демотик язу чыгарылу белән дә аннан элгәре булган әлеге өч төрле язу бөтенләй ташланмаган, бәлки мисырлыларда болар һәммәсе дә һаман бәрабәр истигъмаль ителә биргәннәр. Хәтта мисырлылардагы бу язу системлары бер-берсе белән тәмам аралаштырылып, буташтырылып бетерелгәннәр. Ягъни

[1] Хаузасында – бассейнында.
[2] Карл Вейле, б. 79. *(Авт. иск.)*
[3] Истигъмальдә – кулланылышта.

мисырлылар аерым язу галәмәтләре белән бергә иҗек галәмәтләрен дә, бөтен сүз, ягъни иероглиф галәмәтләрен дә һаман бер-берсенә аралаштырып куллана биргәннәр. Шул рәвешчә, барысы 700 төрле галәмәт вә рәсемнәрдән гаять катлаулы һәм кыен бер язу системы хасил булган. Бәгъзе сүзләр фәкать әлифба галәмәтләре – хәрефләр белән генә язылса, бәгъзеләре дә иероглиф сурәтләр белән дә вә бәгъзе берләре боларның һәммәсеннән кушылма бер рәвештә язылганнар. Тагын әгәр бер сүз иероглиф ысулында язылмастан аваз ысулында язылса, соңында бер детерминатив, ягъни бер аергыч рәсем куйганнар. Мәсәлән, «көч»не белдергән һәр сүздән соң кораллы бер кул, «үсемлек» мәгънәсен ачык аңлату өчен, агач рәсемен кушканнар.

Аваз, иҗек, иероглиф галәмәтләрен һәммәсен бәрабәр куллануларының сәбәпләре дә менә шулар булган:

1) Бу язу системнары белән файдалану мисырлыларда һичбер төрле катгый бер кагыйдәгә ияртелмәгән; нинди дә булса бер фикер вә аңны, сүзләрнең иҗекләрен, авазларны язып аңлату өчен шул язу системнары эченнән кирәкле галәмәтләрне сайлап алуда язучылар тәмам ихтыярлы булганнар. Алар үзләре кайсыларын теләсәләр, шуларны ала биргәннәр.

Мисырлылар искене саклау юлында артык мөхафәзәкяр[1], артык саклыклы бер халык булганнар. Язучыларга бу юлда бу рәвештә ихтыяр куелу да мисырлыларның әнә шушы хосусиятләренең нәтиҗәсе дип карала. Шуның өчен алар язуның иҗек һәм аваз ысуллары белән бергә борынгы бабаларыннан мөкаддәс эш булып калган һәм ничә мең еллык традиция (ганганә) нәтиҗәсе булган иске ысулларны, рәсем һәм сүз ысулларын да һаман нык саклап барганнар вә шуны саклап баруны мотлак тиеш күргәннәр.

2) Мисырлылар язуга, ялгыз фикерләрне аңлау өчен бер васита дип кенә карамастан, шуның белән бергә алар моңа матурлаубизәкләү өчен билгеләнгән декоратив бер нәрсә дип тә караганнар. Шуның өчен дә хәтта Мисыр язучылары «сәнгатькяр» – оста дип аталганнар. Болар үзләренең язу эшләренә сәнгатькә караган шикелле караганнар. Аны сәнгатькяранә бер иҗат дип белгәннәр, гыйбадәтханә вә кәлисәнең диварларына, һәртөрле сөтүннәргә (обелиски[2]), кабер вә кабер ташларына язганда яки язуларны камыш

[1] Мөхафәзәкяр – искелекне яклаган.
[2] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*

каләмнәр белән папирус яфракларына төшергәндә, һәрнәрсәдән элгәре болар бу язуларга бер матурлык, төгәл бер күренеш вә шәкел бирергә тырышканнар. Шуның белән болар бу язуларның соклангыч бер картина рәвешен алып, укучыларны шул яктан үзләренә тәмам җәлеп итә алырлык бер сурәткә килүләрен тәэмин итәргә теләгәннәр.

Менә шушы максат өчен дә алар үзләренең яңа язу системнары белән бергә иске язу системнарының, ягъни рәсем язуы, сурәт язуы һәм иероглиф язуларының гонсырларыннан да файдаланганнар.

Хәтта Мисыр язучылары шул максат белән язуның дөреслеген язуның матурлыгы өчен күп вакытта корбан да иткәннәр. Икенче төрле әйткәндә, язуның каллиграфия ягы орфографиясеннән күп алда тотылган. Һәрнәрсәдән элек язуның каллиграфиясенә зарар килмәү ягына артык әһәмият бирелгән.

Иероглиф язуы исә алар өчен бу турыда иң яхшы бер чара булган. Чөнки бу язу үзе, чынында, бер картина димәктер.

Китапка кушылган таблицадагы Гиза[1] әһрамнарының берсендә табылган дүртенче номерлы картина – әнә шундый матурланган Мисыр язуларының үрнәге. Монда без үзенең кәлисәгә багышланган тәреләре, изге бүләкләре алдында үлүченең үз сурәтен күрәбез. Аның тирәсендәге иероглиф рәсемнәрдән үлүченең Мираб исемендә бер патша углы (сул яктан беренче өч галәмәт күрсәтә) булып, ул үләр алдыннан, үзенең рухын мәңгелек бәхетсезлектән коткару өчен, бик күп һәдияләр, ярдәмнәр багышлап киткән вә башкалар.

Менә бу мәгънәләр сурәтле иероглиф язуы системы белән кыйсмән[2] демотик язуның системыннан гыйбарәт катыш бер язу аркылы аңлатылган.

**Иероглиф язуларын укуның кәшеф ителүе[3].** Мисырның иероглиф язуларын укуны кәшеф итү юлында Яурупа фән дөньясы чиксез күп кыенлыклар, күп азаплар күрде. Бу юлда күп көч, күп энергия сарыф ителде, чиксез күп хезмәтләр куелды. Ләкин шуңа карамастан, бер мең ярым еллар чамасы бу язуларны укый алуның ачкычы табыла алмый торды. Болар һаман борынгы Мисыр мәдәниятенең телсез шаһитлары гына иде. Ниһаять, XIX гасыр безгә шушы язуларны кәшеф иттерде. Боларны да башлап укый алучы

[1] Хеопс, Хефрен һәм Микерин пирамидалары турында сүз бара.
[2] Кыйсмән – өлешчә.
[3] Кәшеф ителүе – ачылуы.

француз галиме Шампольон[1] булды. Бу галим, ниһаять, 1822 елда шушы иероглиф язуларын укый алды[2].

Фән дөньясындагы бу кәшеф иң зур, иң кыйммәтле кәшефләрдән санала. Бу безгә борынгы заманның иң мәдәни халыкларыннан берсенең чиксез киң бер мәдәният хәзинәсен ачып бирде. Шуның белән бергә бу кәшеф безгә бигрәк тә язу-әлифба тарихының иң ерак, иң караңгы төп баскычларын билгеләүнең ышанычлы бер маягы булды.

Бу кәшефнең зур бер адымы 1799 елда башланды, шушы елда Нил елгасы тамаганыннан өч язу килеп чыкты. Ягъни үзендә асыл иероглиф, демотик һәм юнан язулары булган зур бер таш такта табылды. Мондагы юнанча текст (гыйбарә)дән шуны белделәр. Әле яңа гына тәхеткә утырган (миладтан 196 ел элек) Мисыр фиргавене Птолемей Эпифанның[3] шәрәфенә кяһиннарның чыгарган мактау карарларыннан гыйбарәт икән. Шул ук вакытта шушы өч гыйбарәнең өчесендә дә Птолемей исеме овальный[4] рамка эченә алынган булганлыгы күрелгән. Бу хәл галимнәргә шушы сүзнең (Птолемей исеменең) юнанча язылуын иероглиф һәм демотик язулар белән чагыштырып карарга имкян биргән.

Шулай булса да, әле Мисыр язуын укый алу, бу меңьеллык табышмакны чишү мөмкин булмаган.

Күп тә үтмичә, бу юлда тагын икенче иң мөһим бер адым атлана: Фила утравында тагын Мисыр һәм юнан телендә ике язу табыла. Бу ике язуның икесендә дә Клеопатра исеме табылып, бу да әлеге рамка белән әйләндерелеп алынган була. Иероглиф язуы белән булган текст (гыйбарә)дәге бу исемнәр нәкъ югарыда 17 нче шәкелдә күрсәтелгән рәвештә язылган булганнар. Галимнәр шушы ике язуны чагыштыра башлаганнар. Нәтиҗәдә, Птолемей исемендәге беренче урында торган дүрткел рәсемнең Клеопатра исемендә бишенче урында торганы беленгән. Шуның аркасында галимнәр бу дүрткел рәсемнең һәр ике исемдә дә [п] авазын белдерә торган

[1] Жан-Франсуа Шампольон (1790–1832) – француз шәрыкшинасы, Мисырны өйрәнү фәнен нигезләүче. Шампольонның 1822 елның 14 сентябрендә Розетта ташын укуга ачкыч табуы Мисыр иероглифларын укырга мөмкинлек бирә.

[2] Шуның белән бергә бу галим аңарчы һичкемгә мәгълүм булмаган борынгы Мисыр теленең лөгатен, грамматикасын да төзи алды. Бөтен Мисыр язуын бик күп галәмәтләр белән бергә изах итә алды. Мисыр тарихының хронологик якларын да шул галим, гомумән, карарлаштырды (Шампольон 1832 дә 41 яшендә вафат). *(Авт. иск.)*

[3] Птолемей V Эпифан – б. э. к. 205–180 еллар тирәсендә Мисыр патшасы.

[4] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*

бер галәмәт булганын аңлаганнар. Ниһаять, шулай итеп, Мисыр язуында [п] авазының галәмәте дүрткел рәсем булганлык карарына киленгән. Шушы юл белән бу исемнәрдәге башка сурәтләрнең дә кайсы авазларга галәмәт булганлыклары ачылган: элмәк (петля[1]) рәсеме – калын [о] (о)ны, арыслан сурәте – [л]ны, алма агачы яфрагы да – [и]не вә илх... белдерә торган галәмәтләр икәнлеге кәшеф ителгән.

Шул рәвешчә, ниһаять, Шампольон дигән галим аркасында иероглиф язуларны укуның беренче ачкычы табылып, шуңанчы фән дөньясында һичбер юл белән дә чишелә алмыйча торган озак тарихлы, иң кыен бер төен тәмам чишелә алды. Моның белән бөтен кешелек дөньясындагы язу – әлифба тарихларын, аның тәрәккый баскычларын дөрес билгели алуның да киң юлы тәмам ачылып бирелгән булды.

Мисыр язуы иң борынгы бер заманда текә (гомуди), ягъни югарыдан аска һәм уңнан сулга язылган, иероглиф сурәтләр исә уңга табан каратылган булганнар.

Фәкать соңыннан, өфкый ятынкы бер рәвешкә әйләнеп, безнең хәзерге язуыбыз кебек уңнан сулга табан языла торган булып калган[2].

**Кытай язуы.** Иероглиф язуының икенче төре – хәзерге кытай язуыдыр. Кытайлар да, әйбер язуы һәм рәсем язуы баскычларын үтеп, ниһаять, сурәт язуы баскычына килеп бастылар. Ләкин болар, мисырлылар шикелле, аннан арыга китә алмадылар. Әсасән, шул сурәт (фигура) язуы баскычында тукталып калдылар. Хәзерге көндәге кытай язуы да шул әсасдагы бер язу, ягъни аларда хәзердә дә һәрбер иҗеккә яки һәрбер авазга бер галәмәт түгел, бәлки һәр сүзгә бер галәмәт йөртелә, икенче төрле әйткәндә, аларда язу галәмәтләре ялгыз бөтен сүзләрне генә белдерәләр.

Дөрес, бу галәмәтләр – аларда хәзер дә әүвәлге сурәт язуыннан бик күп кыскартылган, җиңеләйтелгән галәмәтләр. Ләкин бу язуның төп корылышы, әсасы һаман да моннан ничә мең еллар элгәре кабул ителгән бер әсас – бөтен сүзгә бер сурәт йөртү әсасы (23 нче шәкел).

Хәзерге кытай язуының беренче әсасы галәмәтләре миладтан 2650 ел элек кытай галиме Сан Ки дигән бер кеше тарафыннан иҗат ителгән. 23 нче шәкелдә ачык күренеп торганча, бу галәмәтләр

[1] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*
[2] Профессор В.В. Струве. «Происхождение алфавита», б. 21, 22. *(Авт. иск.)*

| Мәгънәләре | Кытайча исемнәре | Хәзерге галәмәтләр | Сан Ки галәмәтләре |
|---|---|---|---|
| кояш | жи | 日 |  |
| тау | шан | 山 |  |
| эт | клуан | 犬 |  |
| ат | ма | 馬 |  |
| бала | тесзә | 子 |  |
| авыз | коу | 口 |  |

23 нче шәкел. *Кытай язуының борынгы һәм хәзерге галәмәтләре*

төрле нәрсәләрнең-әйберләрнең сурәтләреннән гыйбарәт булганнар. Аның тарафыннан барысы шундый 540 галәмәт, тугрысы – сурәт алынган булган. Ләкин соңыннан бу галәмәтләр янә дә күп арттырылганнар. Гәрчә язуларында шулар эченнән барысы 30–40 мең генә кулланылып килгән булса да, шушы галәмәтләрнең барысы, бара торгач, хәтта йөз меңгә җиткерелгән булган. Әмма алар да хәзердә шуларның фәкать 4–5 мең генә белү дә гади язу кирәкләрен тәэмин итү өчен җитәдер.

Хәзерге кытай язуында, мәсәлән, 犬口 рәвешендә язылса, бу – эт һәм авыз дигән сүз була. Моны да, укыганда, «өрү» мәгънәсендә укыйлар.

Әмма 口子 рәвешендә язу «авыз» һәм «бала» дигән сүз булып, моны алар «кычкыру» мәгънәсендә укыйлар; авыз һәм кош – «сайрау» мәгънәсендә була.  – «терек кеше»,  – «үлек кеше»,  – «югарыда»,  «түбәндә» дип укыла вә илх... Кытай язуы югарыдан аска табан һәм уңнан сулга языла.

Кытайлар ничөн язуның мондый бик кыен бер баскычында туктапып калганнар? Моның төп сәбәбе – кытай халкының телендә, ягъни кытай теленең корылышы, табигате шуны таләп иткән. Чөнки кытай теле, безнең китапның беренче бабында телләр бәхәсендә аңлатылганча, тамыр телләрдәндер. Бу тел бер иҗекле вак-вак кына тамыр сүзләрдән тора. Бу сүзләрнең саннары барысы 450 гә җитә. Болар һичбер үзгәрмиләр дә, төрләнмиләр дә. Төрк телләрендәге шикелле кушымталану да, гарәп телләрендәгечә игъраблану[1] да вә рус телендәге кебек падеж белән үзгәрү дигән нәрсә бу телдә юк. Кыскасы, монда исемнәр һич төрләнмәгән кебек, бездәге сарыф кылыну дигән бер хосусиятне дә без бу телдә күрмибез. Бәлки бу телнең төп хосусияте вә иң әһәмиятле ягы да менә нәрсәдә: мон-

[1] Игъраблану – сүзләрнең төрләнүе.

да һәр сүз, һәрбер тамыр әллә ничә төрле чиксез күп мәгънәләргә малик[1]. Бер сүзнең мәгънәсе хәтта бәгъзән кырыкка җитә икән. Бу мәгънәләр дә сүзләрнең җөмлә эчендә алган урыннарына, башка сүзләр белән ничек катарлашуларына, басым һәм интонациягә карап билгеләнә ала.

Менә шушы сәбәп белән кытай теле хәзерге башка телләрдәге шикелле әлифба язуына күчә алмаган һәм бу хәлендә барса, ул һаман күчә дә алмаячак.

Кытай язуының баш ягы, кытайлыларның үз риваятьләренә күрә, төен язуы булган, диләр. Ләкин галимнәр кытай язуының турыдан-туры болай төен язуыннан килеп чыккан һәм шуннан тәрәккый итеп киткән булуын мөмкин тапмыйлар. А. Конради[2] дигән галим бу язуның баш токымы бигрәк могаһәдәләр ясар өчен бик борынгыдан кулланылып килгән «киртләч язу» (бирк[3]) булырга кирәк дип таба. (Кытай язуының асылы һәм тәрәккыйсе бу галимнең тикшерүләре белән бик яхшы ачылган санала.) Моның өчен дә аның куәтле дәлиле – кытай язуында гомуди-текә сызыкларның саклануыдыр. Кытай язуының тәрәккый баскычлары 25 нче шәкелдә тагын ачык күрсәтелә.



24 нче шәкел. *Хәзерге кытай язуы белән «Берләшегез, бөтен дөнья пролетариаты!» дигән сүз.*



25 нче шәкел

**Чөй язуы.** Кешелек дөньясында тудырылган язуларның бер рәвеше «чөй язуы» (хат михи – клинопись[4] яки клинообразное письмо[5] дип аталган язудыр (26 нчы шәкел).

Чөй язуы системының әсасын башлап тудыручы һәм шуның нигезен салучылар сумерилар[6] булганнар. Ул – түбәндә, шуларның иҗаты.

[1] Малик – ия.
[2] Август Конради (1864–1925) – кытай теле тарихын өйрәнүче немец лингвисты.
[3] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*
[4] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*
[5] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*
[6] Сумерилар – шумер халкы.



26 нчы шәкел. *Бабил патшаның гонваны: «Дөньяның дүрт тарафының патшасы»*

Бу язу Кечек Азия тарихында зур бер киләчәккә малик була алган, ягъни шушы язу системы соңыннан бабил, асур, иран һәм башка берничә төрле борынгы Шәрык халыкларындагы чөй язуы системының әсасы булып калган.

Шулай булгач, бу урында аның әсасын коручы сумериларның кем икәнлекләре турысында азрак тукталып үтәргә туры килә.

Месопотамиянең яки гарәпчә «Бәйнә нәхрәйн» (Тәүратча исеме – Сеннара)ның иң җәнүб олысында (Халдиядә[1]) яшәгән иң борынгы халык – сумерилар булганнар. Хәзерге Яурупа тарих фәне безгә шулай дип күрсәтә. Боларның нәсел вә гыйрыклары[2] турысында хәзергәчә тарихта гомуми рәвештә кабул ителгән катгый бер фикер юк югын. Хәтта бу халыкның үзләрен үзләре ничек дип атаганлыклары, аларның чын исемнәре ничек булганлыгы турысында мәгълүмат таба алмыйбыз. «Сумерис» исеме исә боларның үз исемнәре булмыйча, фәкать Сеннараның җәнүб өлешенә иң соңыннан бирелгән бер исем, диләр. Димәк, бу халык тарихта шул яшәгән урыннарының соңгы бер исеме белән аталып киткән булалар.

Шулай да хәзерге тарихның бу халык турысында биргән мәгълүматыннан менә шуны аңлый алабыз: «Болар арияләләр түгел, самилар дә түгел, болар турысында дөреслеккә якынрак булган бер фаразия булса, ул да – боларның Төркестаннан килгән булулары фаразиясе. XX гасыр башында Асхабад[3] якынында эшләнгән казынулар, Мирвә[4] тирәсендә табылган нәрсәләр уларның туран (төрк) нәселеннән булуларын уйлата. Бәгъзе сәнәдләр[5] аркылы боларның телләре дә тоташма (агглютинирующий[6]) телләр тибыннан булган-

[1] Халдия – Кара диңгез ярында урнашып, Византия империясенә буйсынган тарихи өлкә.

[2] Гыйрыклары – этник составлары.

[3] Асхабад – Ашхабад.

[4] Мерв, Гәүр-кала – Урта Азиядәге иң борынгы шәһәрләрнең берсе. Төрекмәнстан территориясендәге хәзерге Мары шәһәреннән 30 км көнчыгыштарак урнашкан булган.

[5] Сәнәдләр – ышандыргыч дәлилләр, документлар.

[6] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*

лыгын аңлыйлар һәм аларның телләрен магул телләре тармагына кайтаралар.

Төркестаннан болар (сумерилар) миладтан биш мең ел элек бер заманнарда кузгалып, Гарби[1] Иран аркылы үткәннәр һәм Месопотамиягә килгәч, аларның күп өлеше Месопотамиянең җәнүбендә – Халдиядә урынлашып калганнардыр, дип уйлана. Болар монда миладтан элек дүртенче мең елның соңнарында заһир булалар[2]. Бу вакытта болар игенче һәм сәүдәгәр бер халык булып күренәләр. Үсемлекләрне мәдәниләштерергә, хайваннарны ияләштерергә, бакыр һәм алтын эшләүгә дә белгән булганнар. Кирпеч өйләр, кәлисәләр, сарайлар сала алганнар.

Хасил, миладтан элек дүртенче мең ел эчендә сумерилар, һәрхәлдә, Месопотамия (Сеннара)да баш рольне уйнаганнар. Рухи мәдәнияттә дә сумерилар нык бер әсас салганнар. Шул ук сумерилар килгән вакытта ук, Месопотамиягә Гаребтән – Гарәбстаннан яки Сүрия тирәсеннән килеп урынлашкан самилар, монда килгәч, сумериларның шушы мәдәни әсасына нигезләнгәннәр. Чөнки сумерилар һәрхәлдә мәдәнияттә самилардан өстен булганнар. Самилар, бабиллылар белем вә тәҗрибәнең күп өлешен сумерилардан алганнар. Алардан иске китаплар калган. Әнә шуларны бабиллылар укыганнар. Бигрәк тә бабил вә асуриларның язулары, әлифбалары – сумериларныкыдыр. Бабиллылар аны шулардан алганнар. Хәтта сумер телендә сумер язуы белән иң беренче мәртәбә гаибтән[3] хәбәр бирүләр, күк галәменең тәртипләре һәм календарьлар язылган. Әнә шуларны белү өчен, бабиллылар хәтта сумериларның телләрен өйрәнергә мәҗбүр булган. Шуңа изахлар[4], грамматикалар, лөгатьләр[5] язганнар.

Сумерилар бөтен хуҗалык эшләрендә үзләренең язулары белән һәммә килеш вә чыгышларын яза барганнар. Үзләренә күпме ашлык кергәнен, эшчеләргә, ирләргә, хатыннарга, балаларга күпме азык бирелгәнен, кием туку өчен дә күпме йон киткәнлеген – барын да язып торганнар.

Сумерилар дә башта, мисырлылар кебек, һәрнәрсә өчен рәсемнәр ясарга тырышканнар. Ягъни нәрсәләрне дә рәсемнәр

[1] Гарби – көнбатыш.
[2] Заһир булалар – билгеле булалар.
[3] Гаибтән – яшерен, күз алдында булмаган нәрсәләрдән.
[4] Изахлар – аңлатмалар.
[5] Лөгатьләр – сүзлекләр.

белән аңлатудан башлаганнар. Боларның язу галәмәтләре дә Мисыр иероглифларына охшаш бернәрсә булган.

Шушы иске галәмәтләрдән бәгъзеләре шулар:  йолдызны белдерә;  (түгәрәк урынында) кояшны белдерә;  – камыш.

Димәк, бу язу галәмәтләре баштук эшләпәле яки калпаклы кадак вә чөй рәвешендә булганнар. Бәлки сызык рәвешендә язылганнар. Һәм иң әүвәл болар да, мисырлылар кебек, сыйры[1]ф пиктографик бер рәвештә булганнар. Боларда язу материалы да балчык һәм таш булган, йомшак балчыкка язганда, кәгазьгә кара белән язгандагы шикелле бөтен-өзексез сызыклар чыга алмый, әлбәттә. Бәлки бөтен-тигез сызыклар урынына ялгыз очлайган, тигезсез, төрткеле берничә сызыклар гына чыгарга мөмкин. Моннан котылу өчен Мисырдагы кебек боларда папирус кәгазе дә булмаган.

Әнә шушы сәбәпләр нәтиҗәсендә соңыннан, бара-бара, шушы югарыдагы өч төрле галәмәт менә шушы түбәндәге рәвешкә кергәннәр: .

Бабил вә асуриларда болар, тагын да үзгәртелеп, әүвәлге рәсем рәвешләренә бөтенләй башка булган һәм рәсем икәнлеге бөтенләй беленмәслек бер хәлдә шушы түбәндәге рәвешләрне алганнар:  – бусы йолдыз;  – бусы кояш;  – бусы камыш.

Чөй язуының янә дә катлауландырылып, авырайтылып җибәрелүе бигрәк тә бабиллылар – асурилар тарафыннан эшләнгән. Чөнки бер телгә, ягъни сумерилар теленә яраклаңдырылган бер язуны аңа ят булган икенче бер телгә – самилар (бабиллылар) теленә яраклаңдыру кирәк булган, шуның нәтиҗәсендә Бабилның чөй язуы бөтенләй авырлашып, катлауланып китүгә мәҗбүр булган (21 нче шәкел), иң кыен вә буталчык язу рәвешенә кергән. Шуның өчен хәзер дә Бабил язуын уку – галимнәр өчен Мисыр язуын укуга караганда күп кыен бер нәрсә.

Югарыда әйткәнебезчә, сумерилар дәверендә тәрәккый баскычында бу язу да, Мисыр язуы шикелле үк, рәсем һәм сурәт язу дәверләрен уздырган, Мисыр язуы шикелле үк, бу да һәртөрле сурәтләрдән кыскартылып тәрәккый иттерелә барган. Моның тегеләрдән – Мисыр иероглифларыннан аермасы – ялгыз монда сурәтләрнең чөйгә охшаган галәмәтләрдән ясалып китүендә генәдер.

[1] Сыйрыф – тәгәл, фәкать.

Мисыр язуындагы шикелле, башта монда да рәсемнәр, сурәтләр, сүзләрдәге авазлар һәйәтенә (составына) каралмастан, ялгыз бөтен сүзләрне генә белдергәннәр. 27 нче шәкелдә чөй язуының шушы дәверенең үзәге күрсәтелә.

Рәсемнәр астында сулдан уңга: шуның белән бергә бер үк төрле сурәт әллә ничә төрле мәгънәгә йөртелгән. Мәсәлән, кояш сурәте кояшның үзен генә түгел, бәлки шуның белән бергә шуңа мөнәсәбәтле көн, якты, нур илх... мәгънәләрен дә аңлаткан.




27 нче шәкел. *Борынгы чөй язуының сурәт галәмәтләре*

Башта бу язуда да, Мисырның пиктографик язуындагы кебек, һәртөрле нәрсәләр яки һәртөрле хадисәләр[1] шартый[2] вә схемалы рәсемнәр белән аңлатылганнар. Мәсәлән, «кошлар» дигән сүзне язарга кирәк булса, берничә сызыклар белән кошның гәүдәсе һәм аяклары тәрсим кылынган[3]. «Су» ике дулкынлы сызык белән сурәтләндерелгән. Соңра шул ук сызык рәсемнәргә гаклый вә нәзари аңнарны бирә башлаганнар. Аяклар рәсеме – «йөри» мәгънәсен, ике аяк «анда-монда йөрү» мәгънәсен яки «әйләнү» мәгънәсен биргән. Шулай итеп, пиктография, ягъни буяулы матди шәкел язу идеографиягә – мәгънәви рәвеш язуга әйләнгән. Моның алдынгы адымы да сызыкларның аваз системына (иҗек һәм әлифба ысулына) күчү булган. Тавышлары, әйтелешләре бер булган сүзләр (әлфаз мөтәрадиф[4]), гәрчә төрле мәгънәләрне аңлатсалар да, бер үк төрле галәмәт белән язылганнар. Рәсемнәр аерым-аерым иҗекләрне сурәтләндерә башлаганнар (бу иҗекләр теләсә кайда килсә дә шулай булган).

Чит бер телгә – Бабил теленә алынганнан соң, инде бу галәмәтләр иҗекләргә галәмәт кылынуда саташтырылып җибәрелгәннәр, мәсәлән, йолдыз галәмәте сумерча «күк» һәм «Алла»ны белдергән вә үзе «ан» дип әйтелгән. Бабилча бу галәмәт шул ук «күк» һәм «Алла» мәгънәсен биргән, ләкин бу сүзләр боларда «шәми» (шәмс), «илү» (илаһи) дип әйтелгәннәр. Шулай булганы хәлдә, шул ук хәрефне-галәмәтне бабиллылар «ан» дигән иҗекне язуга галәмәт итеп алганнар.

[1] Хадисәләр – күренешләр.
[2] Шартый – шартлы.
[3] Тәрсим кылынган – сурәте ясалган.
[4] Биредә ялгышлык иткән: «мөтәрадиф» гарәпчәдән «синоним» дип тәрҗемә ителә, дөресе «мөҗанис» (омоним) булырга тиеш.

Чөй язуының Бабилда артык кыенлашуы бер яктан менә шушы юлда булган. Бабил хәрефләре, чиксез күбәеп, барысы 12 000 чамасында булганнар. Аларны хәтергә алу да бик кыен булган. Бабил әлифбасы белән юлдаш булып, шуны хәтерләтә торган дип, кытай әлифбасын күрсәтәләр (монда бар галәмәт 50 000 гә җитә).

Чөй язуының Бабилда һаман кадак-чөй рәвешендә тәрәккый итә баруының бер сәбәбе янә язу материалының балчыктан гыйбарәт булуыдыр. Җәнүби Месопотамиядә Мисырдагы кебек папирус булмаган, таш та бик аз булган. Шуның өчен бу язу тәрәккый итә барган саен, һаман шул кулдагы материал – балчык белән генә эш итәргә туры килгән. Шуннан кечкенә такталар әзерләнгән, балчыклар кибеп җитмәс борын, шуңа кечкенә таяк яки үткен бер чыбыклар белән иероглиф галәмәтләрне чокып төшергәннәр. Йомшак балчык, тиз һәм бик табигый уларак, рәсемнәрнең кысылуларына, кыскартылуларына имкян биргән. Шуның белән бергә балчыкка сызылган сызыклар бер ягы очланган сызыкчалар, ягъни, чыннан, чөй – эшләпәле кадак рәвешен алып киткәннәр. Шушы чөй рәвешендәге галәмәтләр, язуны ташка яза башлаганнан соң, шул хәлләрендә сакланып калганнар.

Бабиллыларда әллә никадәр бер-берсе өстенә салынган кирпечләрдән гыйбарәт китаплар булган. Месопотамиянең (Бәйнә нәхрәйннең) иске шәһәрләре урынында яурупалылар зур бер кирпеч көтепханә тапканнар. Бу да – Бабил белән күрше булган Асури патшалыгына гаид бер көтепханә. Асурилар Бабил фән вә сәнгатен алганнар.

Чөй язулары укуның беренче муаффәкыятьле тәҗрибәләре XIX йөзнең урталарында башлана. Кечек Азия – Анатолида Бабил мәдәнияте галәбәле бер рәвештә таралган булган. Хәтта шул җәһәттән финикә[1] әлифбасы шушы бөек Бабил мәдәниятенә барып бәйләнмиме икән, дигән бер фикер дә торган. Хакыйкатән, чөй язуы, финикә әлифбасы иҗат ителеп мәйдан алганчы (1200 еллар тирәсендә), Гарби Азиянең хәтта бөтен халыкларында һәртөрле телләрнең язуы булып йөртелгән.

Чөй язуы башта Мисыр һәм кытайлыларныкы кебек югарыдан аска һәм уңга табан язылган. Соңыннан аны асури кәлданилар (ба-

[1] Сүз б. э. к II меңьеллык уртасында барлыкка килгән Финикия язуы турында бара.

биллылар) хәзерге Яурупа язулары кебек сулдан уңга әйләндергәннәр. Бу – аларның иҗаты булган.

Менә шулай итеп, чөй язуы ахырда ятынкы (өфкый) юллар булып, һаман уңнан сулга табан язылып китә биргән.

Чөй язуы, ниһаять, миладтан элек VI гасырда иранлыларга күчә. Алар моны үзләренә кабул итәләр дә аны тагын да кыскарта, җиңеләйтә һәм камилләштерәләр. Бабил язуының дүрт әсаси галәмәтләрдән фәкать икесен генә, ягъни чөй белән почмакны гына алып, шулардан утыз алты галәмәт ясыйлар һәм шуларны хәреф урынына йөртәләр (28 нче шәкел) вә үзләреннән, иранлыларның әйтүенчә (тәләффез итүенчә), «Һөрмезд»[1] сүзе чыга торган берничә хәрефләрнең үрнәге күрсәтелә.



a-u-r(a)-m(a)z-d(a)-a.

28 нче шәкел. *«Һөрмезд» сүзенең чөй язу белән язылуы*

Бу шәкелдә һәр хәрефнең астына бер сызык сызылган. Хәрефләр сулдан беренче – [а] икенче – [у], өченче – [р], дүртенче – [м], бишенче – [з], алтынчы – [д], җиденче – [а].

Моннан күреләә ки, иранлылар мисырлыларга караганда әлифба язуына тагын да якынлаша төшкәннәр. Ләкин әле һаман хәзерге кебек әлифба язуы баскычына кадәр тәрәккый итә алмаганнар. Әмма шул баскычка җитүнең иң беренче мөһим адымы булган бер юлны болар, ягъни мисырлылар белән асури вә иранлылар сала алганнар. Ул да булса сүзләрне – иҗекләргә, иҗекләрне дә авазларга аера белүләре һәм язуларын шул юлга куюларыдыр.

**Һитит[2] язуы.** Иске Шәрыкның язуга малик вә мәдәниятта югары торган халыкларыннан берсе – һититләрдер. Боларның яшәгән урыннары Анатолида җәнүб вә шәрыктан Турус (Товра) тавының дугаланып әйләндереп алган бер җирендә күрсәтелә. Мәркәзләре дә (пайтәхетләре) Кызыл ермак (Малис) елгасының баш агымында булып, болар шунда иң элек вак-вак мөстәкыйль феодаль билек (кенәзлек) тәшкил иткәннәр. Ниһаять, миладтан элек XIV йөздә болар көчле бер хәрби феодал дәүләт булып үзгәргәннәр дә, соңра яхшы җир эзләү яки шимальдән бәгъзе халыкларның кысулары буенча шәрыкка һәм җәнүбкә табан хәрәкәт башлаганнар.

[1] Һөрмезд – борынгы Иранда яхшылык алласы.
[2] Һитит язуы – хетт язуы.

Мисырлыларны Фрат елгасы[1] буеннан кысып һәм алардан шимали Сүрияне алып, хәтта Ханган тирәләренә кул сузганнар[2].

Хәзерге Яурупа тарих фәне боларны да Урта Азиядән, Төркестаннан күчеп килеп утыручылар дип күрсәтә. Болар, Төркестаннан Хәзәр диңгезенең җәнүб як буйлары белән таулар аша һәм Әрмәния аркылы үтеп китеп, Анатолига баягы әйтелгән җирләргә барып урынлашкан булалар.

Тышкы кыяфәтләре, киемнәре һәм гореф-гадәтләре белән дә боларны Урта Азиянең – Төркестанның хәзерге күчмә халыкларына охшый дип табалар. Чәчләрен кырып, фәкать артка, аркага табан толымлап үреп төшерү өчен бер учмадай гына калдырулары, башларына очлы бүрек, өсләренә дә киң, озын киемнәр киюләре, кысык күзле булулары кебек хәлләре шундый сыйфатларыннан санала.

Ләкин чынында һититләрнең антропология һәм лингвистика ягыннан кайсы гыйрыктан икәнлекләре – әле тәмам катгый рәвештә билгеләнеп җитмәгән бер мәсьәлә[3]. Боларның тарихлары, мәдәниятләре турысында мәгълүмат бик тар. Язулары да әле һаман укыла алмый тора. Шулай булса да, бу халыкның мәдәни тәэсирләре бөтен Анатолига җәелгән булгандыр дип уйлана.



29 нчы шәкел. *Мессершмидт буенча һитит язуы*

Һитит язуында барысы 35 төрле язу – хатирә табылган. Язу да кеше һәм ерткычлар вә, гомумән, хайван (мәсәлән, куян кебек) вә кошлар башы, кул-аяк сөякләре, аяк

[1] Фрат – хәзерге Төркия, Сүрия һәм Ирак территорияләреннән ага торган елга.

[2] Бабил миладтан элек 1925 йөздә һититләр тарафыннан алынган вә харап ителгән. Морэ һәм Ж. Дави. На заре истории. Б. 131. *(Авт. иск.)*

[3] Боларны ариялеләрдән диючеләр дә бар. Ләкин бу бик зәгыйфь бернәрсә санала. *(Авт. иск.)*

табаны һәм кылыч кебек сурәтләрдән гыйбарәт. Болардан башка тагын үзләрен билгеләү әле мөмкин булмаган һәртөрле нәрсәләрнең сурәтләре дә бар. Һитит язуының Мессершмидт[1] буенча бирелгән үрнәге 29 нчы шәкелдә күрсәтелә.

Һитит язуының хәзер дә бик аз галәмәтләрнең мәгънәләрен генә билгели алуны мөмкин саныйлар. Аларның әйтелүләре янә һичбер төрле беленә алмаган бер хәлдә кала әле.

**Әлифба язуы.** Гареб һәм Шәрыктагы хәзерге язулар әлифба язуы дип атала. Әлифба язуы яки хәрфи язуның төп хосусияте шул: монда һәрбер галәмәт яки һәрбер хәреф фәкать сүзләрнең билгеле бер авазларын гына белдерә.

Соң, бу әлифба язуын башлап кемнәр чыгарган? Аның асылы-тамыры кайда? Ул кайдан һәм кемнәрнең язуыннан алынган?

Хәзерге бөтен Шәрык вә Гареб халыкларының әлифба язуы яки хәрфи язулары һәммәсе финикә әлифбасыннан алынып үзгәртелеп эшләнгән. Аларның төп тамыры яки төп аталары әнә шул булган. Бу – шулай. Мәсьәләнең бу ягында низаг юк. Фән дөньясында бу – байтактан дөрес дип табылып килгән бер фикер.

Ләкин финикә әлифбасын һәм төп әлифба тудыру идеясен үзен башлап кемнәр тудырган? Соң вакытларгача фән дөньясында тиз чишелә алмый торган иң төенле, иң караңгы бер мәсьәлә шушы мәсьәлә булып килде. Шуның өчен бу мәсьәләдә төрле фикерләр булды. Бәгъзе галимнәр әлифба язуын башлап финикәлеләр үзләре тудырды, дисәләр, бәгъзеләрдә кешелек дөньясындагы бер зур иҗатны тудыручыларны борынгы Шәрык мәдәниятенең ике почмагыннан эзләргә тотындылар: моны я мисырлылар (Тацит[2] вә Геллий[3] фикере) яки бабиллылар (кәлданилар) – асурилар (Плиний[4] фикере) тудырган булыр, дигән бер фикергә төштеләр. Бәгъзеләр дә финикә әлифбасы һитит язуыннан дип уйладылар.

---

[1] Даниэль Готлиб Мессершмидт (1685–1735) – Россиягә хезмәт иткән немец медигы һәм ботанигы. Себергә беренче фәнни экспедиция җитәкчесе, петроглифларны башлап ачучы.

[2] Публий (Гай) Корнелий Тацит (50 еллар уртасы – якынча 120) – борынгы Рим тарихчысы.

[3] Гней Геллий – б. э. к. II гасыр уртасында яшәгән борынгы Рим тарихчысы.

[4] Сүз 22/24–79 елларда борынгы Рим тарихчысы Өлкән Плиний турында бара булса кирәк.

Г. Шнейдер, инглиз Артур Эванс[1], Джордж Смит[2] белән бергә Карл Вейле[3] әлифба язуын Кипрның күршесе һәм Кечек Азия – Анатоли кыйтгасына якын торган Крит утравында иҗат ителгән, ул – борынгы Крит мәдәниятенең җимеше, дигән фикерне куәтли вә шуңа дәлил китерәләр. Шуннан фәләстыйнлылыр аркылы Урта диңгез (Бәхре сәфид) ярларына китерелгән. Болардан да финикәлеләр һәм яһүдләр алган була. Боларча критлыларда бер – шәкел яки иероглиф; икенчесе дә фонетика – аваз әсасында сызыклы язу булып (30 нчы шәкел), финикә әлифбасының анасы – менә шушы язудыр. (Боларның фикерләре турысында тәфсилле мәгълүмат Карл Вейленың «От бирки до азбуки» дигән әсәрендә бар. 36 дан 44 кәчә һәм 65 нче биттә).

Шуның белән бергә шул юлда яңадан күп тикшерүләр, күп эзләнүләр башланып китте. Мисырның иероглиф язуларын, Асури, Бабилнең чөй язуларын укуга, шуларны укуның ачкычын табып алырга ныклап тырышыла башланды. Ахырда француз галиме Шампольон Мисыр язуын укуга тәмам муәффәкъ булды. Шул зур муәффәкыять бер төенле мәсьәләне чишеп алу өчен фән дөньясында иң беренче зур бер адым булып чыкты. Моның аркасында Мисыр, Финикә, Бабил язуларын вә хәтта җир йөзендәге бөтен язуларны бер-берсе белән чагыштырып карау өчен дә киң бер юл ачылды, XIX йөзнең урталарында чөй язуын уку тәҗрибәләренең муәффәкыяте дә моңа күп ярдәм итте. Лидзбарский[4],



*Сурәт язуы* *Сызыклы язу*

30 нчы шәкел. *Борынгы Крит язуы*

[1] Артур Джон Эванс (1851–1941) – инглиз тарихчысы һәм археологы.

[2] Джордж Смит (1840–1876) – инглиз ассириологы. «Гөлгәмеш» эпосын инглиз теленә тәрҗемә итә, кипр язуына ачкыч таба.

[3] Карл Вейле (1864–1926) – немец этнографы һәм борынгы җәмгыятьне өйрәнүче.

[4] Марк Лидзбарский (1868–1928) – немец галиме, семитология белгече.

Гардинер[1], Каули[2] һәм Сейте[3] вә ахырда профессор Струве кебек галимнәр бу турыда мәсьәләне үзләренең фәнни тикшерүләре белән ачып җибәрделәр.

Шулай итеп, ниһаять, нәтиҗәдә элифба язуы яки хәрфи язу идеясен башлап тудыручылар һәм элифба язуының үзен мәйданга китерүчеләр, ягъни аны иҗат итүчеләр финикәлеләр түгел, бәлки мисырлылар, ягъни сами халыклары, яһүдләр булганлык беленде.

Шушы XX гасырыбызның башларында Турсинай ярымутравында табылган Сина язулары (Синайские надписи[4]) бу урында фәнни тикшерүләрнең юлларын тагын да яктыртып җибәрде. Мисыр, Финикә, кәлдан (Бабил) язуларын бер-берсе белән чагыштырып карап, шулардан чыгарыла килгән нәтиҗәләрнең тәмам дөрес, туры икәнлеге шушы Сина язулары белән тагын бер кат тасдыйк ителгән[5] булды. (Бу турыда зур хезмәт куючылар: сами язуларын иң яхшы белүчеләрдән Лидзбарский, мисыршинас инглиз галиме А.Г. Гардинер (Сина элифбасын укып изах итүче), самиларны тикшерүче инглиз галиме Каули һәм Сейте вә, ниһаять, профессор В.В. Струве булдылар. Шулар бу хакта мәсьәләне фәнни бер юлда ачып бирә алдылар.

Шулай итеп, бу юлда хәзергәчә булган фәнни тикшерүләрнең иң соңгы нәтиҗәләре безгә элифба язуы тудыруның һәм аның бөтен мәдәни халыкларга таралуының туры тарихи бер сызыгын түбәндәгечә ачык билгели алды.

Әлифба язуы Мисыр язуы әсасында иң элгәре сами ыругыннан булган халыклар, ягъни бәни Исраил – яһүдләр тарафыннан тудырылган. Әлифба язуының төп әсасын шулар салганнар. Бу да сами әүляды[6] вә бәни Исраил халкының Мисырга барганнарыннан соң булган. Алар Мисырдан чykканда, бу язу алар белән бергә Фәләстыйнга китерелгән. Монда килгәч, инде бу язу анда үзенең соңгы тәрәккыйсен дәвам иттергән һәм ул анда тагын да камилләштерелә алган. Соңра ул Фәләстыйннан бөтен җир йөзенә таралган.

[1] Алан Хендерсон Гардинер (1879–1963) – инглиз лингвисты, мисыршинас.
[2] Артур Эрнест Каули (1861–1931) – инглиз шәрыкшинасы.
[3] Сүз Курт Зете (1869–1934) – Мисырны өйрәнүче немец галиме турында бара булса кирәк.
[4] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*
[5] Тасдыйк ителгән – расланган.
[6] Әүляды – нәселе.

Шуннан җир йөзендә әлифба язуының мөстәкыйль рәвештә дүрт төрле гаиләсе мәйданга килгән. Алар менә шулар: 1) Сами әлифбасы; 2) иран әлифбасы; 3) һинди яки ария әлифбасы; 4) Яурупа яки Юнан-Италия әлифбасы.

Урта диңгез (Бәхре сәфид)нең шәрык кырыенда яшәүче Финикә халкы янә шушы сами әлифбасын җир йөзенә таратучы булды. Заманнарында Урта диңгез кырыендагы сәүдә эшләрен үз кулларында әйләндерүче бу халык, шушы сами әлифбасын кабул итеп, аны иң элек Яурупага, ягъни Юнанстанга[1] күчерделәр. Бу эш миладтан 9–10 гасырлар чамасы элек булды.

Юнанстаннан инде бу әлифба бөтен Яурупа халыклары арасына таралып китте (юнаннар бу әлифбага үзләренең сузынкы авазлы хәрефләрен арттырганнар).

Димәк, Мисырның иероглиф әлифбасы соңгы финикә әлифбасы өчен төп үрнәк булган (Шампольон). Финикә әлифбасы, Дазоче нәзариясенчә, Мисырның папирусларга ашыгыч языла торган иероглифларына, ягъни һиератив хәрефләргә барып баглана.

Финикә әлифбасында дүрт хосусият табалар: 1) монда чыннан әлифбалык бар[2], ягъни монда кешенең бөтен сүзләре фәкать 22 хәреф белән языла ала; 2) финикә әлифбасында сузынкы хәрефләр юк. Монда бөтен хәрефләр ялгыз тавышсыз авазларны, ягъни сузылмый торган авазлар гына белдерәләр. Сузынкы авазларны язу бу әлифбада һич игътибарга алынмаган; 3) финикә әлифбасында күп хәрефләрнең исемнәре конкрет нәрсәләрне белдерә. Мәсәлән: *а* ның исеме «әлиф» – «үгез» дигән мәгънәдә, *б* ның исеме «бәйт» – «өй» мәгънәсендә, *д* ның исеме «дәл» – «ишек», *в* ның исеме «уау» – кадак, *и* нең исеме «йәд» – кул, *к* нең исеме «кяф», ягъни кул эче, ягъни уч, *м* ның исеме «мим» (маи) – су, *н* ның исеме «нун» – балык, *г* ның исеме «гъәйн» – күз, *р* ның исеме «рәш» (рәис) – баш, *с* ның исеме «син» (сен) – теш илх... мәгънәләрендәдер; 5) финикә язуының иң характерлы бер хосусияте – аның уңнан сулга таба язылып баруы.

Хәрефләрнең финикә ягыннан булган мәгънәләре окрофоник (окрофонический)[3] бер әсәста: хәрефләрнең исемнәрендәге беренче авазлар шул ук вакытта әлеге хәрефләрнең фонети-

[1] Юнанстан – Греция.
[2] Шампольонча, бу хосусият – Мисыр әлифбасының җаны. *(Авт. иск.)*
[3] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*

ка мәгънәсе булган. Мәсәлән, «бәйт» дип аталган хәреф – *б* га, «дәл» дип аталган хәреф – *д* га, «уау» дип аталган хәреф тә *в* га куелган.

Финикә әлифбасындагы менә шушы биш хосусият, ягъни 1) әлифбалык, 2) авазландыруның, ягъни сузынкы авазлы хәрефләрнең юклыгы, 3) хәрефләрнең пиктографик бер сурәттә булуы, 4) окрофоник әсаста булуы, 5) уңнан сулга табан язылулары иероглиф, ягъни әсаси язуларда да табыла торган хосусиятләрдән.

Финикә язуларының Мисырның иероглифыннан һәм дә шул рәвешчә сами халкының иҗатыннан булганлыгы шушы рәвешчә биш яктан каралып исбат ителә. Шуңа тагын Мисырның әллә ничә йөз иероглифлары эченнән 24 е нәкъ финикә әлифбасындагы хәрефләр булганлыгы кушыла.

Менә шушы дәлилләр белән финикә әлифбасының Бабил язуыннан, ягъни чөй язудан алынганлык фикере дә кире кайтарыла. Чөнки чөй язуда әлифбалылык (алфавитность[1]) юк, ул хәреф дигәнне белми. Ул фәкать саф идеограммалар белән бергә ничә йөз иҗек галәмәтләре генә тудырган. Тагын чөй язуда авазландыру, ягъни сузынкы авазларның галәмәтләре бар. Бу язуда *а, е, и, у, ы* дан гыйбарәт биш сузынкы аваз вә хәреф бар. Шуның өстенә бу язуда галәмәтләр пиктографик сурәтләрен югалтканнар; монда окрофоник әсас та юк. Янә монда язу сулдан уңга табан бара.

Шул хәлдә: 1) иҗеклелек, 2) авазландыручылык, 3) галәмәтләрнең пиктографик рәвешләрен югалткан булучылыклары, 4) окрофоник әсасында юклыгы, 5) сулдан уңга таба язылу кебек төп хосусиятләр чөй язуын финикә язуына әсас һәм аның анасы булмаган икәнен ачык күрсәтә торган хосусиятләреннән булып каладыр. Икенче төрле әйткәндә, чөй язуының бу хосусиятләре аны сами халкының әлифба язуыннан тәмам аерып ташлый. Шуның өчен дә бу әлифбаны (чөй язуын) тудыручылар сами ыругыннан булмаган халыклар – сумерлар тудырган дип табыладыр. Асыл бабиллыларкәлданилар, ягъни аларның җирләренә кереп утырган самилар бу язуны шулардан алганнар.

Фәкать бу турыда шуны да әйтеп үтү кирәк: финикә әлифбасындагы әлифба тәртибе мисырлыларда күренми. Хәтта мисырлыларның әлифбаларын нинди тәртиптә санаганлыклары турысында

[1] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*

дөрес мәгълүмат та табылмый. Иероглифларны санау системын безгә саклап калдыручы соңгы папирус язулары да иероглиф хәрефләрне финикә хәрефләренә башка бер тәртиптә саныйлар.

Сами әлифбасының Мисыр әлифбасыннан алынганлыгын да бигрәк соңыннан Сина ярымутравында Вадий мәгарә[сен]дә табылган унбер төрле язу ачып бирә. Менә мондагы язулар да иероглифтан алынганлыкларын вә сами әлифбасы булганлыкларын күрсәтәләр. Бу язу вә аларда үгез башы (әлиф), өй (бәит), кадак (уау), кул (и), су (мим), күз (г) һәм баш – рәис (р) сурәтләре бар икәнлек беленгән. Болардан янә синай әлифбасын тудыручыларның галәмәтләрне иероглиф язудан сайлап алган икәнлекләрен аңлыйлар. Бу галәмәтләр үзләре – нәкъ финикә әлифбасындагы хәрефләрнең исемнәренә муафикъ булган нәрсәләрнең сурәтләре. Менә шуның өчен генә дә синай әлифбасының аннан соңгы финикә әлифбасы белән багланышлы икәнен ачык күрсәтә торган бер таяныч дип табыла (язылуда исә уңга да, сулга да язылганнары бар).

Хасил, тикшерүләр нәтиҗәсендә синай хәрефләре үзләреннән соңгы сами әлифбаларының вә шул җөмләдән финикә әлифбасының да атасы икәнлеге галимнәр тарафыннан исбат ителә. Шуның өстенә моның белән янә сами әлифбасының Баби мәдәнияте җимеше түгел, бәлки Мисыр мәдәнияте җимеше булганын тәкрар тәэкид итәләр[1].

Синай әлифбасын иҗат итүчеләрнең кемнәр икәнлеге турысында профессор В.В. Струве үзенең «Происхождение алфавита»[2] дигән әсәрендә (1923 елда басылган) шундый бер фәнни карарга килә: синай әлифбасын тудыручылар, шөбһәсез, самилар булганнар. Моны безгә синай әлифбасының финикә әлифбасы белән багланышы булуы да ачык исбат итеп тора. Ләкин бу самилар кайсы самилар иде? Синайның үзенең җирле самилары шундагы бәдәвиләр идеме, әллә болар башка бер самилар идеме? Һәрхәлдә, бу әлифбаны Синайның җирле самилары – бәдәвиләр тудырган булу – ихтималлары һәр яктан ерак бер нәрсә.

Бу синай әлифбасын төзүчеләр, һәрхәлдә, күп вакытлар Мисырда яшәп тә, шуннан соң аннан Синайның Вади мәгарәсенә килеп төшкән самилар булгандыр. Бу самиларның да Мисырда булулары

[1] Тәкрар тәэкид итәләр – тагын бер кат раслыйлар.
[2] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*

һиксуслар хакимияте дәверенә, ягъни миладтан элек 1650–1750 еллар тирәсенә туры килә[1]. Шушы дәвердә Мисыр сами халкының һөҗүме астында калды. Боларның шул вакыттагы башлыклары да мисырлыларның тарафыннан «һиксус», ягъни чит халык мәмләкәтенең хакимнәре дип аталдылар.

Менә шушы сами халыклары Мисыр мәдәнияте вә иероглиф әлифбасының идеясе белән тәмамән танышып һәм аңа тәмам ия булып алдылар. Үзләренең милли исемнәрен дә иҗек галәмәтләре белән түгел, тик әлифба хәрефләре белән яздылар. Бәлки, Мисыр әлифбасы белән шушы танышу тәэсире астында һиксусларның кәнсәләрияләрендә Синай нәмунәсе[2] сакланган әлеге язу тудырылган булгандыр. Мисырның үзендә исә һиксуслар хакимияте хатирәләре харап булган. Әмма Синай таулары арасында һиксусларның гаскәрләре тарафыннан китерелгән хатирәләр монда сакланып кала алганнар.

Хасил, профессор Струвеның исбаты буенча, Синай әлифбасының тудырылу тарихы һиксуслар дәверендә булуы катгыйлык дәрәҗәсенә килә.

Шул ук профессор фикеренчә, һискуслар дәүләте мөнкарыйз булганнан соң[3] , бу сами әлифбасы Фәләстыйнда дәвам итә, анда ул һаман андагы чөй язуын кыса бара. Бу әлифба язуының мәркәзләреннән берсе дә Дебир шәһәре булып, иске сәмави китапларның бәянынча, аны яһүдләр килеп алганчы, ул «язу шәһәре» дип аталган була. Монда (Фәләстыйнда) Синай әлифбасының борынгы галәмәтләре үзләренең әүвәлге рәвешләрен саклап бара алмаганнар, бәлки заман үтүе белән үзгәреп, беренче мең ел эчендәге финикә язуларының хәрефләре рәвешендә ныгып калганнар. Әмма бәгъзе вакытларда җәнүби сами әлифбасы борынгырак, искерәк рәвешләрен саклый алганнар. Бер дә сами хәрефләре баш сами әлифбасы тамырыннан биннисбә[4] иртәрәк аерылган булу белән изах ителә. Ихтимал, шул ук вакытларда юнанлылар финикәлеләрдән аларның әлифбаларын

[1] Мисыр номад-һиксуслар тарафыннан 1680 еллар тирәсендә сугышып алынган. А. Морэ һәм Ж. Дави тарафыннан төзелгән «На заре истории» дигән китап. 133 б. *(Авт. иск.)*

[2] Нәмунәсе – өлгесе, үрнәге.

[3] Мөнкарыйз булганнан соң – инкыйразга дучар булганнан соң.

[4] Биннисбә – чагыштырмача.

алганнардыр[1]. Юнанлыларның финикәлеләрдән алган исемнәре финикә хәрефләренең исемнәре белән бертөрле булу мәгълүм. Ләкин шуның белән бергә бәгъзән юнан хәрефләре җәнүби сами әлифбасын да искәртеп куя.

Синай язуы үзенең финикә, җәнүби сами һәм юнан әлифбасы тармаклары белән бергә юнан язуының алдынгы бөтен тармакларында баш тамыры булган.

### Яһүд-финикә әлифбасының гаиләләре

**Сами гаиләсе.** Яһүд-финикә әлифбасыннан дүрт төрле әлифба гаиләсе туганлыгын югарыда әйтеп үткән идек. Шуларның берсе – сами гаиләсе.

Сами гаиләсеннән булган әлифбалар хәзерге вакытта башкаларга караганда тагын да яхшырак тикшерелгән әлифбалардан санала. Бу турыда Гезениус[2], Ренан[3], Уогини, Уоддингтон һәм шулай ук Леви, Шлютман, Шрадер[4], Нёльдеке[5] кебек галимнәр аеруча зур хезмәт күрсәттеләр.

Сами әлифбалары – бик күптөрле булып, аз бер истисна[6] белән һәммәсе бер үзәкнең тармаклары, ягъни һәммәсе арами әлифбасының балалары. Арами әлифбасы үзе исә яһүд-финикә әлифбасыннан, шуның тәрәккый нәтиҗәләреннән берсе булып торган.

**Арами әлифбасы.** «Арам» – яһүд сүзе булып, сами ыругыннан яһүдләргә нәселдәш булган бер халык шул исем белән аталып киткән. Коръәндә әйтелгән арам халкы вә гад кавеме – шулар[7]. Болар

[1] Яурупада әлифба иң элек Юнанстанда заһир булды. Монда ул миладтан элек IX–X гасырлар тирәсендә финикәлеләр тарафыннан китерелде. Ләкин финикәлеләр бу әлифбаны кайдан алганнар? Менә бу – әле ачык карарлаштырылмаган бер мәсьәлә. В.А. Правдолюбовның «История письма» дигән әсәре. 49 б. Ләкин «финикәлеләр бу әлифбаны кайдан алган?» дигән мәсьәләнең инде без профессор Струвеның исбатларыннан тәмам ачылган вә катгыйлашкан икәнен югарыда күрдек. *(Авт. иск.)*

[2] Вильгелм Гезениус – немец шәрыкшинасы.

[3] Чыганакта «Денан» дип язылган. Биредә сүз француз галиме, сәмит телләре белгече Жозеф Эрнест Ренан (1823–1892) турында бара булса кирәк.

[4] Эберхард Шрадер (1836–1908) – немец семитологы, немец ассириология мәктәбенә нигез салучы.

[5] Теодор Нёльдеке (1836–1930) – немец шәрыкшинасы, филолог һәм тарихчы.

[6] Истисна – чыгарылма.

[7] Вә кәнә йукалү ли-Гад Ирам. Фә ләммә һәләкәт кыйлә ли-Самуд Ирам. Сүммә сүммәү әл-әрманийин вә һум бәкайә Ирам вә һум нәбтус-Сәвад. Вә йукалү ли-Димашк Ирам, фә иртәфәгу гән Сәвадел-Гыйрак фә сару әшилляъә бәгъд фи гарәбел-Әнбар вә гарәбел-Хира (Табари. «Тарихел-умам вәл-мулюк», 2 нче җөзе, 28 б.).

Тәрҗемәсе: Гад кабиләсе әүвәл Ирам дип аталып йөртелгән. Алар һәлак булганнан соң, Ирам дип Самуд кабиләсен атый башлаганнар. Соңрак бу кабилә «әрмәннәр»

башта Фрат елгасы буенда бабиллылар белән күрше булып яшәгәннәр. Аларның яшәгән урыннары да Арамия дип аталган. Ләкин соңыннан хәтта бөтен Месопотамия (Бәйнәлнәһрәйн) һәм Шимали

---

исемен йөртә башлый. [Шулай итеп] әрмәннәр Ирам кабиләсенең калдыкларын тәшкил итәләр һәм аларны Сәвад *(Гыйракның урта өлеше)* нәбатыйлары дип тәгаенләп була. Димәшкъ [шәһәрен дә] Ирам дип атыйлар. [Соңрак] алар, Гыйрак Сәвады [җирләрен] калдырып, Әнбар гарәпләре белән Хира гарәпләре арасында таралып яши башлыйлар.

Һум мин вәләд Ирам, хамис әүляд Сам, әү шамийун. Әтәү мин шәватыә Диҗлә вәл-Фурат фә сәкәнү Мәдинә, әү Бәтра, зәмән Бухтунусур әс-Сани («Хулясат тарихел-гарәб», б. 25. Гали-паша Мөбарәк). Иннә каум Гад җәбу билядел-Гыйрак вәл-Һиндстан тәхтә кыйядәт Шәддад вә Лукман каблә миляд би әксәр мин әлфәйе сәнә. Вә иннәһүм истәүләү галә мәдинәт Бабил сәнә 2218 каблә миляд вә тәгалләбү галә Мысри фи зәликел-гаср. Вә кәнү йусәммәүнә би ругател-ибил әү «әл-әксүс» (шул ук әсәр, б. 20). Фә әмма Гад ибн Гаус ибн Ирам ибн Сам фә әүвәл мән мәләкә минәлгарәб вә мәватыйн би тиһ би Әхкаф әр-рамль бәйнәл-Йәмән вә Гоман илә Хәдрамаут вәш-Шәҗәр. Габәдү әл-әүсан, фә бугисә ләһүм Һуд (шул ук әсәр, б. 20–21). Вә зәкәра Бусифус әл-йәһүди әннә Гаус ибн Ирам ибн Сам бәнә мәдинәт Димәшкъ. Вә әҗмәгу галә әннә нәслә Сам истәүтанәһә мунзү әүвәл гәһдиһә. Вә кад мәрра фи әхбар мәмләкәтел-кәлдәнийин ма йуъхазу минһү әннә бәни-Гад истәүләү галәл-Гыйрак, әй мәмләкәтел-кәлдәнийин, из кыйлә әннә дәүләт гарәбийәт истәүләт галәйһә фи нәхви 1546 сәнә каблә миляд вә мәләкәт фиһа нәхвү 245 сәнә. Вә фи футухәт әл-һәксус фи тарихи Мыср ишарә илә әннәл-гарәб истәүләт галә тилкәд-дияр. Вәл-әрҗәх, әннә әл-һәксус, әү әрруга, гайру каум Гад («ән-Нәһҗ әл-кавим фит-тарих әл-кадим», б. 188). Әл-әрамийун мин бәни-сам истәүтану илә аш-Шәркыйя мин Сүрия мунзү гәһд кадим. Фә иннә Димәшкъ гасыймәтүһүм әл-хасса буният каблә әйям Ибраһим. Вәз-заһир әннәһә кәнәт зәтү шәъэн хинә рахәлә илә Къәнган (шул ук әсәр).

Тәрҗемәсе:

Алар Самның бишенче баласы булган Ирам нәселеннән яки Шам әһелләреннән иде. Навуходоносор II заманында Тигр белән Евфрат буйларыннан килеп Мәдинәдә, ягъни Бәтрадә урнаштылар («Хулясат тарихел-гарәб», б. 25. Гали-паша Мөбарәк). Гад кавеме Гыйрак илен һәм Һиндстанны Шәддад һәм Локман җитәкчелекләре астында раштуадан ике мең ел элек йөреп чыктылар. Алар раштуадан 2218 ел элек Бабил шәһәрен һәм шул ук гасырда Мисырны яулап алдылар. Аларны «дөя көтүчеләр», яки «әл-әксус» дип атадылар (шул ук әсәр, бит 20). Әмма Гад ибне Гаус ибне Ирам ибне Сам гарәпләр арасында беренче булып Йәмән, Гоман белән Хәдрәмәүт, әш-Шәҗәр арасында булган чүлне биләп торганнар. Алар потларга табынганнар, соңра аларга Һуд [пәйгамбәр] җибәрелде (шул ук әсәр, б. 20–21). Йәһүди [галиме] Бусифус әйтүенчә, Гаус ибне Ирам ибне Сам Димәшкъ шәһәрен төзеде. [Галимнәрнәң] гомуми фикеренчә, Самның нәселе Димәшкътә аның башлангыч чорыннан ук яшәп килгән. Халдейлар мәмләкәтенә бәйле хәбәрләргә караганда, Гад нәселе Гыйракны, ягъни халдейлар мәмләкәтен яулап ала, чөнки аны раштуага кадәр 1546 елда гарәп дәүләте яулаган дип әйтәләр, һәм алар аны якынча 245 ел биләп торганнар. Мисыр тарихында искә алынган әл-һәксус яуларында гарәпләрнең ул җирләрне яулап алуларына ишарә дә бар. Төгәлрәк әйткәндә, әл-һәксүс, ягъни көтүчеләр, Гад кавеменнән түгелләр («ән-Нәһҗ әл-кавим фит-тарих әл-кадим», б. 188). Сам кабиләсеннән булган әрамиләр Сүриянең шәрык өлкәсендә борынгы заманнардан ук яшәп киләләр. Аларның башкаласы Димәшкъ Ибраһим заманына кадәр төзелгән. Мөгаен, Ибраһим Къәнганга күчкәндә үк ул мөһим шәһәр булган (шул ук әсәр).

Сүрияне шул исем астына алганнар. Шулай да хәзердә бу турыда тарих бер нәрсә дә күрсәтмәгәнлектән, Арамия мәмләкәтенең туры вә ачык бер хөдүден (чиген) билгеләүне кыен саныйлар.

Арами теле, ягъни арами халкының сөйләшкән теле үзенең маһияте[1] белән борынгы яһүд теленнән бик аз аерыла торган бер тел булган. Бу тел гарби-җәнүби Азия (передняя Азия[2])нең бөтен җирендә хөкем сөрә башлап, Сүриядә, Месопотамиядә, Бөек Асүрия һәм Бабил дәүләтендә дә, Кечек Азиянең шәркый өлешендә шуның белән сөйләшелеп кителгән.

Шушы арами теле белән бергә үк шушы җирләрдә арами язуы да бик күп таралып киткән. Бу язуның күп хатирәләрен Сүрия, Месопотамия, Асүрия вә Бабил хәрабәләрендә, Кечек Азиядә һәм, ниһаять, Мисырда вә Гарәбстан урталарында таптылар. Бу хатирәләрне хронологик бер тәртиптә караганда, арами язуының тарихы тәрәккыйсендә өч төрле әһәмиятле дәвер яки өч төрле баскыч күрәләр: 1) иң борынгы дәвер яки яһүд-финикә дәвере, 2) Асур-Иран дәвере, 3) Мисыр дәвере яки арами язуын Мисырның папирус кәгазе белән яза башлаган бер дәвер.

Беренче дәвер хатирәләре, тәкърибән[3], миладтан элек VII вә VIII гасырларга гаидтер. Бу хатирәләрдәге язуларны үзләренең табигатьләре белән яһүд һәм финикә әлифбасыннан һич аерылмый торган бер рәвештә табалар. Әгәр дә арами теленең хосусиятләре һәм шул язуның бәгъзе гыйбарәләре күрсәтеп тормаса иде, бу хатирәләрдәге язуларны яһүд-финикә әлифбасыннан ук санаган булырлар иде. Һәрхәлдә шушы беренче дәвер хатирәләре арами әлифбасының баш атасы яһүд-финикә әлифбасы булганын һәм бер вакытларда арами халыкларының яһүд-финикә әлифбасын һичбер үзгәртмәстән (хәрефләрнең саны киметелмәгән кебек, шәкелләре дә үзгәртелмәгән) кабул иткән булганлыкларын күрсәтә ала.

Икенче дәвер хатирәләре исә яһүд-финикә әлифбасыннан үзгәртелгән хатирәләр булып, болардан арами язуының иң башлап миладтан элек VII белән VI гасыр урталарында үзгәртелә башлаганлыкны аңлыйлар. Ягъни бу үзгәреш арами әлифбасы асурилар, бабиллылар вә, ниһаять, иранлылар кулына төшкән заманнарда башланган була. Сәүдә һәм бәйнәлмилəл мөнәсәбәтләрне уңай-

[1] Маһияте – табигате.
[2] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*
[3] Тәкърибән – чамалап әйткәндә.

лаштыру максаты белән, болар шушы арами язуын үзләренең чөй язулары белән алыштыру карарына килгәннәр.

Арами язуының бөтен үзгәреше иранлыларның Месопотамиядәге хакимият дәверләрендә тәмам нык утырып, нык карарланып калган була. Шушы вакытларда бу язу үзенең бөтен үзгәрешләре белән тәмам үзенә башка бертөрле рәвешкә керә, ягъни тәмам үзенә аерым яңа бертөрле язу булып әйләнә дә, соңыннан Азиядә мәйданга килгән күптөрле яңа әлифбаларның әсасын тәшкил итүче булып кала.

Өченче дәвердә, ягъни Мисыр дәверендә арами язуы тагын да үзгәртелә. Бу да Птолемей дәверендә папируска яза башлау белән бәйләнешле булып тора. Мисыр папирусы шикелле язу өчен уңайлы бер язу материалының тәэсире белән (папирус хәрефләрне җиңел һәм иркен язу өчен киң бер мәйдан ачты) арами хәрефләренең баштагы кискен табигате күп кенә үзгәрә. Бара-бара тәдриҗән[1], ниһаять, кул язуга охшаш булган матбәга[2] хәрефләре рәвешендә (курсивный[3]) һәм тиз язуга уңайлы бер язу туа. Бу язу хәтта беренче караштa аның яһүд-финикә әлифбасыннан икәне беленмәслек бер рәвешкә керә.

**Арами әлифбасыннан туган әлифбалар.** Арами әлифбасыннан күп яңа тармаклар аерылып чыга. Шулар эченнән беренче тармак – яһүдләрнең дүрткел язулары белән Пальмир әлифбасыдыр.

**Яһүдләрнең дүрткел әлифбалары.** Яһүдләрнең хәзерге язулары – борынгы иске яһүд язуыннан түгел, бәлки Асур-Иран дәверендәге арами язуыннан. Ягъни хәзерге яһүд язуы, югарыда әйтелгәнчә, хәзерендә Азиядә кулланылган күп язуларның анасыннан туган бер язу. Яһүдләр, үзләренең иң борынгы (финикәдән элек булган) вә беренче мәртәбә үзләре иҗат иткән әлифбаларын саклап, шуны үзләренең яшь буыннарына күчереп килә алмыйлар. Бу да менә шундый тарихи сәбәпләр белән була: мәгълүм бер тарихи шартлар астында яһүдләр (бәни Исраил), миладтан элек VI гасырларда үзләренең иң беренче милли әлифбаларын ташлап, аны арами язуы белән алыштыралар. Аны да алар бабиллылардан алалар.

[1] Тәдриҗән – эзлекле рәвештә.
[2] Матбәга – типография.
[3] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*

Соңыннан шушы арами әлифбасына алар характерлы күптөрле хосусиятләр арттыралар. Шулай итеп, тагын тәдриҗән яһүдләрнең дүрткел әлифба яки асури әлифбасы дигән мөстәкыйль бер әлифбалары хасил була. Менә шушы дүрткел язу хәзер дә яһүдләрдә китап һәм журналлар басу өчен кулланыла. Хәзерге яһүд язуларының башка бөтен төрләре дә шушы дүрткел язудан хасил булган.

Яһүдләр, үзләренең артык консерватик (мөхафәзәкяр) бер халык булуларына карамастан, үзләренең борынгы милли әлифбаларын ташлап, бу рәвештә арами әлифбасын кабул итүләре шушы тарихи сәбәпләр белән булган: яһүд дәүләте төзелеп, дүрт йөз ел (587–980) дәвам иткәннән соң, Бабил патшасы Бәхт эн-Наср тарафыннан фәтех ителә[1]. Миладтан элек 587 елда ул яһүдләрнең пайтәхете булган Кодс (Иерусалим)ны ала, аның гыйбадәтханәләрен харап итә. Менә шушы Бабил әсарәте[2] вакытында яһүдләр бабиллылар белән шулкадәр дә нык катышып, аралашып һәм аларга йотылып киткәннәр ки, хәтта үзләренең борынгы мөкаддәс телләрен дә тәмам оныткannнар, фәкать арами телендә генә сөйләшә торган булып калганнар (чөнки ул вакытларда Бабилда арами телендә сөйләшелгән). Шуның белән бергә яһүдләр шул ук вакытларда үзләренең борынгы милли әлифбаларын да тәмам ташлаганнар. Аны үзләре бабиллылардан алган арами язуы белән алыштырганнар.

Бабил дәүләте Иран патшасы Кир[3] тарафыннан алынганнан соң, яһүд әсирләре аннан Фәләстыйнга кайтырга һәм анда Кодсны гыйбадәтханәләре белән бергә яңартырга рөхсәт алалар. Ләкин яһүдләр, үз илләренә кайткач, үзләренең борынгы әлифбаларында язылган мөкаддәс китапларны хәтта һич укый алмас булганнар. Шуның өчен аларны һәм үзләренең бөтен борынгы дини тәгълиматларын арами теле белән арами язуына тәрҗемә кылганнар. Яһүдләр, әсирлектән кайтканнан соң, үзләренең язуларын «Самири» (Самиританский[4]) дип яки чын яһүд әлифбасыннан аеру өчен «арами язуы» яхуд «асур язуы» дип атауларының да хикмәте шундадыр. Самириләр исә ул вакытларда һаман борынгы яһүд әлифбасын дәвам иттергәннәр.

[1] Фәтех ителә – яулап алына.

[2] Әсарәте – коллыгы.

[3] Бөек Кир II (Куруш) – б. э. к. 559–530 елларда фарсы патшасы. Б. э. к. 539 елда Вавилон дәүләтен буйсындыра.

[4] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*

**Пальмир әлифбасы.** Хәмес шәһәренең шәркында Тәдмүр[1] шәһәре булган. Бу – гыйбраничә бер сүз, «хөрмә» мәгънәсендә. Әнә шуны юнан вә румалылар «Хөрмә шәһәре» мәгънәсендә «Пальмир» дип тәрҗемә иткәннәр[2]. Бу шәһәр бер вакытларда Сүрия далаларының вахә (оазис[3])ында салынган әһәмиятле бер сәүдә шәһәре була. Тәүрат хәбәренчә, аны гүя Сөләйман пәйгамбәр салдырган була. Бу шәһәрнең иң шәүкәтле вакыты миладтан элек 273–267 елларда була. Яһүдләрнең дүрткел язулары белән бер үк заманда арами әлифбасыннан Пальмир әлифбасы дигән бик мөһим бер тармак аерылып чыга. Үзе, Пальмир шәһәренә нисбәт белән, юнан вә румалыларда «Пальмир әлифбасы» дип мәшһүр булып китә. Бу әлифба үзеннән бик күп ботаклар үстергән. Бу – бер яктан «Инҗил язуы» (Странҗил[4] – Эстрангело[5]) дип аталган Сүрия язуын (Сурийское письмо[6]) яки сөрьяни язуын тудырган булса, шушы сөрьяни язуыннан да соңыннан, икенче яктан, уйгур язуы белән «нәбатый» (нәбатый-номад) әлифбасы туган. Нәбатый әлифбасы соңыннан асыл гарәп әлифбасының әсасын тәшкил иткән (бу турыда соңыннан тәфсилле тукталачакбыз).

Пальмир язуы Сүриядә беренче мәртәбә миладтан элек II яки I гасырда заһир була. Ләкин ул үзенең баштагы беренче рәвешендә озак дәвам итә алмый, үзгәрә башлый. Бик күп тәдрижи үзгәрүләр нәтиҗәсендә, ниһаять, сөрьяни язуына (Сүрия – Инҗил язуына) әйләнә. Сөрьяни язуы исә, кыскартылган һәм дә тиз язуга тагын да сәляхиятле[7] бер язу булганлыктан, бөтен Сүриядә бик

---

[1] Сүриянең үзәк территориясендә урнашкан шәһәр.

[2] Вә илә шәрк Хымс Тадмур. Вә һийә ляфза гыйбранийа мәгънәһә әт-тәмр. Фә тәрҗәмәһә әл-йунанийун вәр-руманийун Бәлмира, әй Мәдинәтен-нәхл. Йукалү бәнәһа Сөләйман ибн Давуд. Вә ләгаллә әл-морад әннәһү хәссәнәһә вә зәдә фи әбниятиһа (Нәүфәл әфәнде Нигъмәтуллинның «Сыйнагатет-тараб фи тәкаддумател-гарәб» дигән әсәре, б. 25).

Тәрҗемәсе:

Хымс [шәһәреннән] көнчыгышка таба Тадмур [шәһәре] урнашкан. Бу – борынгы яһүдиләр сүзе, аның мәгънәсе «хөрмә» дигәнне белдерә. Борынгы греклар һәм римлылылар аны Бәлмира, ягъни Пальмалар шәһәре, дип тәрҗемә итәләр, Сөләйман Давыд углы тарафыннан төзелгән дип сөйлиләр. Мөгаен, алар [бу сүзне] андагы биналарны арттырырга һәм төзекләндерергә теләп әйткәннәрдер.

[3] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*

[4] Странҗил (эстрангело) – Сүрия язуларының иң борынгы төренең исеме.

[5] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*

[6] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*

[7] Сәляхиятле – сәләтле.

таралып өлгерә. Пальмир язуы үзе фәкать Сүриянең башка киң далаларыннан аерым Пальмир шәһәрендә генә сакланып кала ала. Ул анда үзен һичбер үзгәрешкә очратмастан бик озак саклап килә. Пальмир язуының соң заманнарда иске әсәрләрне казып эзли башлагач кына килеп чыгуы һәм табылуы да әнә шул сәбәптән булган.

Пальмир язуын яһүдләрнең дүрткел язуларын бик искә төшерерлек бер рәвештә дип табалар. Бу табигый да. Чөнки бу ике кардәшнең, ягъни яһүдләрнең дүрткел язулары белән Пальмир язуының икесе дә арами әлифбасыннан туып үскән икәне югарыда әйтелгән иде. Фәкать Пальмир язуына соңыннан яһүдләрнең дүрткел язуларының тәэсире булган булучылыкны да бик мөмкин саныйлар.

**Сөрьяни әлифбасы.** Пальмир әлифбасы Пальмир тирәләрендә һич үзгәртмәстән берничә йөз еллар яшәгәне хәлдә, Сүриянең башка якларында ул аз дәвам иткән. Чөнки милади II гасырда Сүриянең башка якларында сами әлифбасының аерым рәвеше гамәлгә куелып киткән. Бу да, югарыда әйтелеп үтелгәнчә, «Инҗил язуы» («Эстранҗил – письмо эстранчело[1]) дип атала (Инҗил язуында сүзләрнең ике нокта белән аерылу хосусияте бар).

Болай аталуының сәбәбе дә аның Инҗилне язуда бердәнбер язу булып хезмәт итүеннән булган. Ләкин бу язуны хәрефләрнең сызылу рәвешләре белән Пальмир язуына бик якын килә дип күрсәтәләр. Аерма фәкать сөрьяни язуында хәрефләр кушып язуга тагын да уңайлаштырыла төшкән һәм шуның өчен дә тиз язуның үзенә махсус бер характер бирә торган бер рәвештә (лигатура[2]) белән күп тәэмин ителгән булуындадыр. Бу ике язуның, ягъни сөрьяни белән Пальмир язуының бер-берсенә охшаулары боларның бер-берсенә туганлыгы белән изах ителә. Сөрьяни язуы (Инҗил язуы)ның әсасы Пальмир әлифбасының курсив (курсивный[3]) бер рәвештә язылуыннан алынган икәне хәзерге вакытта инде бик нык дөресләнеп, ачык карарлаштырылган бер нәрсә дип санала.

Месопотамиядә һәм Шимали Сүриядә Пальмир язуының сөрьяни язуы булып әйләнүенең күчү һәм тәрәккый баскычларын сурәтләндереп күрсәтә торган күп хатирәләр табылган. Хатирәләрдән

[1] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*
[2] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*
[3] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*

аңлашылуынча, Пальмир язуыннан Инҗил, ягъни сөрьяни язуына күчү тәкърибән миладның беренче гасырында булган дип табыла. Бик соңга куйганда да, бу күчүне, һәрхәлдә, II миладтан да соң түгел, диләр.

Месопотамиядә булган мәшһүр «Идәс мәктәбе»[1] (Эдесская школа[2]) Сүриядә бервакытлар христианлык тәгълиматы вә тәхсиленең баш оясы була. Әнә шушы мәктәпнең тәэсире белән, миладиVI гасыргача, Сүриядә Инҗил, ягъни сөрьяни язуы аннан элек анда дәвам итеп килгән Пальмир язуы урынына кулланылып киткән бердәнбер язу була.

**Настори[3] язуы.** VI миладтан башлап Сүрия тирәләрендә тагын да курсиврак булган һәм дә инҗил-сөрьяни язуына караганда көндәлек тормышның кирәкләренә тагын да яракландыра төшкән янә башка бер язулар мәйдан алалар. Болар янә сөрьяни язуын кысрыклап, аны истигмальдән туктатканнар.

Шушы язуларның берсе настори язуы була. Аннан соң якут, мәлхид һәм бәсит (хатты мәбсут) (пашито[4]) язулары шул җөмләдәндер. Бу язулар һәммәсе хәзердә дә Сүриядә кулланылмакдадыр.

Сөрьяни язуын алыштыручы бу язуларның туулары Сүриядә христиан чиркәүләрендә зоһур итеп[5], бер-беренә дошман мәзһәбләрнең хасил булуына сәбәп булган дини бер ихтилаф белән баглый. Болар эчендә дә настори мәзһәбендәгеләргә каршы Эдесс епископы Рауил (Равула?) тарафыннан каты бер кысу башлана. Шул сәбәпле настори мәһзәбендәгеләр Иранга күчеп киләләр. Анда болар, үзләренең дини тәгълиматларын уңышлы бер рәвештә тарату өчен, үзләренә махсус бер язу тудырырга карар бирәләр. Менә шушы максат белән

---

[1] Вә әншәъә ән-нистурийун фи мәдрәсә Идисә би билядел-Гыйрак әл-гарәби (Бабил) мәдрәсә тәгәлләмә биһа минәл-этыббаъэ җәмгъ кәнү зәмәнен-нәбийи саләл-Ляһү галәйһи вә сәлләм. Вә биһа кәнә бәдъү гыйльмил-гарәб әл-мәвадд вәл-гәкакыйр әл-мөстәфад («Холяса тарихел-гарәб», б. 207).

Тәрҗемәсе:

Несторианнар гарәпләрнең Гыйрак илендәге (Вавилонда) Идисә шәһәрендә мәдрәсәгә нигез салдылар. Анда пәйгамбәр (Аллаһы Тәгаләнең аңа сәламе ирешсен) заманында яшәгән табиблар гыйлем алган. Биредә гарәпләр төрле матдәләр һәм дарулар өйрәнә башлыйлар.

[2] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*

[3] «Настори» дигәндә, несторианнар күздә тотыла.

[4] *Кирилл хәрефләре белән язылган.* (Биредә пушту язуы турында сүз бара булса кирәк.)

[5] Зоһур итеп – килеп чыгып.

алар, ниһаять, Инҗил-сөрьяни язуын бераз үзгәртәләр дә, шулай итеп, ахырда сөрьяни язуының «настори язуы» исемендәге яңа бер рәвешен эшләп чыгарып, дөньяга тараталар.

**Яковит язуы һәм мәбсут язуы.** Шул ук вакытларда гарби сүриялеләр вә хосусан якутлыларда һәм марундиларда сөрьяни язуы тиз язуга тагын да уңайлы булган үзенә башка бер курсив язуга әйләнә. Моннан янә милади VIII гасырда яковит язуы белән бәсит язуы (хатты мәбсут – пешито[1]) хасил була. Ниһаять, Сүрия мәлхитләре[2], сөрьяни язуына янә үзләре бер үзгәреш кертеп, аннан «мәлхит язуы» дигән язуны яки сөрьяни язуының Сүрия-Фәләстыйн язуы рәвешен тудыралар.

Үзләренең әүвәлге милли телләрен гарәп теленә алыштырган сүриялеләр исламга һәм гарәп теленә дошманлыклары сәбәпле, алар тагын сөрьяни язуына багланып калганнар. Ләкин болар тагын гарәп теле фонетикасы буенча аңа берничә төрле үзгәреш керткәннәр вә аны тагын да тәгәлләндергәннәр. Шулай итеп болар тагын сөрьяни әлифбасының каршуни[3] дигән аерым бер төрен тудырганнар.

Инҗил-сөрьяни язуын алыштырган шушы язуларның һәммәсендә дә яһүд язуының соңгы тәрәккыйсендә күрелгән бер хосусият күрәләр. Ул да – тавышлы авазларны белдерү өчен аерым галәмәтләр кулланыла башланудыр. Бу галәмәтләр янә Яурупа вә хәзерге төрк язуларындагы кебек тавышсыз хәрефләр белән бер рәттән түгел, бәлки аларның я өст, яки аст якларына куела торган булган. Мәсәлән, насториларда шундый галәмәтләр кулланылган: . Болар да а, ĕ, é, Ĭ, Í, ŏ, ó ләргә бәрабәрдер. Яковитларда янә шул ук галәмәтләр. Ләкин бу галәмәтләрнең белдергән авазлары гына боларда башкачарак.

Әмма бәсит язуында исә тавышлы-сузынкы аваз галәмәтләре, һичбер үзгәртелмәстән, юнан әлифбасыннан алынганнар. Монда аерма ялгыз шул: бәсит язуында бу галәмәтләр юнанчадагыча булган хәлендә язылмыйча, бәлки кабыргага яки юл астына табан әйләндереп куелганнар.

[1] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*

[2] Мәлкит, мәлхит – Урта гасырларда Якын Көнчыгыш территориясендә яшәгән православие динендәге халыкларның атамасы.

[3] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*

Шушы югарыдагы сөрьяни әлифбалары белән бер туганлык бәйланышында булган мандей яки сабилар әлифбасы бар. Болар – хәзердә калдыклары Месопотамиядә Шәттелгарәптә[1] яши торган дини бер мәзһәб адәмнәрдер. Бу әлифба да, Куппе фикеренчә, Җәнүби Азиядәге дүрт әлифбадан алынып төзелгән. Шулар эченннән унбер галәмәт – Пальмир әлифбасыннан, бер галәмәт – Инҗил-сөрьяни язуыннан, биш галәмәт – насторилардан, тагын бишесе Сасанилар заманындагы пәһләви язуыннан алынган.

Ләкин Ленерман дигән бер тикшерүче галим бу фикерне көчләнеп тудырылган бер фикер дип саный. Һәм ул мандей (саби) әлифбасын, Инҗил язуы шикелле үк, Пальмир әлифбасыннан хасил булган, ди.

Мани-саби әлифбасындагы бер кызык хәл: анда тавышлы авазларның галәмәтләре иҗек ясалганда аз гына бер кушымта белән берләштереләләр. Шул рәвештә ки, гүя бөтен бер иҗек галәмәте тугандай була.

## Хәзердә төрк халыкларында кулланылган гарәп язуының нәселе

**Нәбатый (номад-нәбатый) язуы.** Исламнан элекке мандей гарәп кавемнәреннән берсе нәбатыйлар[2] булганнар. Бу халыкның исеме Нәбайүт бин Исмәгыйльгә нисбәт белән нәбатый дип аталган. Болар – Фәләстыйн белән Синай ярымутравы арасындагы Бәтра[3] шәһәренә мәнсуб халыклар. Боларның мәмләкәтләре, шушы ярыматауны эченә алганы хәлдә, Гарәбстан ярыматавыннан шуның тирәсендә булган җирләрнең Хиҗазгача[4] булган урыннарына җәелгән. Бәтра шәһәрләрендә боларның хәрабәләре дә бар. Бу халыкның язуы нәбатый язуы булып, бу язуны химьяри[5] язуы кебек укыганнар.

[1] Шатт әл-Гарәп – Иран һәм Гыйрак территорияләрендә агучы елга.

[2] Нәбатыйләр – Идумея һәм Иордания аръягында патшалык иткән ярымкүчмә семит халкы.

[3] Әл-Бәтра – хәзерге Иордания территориясендә урнашкан борынгы шәһәр.

[4] Хиҗаз – Согуд Гарәбстанынының бер өлеше, Мәккә һәм Мәдинә шәһәрләре урнашкан өлкә.

[5] Химьярилар – Көньяк Гарәбстан (хәзерге Йәмән) территориясендә яшәгән борынгы семит халкы.

Бу язуның хатирәләре Хауран[1] һәм Бәлка[2] тирәләрендә сакланып калган[3].

Нәбатый язуы бөтен сами язулары белән гарәп язулары арасында шуларның бер-берсен баглый торган бер буын рәвешендә санала. Гарәп язуы да арами әлифбасыннан сами гаиләсенең соңгы бер әгъзасыдыр.

Сәяхәтче күп галимнәр Хауранның Синай тауларында табылган язуларга бик күп вакытлар буенча яһүдләрнең, Тәүратта хәбәр ителгәнчә, Муса риясәте[4] астында ком далаларында, ягъни Тия сахраларында гизгән вакытларында калдырган хатирәләре дип карап килсәләр дә, соңгы тикшерүләр бу карашның яңлыш икәнен күрсәтәләр. Күптән түгел генә бу хатирәләрнең телләре, мөндәриҗәләре белән якыннан танышып, шуның нәтиҗәсендә, бердән, бу язуларның миладның беренче гасырыннан да элек булганлыгы, икенчедән, бу язулар, әүвәлдә уйланганча, яһүдләргә түгел, бәлки самиларның күчмә ыруглары булган нәбатыйларга гаид бер язу икәнлеге исбат ителә. Бу халык бер вакытларда Иордан[5]ның шәркында киң бер өлкәгә малик булганнар.

Бу язуларның берсе – гыйбрани, икенчесе дә «асыл нәбатый» дип йөртелгән һәм фәндә хәзердә дә шулай йөртеләдер. Ләкин соңыннан яхшылап тикшерү нәтиҗәсендә, асылда бу ике язуның икесе дә бер

---

[1] Хауран – Сүриянең көньягын һәм Иорданиянең төньягын биләгән өлкә.

[2] Бәлка – Иорданиянең бер өлкәсе.

[3] Вә минәл-өмәм әл-гарәбийә әл-ләти тәмәддәнәт кабләл-Ислам әл-әнбат. Нисбәтүһум илә Нәбт ибн Исмәгыйль. Вә һум әсхаб мәдинәт Бәтра бәйнә Филәстыйн вә шибһ җәзирә Сәйнаъэ. Вә кәнәт мөмтәддәтән галә зәликәл-җәзирә вә ма җәвәраһә мин җәзирәтел-гарәб иләл-Хиҗаз. Вә лә тәзәлү анкадуһа фи биляд Бәтра вә галәйһә әл-китаба ән-нәбәтыййа йәкъраүнәһә кәмә йәкъраүнә әл-китаба әл-химьярийә (Җөрҗи Зәйдан. Тарих әт-тәмәддун әл-ислами. 1 нче җөзе, б. 13). Вәл-әнбат фиш-шималь кәтәбү бил-хәрф ән-нәбәтый вә әсаруһум бакыя илә һәзиһил-гая фи нәвахи Хауран вәл-Бәлка (шул ук әсәр. 1 нче җөзе, б. 53).

Тәрҗемәсе:

Исламга кадәр үк мәдәниятkә ия булган гарәп кабиләләренең [берсе] – әл-әнбат. Алар [килеп чыгышлары буенча] Нәбт ибне Исмәгыйльгә нисбәтле. Алар Фәләстыйн белән Сәйна ярымутравы арасында булган Бәтра шәһәренең әһелләре. Ул шәһәр шул ярымутрауга һәм аның янәшәсендәге Гарәп ярымутравына һәм Хиҗазга кадәр сузылган иде. Аларның калдыклары Бәтра илендә бүген дә яши. Аларда нәбатый язулар бар. Алар бу язуларны химьяр язуын укыган кебек укыйлар (Җөрҗи Зәйдан. Тарих әт-тәмәддун әл-ислами. 1 нче җөзе, б. 13). Төньяк нәбатыйлары нәбат хәрефләре белән язганнар, аларның әсәрләре бүгенге көннәргә кадәр Хауран һәм әл-Бәлка тирәләрендә сакланып калган (шул ук әсәр. 1 нче җөзе, б. 53).

[4] Риясәте – рәислеге, җитәкчелеге.

[5] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*

үк төрле нәбатый язуының төрле дәрәҗәсендәге төрле баскычларыннан гыйбарәт икәне беленгән. Болар фәкать үзләренең бер-берсеннән озак вакытлар белән аерылган ике төрле тарихи дәвергә гаид булулары белән генә аерылганлыклары күрсәтелә.

Соңгы тикшерүләргә караганда, гарәби язуы – нәбатый язуының борынгы бер рәвеше, бу язу янә үзенең тышкы күренеше белән Пальмир язуына бик якын дип күрсәтелә вә бу язу үзенең әсасын, шөбһәсез, шуннан алганлыгы галимнәр тарафыннан ачык бәян ителә.

Асыл нәбатый язуы исә гыйбрани язуының соңгы үзгәртелгән бер рәвешеннән башка бернәрсә түгел икәне дә ачык исбат кылына. Нәбатый язуының төп хосусияте ике төрле булып, шуннан гыйбарәт:

1) Хәрефләрне бер-берсе белән кушып язу өчен монда баглаучы сызыклар (лигатура[1]) кертелгән.

2) Бәгъзе бер хәрефләр өчен, урыннарына карап, ике вә хәтта өч төрле шәкел кулланылган: баш, ахыр, урта хәрефләр кебек. Менә шушы ике хосусияте белән нәбатый язуы гарәп язуына якын килә дип табыла. Бу хосусият тә тиз язу рәвеше тудыруга өметләнүдән булып, башта Мисыр дәверендәге арами язуында һәм Пальмирның курсив рәвешендәге «рәсме хат»ында тудырылган булган. Шуның тагын да тәрәккыйсе, ниһаять, гарәп язуында күрелгән.

Нәбатый язуы, гомумән, үзенең тышкы күренеше белән гарәп язуына бик якын килгәнлектән, менә шуны уйлыйлар: нәбатый-номадлар үзләренең ыругдашлары булган гарәпләр белән иң еш мөнәсәбәттә булынып, шуның аркасында алар гарәп язуының тәрәккыйсен уңайлаштырганнардыр. Бу турыда 1872 елда Урта Гарәбстанда әл-Һиҗри хаузасында[2] табылган нәбатый язулары шаһит итеп китерелә. Яурупа галимнәре бу язуларның янә, һич шөбһәсез, миладның беренче гасырында нәбатыйларның Гарәбстан эчләренә кергәнлекләрен һәм әле дә алар ислам килгәненчә булган гарәп халыклары арасына үз язуларын таратканлыкларын күрсәтә дип бәян итәләр. Шул рәвешчә, гарәпләрнең үз язулары тудырылмастан элек нәбатый язуы гарәпләрнең язуы булганлык бик мөмкин санала.

---

[1] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*

[2] Хаузасында – бассейнында.

Гарәпнең соңгы тарихчыларыннан Җөрҗи Зәйдан[1] бу турыда шушы сүзләрне язадыр: «Хиҗаз гарәпләреннән бәгъзеләр ислам килүдән элгәре генә Гыйракка яки Шамга сәфәр кылып, анда мәдәниләшкәннәр һәм алардан язу алып торганнар. Соңра болар илләренә кайтып, бәгъзеләре гарәпчәне нәбатый яки гыйбрани яисә сөрьяни хәрефләре белән язганнар. Кыскасы, һәрхәлдә, гарәпләр, Шамга сәүдәгә йөргән чакларында, нәбатый язуын Хаураннан өйрәнеп килгәннәрдер»[2].

Фәкать Җөрҗи Зәйданның бу хәбәренчә, нәбатыйлар язуларын үзләре гарәпләр эченә килеп таратудан бигрәк, гарәпләр үзләре аны алардан барып алып кайтып, үз илләренә тараткан булалар. Нәбатыйларда әлифба хәрефләре «әбҗәд, һәүвәс, хоттый, кәләмән, сәгъфәс, карашат» дип теркәлеп куелган. Гарәпләр менә шушы хәрефләрне нәбатыйлардан шул хәленчә (барысы 21 хәреф була) алганнар да, шуларга тагын үзләреннән «ث , خ , ذ , ض , ظ , غ» хәрефләрен кушып, боларны «ثخذ , ضظغ» рәвешендә тегеләргә ялгаганнар. Әнә шунлыктан «әбҗәд» китабындагы әүвәлге алты сүз, «асыл» соңгы икесе дә «рәвадиф», ягъни ялганма, кушылма дип аталганнар.

**Гарәп язуының төрләре.** Гарәп язуы – арами әлифбасының сами гаиләсенең иң соңгы яшь һәм иң күп таралган бер тармагы. Бу язу – ислам килүдән бераз элгәре Гарәбстан ярымутравында тудырылган бер язу. Ул соңыннан Мөхәммәд тәгълиматының бердәнбер язуы булып китә. Бу язу ислам тәэсире астында һәм аның белән бергә җир йөзенең иң күп таралган урыннарына тарала. Бу язуның бигрәк тә күп таралган урыны Азия була. Бу монда хәтта Атлантик

[1] Җөрҗи Зәйдан (1861–1914) – атаклы гарәп (Ливан, Мисыр) әдибе, публицист, «әл-Һилял» журналы мөхәррире. Биш томлы «Тарих әт-тәмәддун әл-ислами» (1901–1906) исемле хезмәт авторы.

[2] Үз гыйбарәсе: «Галә әннә бәгъдел-ләзинә рахәлү минһүм әл-Гыйрак вәш-Шам кабләл-Ислам тәхалләку би әхлак әл-хәдар вә икътәбәсү әл-китабә минһүм галә сәбилел-истигара фә гәдү. Вә бәгъдүһүм йәктүбү әл-гарәбийәтә бил-хәрф ән-нәбәтый әү әл-гыйбрани әү әс-сүрьяни... Вәл-холяса фи күлли хәл әннәл-гарәб тәгалләмү әл-хатт ән-нәбәтый мин Хауран фи әснаи тиҗәратиһим иләш-Шам» (Тарих әт-тәмәддун әл-ислами. 3 нче җөзе, б. 53).

Тәрҗемәсе:

Аларның исламга кадәр Гыйрак һәм Шәм җирләрен калдырып киткәннәренең кайберләре утрак тормышта яшәүчеләрнең гореф-гадәтләрен үзләштерделәр һәм аларның язуларын өйрәнделәр, әмма соңрак алар [әүвәлге хәлләренә] кире кайттылар. Кайберләре исә гарәп телендә нәбат, яки борынгы яһүди, яки борынгы сүриялеләр хәрефләре белән яза... Кыскасы, гарәпләр нәбәт язуын Хауран [җирләрендә] Шәмгә сәүдә өчен килгәндә өйрәнделәр.

| Хәрефләрнең исемнәре | Аерым хәрефләр | Ахыр хәрефләр | Урта хәрефләр | Баш хәрефләр | Мәгънәләре | Хәрефләрнең исемнәре | Аерым хәрефләр | Ахыр хәрефләр | Урта хәрефләр | Баш хәрефләр | Мәгънәләре |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|




31 нче шәкел. *Гарәпләрнең борынгы куфи әлифбалары*

вә Һинд диңгезе арасындагы бөтен дәүләтләрдә үзенең хакимиятен ныгытып ала. Бигрәк тә Гарәбстанда, Кечек Азиядә, Сүриядә, Иранда, Әфганстанда вә кыйсмән[1] Һиндстан вә Монголиядә бу язу каты хөкем сөрә һәм шуларда тәмам гомумиләшеп китә. Соңра ул Азиядән Африкага барып керә: Фәс[2], әл-Җәзайир[3], Тунис, Тараблис[4] һәм Мисыр дәүләтләрендә хөкем сөрә башлый. Ниһаять, ул тагын Яурупага килеп керә. Хәзер дә ул Балкан ярымутравында вә кыйсмән Испаниядә дәвам итә.

Гарәп язуы ике төрлегә аерыла: 1) куфи язуы (Фөрат елгасы буендагы Куфә шәһәренә нисбәт белән), 2) нәсих – нәсех язуы. Куфи

[1] Кыйсмән – өлешчә.
[2] Фәс – Мороккодагы борынгы шәһәрләрнең берсе.
[3] Әл-Җәзайир – Алжир.
[4] Тараблис – Триполи, Ливиянең башкаласы.



الم، الله لا اله الا هو الحى القيوم
نزل عليك الكتاب بالحق مصدقا لما
بين يديه وانزل التوراة والانجيل.

Шул ук язуның нәсех белән язылган күренеше

32 нче шәкел. *Куфи язуыннан үрнәк.*

язуы тышкы күренештә уставный[1] – аерым-өзек хәрефле бер язу рәвешендә. Монда нәсехтәге кебек нокталар юк[2].

Куфи язуы – гарәп язуының иң иске, иң борынгы бер рәвеше. Һиҗри белән VII яисә милади белән XIV гасырда бу язу үзенең гомуми истигмаль ителүеннән тәмам туктала да, матур сәнгатькяранә ясалган бина-гыйбарәтләр дә мозаикаларны зиннәтләү өчен генә тәтбикъ ителә торган булып кала; хатирәләрдә, акчаларда, сарай һәм мәчетләрдә эпиграф язуларындагы нәкышьләр өчен генә йөртелә башлый.

Шул ук вакытлардан башлап нәсех язуы гарәпләрнең көндәлек кирәкләрен үти торган бердәнбер язулары булып йөртелеп китә. Нәсех язуы – тагын да уңайлаштырылган бер язу, ягъни тагын да күрсиврак язу.

Нәсех язуы да, куфи язуы да мөселман хаттатлары (каллиграф[3]лары)ның тәэсире астында бик тизлек белән берничә төрле

---

[1] Кирилл хәрефләре белән язылган.

[2] Кәнәл-хатт ләммә икътәбәсәһүл-гарәб минәс-сурьянийәти вәл-әнбат халиян гәнин-нукат. Вә лә тәзәлүл-хутут әс-сүрьянийә билә нукат иләл-йәүм. Фәл-игъҗам хәдис фил-гарәбийәти (Җөрҗи Зәйдан. Тарих әт-тәмәддун әл-ислами. 3 нче җөзе, б. 153–155).

Тәрҗемәсе:

Язу, гарәпләр аны борынгы сүриялеләр һәм нәбатыйлар [телләреннән] алганда, ноктасыз иде. Борынгы сүриялеләр телендәге язулар бүгенге көнгә кадәр ноктасыз. Нокталар гарәп язуында элек булмаган, алар соңрак барлыкка килгәннәр.

[3] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*

«рәсме хат» (почерк[1]) хасил итеп китә[2]. Нәсех язуының рәсме хатларыннан хасил булып хәзерендә күбрәк кулланылганлыклары шулар:

1) Җәри – бу язу гадәти нәсехтән хәрефләренең эрелеге белән аерыла.

2) Сөлес язуы – монда хәрефләр, хәзерге монограмнарга (төрле рәсем-нәкышьләр белән зиннәтләнгән баш хәрефләргә) охшашлы бер рәвештә матурланып, китап башлары өчен куллана;



33 нче шәкел.

3) Рыйкка язуы. Госманлы төрекләренең хәзерге кульязмалары – шул рыйкка язуы. Бу язу да басма китапларда китап исемнәре, сүз башлары сәрләүхәләр өчен һәм документлар, паспортлар өчен куллана. Рыйккадан үрнәк:



(Бу язу – бигрәк каләм белән язу рәвеше. Монда «ش , س» хәрефләре тешсез языла. «ق , ن» хәрефләре «ں , ى» , рәвешендә асыл хәрефкә кушылып куела. «ر د» хәрефләре дә кечерәйтелеп, үзгәртелебрәк язылалар, гомумән, хәрефләрдә ике нокта, өч ноктлар «ٮ ..» рәвешендә кушылып кулланылалар).

[1] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*

[2] Үз гыйбарәсе: «Галә әннә бәгъдел-ләзинә рахәлү минһүм әл-Гыйрак вәш-Шәм каблән-Ислам тәхалләку би ахляк әл-хәдар вә икътәбәсү әл-китаба минһүм галә сәбилел-истигара фә гәдү. Вә бәгъдуһүм йәктүбү әл-гәрабийятә бил-хәрф ән-нәбәтый әү әл-гыйбрани әү әс-сүрьяни... Вәл-холяса фи күлли хәл әннәл-гәраб тәгәлләмү әл-хатт ән-нәбәтый мин Хауран фи әснаъэ тиҗаратиһим иләш-Шәм» (Җөрҗи Зәйдан. Тарих әт-тәмәддун әл-ислами. 3 нче җөзе, б. 53).

Тәрҗемәсе:

Аларның исламга кадәр Гыйрак һәм Шәмне калдырып киткәннәрнең кайберләре утракларның әхлякъларын алдылар һәм алардан вакытлы рәвештә язуны өйрәнделәр, ләкин аннан соң [әүвәлге хәлгә] кайттылар. Аларның кайберләре гарәп телендә нәбәт, яки гыйбри, яки сурьяни хәрефләре белән яза... Кыскасы, һәрхәлдә гарәпләр нәбәт язуын Хауран [җирләрендә] Шәмгә сәүдә өчен килгәндә өйрәнделәр.

4) Тәгъликъ язуы. Бу язуны бигрәк иранлылар һәм үзбәкләр куллана. Иран вә чыгтай әдәбиятының хатирәләре Ташкент басмаларында һәммәсе диярлек тәгъликъ язуы белән язылгандыр.



34 нче шәкел. *Тәкъликътән үрнәк (Һибәтулла шигыреннән)*



35 нче шәкел. *Тәгъликътән үрнәк (эре хәреф һәм яңа имля белән)*

**Күфи һәм нәсех язуы кайчан туган?** Гарәп язуын ислам тудырды. Күфи язуы – янә гарәп язуының иң беренче рәвеше, ягъни гарәп язуы иң элгәре күфи язуы рәвешендә иде. Ул үзе башлап Күфә шәһәрендә[1] заһир булды.

Гарәп мөхәррирләре вә тарихчылары менә шушы фикердәләр. Аларга таянып, бу фикер вә игътикад соңыннан Яурупа галимнәре арасында да күп вакытларгача хөкем сөреп килде.

Ләкин иң соң вакытларда бу мәсьәләне чынлап тикшерү аркасында, күптән түгел генә бу фикер вә карашның хата икәне беленә. Бу фикернең тарихи яктан дөрес түгел икәне ачыла. Я.Б. Шницер үзенең «История письма»[2] дигән вә рус матбугатында бу бабта бердәнбер әһәмиятле мәнбәгъ саналган бер әсәрендә[3] шушы мәгънәдәге сүзләрне яза (138 биттә). Ләкин без аның бу сүзләрне гарәп тарихларыннан кайсы мәнбәгъләргә таянып әйткән белмибез. Хәлбуки, гарәпнең мәшһүр ышанычлы тарихчыларыннан Ибн Хәлдун[4]

[1] Күфә шәһәре – һиҗри белән I гасырда Гомәр хәлифә заманында бина кылдырылган бер шәһәр. *(Авт. иск.)*

[2] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*

[3] Бу әсәр яхшы кәгазьдә 155 рәсемнән һәм 19 таблицадан гыйбарәт булып Петербург (Ленинград)та 1903 елларда басылган. 264 бит зурлыгында. *(Авт. иск.)*

[4] Әбү Зәйд Габд әр-Рахман ибн Мөхәммәт ибн Хәлдун әл-Хадрами (1332–1406) – гарәп мөселман фәлсәфәчесе, тарихчы.

(«Мөкаддимә бин Хәлдун» – гарәп басмасы, 339–344 битләргә; Бейрутның өченче басмасы, 418–430 битләргә каралсын), Бәләзури[1] (аның «Фәтх әл-бәлдан»ының 476–479 нчы битләренә каралсын), Ибн әл-Әсир[2] һәм соңгы гарәп тарихчыларыннан Җөрҗи Зәйдан («Тарих әт-тәмәддун әл-ислами», 3 нче җөзе, б. 55, 153–157), Мәхмүд әфәнде Шөкри Багдади[3] (аның «Бөлуг әл-гарәп фи әхвале әл-гарәп»[4] дигән әсәренең 395 нче бите каралсын) кебек галимнәрдә без андый бер фикерне таба алмадык. Бәлки аларда Шницер язганның киресе бар. Мәсәлән, алар һәммәсе дә гарәп язуының асылда Йәмәннән, химиярилардән алынганлыгын, аларның да арамилардан алганлыкларын, шуннан бу язу әнбариләргә, аннан хиралыларга[5] күчкән икәнлеген вә шуңа Күфә шәһәрендә шушы язу тәмам тәрәккый итеп, эшләнеп киткәнлеген язалар. Күфи язуы үзе үк исламнан элек хира язуы дип аталган. Соңыннан шул ук язу Хира[6] шәһәре тирәсенә салынган Күфә шәһәренә нисбәт белән «күфи» дип мәшһүр булып киткән һәм ул шунда күп тәрәккый иттерелгән, матурланган[7].

Гарәп язуының җәзем дип аталганы да мәгълүм. Чөнки күфи язуы, Күфә салынып анда күчмәстән элек, «җәзем» язуы дип

[1] Әл-Бәләзури (892 ел тирәсендә вафат булган дип фаразлана) – гарәп мөселман тарихчысы, «Китап фөтүх әл-булдан» («Илләрне яулап алу турында китап») дигән тарихи һәм «Әнсаб әл-әшраф» дигән тарихи-генеологик әсәрләр авторы.

[2] Ибн әл-Әсир (1160–1233/1234) – гарәп тарихчысы. Унике томлы «әл-Камил фит-тарих» («Тулы тарих» хезмәте авторы).

[3] Мәхмүд Шөкри ибн Габдуллаһ ибн Шиһаб әт-Дин әл-Алуси (1273–1342) – күренекле гарәп галиме, тарихчы, әдәбиятчы.

[4] Сүз Мәхмүд Шөкринең «Бөлуг әл-гарәп фи-мәгърифәти әхвале әл-гарәп» хезмәте турында бара.

[5] Хира да, Әнбар да – Месопотамиядә гарәпләрнең ислам килмәстән элгәре булган шәһәрләре. Әбүбәкер Хираны килеп алгач, ул шәһәр анда азрак хәлифәт мәркәзе булып тора да, соңра мәркәз Әнбарга күчерелә. Әнбар исә Фрат елгасының шәркында Багдадтан 10 фәрсах ераклыкта булган бер шәһәр булган («Сонаҗа әт-тараб», б. 16). *(Авт. иск.)*

[6] Хира – хәзерге Гыйрактагы Күфә шәһәреннән көньяктарак урнашкан борынгы кала, хәзерге вакытта сакланмаган.

[7] Вә кәнәл-хатт әл-күфи йусәммә кабләл-Ислам әл-хири нисбәтән иләл-Хира, вә һийә мәдинәтү Гыйракыль-гарәб кабләл-Ислам. Вә ибтәнәл-мөслимун әл-Күфә би җивариһа (Җөрҗи Зәйдан. Тарих әт-тәмәддун әл-ислами. 3 нче җөзе, б. 53).

Тәрҗемәсе:

Исламга кадәр күфи язуы, әл-Хирага мөнәсәбәтле рәвештә, «әл-хири» дип атала иде. [әл-Хира] – гарәп Гыйракында исламга кадәр булган шәһәр. Аның янында мөселманнар Күфә шәһәрен төзеделәр.

аталган. Моның сәбәбе дә хәрефләре өзек булганлыгыннандыр (*җәзем – кисәк, өзек мәгънәсендә*)[1].

Гарәбстан харәбәләрендә борынгы гарәп язуының хатирәләре табылыр. Менә бу хатирәләрдән күфи язуының гарәпләрдә ислам дини кәлимәсеннән элек үк булганы беленә. Димәк, бу язу әле Күфә шәһәре дигәннең исе дә, исеме дә юк вакытта ук мәйданда булган була. Бу язулардан бигрәк тә әһәмиятлесе итеп галимнәр Васштейн тарафыннан Ләҗи тирәләрендә Хәрран[2] шәһәрендә табылган язуларны күрсәтәләр. Бу язу хатирәләрендә ике төрле язу, ягъни күфи һәм юнан язуы була. Юнанча язуда боларның кайчан язылганлыклары, ягъни еллары күрсәтелгән. Монда күрсәтелүенчә, болар милади белән 568 елда, димәк, ислам килүдән 60 ел элек язылган була.

Димәк, шушы табылдыкларның биргән нәтиҗәләре белән гарәп мәнбәгъләре[3] бу хакта аерылмыйлар. Әмма гарәпнең нәсех язуы турысында элекке гарәп галимнәренең бәгъзеләре Шницерның күрсәткәне шикелле хатага төшкән булганнар. Ләкин бу галим янә гарәп галимнәрен һәммәсе дә бу турыда беравыздан хаталанганнар итеп күрсәтә вә, шуларга таянып, күп гарәп галимнәренең дә бу хакта күп вакытлар саташып килгәнлекләрен әйтә[4]: 1825 миладигача, бу турыда янә гарәп мөхәррирләренең беравыздан биргән мәгълүматларына таянып, бу язуны күфи язуыннан ике-өч ел соң туган бер язу дип уйлап килгәннәр. Шуның өстенә тагы нәсех язуы гүя күфи язуының хөсне хат[5] ягыннан яңадан үзгәртелеп эшләнгән бер рәвеше генә дип уйлаганнар. Болай үзгәртелештә гүя вәзир Ибне Мукълә[6]

---

[1] Вә суммия хаттуль-гарәб би хаттыль-җәзм ли әннә әл-хатт әл-күфи кәнә әүвәлән йусәммә әл-җәзм каблә вөҗүдел-Куфә ли әннәһү укътутыйгә, әй җүзимә, вә вулидә минәл-мөснәд әл-химьяри вә Мурамир (шәхес исеме) һувә әлләзи икътәтагаһү («Булюг әл-ираб фи әхваль әл-гарәб», б. 382–385).

Тәрҗемәсе:

Гарәп язуы «җәзем язуы» дип аталган, чөнки күфи язуы Күфә [шәһәре] барлыкка килгәнче «җәзем» дип йөртелгән. Билгеле булганча ул «әл-мөснәд әл-химьяри» [язуыннан «җәземи» рәвештә], ягъни киселеп алынган һәм аннан барлыкка килгән. Аны кисеп алучы − Мурамир (шәхес исеме).

[2] Хәрран – Беренче тапкыр хетт язмаларында, аннары Иске Васыятьтә һәм Ассирия патшалыгы язмаларында искә алынган төньяк Месопотамиядәге борынгы шәһәр. Хәзерге вакытта Төркиянең Шанлыурфа провинциясендәге шул ук исемдәге районның административ үзәге.

[3] Мәнбәгъләре – чыганаклары.

[4] История письмен. 139 б. *(Авт. иск.)*

[5] Хөсне хат – матур язу.

[6] Ибне Мукълә һиҗри белән 328 дә вафат. *(Авт. иск.)* Ибне Мукълә – атаклы гарәп каллиграфы.

тарафыннан һиҗри IV, милади белән дә X гасырда уйланып чыгарылган була[1].

Соңыннан табылган хатирәләр нәсех язуының күфидән тумаганлыгын күрсәтәләр. Бу турыда мәсьәлә менә болай ачыла: 1825 елда Мисырдагы француз консулы Дроветти[3] Парижга фәнни тикшерү өчен үзе тарафыннан Сахраи кәбирдә[4] табылган берничә гарәпчә язылган папируслар җибәрә. Бу табылдыклар француз галиме де Зуси[5] кулына төшеп, ул шушы папирусларның гыйбарәләрен тикшерә башлый. Шул вакытта ул гарәп тарихчыларының биргән

---

[1] Әмма Җөрҗи Зәйдан бу фикергә каршы, ул әйтә: «...фә кәтәбү әл-Коръән билкүфи әйямер-рәшидин вә әйям бәни-умәйә. Вә фи әйямиһим тәфәррагә әл-хатт әлмәзкүр илә әрбәгати әкълам уштукъка бәгъдүһа мин бәгъд. Фә зәдәт әл-хатт галә гыйшринә шәклән вә күллүһа түгәддү минәл-күфи. Вә әмма әл-хаттән-нәсхый вәннәбәтый фәкад кәнә шаъиган бәйнән-нәс ли гайрил-махтутат әр-рәсмийәти хәттә изә нәбәга Ибн Мукълә, әл-мөтәвәффа сәнә 328 һ., фә әдхалә фил-хатт әл-мәзкүр тәхсинән җәгаләһү галә нәхви ма һүвә галәйһи әлән вә әдхаләһү фи китабатед-дәвавин. Вәлмәшһүр гыйндәл-мөәррихин әннә Ибн Мукълә нәкалә әл-хатт мин суратил-каләм әл-күфи илә суратил-каләм ән-нәсхый. Вәл-галиб фи игътикадинә әннәл-хаттайн кәнә нәшиәйни мәган мин әүвәлил-Ислам әл-күфи фил-мәсахиф вә нәхвиһа вәннәсхый (әү ән-нәбәтый) лир-расаил вә нәхвиһа кәмә тәкаддәм. Вә ган Ибн Мукълә иннәмә җүгыйлә әл-хатт ән-нәсхый галә кагыйдә җәмилә хәтта йәслүхә ли китабәтелмәсахиф (Тарих әт-тәмәддун әл-ислами. 3 нче җөзе, б. 504). Вәл-әрҗәх әннәһүм кәнү йәстәхдимунәл-каләмәйн мәган әл-күфи ли китабәтел-Коръән вә нәхвиһи минәннусус әд-динийә кәмә кәнә сәләфүһ әс-сәтранҗили йустәхдәмү гыйндәс-сурьян ли китабәтел-әсфар әл-мөкаддәсә ән-нәсранийә вә-нәбәтый ли китабәтел-мәрасил вәлмөкатәбәт әл-игътийәдийә» (Тарих әт-тәмәддун әл-ислами. 3 нче җөзе, б. 53–54).

Тәрҗемәсе: ...һәм тугъры [хәлифәләр] белән бәну-умәйә [чорында] алар Коръәнне күфи язуы белән яздылар. Бәну-умәйә заманында ул хат дүрт төргә бүленде һәм берсе берсеннән аерылды. Соңра язу егерме төрдән артты һәм һәрберсе күфи язуы булып саналды. Нәсех һәм нәбатый язулары кешеләр тарафыннан рәсми булмаган язулар өчен кулланыла иде. Ибне Мукълә (һиҗри белән 328 вафат) әйтеп үтелгән язуны камилләштерде һәм аны бүгенге рәвешкә китерде. Соңрак аны рәсми хатлар өчен куллана башладылар. Тарихчылар арасында билгеле ки, Ибне Мукълә нәсех язуын күфи язуыннан ясаган. Безнең уебызча, ике язу да ислам барлыкка килгән чорда ук кулланылышта иде. Алда искәртелгәнчә, күфи язуы Коръән һәм шуңа охшаган язулар өчен, нәсех яки нәбатый язуы хатлар һәм шуның кебек әйберләр өчен кулланылды. Нәсх язуы Коръән текстлары язар өчен матур кагыйдәләргә нигезләнеп ясалды дип, Ибне Мукъләдән хәбәр ителә (Тарих әт-тәмәддун әл-ислами. 3 нче җөзе, б. 504). Дөресрәге, гарәпләр бер үк вакытта ике язу төрен дә кулланганнар: борынгы сүрияләләр әссәтранҗили язуын изге христиан китапларын күчерү өчен кулланган кебек, гарәпләр күфине Коръән һәм дини текстлар язу өчен, ә нәбатый [язуын] гади хатлар һәм үзара язышу өчен файдаланганнар (Тарих әт-тәмәддун әл-ислами. 3 нче җөзе, б. 53–54).

[3] Бернардино Дроветти (1776–1852) – 1803–1814 елларда Франциянең Искәндәриядәге консулы, борынгы язмалар җыючы.

[4] Сахраи кәбир – Сахара чүле.

[5] Де Зуси – биредә сүз француз галиме, тел белгече, ориенталист Антуан Исаак барон Сильвестр де Саси (1758–1838) турында бара булса кирәк.

мәгълүматларының буш бер әфсанә икәнлеге, бу әфсанәләрнең гарәп тарихындагы чын вакыйгалар белән һичбер мөнәсәбәте булмаганлыгы ачыла.

Шушы папирус кәгазенә язылган язулар һиҗри белән беренче гасырда язылган нәсех язуы булалар. Язуларның гыйбарәләре шуны күрсәткән. Шуның белән бергә папируслардан берсе ниндидер бер Сәед углы Госам (Осам[1])га язылган яшерен бер хат булып, һиҗри 40 елда язылган була. Бу милади белән 660 елга туры килә. Шулай булгач, нәсех язуы, Шницер фикеренчә, гарәп тарихчыларының биргән мәгълүматларына каршы, һиҗрәтнең беренче гасырында ук мәйданга килгән булып чыга.

Иң борынгы күфи язуының хатирәләре заһир булган вакытларны игътибарга алып, соңгы Яурупа галимнәре гарәп язуының шушы ике төре (күфи белән нәсех) я икесе дә бер үк вакытта мәйданга килгәннәр, яки берсе – соңыннан, икенчесе бик тиз бер вакыт эчендә туган булганнар дип уйлыйлар.

**Күфи һәм нәсех язуының асылы-тамыры.** Бердән, гарәп язуының заһир булган җәгърафи урыны (Сүрия тирәсендә), икенчедән – күфи язуының бәгъзе хәрефләренең сызыклары шул ук хәрефләрнең сөрьяни әлифбасындагы сызыкларына бик туры килү, өченчедән – хәрефләрнең саннары бер төрле, ягъни 22 хәрефтән булу, дүртенчедән – бу ике язуның икесендә дә хәрефләрнең әлифба тәртибе бер төрле булу – тикшерүче галимнәрне бу турыда гарәп язуы, ягъни күфи язуы үзенең әсасын инҗил язуыннан[2] алган икәнлек фикеренә китергән[3]. Иң элек шул фикергә килүче – француз галиме де Зуси була. Вакыты белән бу галимнең шушы фикере башка галимнәр тарафыннан да бик муафикъ[4] күрелә, кабул ителә. Ориенталист-

[1] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*

[2] Инҗил язуы – биредә странҗил язуы (эстрангело) – сүриялеләрнең борынгы язулары күздә тотыла.

[3] Җөрҗи Зәйдан да шул фикерне алып: «Ләкин нәбатый һәм сөрьяни язулары аларда ислам яулап алулары тәмамланганчы кулланылышта булган һәм [соңрак] нәбатый әлифбасыннан нәсех язуы, ә сөрьяни әлифбасыннан куфи язуы (Күфә шәһәре исеменә мөнәсәбәтле) барлыкка килгән» һәм «Моннан шул аңлашыла ки, Гыйрак җирендә яшәүчеләр арасында сөрьяни әлифбасының берничә төре кулланылышта йөргән. Алар аның эстрангело төрен Изге китапларны күчереп язу өчен файдаланганнар. Гарәпләр исламга кадәрге йөз ел дәвамында әлеге язуны үзләштергәннәр һәм бу аларның мәдәни үсешенә сәбәп булган. Эстрангелодан куфи язуы барлыкка килгән һәм әлеге язулар бүген дә бер-берсенә охшаш», ди (Тарих әт-тәмәддун әл-ислами. 3 нче җөзе, б. 53).

[4] Муафикъ – урынлы.

палеографлардан Куб, Гезениус, Фреснель[1], Ренан кебек галимнәр шулар җөмләсеннән.

1880 елгача гарәп язуының асылы – тамыры турысында мәсьәлә менә шулай булып килә. Әмма шушы елда Гарәбстанда әл-Һиҗрә хаузасында[2] нәбатый язулары табылгач, гарәп язуының инҗил язуыннан түгел, бәлки нәбатый язуыннан туып тәрәккый итеп килгәнлеге аңлашыла. Чөнки нәбатый язуы Гарәбстан хөдүдендә[3] миладның беренче гасырыннан ук кулланылган булган. Нәбатый язуын тикшерүләр шул нәтиҗәне бирәләр. Бу – бер. Икенчедән, гарәп язуы белән нәбатый язуы арасындагы ыругдашлык хосусиятләрен[4] инҗил (странҗил) язуына караганда тагын да күбрәк табалар. Җөмләдән, мәсәлән, күфи язуындагы  «син»нең – «с» хәрефенең, әлбәттә, нәбатый язуындагы  «с»дан, күфи язуындагы гайнның – «ع» хәрефенең нәбатый язуындагы  дан икәне ачык күренеп тора. Башкалары һәм шулай.

Фәкать шул кадәресе бар: нәбатый язуыннан мирас булып алынган галәмәтләрне күфи язуында нәсех язуындагы шикелле үк ачык бер рәвештә күрмиләр. Шуның өчен күфи язуы, шөбһәсез, сөрьяни әлифбасы тәэсире астында калгандыр дип уйлыйлар. Бу тәэсирдә аның иң борынгы табигатен үзгәртеп, аның тышкы күренешенә аерым бер саф сөрьяни рәвешен биргәндер, дип төшенәләр. Гарәп әлифбасы сөрьяни нәселеннән дигән карашның да әсасы нәкъ менә шушы тышкы күренеш булгандыр, дип уйлана.

Әмма нәсех язуы турысында бу хәл, ягъни сөрьяни тәэсиренә төшү дигән нәрсә юк. Бу язу иң элек бигрәк тә Мисыр гарәпләрендә нык урынлашып калганлыктан, ул сөрьяни әлифбасы системының тәэсиреннән читтә сакланып кала алган. Шуның өчен дә ул үзендә нәбатый әлифбасының табигатен саф хәлендә саклый алган.

Шул хәлдә без моннан менә шуны ачык күрәбез: әүвәлге бәгъзе мөхәррирләрнең биргән мәгълүматларына таянып уйланганча, нәсех язуы күфи язуыннан соңыннан үзгәртелеп эшләнгән бер язу

[1] Фреснель – биредә сүз француз ориенталисты Фульгенс Френель (1795–1855) турында бара.

[2] Әл-Һиҗрә хаузасында – Һиҗрә бассейнында. Һиҗрә – Гарәп ярымутравы сахраларында борынгы чорларда нәбатыйлар яшәгән төбәк. Гарәп ярымутравының көньягын аның төньягы белән тоташтыручы бу җир элек-электән үк сәүдә кәрваннары юлы кисешкән урын булган.

[3] Хөдүдендә – чикләрендә.

[4] Хосусиятләрен – үзенчәлекләрен.

түгел, бәлки ул гарәп язуының шул ук нәбатый язуыннан туып мәйданга чыккан үзенә аерым бер язу булган икән.

Куфи язуы 22 хәрефтән тора. Бу хәрефләр дә сами әлифбасы тәрбиясендә. Борынгы нәсех язуында да хәрефләрнең шул ук санда булган икәнлекләре шөбһәсез бернәрсә итеп күрсәтелә.

Ләкин борынгы гарәп системасында шушы хәрефләр эченнән һәммәсе дә үзенә аерым бер шәкелдә түгелләр. Язуны даимән кыскартуга омтылып тору тәэсире белән бәгъзе хәрефләрнең шәкелләре бер-берсеннән аерыла алмаслык дәрәҗәдә бертөрле булып әйләнгәннәр. Шул рәвешчә, гарәп әлифбасының төрле хәрефләре иң ниһаять, тәмамән бер-берсенә охшаган галәмәтләр аркылы языла торган булганнар. Мәсәлән, ض, ص ,ز , ر , غ, ع, ح, خ, ش, س , ث, ب, ت ق, ف, ظ, ط хәрефләре кебек.

Хасил, борынгы гарәп әлифбасының 22 хәрефен язу өчен гарәпләрдә барысы 17–18 төрле шәкел булган. Бу хәл, әлбәттә, укуны кыенлаштырган һәм гарәп язуына артык бер билгесезлек биргән. Шуның өстенә тагы 22 хәрефтән гыйбарәт булган әлифба да әле гарәп теленең бөтен авазларын биреп бетерә алмаган.

Менә шушы уңайсызлыкларның һәммәсеннән котылу өчен, Габделмәлик хәлифә[1] заманында, ягъни һиҗри I гасыр соңында гарәп әлифбасына гади бер яңалык кертелә. Диакретик (диакритический[2]) галәмәтләр, ягъни бердән өчкәчә булган гади нокталар уйланылып чыгарыла. Болар да, я юлның өстенә, яки астына куелып, берберсенә охшаган шәкелләрне үзләренең белдергән авазлары белән яхшы аерып тану өчен бер ярдәмче галәмәт булалар. Гарәп әлифбасына кертелгән шушы гади бер яңалык, нәтиҗәдә, гарәпләр өчен күп файда бирә. Бердән, моның аркасында гарәп язуына электә булмаган бер ачыклык һәм мөгайянлык[3] бирелә, икенчедән, хәрефләрнең саннарын гарәп теле өчен кирәк булган микъдарга җиткерүдән яңа шәкелләр уйлап чыгаруга хаҗәт калмый.

Бәлки шул гади бер яңалык белән гарәп теле фонетикасының бөтен вак оттенкаларынача төгәл аңлата алу мөмкин була.

Хәзерге гарәп әлифбасы барысы 28 хәрефтән тора. Димәк, гарәп әлифбасының борынгы һәйәтенә (составына) яңадан 6 хәреф арт-

[1] Биредә сүз Өммәвиләр хәлифәлегенең бишенче хәлифе Әбүл-Вәлид Габдел-Мәлик ибне Мәрван әл-Өмәйя (646–705) турында бара булса кирәк.

[2] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*

[3] Мөгайянлык – аныклык.

| Пальмир хәрефләренең исемнәре | Пальмир әлифбасы | Нәбатый язуы | | | | Гарәп язуы | | | | Гарәп хәрефләренең исеме |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | Хауран язуларында | | Синай язуларында | | Куфи әлифбасы | Нәсех язуы | Куфи әлифбасы | Нәсех | |
| | II миладида | II миладида | III миладида | IV миладида | V миладида | VII миладида | VII миладида | XII миладида | Хәзерге рәвеше: Баш, урта, ахыр, аерым | |




36 нчы шәкел. *Гарәп язуларының каян чыгуы һәм ничек камилләшүе*

тырылган була. Бу алты хәреф тә гарәп теленең үзенә хас булган тавышсыз – самит авазларны күрсәтергә кирәк булуыннан хасил булган. Бу алты хәреф шулар: غ, ذ , خ, ظ, ض, ث. Күрәсез, боларның асыл шәкелләре әүвәлге гарәп әлифбасындагы әүвәлге шәкелләр булып, бары тик шуларның өстенә нокталар гына арттырылган.

Яһүдләр, финикәлеләр һәм башка сами халыклары кебек үк гарәпләр дә башта гел тавышсыз – саңгырау авазларны гына язып, тавышлы – сузынкы авызларны язуда күрсәтмәгәннәр. Сүзләрнең төп мәгънәләре дә аларда фәкать тавышсыз гонсырлар[1] белән генә бирелгән. Тавышлы авазлар исә аерым бер табигатькә һәм ачык бер тәләффызга[2] ия була алмаганнар. Алар бөтенләй укучының үзенә тапшырылган. Иң соңыннан Коръән сүрәләренең гарәптән башка мөселман халыкларының авазларында үзгәртелүеннән куркып, гарәпләр тавышлы авазларны язуда күрсәтү өчен махсус галәмәтләр, ягъни хәрәкәтләр арттырганнар. Хәрәкәт арттыруга ихтыяҗны беренче мәртәбә сизгән һәм аларның галәмәтләрен вә аларның урыннарын билгеләгән кеше гарәп теленең нәхүен[3] башлап төзүче Әбү Әсвәд әд-Дөэли[4] булган (69 h[ижри]дә вафат). Ул бигрәк бу галәмәтләрне исемне фигыльләрдән һәм «хәреф» дип аталган сүзләрдән аерту өчен куйган. Аның да бу галәмәтләрне кәлдани яки сөрьяниләрдән алган булуы дөресрәк булыр дип уйлана. Бу хәрәкәтләр дә баш хәрефләрнекеннән башка төстәге кара белән язылганнар[5]. Бу галәмәтләр – хәрәкәтләр – янә хәрефләр белән бер катардан[6] язылмыйча, я тавышсыз хәрефләрнең өстенә, яки астына куелганнар[7]. Ул галәмәтләр – хәрәкәтләр дә шулардан гыйбарәт: фәтхә өст (ئه – ه), кәсрә – аст (ئى – يـ), заммә – өтер (ؤ – و). Өст үзе ике төрле: кыска (´), озын ('). Аст янә шулай (ِ), ( ٖ ), әгәр бу хәрәкәтләрне (ً), (ٍ), (ٌ ) рәвешендә икешәрдән куелса, болар «ән», «ин», «ун» дип

[1] Гонсырлар – элементлар.

[2] Тәләффызга – әйтелешкә.

[3] Нәхүен – синтаксисын.

[4] Әбү әл-Әсвад әд-Дөэли (603–688) – атаклы гарәп лингвисты.

[5] Җөрҗи Зәйдан. «Тарих әт-тәмәддун әл-ислами». 3 нче җөзе, б. 153–157. *(Авт. иск.)*

[6] Бер катардан – беррәттән.

[7] Фә каләә ләһү Әбүл-Әсвәд: “Изә раъәйтәни кад фәтәхтү фәми фәнкут нуктатән фәүкаһә галә әгъләһ. Вә изә дамәмтү фәми фәнкут нуктатән бәйнә йәдәйил-хәрф. Вә ин кәсәртү фәҗгәлән-нуктатә мин тәхтил-хәрф. Фә кәнәл-гәрабү бәгъдә зәликә йәстәгъмилүнә һәзиһин-нукат. Вәл-галиб ән йәктәбүһә би-ләүн гайри ләүнил-хатт. Фән-нуктату фәүкаль-хәрф фәтхә, вә тәхтәһү кәсрә, вә бәйнә йәдәйил-хәрф даммә кәмә вәдагәһә Әбүл-Әсвәд (Тарих әт-тәмәддун әл-ислами. 3 нче җөзе, б. 153–157).

укылган һәм укылалар. Янә гарәпләрдә бер хәрефне ике мәртәбә укыту өчен дә – тәшдид (ّ), хәрефләрне сузып әйтү өчен мәд (~) галәмәте кулланылган.

Бөтен шушы ярдәмче галәмәтләр белән булган гарәп язуы бигрәк тә Шимали Африка (Фәс, әл-Җәзаир кебек) гарәпләрендә күп кулланылган. Боларда бу язу, аерым бер исем алып, мәгъриби[1] дип йөртелеп киткән.

## Җәнүби[2] сами әлифбалары

Сами әлифбаларының янә кечек бер төркеме бар. Әлифбалар турысындагы мәгълүматны тутыру өчен, бу урында болар турысында да бераз язып үтәргә кирәк. Югарыдагы сами әлифбалары шимали[3] самиларда туган әлифбалар иде. Шулардан аеру өчен, боларны «җәнүби сами әлифбалары» дип атыйлар.

Җәнүби сами әлифбалары төркеме үзенең нәселе һәм тарихи тәрәккыйсе белән сами әлифбасының гомуми тәрәккыйсеннән (эволюциясеннән) аерыла. Шуның өчен бу кечек төркемне фәндә аерып тикшерәләр.

Җәнүби сами әлифбалары үзләренең тәрәккыйләрен шул ук самилар гыйркыннан булып та, самиларга тел вә этнография җәһәтеннән ыругдаш булган халыкларда табалар. Бу язуга малик булган сами халыклары: минәйләр[4], савиләр[5], химьярилар һәм хәбәшиләрдер[6]. Димәк, бу язуларның асыл урыны Бәхре Әхмәр (Кызыл диңгез) нең ике ягыннан бер-берсеннән Бабелмәндаб бугазы белән аерылган ике мәмләкәттә, ягъни Йәмән белән Хәбәшестанда була.

---

Тәрҗемәсе:

Шуннан соң Әбүл-Әсвәд аңа әйтте: «Әгәр минем авызымны ачканымны күрсәң, шул чакта ноктаны хәреф өстендә куй. Әгәр минем авызымны бергә кушканымны күрсәң, шул чакта ноктаны хәреф алдыннан куй. Әгәр минем авызымны ватканымны күрсәң, шул чакта ноктаны хәреф астында куй». Шуннан соң гарәпләр бу нокталарны куллана башладылар. Башлыча аларны язу төсеннән башка төс белән яза торган булганнар. Хәреф өстендә нокта – фәтхә, хәреф асында – кәсрә, хәреф алдыннан – даммә (Тарих әт-тәмәддун әл-ислами. 3 нче җөзе, б. 153–157).

[1] Бу Көнбатыш язуы – Африка язуы димәк буладыр. *(Авт. иск.)*

[2] Җәнүби – көньяк.

[3] Шимали – төньяк.

[4] Минәй (Маин) – элеккеге Көньяк Гарәбстандагы (хәзерге Йәмән территориясенең төньяк өлеше) борынгы кабилә һәм дәүләт. Б. э. к. XIV гасырда барлыкка килгән.

[5] Савиләр – Көньяк Гарәбстан (хәзерге Йәмән) терриияториясендә яшәгән һәм Сабей патшалыгы төзегән халык.

[6] Хәбәшиләрдер – эфиопиялеләрдер.

Бөтен шушы төркем әлифбалар эченнән тагы да борынгырак бер язу – химьяр яки сави әлифбасы дип аталган әлифба. Яурупа галимнәренең сүзләренә күрә, бу әлифба үзенең хәрефләренең шәкеле белән ике төрле рәвеш күрсәтә. Болардан берсенең зоһуры миладтан элек[1] I гасырдан да югары бармый. Икенчесенең хатирәләре Йәмәннең шималендә Минәй дәүләтенең хәрабәләрендә табылган. Димәшкъ язуының хатирәләре дә шуңа нисбәт бирелә.

Химьяр язуы белән якын ыругдаш булган язу – хәрефләрнең шәкеле ягыннан хәбәш язуы дип күрсәтелә. Ләкин хәбәш язуы – химьяр һәм башка сами язулары кебек уңнан сулга таба язылмыйча, бәлки хәзерге Яурупа язулары кебек сулдан уңга таба языла торган бер язу. Бу да хәбәшиләрнең юнаннарга тәкълид итүләреннән[2] булган, диләр. Чөнки хәбәшиләр, христанлыкны кабул иткәч, юнаннар тәэсире астында калганнар. Бу рәвештә хәбәшиләрнең язулары юнаннарга тәкълид белән уңнан сулга таба әйләндерелү милади IV гасырда булган.

Сави язуының да шул ук юнанларга тәкълид белән юллары үзгәртелгән, ләкин болар аралаш язганнар. Ягъни бер юл уңга таба барылса, икенче юл сулга таба киткән.

Хәбәш язуында җиде тавышлы хәреф барлыгын бәян итәләр.

Хәбәшиләрнең хәзерге әлифбалары да әнбари дип атала. Бу язуны алар милади XIV гасырда кабул итәләр. Бу да хәбәши теле урынына әнбари теле кабул ителгәндә була. Хәзерге әнбари әлифбасы да – хакыйкатьтә, борынгы хәбәши язуы булып, шуннан үзгәртелгән бер әлифба.

## Иран әлифбасы

Сами (арами) әлифбасы, ниһаять, Иранга да килеп керә. Иранлылар, үзләренең чөй язуларын ташлап, шушы сами әлифбасын кабул итәләр. Бу әлифба монда, иран теленең фонетикасына яраклandырылып бераз үзгәртелгәннән соң, ниһаять, «пәһләви» яки «гүзвәрмеш» исемендәге бер әлифба рәвешенә әйләнеп китә.

Пәһләви әлифбасы чөй язудан соң Иранның иң борынгы әлифбасы булып, озак вакытлар пәһләви теленең ифадәсе[3] булып хезмәт

[1] Зоһуры миладтан элек – безнең эрага кадәр.
[2] Тәкълид итүләреннән – иярүләреннән.

[3] Пәһләви теленең ифадәсе – пәһләви теленең язма гәүдәләнеше.

итә. Пәһләви теле исә – Әрзакиләр сөлялəсе[1] дәверендәге патшалар заманында, ягъни миладтан 256 ел элек вә 226 ел соң булган заманнар арасында йөртелгән бер тел. Пәһләви язуы Ираннан чөй язуны тәмам кысып чыгарганнан соң, ул анда иң күп вакытлар хөкем сөрә.

Иранда Сасанилар сөлялəсе мөнкариз була[2]. Иранлылар да гарәп тәэсире астында калалар. Менә шуннан соң пәһләви язуы да тәдриҗән[3] халык арасында гомуми истигъмальдан чыга да, урынын гарәп әлифбасына бирергә мәҗбүр була. Ул (пәһләви язуы) хәзердә фәкать утка табынучы иранлыларда гына калган, һәм бу аларда дини китапларны язу өчен кулланыла, диләр.

Пәһләви әлифбасының асылы – нәселе – арами әлифбасы булып, аның шуннан эшләнеп чыккан бер әлифба икәне хәзердә фәндә шөбһәсез бер нәрсә санала.

Күптән түгел генә язулы акчалар табыла. Шушы акчалардагы язулар пәһләви әлифбасының иң борынгы бер рәвеше булып чыгалар. Боларны иранлыларның иң шәүкәтле вакытларында кулланылган арами әлифбасы белән чагыштырып караганнан соң, пәһләви әлифбасының арами әлифбасыннан туган икәнлеге тәмамән ачылган хисаплана.

Пәһләви әлифбасы әсасында[4] вә шушы тамырдан Иранда тагы фарис, яки зәнд әлифбасы туа. Бу язу белән Иран пәйгамбәре Зәрдәшт хәкимнең дини тәгълиматы язылган була. Зәнд язуының иң борынгы хатирәләренә карап, аны пәһләви язуыннан байтак заманнар соң тугандыр дип уйлыйлар.

Хәрефләрнең шәкеле ягыннан зәнд әлифбасы пәһләвинең гайне[5] булып, аннан ялгыз хәрефләренең саны белән [генә] аерыла, диләр. Зәнд әлифбасында барысы 45 хәреф күрсәтәләр. Шулар эчендә 30 тавышсыз, 15 тавышлы авазларының хосусияте белән дә һиндиләрнең санскритларына якын килгәнен бәян итәләр. Зәнд әлифбасы янә озак дәвам итә алмый. Ләкин үзеннән хәзерге көндә дә дәвам итеп торган ике төрле ботак чыгарып калдыра. Ягъни аннан әрмән әлифбасы белән грузин әлифбасы хасил була.

Әрмән әлифбасы зәнд әлифбасыннан милади белән V гасырда Тәүратны әрмән теленә тәрҗемә итү мөнәсәбәте белән тудырыла.

[1] Сөлялəсе – династиясе.
[2] Мөнкариз була – юкка чыга.
[3] Тәдриҗән – әкренләп.
[4] Әсасында – нигезендә.
[5] Гайне – күчерелмәсе.

Әрмәннәр аңынчы юнан язуын кулланган булалар. Аннан да элек Иран патшасы Дара вакытында Иранның борынгы чөй язуын үзе белән алыштырган пәһләви язуын эшләткәннәр.

Грузин язуы исә чиркәү язуы (V миладида тудырылган) һәм гражданнар язуы дип икегә бүленә. Мәсруп[1] тарафыннан ихтираг кылынган[2] гражданнар язуы соңрак тәкърибән[3] XIV миладиларда тудырылган була. Әрмән язуы да, грузин язуы да зәнд язуының киресенчә – сулдан уңга таба язуга уңайлаштырылган.

Иран язуының төркемнәреннән янә һинду-бактрия әлифбасын саныйлар. Бу язу шимали Һиндстанда Бактрия[4] хөдүдендә кулланылган булган. Бу әлифбаны янә үзенең табигате, күренеше белән һәм эчке ягы белән арами әлифбасына бик якын табалар. Аерма фәкать монда – сами теле өчен тәмам чит булган уналты төрле хәрефнең булуында гына күрсәтелә.

Һинду-бактрия язуы сами әлифбасы кебек үк уңнан сулга табан язылган.

## Һинд әлифбасы

**Диваны гари[5] яки санскрит язуы.** Соң вакытларгача бу язуны бик иске бер язу дип, аны хәтта миладтан элек XV яки XVI гасырларга нисбәт биргәннәр. Әмма иң соңгы тикшерүләр исә бу язуның миладның башыннан бу якка карап XVI яки XVII гасырлар эчендә заһир булганын күрсәтә. Борынгы һиндиләрнең санскрит әдәбиятлары башта халык авызында гына сакланып йөреп, ул фәкать миладтан IV яки III гасыр элек кенә җыелып, язма хатирә рәвешенә килә алган.

Бу язуны, үзен башка әлифбалардан аера торган бәгъзе хосусиятләренә карап, үзенә башка бер мөстәкыйль әлифба дип уйлап килгәннәр һәм аны турыдан-туры һиндлеләрнең үз иҗатлары дип санаганнар. Ләкин соңыннан Һиндстанда табылган хатирәләр бу карашның хата икәнен күрсәткән. Ягъни бу хатирәләр аркылы һинднең шушы санскрит әлифбасының да сами нәселеннән икәне ачылган.

---

[1] Мәсруп Маштоц (361/362–440) – әрмән әлифбасын булдыручы тел галиме, әрмән әдәбиятына, язуына, педагогик фикеренә нигез салучы, мәгърифәтче, миссионер.
[2] Ихтираг кылынган – уйлап табылган.
[3] Тәкърибән – якынча.
[4] Бактрия хәзерге Әфганстан җирләрендә булып үткән дәүләттер. *(Авт. иск.)*
[5] Диваны гари шәһәр әһелләренең илаһи язулары дигән мәгънәдә. *(Авт. иск.)*

Үзләренең табигатьләре белән бу хатирәләрдәге язуларны ике төркемгә аералар: 1) шимали яки һиндү-бактрия; 2) җәнүби яки асыл һинд язуы.

Беренче төркем хатирәләре Һиндстан ярыматавының шималендә табылган. Шушы һиндү-бактрия исемен алган язу, сами әлифбасындагы кебек үк, уңнан сулга табан язылган. Бу язуның тышкы күренешеннән аның сами системы ыругыннан икәнен ачык күрәләр. Хәзерге һиндү-бактрия язуы үзенең әсасын-тамырын арами әлифбасыннан алган дип табыла. Шул ук хәзерге фәннең күрсәтүенчә, ул соңра үзенең беренче тәрәккыйсен борынгы Бактриядә таба. Аннан ул, Һиндстан әхәмәниләренең[1] хакимиятләре астында булган чакларда, шимали Һиндстанга китерелгән була.

Җәнүби язу яки асыл һинд язуы, яисә мәгади язуы исә үзенең тышкы күренеше белән һиндү-бактрия язуыннан күп аерылган, хәтта монда юллар да һиндү-бактрия язуындагыча уңнан сулга таба түгел, бәлки сулдан уңга таба барган.

Соңгы тикшерүләр шушы асыл һинд язуы «Диваны гари» язуының әсасы-тамыры булганын күрсәтәләр. Хәлбуки, күп заманнаргача «Диваны гари» язуын бөтен һинд язуларының анасы дип уйлап килгән булганнар.

Кыскасы, шулай итеп, соңгы фәнни тикшерүләр нәтиҗәсендә Һиндстан язуларының үзләренең башка бер мөстәкыйль әлифба булмастан, бәлки шул ук дөньядагы башка әлифбаларның туганы вә шул ук сами – арами әлифбасының баласы икәне ачык беленә.

Фәкать тикшерүче галимнәрдән Тейлор[2] һинд язуларының беренче мәнбәгъләрен[3] химьяр һәм хәбәши түгел, бәлки сави әлифбасы дип күрсәтә. Хәзер дә шушы нәзария һәрьяктан мәкъбуль[4] дә. Тарихи яктан да Һиндстан язуларының башлап заһир булган[5] заманалары Һиндстан ярымутравындагы халыкларның Җәнүби Гарәбстан вә хосусан савиләр белән бик җанлы бер сәүдә мөнәсәбәтендә булынган вакытларына туры килүе дә шул нәзариянең дөреслегенә дәлил итеlә. Савиләр дәүләте (хәзерге Йәмәнгә туры

[1] Биредә сүз борынгы Персиядәге Әхәмәниләр дәүләтенең патша династиясе турында бара булса кирәк.

[2] Биредә сүз инглиз галиме, этнологы, культурологы Эдвард Бёрнетт Тайлор (Тэйлор) (1832–1917) турында бара.

[3] Мәнбәгъләрен – чыганакларын.

[4] Мәкъбуль – яхшы табылган.

[5] Заһир булган – барлыкка килгән.

килә) һиндиләрнең үзләрендәге табигый байлыкларны ташый торган бердәнбер урыннары (пунктлары) булган. Үзләренең язулары булмаганлыктан, әлбәттә, бик табигый уларак, һиндстанлылар бик күп вакытлар сәүдә васитасы итеп сави әлифбасы белән файдаланганнар. Һиндстандагы Сәйлүн, Сиям, Пирман, Ява, Мали вә башка шулар кебек язулар һәммәсе һинд язуының ботакларыннан санала.

## Яурупа әлифбалары яки Юнан-Италия әлифбасы гаиләсе

Хәзерге вакытта бөтен Яурупа язулары арасында иң тыгыз бер ыруглык багланышы-элемтәсе бар икәнлегендә һич шөбһә юк. Бу язулар һәммәсе дә борынгы самилар әлифбасының ыругыннан булып, бөтен палеограф (иске язуларны тикшерүче) галимнәрнең беравыздан кабул иткән фикерләре буенча уртак бер атадан (родоначальник[1]) ягъни финикә әлифбасыннан чыкканнар. Икенче яктан янә юнаннар үз әлифбаларын хакыйкатән[2] самилардан алган икәнлекләре ачык мәгълүм. Моның өчен дә безгә башка дәлилләргә мөрәҗәгать итеп торырга хаҗәт юк. Моның өчен эчке җиһәт яки палеографик исбатлар гына да җитә, ягъни әлифбаның үз хосусияте һәм юнан хәрефләренең форма-шәкелләрендәге хосусиятләр, хәрефләрнең берсе артыннан икенчесе килүләрендәге тәртипләр, хәрефләрнең алган исемнәре, юлларының юнәлешләре вә башкалар кебек хосусиятләр шул җөмләдәндер. Юнанстанда табылган бөтен иске юнан әлифбасының хәрефләре финикә әлифбасының хәрефләреннән һич аерылмыйлар. Болар арасындагы охшашны хәтта шул кадәре гаҗәпкә калдырырлык бер рәвештә табалар ки, монда нинди дә булса бер тәсадефе[3] вә иттифаклык турысында сөйләү бөтенләй килешмәгән ят бер нәрсә булыр иде, диләр.

Иске юнан хәрефләренең тәртипләре дә – нәкъ финикә әлифбасындагы тәртип. Хәрефләрнең исемнәре нәкъ самилардагыча. Самиларда һәрбер хәрефнең бер исеме булып, шушы исемнәрнең һәрберсе мәгълүм бер аңны, мәгълүм бер мәгънәне бирәләр. Мәсәлән, «әлифба» дигән сүз – яһүдләрчә һәм финикәлеләрчә «үгез» дигән мәгънәдә, «Бәйт» (ب) – «өй» дигән мәгънәдә. Юнанлыларда янә шул ук исемнәр.

[1] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*
[2] Хакыйкатән – чыннан да.
[3] Тәсадефе – очрашуы, бәрелеше.

Ләкин боларда шушы исемнәрнең вакыйгый[1] һичбер мәгънәләре юк. «Әлиф», «ба», «дәл» дигән сүзләр боларда һичбер мәгънәгә йөртелми, һәм болар аларда ялгыз шартый[2] бер галәмәтләр генә, чөнки боларның телләрендә мондый сүзләр юк.

Шулай ук юнанлылар, самилар шикелле үк, юлларны башта уңнан сулга таба язганнар. Менә бу инде юнан әлифбасы сами әлифбасының баласы икәнен ачыктан-ачык күрсәтеп торган төп бер факт санала.

Үзләрендә хәрефләр мәркәзгә юнәлеш (центростремительное направление[3]), ягъни уңнан сулга барыш юлында язылган борынгы юнан язулары безгә сакланып калалар. Димәк, юнаннар, язуны һәм аның хәрефләренең исемнәрен самилардан алу белән бергә, юлларның язылуда мәркәзи юнәлешләрен дә алардан алган булалар. Тик соңыннан гына юнаннар мәгълүм бер шәраит[4] астында тәдриҗән[5] язуда юлларның юнәлешен мәркәздән тайпылу (центробежное направление[6]) ягына әйләндергәннәр, ягъни юлларны сулдан уңга яза башлаганнар.

Иң борынгы юнан язуларының хатирәләрендә дә әлифбаның хәрефләре барысы финикәлеләрдәгечә, 23 хәреф.

**Юнаннар финикәлеләрдән әлифбаны кайчан алганнар.** Бу турыда иң иске юнан язуларының хатирәләренә карап хөкем чыгаралар. Ленорман[7] һәм Тейлор кебек галимнәр бу хатирәләрнең һәрхәлдә миладтан элек[8] IX йөз елдан вә ниһаять VIII йөз елдан да соң язылмаганлыкны әйтәләр.

Янә юнаннарда миладтан элек VIII гасырның ярымыннан VII гасырның ярымынача, ягъни шул ике арада, юнаннарның бустрафедон (бустрафедон[9]) дип атаган бер язуларының хатирәләре дә булып, монда юлларның юнәлеше аралаш, ягъни уңнан сулга да, сулдан уңга табан да язылган була.

---

[1] Вакыйгый – реаль.

[2] Шартый – шартлы.

[3] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*

[4] Шәраит – шартлар.

[5] Тәдриҗән – әзлекле рәвештә.

[6] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*

[7] Франсуа Ленорман (1837–1883) – француз ассириологы, антрополог, нумизмат, сәнгать белгече. 1874 елдан Франция милли китапханәсендә археология профессоры.

[8] Миладтан элек – безнең эрага кадәр.

[9] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*

Юнаннарның тагы иң соңгы борынгы язу хатирәләре дә булып, болар фәкать сулдан уңга таба гына язылган була. Бу язуда инде юнаннарның саф үз хәрефләрен дә очраталар. Бу соңгы язулары исә миладтан элек VII гасырның 2 нче ярымына гаидтер[1].

Менә шушы тарихи хатирәләргә карап, юнаннарның финикә әлифбасын кайчан кабул иткәнлек мәсьәләсенә килгәндә, галимнәр моны миладтан элек X гасырга кайталар. Һич булмаганда да IX гасырдан да соң түгел, диләр. Ленорман, Тейлор һәм Кирхгок[2] дигән галимнәр һәм башка юнан язуларын белүче күп алдынгы галимнәр шуны әйтәләр.

Соңыннан юнаннар финикәлеләрдән алган сами әлифбаларын һаман үзгәртә баралар: 1) юлларның юнәлешен сулга әйләндерү; 2) телләренең таләбе буенча үзләреннән яңа хәрефләр арттыру (самиларда тавышлы авазларны белдерү өчен һичбер махсус галәмәтләр булмаган. Юнаннар әнә шуны арттырганнар); 3) юнан теле өчен муафикъ булып җитмәгән[3], аның фонетикасына килмәгән бәгъзе бер хәрефләрне чыгарып ташлыйлар.

Бара-бара юнаннарда барысы дүрт төрле әлифба хасил булып, шулардан икесе күп тәрәккый итеп һәм таралып китә. Бу ике әлифба шулар: 1) ионнар әлифбасы (алфавит ионский[4]) яки Кечек Азия юнаннарының әлифбасы; 2) иоло-дор яки Элладаның һәм Италия колониясенең (Бөек Юнанстан) әлифбасы.

Болардан беренчесе Афинада рәсми рәвештә Икълидс[5] дәверендә 403 миладта гамәлгә куела һәм шуннан соң бу бөтен Юнанстанда бик тиз таралып китә. Икенче әлифба исә (иоло-дор әлифбасы) «халкиди» әлифбасы дип тә аталып, бу әлифбаны юнаннардан Италия халыклары алганнар. Һәм шушы әлифба италиялеләрдә аларның икенче бер әлифбаларының атасы булып әйләнгән. Арада шу-

---

[1] Гаидтер – карый.

[2] Биредә сүз немец филологы, Берлин университеты профессоры Иоганн Вильгельм Адольф Киргхоф (1826–1908) турында бара булса кирәк. Автор тарафыннан, яки типографиядәге хәреф җыючы тарафыннан төгәлсезлек китеп, Киргхоф урынына Киргхок дип басылган булуы мөмкин.

[3] Муафикъ булып җитмәгән – туры килеп бетмәгән, кулай булмаган.

[4] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*

[5] Икълидс – Евклид (б. э. к. 325–265 еллар тирәсе), борынгы грек математигы, геометр, Александриядә математика мәктәбенә нигез салучы.

лар: 1) этрус[1] әлифбасы. Моннан берничә төрле үзгәрешләр белән умбрлар[2], осклар[3], сабилләр[4] һәм башка Италия халыклары файдаланалар; 2) латин әлифбасы. Менә бу әлифба бөтен Гарби Яурупа әлифбалары типларының төп тамыры булып әйләнә.

**Италиягә юнан әлифбасы күчү.** Мәгълүм тарихи шәраитнең кысуы буенча бик борынгы бер заманнарда юнаннар күпләп-күпләп Җәнүби Италиягә күчәләр дә, анда «Бөек Юнанстан» исемендә күп колония (мөстәмләкә)ләр ясыйлар, әнә шул вакытларда юнан әлифбасы Италиягә китерелеп, Аппенин ярымутравының хәтта бөтен халыклары тарафыннан шул юнан әлифбасы кабул ителә. Шулай итеп, моннан Италиядә төрле әлифбалар хасил була: 1) этрус әлифбасы; 2) умбр әлифбасы; 3) оскис әлифбасы; 4) фаллис әлифбасы; 5) сабил әлифбасы; 6) борынгы латин әлифбасы вә башкалар. Болар башта юнан әлифбасыннан һич аерылмыйлар. Ләкин соңыннан, телләренең хосусиятләренә карап, үзгәреп китәләр. Ниһаять, болар, шулай итеп, телләренең таләпләренә яракландыралар һәм хәрефләренең шәкелләре вә исемнәре белән юнан әлифбасыннан тәмам аерылып китәләр.

Италия зәминендә[5] юнан әлифбасыннан хасил булган иң беренче әлифба этрус әлифбасы була. Ләкин бу көнгәчә бу язу һәм этрус теле әле тикшерелеп тәмам укыла алмаган бер хәлдәдер (бу язулар күбрәк савыт-сабаларда очратыла). Әмма бу язуның финикәдән түгел, бәлки юнан әлифбасыннан алынган булуы хәзердә ачык бер хакыйкать санала. Бу язу да, борынгы юнан язуы кебек, уңнан сулга язылган була.

Шул ук этрус язуын артык бер үзгәрешсез үк умбрлар, осклар, сабилләр, кәлтибрләр һәм борынгы башка күп Италия халыклары алалар. Боларда һаман уңнан сулга таба язылган була.

---

[1] Этрус – б. э. к. I меңьеллыкта Аппенин ярымутравының төньяк-көнбатышында (борынгы Этрурия өлкәсе, хәзерге Тоскана) Арно һәм Тибр елгалары арасында яшәгән һәм Рим культурасыннан алдарак үсеш алган, аңа зур йогынты ясаган борынгы цивилизация.

[2] Умбрлар – борынгы Италия кабиләсе. Бронза гасыры ахырында Үзәк Италиядә формалашкан борынгы итальян халкы.

[3] Осклар – б. э. к. II меңьеллык ахырыннан көньяк һәм урта Италиядә яшәгән борынгы итальян кабиләләре.

[4] Сабилләр – антик Италиядә Римга нигез салынганчы, хәзерге Лацио, Умбрия һәм Абруццо административ районнары территориясендә, Аппенин тау итәгендә яшәгән халык.

[5] Зәминендә – җирлегендә.

Ләкин бу язулар күп дәвам итә алмый. Бәлки Италия утравының төрле халыклары Рума хакимияте астында куәтле бербөтен хәлендә берләшеп, укмашып алганнан соң, бу әлифбалар һәммәсе тәдриҗән бетә баралар һәм урыннарын латин яки рум язуына бирәләр. Ниһаять, тиз заманда латин язуы бөтен Италия ярымутравы халыклары өчен уртак бер язу булып әйләнә.

**Латин язуы-әлифбасы.** Һич шөбһәсез, Рума халыклары бик иске заманнардан бирле язу истигъмален белгәннәр.

Ләкин латин әлифбасының кайдан алынганлыгы турысында галимнәрнең фикерләре төрлечә: берләре – румалылар әлифбаны, башка борынгы Италия халыклары кебек үк, этруслардан алганнар дисәләр, бәгъзе берләре дә рум әлифбасы-язуы турыдан-туры юнан әлифбасыннан алынганлыгын исбат итәргә тырышалар. Димәк, латин әлифбасының кайдан алынуы мәсьәләсе ихтиляфлы[1] бер мәсьәлә булып, әле катгый хәл ителмәгән санала.

Бу ике бер-берсенә каршы фикерне болай берләштерергә дә телиләр: румалылар иң элек этрус әлифбасын яки шуңа якын булган бер әлифбаны кулланган булып, соңыннан (миладтан тәхминән[2] V вә IV гасыр элек бер заманда) болар аны юнан әлифбасы белән алыштырган булырлар. Моны да табылган тарихи хатирәләргә таянып эшлиләр.

**Латин әлифбасының таралуы.** Рума язуы бер вакытларда хәтта бөтен дөньяга хаким бер халыкның һәм дә христианлык тәгълиматы белән бергә үзләренең язуларын һәркайда таратучы рума католик чиркәүләрендә (кәлисәләрендә) дини китапларның язуы булганлыктан, бу язу рума мәдәнияте белән мөнәсәбәтле була вә һәртөрле халык арасында бик тизлек белән таралып өлгерә. Шулай итеп бу язу шимали һәм мәркәзи Яурупаның күп халыкларында истигъмальдә булган җитешсез рун язуы системасын һәр җирдә кысып, бөтен роман һәм герман (җәрмән) шивәләрендә[3] ныгып тамырланып ала. Шул рәвешчә, төрле вакытлар эчендә Италия, Испания, француз, инглиз, Голландия, немец, швед, дад[4], литва телләренә һәм борынгы

[1] Ихтиляфлы – каршылыклы.
[2] Тәхминән – якынча.
[3] Шивәләрендә – сөйләшләрендә.

[4] Дад – дат.

рус вә серб, болгар телләреннән башка бөтен эслау телләренә кабул вә татбикъ ителә[1].

Шушы төрле яңа халыкларда инде соңыннан бара-бара латин әлифбасы төрле үзгәрешләргә очрый. Бу үзгәреш тә бигрәк хәрефләрнең язылу рәвешләрендә күрелеп, әлифбаның составы, гомумән, һаман әүвәлгечә кала.

Башта бу халыклар капитальное[2] яки прописное[3] язу дигән туры сызыклар һәм тигез почмаклардан гыйбарәт эре хәрефләр белән язалар. Соңра шәп язу, тиз язу ихтыяҗы белән бу язу унциальное[4] яки строчное письмо[5] дигән язуга алмашына. Бу язуда инде хәрефләр түгәрәк бер шәкелне һәм ятынкы бер хәлне алалар. Янә соңрак моннан аерым бер тиз язу рәвеше туа. Монда инде хәрефләр бердән һәм дә үзара сызыклар белән багланып языла торган була. Ниһаять, милади XIII гасырның башында, хәрефләрнең бик күптөрле тәдрижи[6] үзгәрешләре нәтиҗәсендә, латин язуы готик (готическое[7]) дип яки схоластик яисә лудвикавик дип аталган бер рәвешне ала. Үзенең матур, нәфис рәвешле булганлыгы өчен готик язу бөтен Яурупага бик тиз таралып китә. Соңыннан бу язу үзенең урынын язуга тагы да җиңелрәк булган борынгы классик рума әлифбасы язуына бирә. Бу соңгы язу да венецианский почерк[8] дип атала.

Готик язуның хәзердә дә истигъмале немецларда һәм немецлашкан эслауларда гына сакланып калган. Немецлар бу язуда үзләренең милли хосусиятләренең саклануларын күрәләр.

## Рун язуы

Рун язуының нәселе, аның кайдан туганлык мәсьәләсе һәм рун язуы системының тәрәккыйсе мәсьәләсе иң борыны заманнарда Шимали Европа халыкларында кулланылган идеографик сызыкларның мәгънәсе һәм маһияте[9] мәсьәләсенә баглы. «Рун» исеме яки «рун

[1] Татбикъ ителә – яраклаштырыла.
[2] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*
[3] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*
[4] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*
[5] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*
[6] Тәдрижи – эволюцион.
[7] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*
[8] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*
[9] Маһияте – үзлеге.

галәмәтләре» исеме иң башта шушы идеографик сызыклар өчен заһир булгандыр. «Рун» сүзе үзе гот яки ингло-саксон[1] сүзеннән булып, «сихерле язу» яки «серле хикмәт» мәгънәсендәдер. Хакыйкатән дә[2] бу рун язуы галәмәтләре Шимали Яурупа халыкларының әлифба системын кабул иткәнчә булган серле-сихерле язуларыннан булган. Рун язуының галәмәтләре һәм мәгънәләре торышында таянычлар – сәнәдләр[3] юк. Бу турыда ялгыз тарихи нәкыльләр[4] генә бар. Боларга таянып, бу язу турысында шуны әйтәләр: ирландиялеләр, скандинавиялеләр, скифлар, германлылар һәм башка Шимали Яурупа халыклары бер вакытларда, кыйсмән[5] үзләренең фикерләрен аңлату өчен вә бигрәк тә гыйбадәтләрне, дини гадәтләрне үтәгәндә, махсус бер таякчалар кулланганнар. Бу таякларга да һәртөрле киртек вә сызыклар рәвешендә үзенә махсус бер галәмәтләр белән киртәчләгәннәр[6]. Бу галәмәтләрнең дә һәркаюсы[7] мәгълүм бер мәгънә белән баглы булганнар. Һәм соңгы рун язулары системындагыча бу галәмәтләр аерым авазларны аңлату өчен түгел, бәлки бөтен бер аңны, бөтен бер фикерне вә хәтта бөтен бер гыйбарә (фраза[8])ны аңлату өчен хезмәт иткәннәр. Димәк, бу яктан бу галәмәтләр Мексика һиндиләрендәге язулар кебек булганнар.

Мәшһүр латин тарихчысы Тацикның[9] бәянынча, киртекле галәмәтле бу таяклар күп вакытта борынгы германлылар тарафыннан серле мәгънәләрне табу (гадание[10]) өчен кулланган булганнар. Бу да менә шулай эшләнгән: һәртөрле сызыклар белән чуарланып беткән таякчалар киндер кебек (полотно[11]) бер нәрсәгә җәелеп, таратып салынганнар да, һәрбер бәхет сынатучы үзенә өч таяктан сайлап алган. Әмма багучы-сихерче алардагы сызыкларны мөбһәм[12], сихерле сүзләр белән изах итә[13] торган булган.

---

[1] Ингло-саксон – англо-саксон.
[2] Хакыйкатән дә – чынлап та.
[3] Сәнәдләр – дәлилләр.
[4] Нәкыльләр – риваятьләр.
[5] Кыйсмән – берникадәр.
[6] Киртәчләгәннәр – киртләчләгәннәр.
[7] Һәркаюсы – һәркайсы.
[8] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*
[9] Биредә борынгы Рим тарихчысы Публий (Гай) Корнелий Тацит күздә тотыла булса кирәк.
[10] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*
[11] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*
[12] Мөбһәм – аңлаешсыз.
[13] Изах итә – аңлата.

Борынгы рун галәмәтләре кебек мондый галәмәтләрнең мәҗүси вакытларында борынгы эслауларда да кулланылган булуын уйлыйлар.

Бөекбританиянең ике утравындагы язу хатирәләрендә күренгән һәм «әгами язуы» дип аталган үзенә махсус бер язуны да Шимали Яурупа халыкларының үзләренең фикерләрен аңлату өчен киртек вә сызыклар куллану гадәтләре белән изах итәләр. Бу язу да үзенең исемен борынгы Ирландия мифологиясендәге бер алла исеменнән – «Әгъма»дан алган, ягъни бу язу шуңа нисбәт бирелгән була.

Герман нәселеннән булган борынгы халыкларда рун әлифбасы да тудырылып, монда сүзләрдәге авазлар, сызыклар аркылы белдерелергә эстәлгән[1].

Гомуми герман, рун язуы башта 24 хәрефтән гыйбарәт була. Миладе IX гасырда исә Скандинавия ярымутравындагы халыкларда ул бераз үзгәрешләргә очрый башлый. Ниһаять, рун язуы боларда 16 хәрефкә генә калдырылып, рун системының кыскартылган яки яшь бер тибы тудырыла. Соңра, X гасырдан башлап, скандинавиялеләр, бу язуның телләренә төгәл җитмәгәнлеген күреп, моңа гарәпләрнең язуындагы нокталарга охшаш бәгъзе рун хәрефләренә диакретик нокталар арттыралар. Шулай итеп, ниһаять, пунктированный[2] рун әлифбасы дигән бер рун системының соңгы бер тибы мәйданга чыга.

## Төрк[3] халыкларында язу

Кешелек дөньясында әле чын язу дигән нәрсәне тудырудан элек, шуңа хәзерлек дәверләре – әйбер язуы һәм сурәт-фигура язуы баскычлары булып үткәнен без китапның баш ягында күреп уздык. Бу дәвер вә баскычларның да Америка (астекләр), Гарби Европа (Скандинавия, эслау, герман), Африка (Африка вәхшиләре, зәнҗиләр[4]) һәм Азия (тунгус, магул, кытай) халыкларында булып үткәнен дә аңладык. Төен язу, кабык язуы, ырмау[5] һәм киртләч язу кебек язулар шундый баскычлардан иде.

[1] Эстәлгән – теләнгән.
[2] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*
[3] «Төрк» дигәндә төрки халыклар күздә тотыла.
[4] Зәнҗиләр – кара тәнлеләр.
[5] Ырмау – уенты, киртләч.

Менә шушы дәверләрне, шушы баскычларны, әлбәттә, төрк халыклары да үткәргән булу – бик табигый бер нәрсә. Бу – шул юлдагы тарихи бер мәҗбүрият. Бу дәвер, әлбәттә, аларда булып үткән булырга тиеш. Башкалар, үзләренең хәтерләренә төрле юллар белән ярдәмчеләр эзләп, башта шул юлда төрле әйберләрдән, төеннәрдән, ырмаулардан, төрле сурәтләрдән файдаланганнар икән, иң борынгы вәхшәт дәрәҗәсендәге төрк халыклары да шулардан, әлбәттә, файдаланганнардыр.

Төрк халыклары болар җир йөзенең – Азиянең иң иске бер халыклары, шуның белән бергә болар бик күптәннән кытайлар белән бик якын мөнәсәбәттә булып, алар белән сәяси, иҗтимагый, икътисади яктан багланып килгәннәр, алар белән күп сугышлары, алыш-бирешләре булып торган. Бәлки төрк халыкларының кытайлардан да элек башка бер хәл белән мөнәсәбәтләре булмаган, дисәк мөмкин. Аларның беренче яшәгән бишекләренең җәгърафи[1] мәүкыйглары (урыннары) үзе үк шуны күрсәтеп тора. Шуның өстенә аларның соңыннан бөтен җәелгән урыннарын[2] алсак, моннан аларның хәтта күптән үк бөтен Яурупа вә бөтен Азия халыклары белән дә мөнәсәбәттә булып, багланышып килгәнлекләрен күрербез.

Шулай булгач, төрк халыкларының һич булмаганда шуларның тәэсирләре белән дә язуның борынгы хәзерлек дәверләрен кичергән икәнлекләре шөбһәсез бернәрсә булып кала. Шуның белән бергә әүвәлдән үзенә һичбер хәзерлеге булмаган, шуңа хәзерлек баскычларын һич үткәрмәгән бер халыкның соңыннан бердән әлифба язуын (настори әлифбасы кебек) кабул итүләрен уйлау кыен да булыр иде.

Я.И. Шницерның татар-уйгур турысында: «Татар-уйгурлар Урта Азия халыклары арасында үзләренең фикерләрен «кхему» («кхе-му[3]») дип аталган язу, ягъни ырмаулы – киртләчле таяклар

[1] Җәгърафи – географик.

[2] Охотский диңгезендә Печора елгасына барып, аннан Вятка елгасының мәнбәгына *(чыккан урынына)* килсәк, шуннан янә Днепрның койгалагына – мәнсабына төшеп, аннан шәркый җәнүбигә борылсак, һәм Тарик, Кубань елгаларына барып, Кавказ тауларына терәлсәк, аннан Хотанның җәнүбенә бер сызык сызып, шуннан Япон диңгезендәге Пётр Великий көрфәзенә *(култыгына)* барып чыксак, шуның белән төрк халыкларының вә магул-татарларның яшәгән вә бер заманнар хөкем сөргән урыннарын тәкъррибән *(якынча)* чикләп чыккан булырбыз (бу сызык эченә Мавәраэннәһерне дә керттек). *(Авт. иск.)*

[3] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*

аркылы аңлата алу белән мөмтаз[1] иделәр. Хәтта боларда әле шушы көнгәчә ачылып, беленеп җитмәгән үзенә махсус бер төрле фигуралы язу да бар иде. Моның намүнәләре[2] Себердә күп табылган»[3], – дигән сүзләре дә шушы югарыдагы фикерләребезгә куәт бирә. Моңа янә Томсенның[4] Орхон язулары башта, рун язулары шикелле үк, агачларга чокылып язылганын вә шуның өчен аларның гомуди һәм авык сызыклардан гыйбарәт булырга тиешлеген бәян итүен дә кушсак, мәсьәлә тагын да ачыла төшә. Бер кытай мөхәрриренең «төркләр, мөгаһадә – шартнамә ясаганда, тактага галәмәтләр (хәрефләр) чокып төшерәләр»[5] дигән сүзе инде мәсьәләне яхшы ук ачып җибәрә. Шницерның «кхему» дигән язуы нәкъ шушы язу булу ихтималын көчәйтә.

Шуның өстенә тагы Радлов үзенең 1910 ел 28 октябрьдә Петербург әсаре гатика[6] җәмгыятенең шәрык бүлемендә уйгурлар һәм аларның язулары турысында ясаган бер докладында: «Төркләр язу язарга кытайлардан өйрәнделәр. Төрк телендәге «битмәк, бите» сүзләре шуны исбат итәләр. Бу сүз кытайча «би» (яки пи, борынгы әйтелүе – «бит») сүзеннән алынган», – дигән фикерне катгый кылып әйтеп үтә[7].

Вакыйган, уйгур (Кашгар) төркләрендә «язмак» мәгънәсендә «битмәк» сүзе йөргән кебек, тунгусларда һәм магулларда да бу мәгънәдә шул сүз йөри (тунгусчада «бетим – язмак», «битмәти – язышмак», магулчада «битмиху – язмак», «битми хуху – яздырмак», «битиләчху – язышмак» мәгънәсендә) – маҗарчада исә «бәтү» сүзе – язу хәрефе мәгънәсендәдер[8].

Менә бу фикердән янә без төркләрдә иң элекке язу кытайларныкына охшаш (мәсәлән, ырмау, төен язу кебек) язу булганын һәм аларның бу турыда иң элек алар тәэсирендә калган икәнен аңлый алабыз.

---

[1] Мөмтаз – өстен.

[2] Намүнәләре – үрнәкләре.

[3] Е.Я. Шницер. Иллюстрированная всеобщая история письмен. С. 130–133. *(Авт. иск.)*.

[4] Вильгельм Людвиг Петер Томсен (1842–1927) – данияле тел бегече, тюрколог, тарихчы.

[5] «Сборник трудов Орхонской экспедиции» мәҗмугасына кушылган «Орхонские надписи по истолкованию датского ученого» дигән мәкалә. *(Авт. иск.)*

[6] Әсаре гатика – борынгы әсәрләр.

[7] Зап. Вост. Отд. Имп. Русск. Арх. О-ва, т. XXI, вып. IV. *(Авт. иск.)*

[8] Гасыйм Н. Төрек тарихы. Б. 34. *(Авт. иск.)*.

Тарихлар кытай вакаигънамәләреннән[1] алып, миладтан ничә гасырлар элекке тарихлары мәгълүм булган «Һиунг-ну»[2] (һун-ну), ягъни һун төркләрендә язу булганлык хәбәрен бирәләр. Дөрес, боларның бу язулары нинди бер язу икәнлек безгә ачык мәгълүм түгел. Чөнки аларның бу язуларыннан табылган хатирәләр, документлар юк. Шулай да кытай вакаигънамәләренең бу хәбәрләре, әлбәттә, буш хәбәр булмас. Аларның кулланган бу язулары үз язуларымы, әллә алар башка бер халыкның әлифбасын алып, шуннан файдаланган булганнармы – менә бу мәсьәлә дә безгә караңгы. Кытай язулары белән язган булулары да ихтимал. Ләкин кытай язуы белән язган булсалар, әлбәттә, кытай вакаигънамәләрендә бу әйтелмәстән, күргәзелмәстән ничек калды икән, дигән шөбһә дә башка килә.

Һәрхәлдә төркләрдә миладтан берничә гасырлар элек үк кытайлар тарафыннан язу дип әйтерлек бер дәрәҗәдә тәрәккый иткән бер фикер аңлату васиталары булган. Димәк, ул вакытларда болар инде язуның хәзерлек баскычларыннан (ырмау һәм төен дәрәҗәсеннән) да үткән булалар.

Борынгы төркләрнең «тамга» дип аталган ыруг билгеләре булганы безгә тарихтан мәгълүм. Һәр ыруг, үзенең хайваннарын башкалардан аеру өчен, үз тамгасын тимердән ясап кыздырып, үз хайваннарына баса торган булган. Аларның шул үз тамгалары кул кую урынына да йөртелгән.

---

[1] Вакаигънамәләреннән – елъязмаларыннан.

[2] «Һиунг-ну», ягъни һуннар – Кытайның шималендә Байкал күленең шәркый җәнүби һәм җәнүб якларында яшәгән бер төрк җәмгыятьләре. Болар даимән кытайларга һөҗүм итеп торганнар. Болар Һиунг-ну елгасы тирәсендә вә аның шималендә яшәгәнлекләре һәм һаман Кытайга баскынлык кылып торганлыклары өчен кытайлар тарафыннан «һиунг-ну» дип аталганнар. «Басмачылар – гасыйлар» *(буйсынмаучылар),* «хезмәткәрләр» дигән мәгънәдә. Кытай коймасы (сәд-е чин) миладтан 124 ел элек менә шушы һун төркләренә каршы тору өчен корылган булган. Боларның һун дип аталулары Орхон елгасының борынгы исеме Һун булганлыктан, шуңа нисбәт белән алар шулай дип аталганнардыр дип тә әйтәләр. Милади I гасырның беренче ярымының соңында болар шимали вә җәнүби һун исеме белән икегә бүленәләр. Кытайлар шимали һуннарны нык туздырганнан соң, боларның бер эзе җәнүби һуннарга кушылсалар да, күбесе Урал сахраларына, Хәзәр диңгезенең шәрык һәм шималь якларына, ягъни кыпчакка, башкортлар тирәсенә китәләр (беренче миладның соңларында) боларның анда төзегән дәүләтләре һун-угур (һунгур) исемендә булып, соңыннан сахрага нисбәт белән кыпчак дип аталып китә. Җәнүби һуннар исә өченче миладның беренче чиреге эчендә таралалар. Моннан соң Монголиядә боларның җиренә шәрык тарафыннан «сианпи» дип аталган татарлар да дәүләт торгызалар. *(Авт. иск.)*

Менә шушы тамга салу дигән нәрсәне тарихлар безгә төркләрдә бик искедән, бик борынгыдан булып килгән бер нәрсә итеп күрсәтәләр. Хәтта аны төрк халыкларына махсус диярлек бер нәрсә дип караучылар да бар. Хәзергәчә татар-башкорт авылларында да һәр нәселнең үзенә махсус бер тамгасы булганы безгә билгеле. Моңарчы татар-башкорт авылларындагы укый-яза белмәгән кешеләр приговорга, авылның гомуми карарнамәсенә яки бер ышаныч язуына үз исемнәре урынына шушы үз нәселенең тамгасын сала торган иделәр. Үз атының тәненә һәркем үз нәселенең тамгасын тимер белән кыздырып салу гадәте дә бездә күптәннән дәвам итеп килде. Сыер, сарык кебек хайваннарның – колакларын, тавык, каз кебек кошларның тырнакларын кисеп, үз тамгалары белән тамгалау да – бездә бар нәрсә. Бу тамгалар да үзләре яшәгән мохитләрендәге һәртөрле нәрсәләрнең һәм үз тормышларында кулланылган корал-әсбабларның сурәтеннән алынганнар. Тамгаларның «урак тамга», «сөңге тамга» , «алка тамга», «сәнәк тамга», «китек тамга», «тарак тамга» дигән кебек исемнәре дә шуны күрсәтеп тора.

Төрк халыкларындагы менә шул рәвештә «тамга салу»ларны без, әлбәттә, төен һәм ырмау язуларның туганы дип аңлый алабыз. Хасил, төрк халыклары да язуның шушы хәзерлек баскычларын бер вакытлар үткәргән булалар.

Шушы югарыда сөйләгәннәргә, бәгъзе хәрефләренең тамгаларга охшавына карап, Орхон әлифбасының төркләрнең ыруг тамгаларыннан ясалу фикерен дә китереп кушсак, төрк халыкларының әйбер, сурәт язу аркылы тәдриҗән әлифба, ягъни иҗек вә хәреф язу баскычына килеп чыккан икәнлекләре тагы куәтләнә төшәдер.

**Төркләрдә әлифба язулары.** Төрк халыкларында иң беренче әлифбаның кайсы төркләрдә булганлыгы һәм аның кайчан тудырылганлыгы яки кемнәрдән алынганлыгы мәгълүм түгел. Югарыда әйтелгәнчә, кытай вакаигънамәләре һун төркләренең язулары булганыннан хәбәр бирсәләр дә, бу язуның нинди бер язу булганлыгы, аны үзләре иҗат иткәннәрме яки башка бер халыктан алганнармы икәне һәм дә аннан соңгы төрк әлифбаларының ул язу белән нинди бер мөнәсәбәттә булганлыгы безгә тәмамән караңгы, шуның өчен без ул ягына керә алмыймыз.

Төрк халыкларының хәзерге фән дөньясына килеп ирешкән һәм тәмамән нык тикшерелеп беленгән язу хатирәләре безне милади белән VIII гасырның беренче ярымы эчендә туктата. Ләкин VIII гасырда язылган икәнлекләре ачык мәгълүм булган шушы язулар, шушы әлифбалар, әлбәттә, шул үзләре язылган елларда гына бердән тудырылган әлифбалар булу мөмкин түгел. Бу хатирәләрнең рәсми хатлары, имлялары яхшы гына эшләнгән, тәрәккый иткән бер рәвештә күренүләре дә боларның һәрхәлдә бер-ике гасыр элегрәк, ягъни VI яки VII миладиларда тудырылган булуын күрсәтәләр.

Бу хатирәләр безгә иң мөһим ике төрле төрк әлифбасы яки төрк язуы бирәләр: 1) Орхон әлифбасы; 2) уйгур әлифбасы.

**Орхон әлифбасы.** Орхон әлифбасы – иң элек тукю[1] төркләренең кулланган әлифбалары. Шуның өчен бу урында бу төркләрнең (боларга Алтай яки Орхон төркләре дип тә әйтелә) җәгърафи, сәяси, иҗтимагый, икътисади якларына азрак кагылып үтмичә булмый. Бу төркләрнең яшәгән төп урыннары Байкал күленең җәнүбендәге җирләрнең шәркый һәм гарби яклары белән чикләнә. Гаребтә Байкал күленнән Алтайга, аннан Зайсанга[2], аннан янә Ыссык күл тирәләренә килсәк – тукюләрнең яшәгән җирләреннән үткән булырбыз. Бу төркләр VI милади урталарында Урта Азиядә яңа бер зур күчмә төрк императорлыгы тудыралар. Алтайдан чыккан бу фатихлар[3] кыска бер мөддәт[4] эчендә Мохит диңгезеннән[5] Кара диңгезгәчә булган бөтен халыкларны үзләренә караталар. Болар мәмләкәтенең мәркәзләре шул ук һуннар мәмләкәтенең мәркәзе булган. Болар үзләре асыл ыруглары ягыннан да, кытай вакаигънамәләренең биргән хәбәрләренә караганда, Коби яки Гоби даласы-

[1] «Тукю» дигән исем – бу төрк халыкларына кытайлар тарафыннан тагылган бер исем. Тикшерүче галимнәр бу сүзне «төрк» дигән сүзнең кытайлар тарфыннан бозылып әйтелгән бер рәвеше дип аңлаталар (бу сүз «тухию», «тукию», «ту-ку» рәвешендә дә әйтелгән). Тарихларда болар фәкать «төркләр» дип кенә дә йөртеләләр. Бу төрк халыклары үзләренең калдырган язуларында да үзләрен фәкать «төрк» дип кенә йөрткәннәр. Тукю сүзенең асылы төрекчә «байрак» (знамя) мәгънәсендәге «тугъ» яки «түк»тән алынып кушылганлыгын, гомуми вә сәяси мәгънәсенә күрә «түка» рәвешендә икәнен язучылар да бар (А. Панов. К истории народов Средней Азии). *(Авт. иск.)*

[2] Зайсан – хәзерге Казахстанның көнчыгыш өлкәсендәге күл.

[3] Фатихлар – яулап алучылар.

[4] Мөддәт – вакыт.

[5] Мохит диңгезеннән – Атлантик океаннан.

ның төньягында булган җирләрдәге һун (һьюнг-ну) төркләренең бер кабиләсе[1] булганнар[2]. Алар, асыллары белән һаман шул борынгы һуннарның үзләредер. Һуннарның асыл мәркәзе дә, Төркестанда калганнары 3–4 йөз еллар эчендә җайлап куәт җыйдылар да «тукю» (төрк) исеме белән каган булдылар[3].

Безгә мәгълүм: төрк халыклары һәрвакыт дәүләтләрен яңартып, аны икенче бер нәүгъ[4] вә сөлялэгә[5] күчереп, алыштырып торганнар. Һәрбер яңа хакимият башына чыккан төрк кабиләсе үзе дәверендәге төрк дәүләтенә үз ыругы, үз сөлялэсенең (яңа яшәгән җиренең) исемен тагып, аны шул исем белән гүя бөтенләй яңа төзелгән бер дәүләт рәвешендә идарә итә биргән. Хакыйкатьтә исә төрк җирләрендә төзелгән төрле ханлык-императорлыклар шул ук бер төрк иленең төрле дәверләрдәге төрле исемнәрдә дәвамы иде.

Монголиядә һуннардан соң «сиянпи» татарлары хакимият сөрсә, алардан соң IV гасырның соңыннан башлап VI гасырның ярымынача Урта Азиядә «җүҗеннәр» (юэджи[6]) өстенлек казаналар[7]. Амур елгасыннан Хәзәр диңгезенәчә сузылган киң бер төрк теле шулар исеме белән идарә кылынып китә (кытайларның «җүэнҗүэн» вә «җөҗү» дигәннәре, гарәпләрнең дә «Яәҗүҗ вә Мәҗүҗ» дигәннәре шушы төркләр булганнар). Шушы җүҗеннәр, кытайлар тарафыннан һуннарга каршы кортылган вә һуннар тарафыннан җиңелгән «өсеннәр»не дә[8] Җидесу җирләреннән кысып чыгарып,

[1] Мелиоранскийның «Записки Восточного отделения Императорского Русского Археологического общества» мәҗмугасының 1899 елда XII җилдендә басылган «Памятник в честь Кюл-тегина» дигән әсәре һәм Н. Гасыймның «Төрек тарихы», б. 55. *(Авт. иск.)*

[2] Фәкать Самойлович 24 нче ел Мәскәүдә басылган «Әфганстан» дигән китаптагы мәкаләсендә бу төркләр (тукюлар) төрекмәннәрнең хәлифәләре булган угызлар икәнен яза, б. 101. *(Авт. иск.)*

[3] З. Вәлиди. «Төрк-татар тарихы», б. 34. *(Авт. иск.)*

[4] Нәүгъ – төр.

[5] Сөлялэгә – династиягә.

[6] Сианпиләрне дә, җүҗеннәрне дә тунгус ыругыннан саныйлар. А. Самойлович «Западный Туркестан», б. 36–40. *(Авт. иск.)*

[7] Шәрыкта җүҗеннәр көчәйгәндә гаребтә (төньякта) Идел, Дон тирәләрендә һуннар – кыпчаклар көчәйгәннәр. *(Авт. иск.)*

[8] Өсеннәр дә, Радлов вә Аристовлар фикеренчә, шул ук төрк ыругыннан булып, боларның гарби-җәнүби яклары Фирганә, гарби якларында, ягъни Чу елгасы буйлары хәзерге Әүлия ата, Тукмак тирәләрендә [яшәп,] төркләрдән канклилар (кан-гуй) булганнар. Боларның чикләре тәкърибән Сырдәрья белән Җидесу вилаяте арасына туры килә. Өсеннәр барысы алты йөз утыз мең җан яки бер йөз егерме мең гаилә хисапланганнар (Самойлович. Западный Туркестан, б. 36). *(Авт. иск.)*

аларны Тянь-Шань тауларына күчәргә мәҗбүр итәләр. Тукю төркләре дә милади VI гасырның урталарынача шушы җүҗен төркләренең идарәсе кул астында булалар[1]. Бара торгач, җүҗеннәр белән тукюлар арасында нык бәрелешләр, сугышлар башлана. Ниһаять, җүҗеннәрне җиңеп, «илхан» гонванын[2] алган Тумын дигән башлыклары (Тумын 553 миладида вафат) кул астында тукюлар дәүләтен төзиләр, Һун императорлыгы урынына икенче бер шундый ук гаять зур, киң бер күчмә империяторлык мәйданга китерәләр.

Милади 600 ел тирәләрендә тукюларда ханлык талашы башлана. Тукю төрк хөкүмәте «гарби» һәм «шәркый» булып икегә бүленә (Тубу хан үлгәч – 581 миладида), зәгыйфьләнәләр. Ахырда Кытай кул астында аларга вассал булып калалар (630 елларгача). Тукюларның бер кыйсеме хәтта Кытай чикләренәчә күчерелеп утыртылалар. Илле елларча вакытлар шулай Кытайга вассаллык белән үтә. Соңра Билге һәм Күлтәгиннең атасы Котлуг (Худулу яки Әлтәрес) ханлыгы заманында төрк иле тагын күтәрелә башлый. Котлугтан соң (ул 690–691 миладиларда вафат) шушы шәркый тукюлар дәүләтенә аның энесе Муччу хан булып, Күлтәгин аның гаскәренә командан була (Муччу 716 да вафат, ягъни Күлтәгин тарафыннан үтерелә). Муччу заманында Гарби төрк дәүләте дә, Шәркый төрк дәүләте дә кушыла. Ниһаять VIII гасырның башларында сугышчы батыр Күлтәгиннең булышлыгы белән аның туганы Билге каган (бу – ләкабе[3], асыл исеме Мәгыйлән яки Мөгилән) хан була. Билге каган, хан-патша булганнан соң, үзенең гаскәренең командасын энесе Күлтәгингә тапшыра. Шулай итеп, берсе – хан, берсе аның гаскәр башлыгы булган шушы ике туганның юлбашчылыклары белән тукю (төрк)ләр мәмләкәтләрен яңадан әүвәлге көченә кайтара башлыйлар[4]. Үз араларында үзләренә буйсынмаучы, үз кабиләләренә каршы сугыш бару өстенә, бер яктан – кытайлар, икенче яктан Мавәраэннәһергә басышып килгән гарәпләр – ислам[и]ларга каршы да каты сугышлар ачыла. Күлтәгин гаскәр башлыгы булган хәлдә бе-

---

[1] Мелиоранскийның «Зап. Вост. Отд. Имп. Русск. Арх. О-ва» мәҗмугасындагы әсәре. *(Авт. иск.)*.

[2] Гонванын – титулын.

[3] Ләкабе – кушаматы.

[4] VIII гасырның соңында Шәркый төрк дәүләтенең яңадан терелүе чак кына төрк мәмләкәтенең берләшүен яңартмады. «Западный Туркестан», б. 36–40. *(Авт. иск.)*

ренче мәртәбә гарәпләр белән каты очрашалар. Сәмәрканд янында Күлтәгин гарәпләргә Тимер Капу дигән урында нык галәбә итә[1]. Мөселман гаскәрләрен шуннан бу якка төркләр ягына уздырмый. Билге хан 721 миладида Кытай императоры белән дә могаһәдә[2] ясый.

731 дә Күлтәгин вафат була. Аның үлүе мөнәсәбәте белән Кытай императоры Билге ханга зур бер вәкаләт һәйәте[3] җибәреп, аны тәгъзия итә[4]. Шушы һәйәт Билге ханга һәртөрле һәдияләр китерә. Күлтәгингә дә кабер ташы хәзерләп бирә. Шул ук вакытта, ниһаять, Билге ханга Кытай принцының кызын бирү вәгъдә ителә (моннан элек Билге ул кызны Кытай императорыннан ике мәртәбә сораган булса да, рәдд ителгән[5]).

734 елда Билге хан үзе бер кеше тарафыннан агулап үтерелә. Хан үлгәч, Кытай императоры тагы вәкаләт һәйәте (посольство[6]) күндерә һәм аңа янә бер кабер ташы (надгробный памятник[7]) тәкъдим итә. Билге урынына аның углы Иҗан хан булып, сигез ел ханлык итә. Шуннан соң чуалулар башлана, икътисади кризислар туа. Аларның шул чуалу һәм кризисларыннан уйгурлар файдаланып, ниһаять, 745 миладида тукю төркләренең мәмләкәтен үзләренә алалар, тукюлар мөнкарыйз була[8]. Уйгурлар Кытай һәм башка халыклар белән мөнәсәбәт мәсьәләсенә дә тукюлар дәрәҗәсендә үк бер әһәмияткә малик булып калалар[9]. Димәк, шулай итеп, тукюлар дәүләте уйгурлар дәүләтенә алмашына.

Тукю төркләренең сәяси, икътисади һәм мәдәни яктан иң шәп вакытлары – милади VI гасырның ярымыннан VII гасырның ярымынача булган чаклары. Болар иген иккәннәр, сәүдә кылганнар, Мавәраэннәһер белән дә сәүдә мөнәсәбәтләре шәп булган. Боларның шәһәрләре дә булган. Димәк, болар тик бер күчмә императорлык кына булмыйча, бәлки инде утраклана да башлаганнар.

---

[1] Галәбә итә – җиңә.
[2] Могаһәдә – килешү.
[3] Вәкаләт һәйәте – вәкаләтле делегация, илчелек.
[4] Тәгъзия итә – кайгысын уртаклаша.
[5] Рәдд ителгән – кире кагылган.
[6] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*
[7] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*
[8] Мөнкарыйз була – юкка чыга.
[9] Мелиоранский. «Зап. Вост. Отд. Имп. Русск. Арх. О-ва», т. XII. *(Авт. иск.)*

Шушы вакыт эчендә без боларда яхшы ук эшләнгән, тәртипкә салынган бер әлифбаның да гамәлдә булганын күрәмез. Бу әлифбаның чын нәмунәсен дә безгә Күлтәгин һәм Билге хан исеменә утыртылган ташлардагы язулар бирәләр. Күлтәгин исеменә утыртылган таш – Билге хан тарафыннан, Билге ханныкы да аның хәләфләре[1] тарафыннан утыртылган булган.

Бу ике таш, шушы ике язу хатирәләре XIX гасырның соңында гына табылды һәм галимнәр тарафыннан тәмам төпле бер рәвештә тикшерелеп, ачык укыла алды. Боларның табылган урыннары Орхон елгасының көнчыгыш ягында, тирәләре һәрнәрсәдән ялангач булган Кушу-Чайдам күле янында. Ике һәйкәлнең арасы бер километр кадәрле. Боларның бүленгән урыннары иске Каракорым шәһәренең төньягыннан 60 километр кадәр җирдә. Орхон елгасының көнбатыш ягыннан иске уйгур хөкүмәтенең мәркәзе – пайтәхете булган Карабалгасун шәһәренең дә төньяк-көнбатышында 30 километр кадәрле бер урында.

Бу хатирә – һәйкәлләр табылу тарихы болай.

Әүвәл моннан ике йөз еллар элек Страленберг[2] исемле бер швед офицеры (Беренче Пётр тарафыннан сугышта әсир алынып, Себергә сөрелгән булган) Енисей (Яңычай) суының югары агымында, ягъни Җәнүби Себердә кабер ташлары таба да, европалыларга шулар турысында башлап хәбәр бирә. Ләкин ул вакытта әле бу ташларның кемнәр тарафыннан утыртылган ташлар икәне һәм алардагы язуларның кемнәрнең язулары икәне беленми. Ялгыз шул кадәресе бар: болардагы язулар скандинавиялеләрнең рун язуларына охшаган кебек күренгән була[3].

[1] Хәләфләре – алмашлары.

[2] Филипп Иоган (Юхан) Табберт фон Страленберг (1676–1747) – Төньяк сугышта (1700–1721) швед короле Карл XII армиясе составында катнашкан хәрби офицер. Полтава янындагы сугыштан соң әсирлеккә алына, соңрак Себергә Тобольскига җибәрелә. Биредә ул төньяк-көнчыгыш Азия тарихы һәм географиясенә караган материаллар җыя. Себернең берничә картасын төзи. Төньяк сугыш тәмамланганнан соң, «Европа һәм Азиянең төньяк һәм көнчыгыш өлешләренең тарихи-географик тасвирламасы» китабын һәм Тартариянең зур картасын төзеп бастыра (1730).

[3] Соңыннан бу ташлар кара кыргыз тарафыннан утыртылган булып чыга. *(Авт. иск.)*

Шундый язулы ташлар һаман табыла торалар. 1818 елда алар турысында «Сибирский вестник»[1]та Г. Спанский[2] дигән берәүнең «Древности Сибири»[3] дигән тәфсилле бер мәкаләсе басылып чыга. Граф Румянцев[4] тапшыруы белән, академик Круг[5] бу мәкаләне латин теленә тәрҗемә итә. Шушы тәрҗемә, 1822 елда нәшер ителеп, күп Европа ориенталистларында көчле бер кызыгу тудыра. Абель-Ремюз[6] 1822 елдагы мәкаләсендә Азия халыкларының «пәй» дип аталган бер хатирә, ягъни ике яки өч телдә язылган дүрт кырлы бер таш багана – ташбилге (обелиск[7]) утыртуга да рәтләре булганын әйтә.

Ниһаять, 1889 елда, М. Ядринцев[8] дигән бер ориенталистны баш итеп, «Җәгърафия җәмгыяте» тарафыннан Монголиягә гыйльми бер һәйәт җибәрелә. Бу һәйәт тарафыннан Орхон елгасы хаузасында[9] борынгы Карабалгасун[10] шәһәренең хәрабәләреннән 15 чакрымнар чамасы бер урында, «Ирдәни сәзү» дигән Будда монастыреннан 60 чакрым шимальдә ниндидер гыймарәтнең[11] калдыклары табыла. Ныклап тикшереп караганнан соң, болар арасында өч кисәккә ватылган зур бер ташбилге (таш багана) килеп чыга. Бу да өч

---

[1] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*

[2] Биредә сүз рус тарихчысы, археолог, Себерне һәм Көнчыгышны өйрәнүче галим Григорий Иванович Спасский (1783–1864) турында бара. Г. Спасский – төрле фәнни җәмгыятьләр һәм Император Фәннәр академиясе мөхбир әгъзасы (1810). Шактый еллар дәвамында (1804–1817) эшчәнлеген Себердә алып баруы Г. Спасскийга төбәк турында бай тарихи, археологик, этнографик материаллар һәм кызыклы коллекцияләр тупларга мөмкинлек бирә.

[3] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*

[4] Сергей Петрович Румянцев (1755–1838) – меценат, коллекционер, дәүләт эшлеклесе, Румянцев музеена нигез салучы. Россия Император академиясенең мактаулы әгъзасы (1819).

[5] Филипп Иванович Круг (1764–1844) – немец һәм рус нумизматы, археолог һәм тарихчы.

[6] Жан-Пьер Абель-Ремюз (1788–1832) – француз синологы, хәзерге Көнбатышта Кытайны өйрәнү белеменә нигез салучыларның берсе. Абель-Ремюз 1814 елда Парижның «Коллеж де Франс» дип аталган уку йортында ачылган кытай теле кафедрасын җитәкли. Шул вакытта үзен тулысынча Көнчыгышны өйрәнүгә багышлый, аеруча төркиләр һәм монголлар тарихын яктырткан кытай чыганаклары белән кызыксына.

[7] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*

[8] Николай Михайлович Ядринцев (1842–1894) – рус язучысы һәм җәмәгать эшлеклесе, Себер һәм Үзәк Азияне өйрәнүче. Орхон елгасы буендагы борынгы төрки һәйкәлләрне беренче булып ачкан галимнәрдән.

[9] Хаузасында – бассейнында.

[10] Кара Корым. *(Авт. иск.)*

[11] Гыймарәтнең – корылманың.

ягыннан – Енисей язуы белән, дүртенче ягы[н]да Кытай язуы белән языльп тутырылган була. Соңыннан бу хатирәнең төрк ханы Билге каган шәрәфенә утыртылган икәне беленә. Шул ук урыннан ярым чакрым бер җирдән Ядринцев янә шундый ук гыймарәт вә баганаларның калдыкларын таба. Үзе гәрчә яткан хәлдә булса да, бу хатирә һич зарарланмаган була. Моның да бер ягы Кытай язуы белән язылган булса, өч ягы Енисей язуы белән язылган була. Соңыннан бу ташның да Билге каганның туганы Күлтәгин шәрәфенә утыртылган икәне ачыла.

Ядринцев артыннан, фин-угор җәмгыяте тарафыннан хәзерләнеп, башында Г. Гейкель[1] торган хәлдә, Орхон буйларына Килсенгфорс[2] шәһәреннән янә бер гыйльми һәйәт (экспедиция) җибәрелә. Бу һәйәтнең җибәрелүе ташлардагы язуларның борынгы скандинавиялеләрнең рун язуына охшаган булганлыгыннан һәм борынгы финнарда да шул рун язуы истигъмаль ителгәнлектән булган булса кирәк. Бу гыйльми һәйәт 1890 елда язуның күчермәсен ала, 1892 елда инде болар нәшер ителәләр.

1891 елда шул ук тарихи язуларны (шуның белән бергә магул һәм тибет телендәгеләрне) тикшертү өчен, Петербург Фәннәр академиясе тарафыннан да бер гыйльми һәйәт җибәрелә.

Бу һәйәтнең башында мәшһүр тюрколог Радлов тора. Язулардан бу юлы яңа ысул белән коленкорга эстампаж[3] – дөрес күчермәләре алына. 1892–1896 елларда шушы гыйльми һәйәтнең өч бүлемдә «Орхон гыйльми һәйәтенең хезмәтләре» һәм «Борынгы Монголия атласы»[4] дигән бер мәҗмуга чыга. Моны үзенә Петербург Фәннәр академиясенең тапшыруы белән В.В. Радлов нәшер итә. Ләкин әле бу язулар һаман бер табышмак булып тора. Андагы язулар әле бернәрсә дә сөйләми, аларның нинди халыкның нинди бер әлифбасы икәне әле дә караңгы була. Ялгыз ташларның бер ягындагы кытайча язулардан һәм аларның мөндәриҗәсенә[5] карап, икенче ягындагы язуларның төрк халыклары тарафыннан төрк телендә язылган булучылыгы уйланган.

---

[1] Аксель Олай Гейкель (1851–1924) – фин этнографы һәм археологы. Хельсинки университеты профессоры, фин-угор этнографиясенә нигез салучыларның берсе.

[2] Килсенгфорс – Гельсингфорс (хәзерге Финляндиянең башкаласы Хельсинки шәһәренең 1926 елга кадәр рус телендә кулланылып килгән шведча атамасы).

[3] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*

[4] Труды Орхонской экспедиции, Атлас древности Монголии. *(Авт. иск.)*

[5] Мөндәриҗәсенә – эчтәлегенә.

Бу турыда мәсьәлә шулай томанлы һәм төенле булып торган бер вакытта, Копенһаген дарелфөнүненең[1] филология мөдәррисләреннән тюрколог мосье Томсен[2] шушы язуларны уку юлын таба. 1893 елда ул шуларны тәмам укый алуга һәм шуны бөтен фән дөньясына игълан кылуга да муаффәкъ була[3]. Орхон хатирәләрендәге язуларның елларын да Томсен дөрес билгеле. 1895 елда инде Орхон буендагы хатирә вә һәйкәлләрнең (мәхкүмат-тәкмилләр) һәммәсен укып һәм тәрҗемә итеп, 224 битлек гаять әһәмиятле вә зур бер әсәр мәйданга китерә һәм шуны нәшер итә. Радлов тарафыннан да бу язулар тәрҗемә кылынып нәшер ителә.

Менә шуларның һәммәсенең нәтиҗәсендә борынгы төркләрнең үзләренә махсус язулары – әлифбалары булган икәнлек ачыла.

Бу язулар, Орхон буйларында табылганлыгы өчен Европа фән дөньясында Орхон әлифбасы дип аталып, шул исем мәшһүр булып китә.

Орхон әлифбасы табылуның һәм укылып фән галәменә мәгълүм булуының кыскача тарихы менә шулай. Инде шушы Орхон әлифбасының үзенә килик. Орхон әлифбасы (Күлтәгин вә Билге каган һәйкәлләрендәге әлифба) өзек хәрефләрдән гыйбарәт бер әлифба булып, барысы 38 хәрефтән яки тагын да тугрысы – галәмәтләрдән тора. Галәмәтләрнең саны, һәрхәлдә, шуннан артык түгел. Бу әлифбаны аваз әсасыннан бигрәк иҗек әсасындарак, яки шул икенең уртасындарак булган бер язу дияргә мөмкин. «Бу язу һәрбер авазга бер галәмәте булган гадәти язу түгел, бәлки ул я иҗек язу, яки һич булмаганда мәгълүм бер үлчәүдә һәм төрле шартларга карап бер үк төрле авазның галәмәте төрле урында төрлечә йөртелә» (Томсен) торган бер язу. Бу язуның хәрефләре түбәндә 37 нче шәкелдә җыелып күрсәтеләләр.

Күрәсез: 38 галәмәт эченнән фәкать дүртесе – сузык аваз галәмәтләре. Монда калын һәм нечкә сузык авазларның һәр икесенә бер

---

[1] Копенһаген дарелфөнүненең – Копенгаген университетының.

[2] Вильгельм Людвиг Петер Томсен (1842–1927) – данияле тарихчы, тюрколог һәм лингвист, профессор, Россия Фәннәр академиясенең чит ил мөхбир әгъзасы (1894 елдан). Һинд-Европа, Балтыйк буе – фин, төрки телләр тарихы, рус теле, шулай ук тел белеме тарихы һәм Европа тарихы буенча хезмәтләр авторы.

[3] Орхон язуларын укуның юлын ничек кәшеф итүе, аларны ничек укый алуы һәм бу язуларның теле турысында Томсеннең үзенең мәкаләсе «Зап. Вост. Отд. Имп. Русск. Арх. О-ва» мәҗмугасының VIII җилдендә вә III, IV җөзендә русчага тәрҗемә кылынып басылды (б. 329–337). *(Авт. иск.)*

галәмәт. Ягъни болар, урынына карап, калын да, нечкә дә укылганнар була. Әмма алты тартык аваз өчен Орхон әлифбасында һәрберсенең үзенә аерым бер хәрефләр бар. Алар да [ч], [ш], [н], [п], [г], [м] авазларының билгеләре. Болардан калган 28 тартык хәрефләрдән күбесе бер тартык аваз белән бер сызык аваздан мөрәккәб[1] иҗекләрне күрсәтә. Хосусан[2] боларның күпләре тартык авазлар белән [а], [ә] сузык авазларының бер шәкелдә – бер хәрефтә берләшүеннән гыйбарәт. Мәсәлән, бер галәмәтнең «та», «ат» иҗекләре урынына йөртелүе кебек.




37 нче шәкел. *Югары дүрт хәреф – сузыклар, калганнары – тартыклар*

[1] Мөрәккәб – оешкан.
[2] Хосусан – аерым алганда.

## Орхон хәрефләренең аңлатулы җәдвәле[1]

*Сузыклар (мәдләр)*



ә – а

Академия транскрипциясенчә «а, ä» – әлиф мәмдүдә[2], һәмзәи мәфтухә[3]. Бу хәреф гел сүзнең соңында гына язылган диярлек. Ул бу урында гадәттән тыш күп очрый. Орхон язуларында сүз ахырында бу авазларның галәмәтләре язылмаган сүз юк диярлек. Сүзнең башында һәм уртасында бу хәреф һич язылмый дип әйтергә була. «а»мы, «ә»ме укырга кирәклеген (бу хәрефләр язылса да, язылмаса да) сузылгыч (тартык) хәрефләр белән күрсәтелә. Үзендәге сузык авазның табигатен (калынлык, нечкәлеген) күрсәтеп тормый торган сузыкларны бик аз очраталар (бу хәрефләр авазда французча «а», «е» хәрефләренә туры киләләр).



и – ы

Академия транскрипциясенчә «ы, і» – кәсрәи хәфифә[4] вә сәкыйлә[5]. Бу галәмәт калын һәм нечкә аст урынына, [и], [ы] урынына тора (французча [i], [y] га туры килә).



Калын вау

(«о, у» – заммәи сакыйлә)

Бу галәмәт калын өтер, ягъни бездәге «о», «у»га туры килә, французча [ои], [о] галәмәтләренә бәрабәр килә. Болар да сүз соңында гына языла.



Нечкә вау

(«ö, ÿ» – заммәи хәфифә)

Бу галәмәт бездәге «ө – ү» гә туры килә.

*Тартыклар (самитләр[6])*

Һәрбер тартык аваз өчен ике галәмәт кулланылган диярлек. Боларның да бер төрлесе – фәкать сузык авазларның бугаздан чыга

[1] Җәдвәле – таблицасы.
[2] Әлиф мәмдүдә – [а] авазы («озын әлиф»).
[3] Һәмзәи мәфтухә – [ә] авазы («фәтхәле һәмзә»).
[4] Кәсрәи хәфифә – [и] авазы.
[5] Кәсрәи сәкыйлә – [ы] авазы.
[6] Самитләр – тавышсызлар.

торганнары ([а], [о], [у], бигрәк тә [ы]) белән, икенче бертөрлеләре дә фәкать яңкау сузыклары ([і], [ÿ], [ö], [ä]) белән кушылалар.



Боларның өчесе дә – шартлавык (взрывн.[1]) [къ] авазының галәмәте (к[2]) («каган», «кымыз», «кул» дигәндәге кебек). Уңнан беренчесе күп кулланылган, икенчесе фәкать калын асттан ([ы]дан элек яки соң гына, димәк, калын иҗекләрдә генә) кулланылган. Өченчесе исә фәкать калын «вау»лы иҗекләрдән элек һәм соң йөртелгән, ягъни «у», «о» лардан элек яки соң кулланылганнар.



Боларның икесе дә – «к» хәрефе. Уң яктагысы арткы тел – аңкаудан чыга торган шартлавык аваз булып, нечкә аст = [э, и] (і), кыска өст – [ә] (ä), нечкә өтер [ү, ө] ([ÿ, ö]), (французча [і], [е], [и], [еи] авазлары) булган иҗекләрдә генә кулланылган. Икенчесе исә үзендә кыска өтер = «э» (французча – [eu], [u], транскрипциячә [ÿ], [ö] авазлары) булган иҗекләрдә генә йөртелгән. Ягъни бу да шул ук «к» хәрефе булып, «ө», «ү» ([ö, ÿ]) дән элек яки соң килә.



Боларның уңнан беренчесе – [гъ] авазының билгесе. Икенчесе – [г] авазының билгесе. Әйтелүләре бер-берсенә якын. Уңнан беренчесе үзендә калын [вау], бугаз сузыклары (французча [о], [oe]) һәм кыска [у] (французча [у]), [а] (а) булган иҗекләрдә кулланылган. Икенчесе исә [ә], [е], нечкә [ү] (французча [eu], [u], [i], [e] авазларына туры килә) сузыклары, ягъни аңкау сузыклары белән йөртелгән. Боларның һичберсе сүз башында килмәгәннәр. Әмма сүз уртасында, ахырында күп очрыйлар.



Боларның икесе дә – [т] авазларының билгеләре. Уңнан беренчесе калыны булып, үзләрендә [а], [у] (калын) сузгыч авазлары булган ([а], [о], [ou]) иҗекләрдә, ягъни бугаз сузыклары белән йөртелгән. Икенчесе исә үзендә [ә], [и], [ү] (нечкә) ([e], [i], [п], [ou]) авазлары булган иҗекләрдә, ягъни аңкау сузыклары белән язылган. Әйтелешләре икесе дә бер төрле үк.

---

[1] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*

[2] *Чыганакта шул рәвешле язылган.*


Болар икесе дә – [б] авазларының галәмәтләре. Уңнан беренчесе – [а], [у] (калын, ягъни бугаз сузыклары) ([у], [ои], [о], [а]) белән, икенчесе аңкау сузык авазларының галәмәтләре белән бергә кулланылган. Бу аваз сүз башында күп килә.


Болар икесе дә – [д]лар. Уңнан беренчесе – бугаз сузыклары белән, икенчесе аңкау сузыклары белән әйтелә (уңнан беренчесе гарәпнең «ض» сына якынрак). Бу аваз сүз башында һич очрамый, күбрәк уртада һәм сирәгрәк ахырда була.


Боларның өчесе дә – тартык [й] (русча [й], академик транскрипциясенчә [j]) авазының галәмәтләре. Уңнан беренчесе – бугаз сузыклары, икенчесе аңкау сузыклары белән кулланыла. Икенчесе сүз башында һәрвакыт [ы]дан элек килә. Боларның уңнан беренче[се] – [а], [у] (калын), [ы] (калын) ([у], [ои], [о], [а]) сузык авазларының билгесе белән, икенчесе – болардан башка сузыклар һәм [ы/е] авазының билгесе белән, өченчесе дә иҗекләрнең соңыннан һәм күбрәк «ай» мәгънәсендә йөртелгән.


Бу – [п] авазының билгесе. Ләкин сүз башында кулланылмаган. Бу хәреф күбрәк сүз ахырында, бигрәк тә хәл фигыльләрендә йөртелгән (*тотып*, *тотыпан* кебек). Сүз уртасында да бу хәреф еш кына очрый. Сүз башында ул һич килми диярлек. Аның урынына [б] килә. Хас исемнәрнең[1] [п] белән башланганнары гына шушы галәмәт белән язылган.


Бу – [ң] галәмәте. Бу галәмәт тә сузыклар белән килә ала. Бу аваз сүз башында һич килми.


Бола[р] икесе дә – «н» (нүн) авазының билгесе. Уңнан беренчесе – калын, икенчесе – нечкә. Уңнан беренчесе – бугаз сузгычлары белән, икенчесе аңкау сузгычлары белән килә. «Н» белән бик аз сүзләр башлана.


Болар – «л» («l») хәрефләре. Уңнан беренчесе – бугаз сузыклары, икенчесе аңкау сузыклары белән кулланылган, «р» шикелле үк, болар да сүз башында һич килми.

[1] Хас исемнәрнең – ялгызлык исемнәренең.

 Бу – «м» хәрефе.

 Болар икесе дә – [ч] яки [ж] авазларының билгесе. Боларның бигрәк тә [ж] икәнен күрсәтәләр. Ләкин боларның уңнан икенчесе бик аз кулланылган.

 Болар икесе дә – «р» хәрефләре, тик уңнан беренчесе – бугаз сузыклары, (калын) икенчесе аңкау сузыклары (нечкә) белән кулланылганнар. Сүз башында бу хәреф һич килмәгән.

 Болар – [с], [ш] авазларының билгесе. Уңнан беренчесе калын авазлы, ягъни бугаз сузыклары белән килгәндә саңгырау [с] (калын һәм нечкә) авазын биргән. Боларның уңнан икенчесе [ш] белән [с] арасында йөртелгән, өченчесе, сузык хәрефләрнең калын һәм нечкәләре белән кулланылып, [ш] авазын биргән. Уңнан икенче хәреф исә, аңкау сузыклары белән булганда, [с]ны белдергән, [ы]дан элек һәм соңда бу галәмәт [с]ны аңлаткан. Кайбердә ул өченче галәмәт («ш») урынында да йөртелгән.

 Бу – «з» хәрефе. Үзе һәм сузыклар белән языла.

 Болар – кушма авазлы хәрефләр. Уңнан беренчесе – «лд», икенчесе – «нд», өченчесе «нч, нҗ» иҗекләрен бирәләр. Болар бөтен сузыклар белән кулланылалар.

Югарыда сөйләнгәннәрне ачык аңлау өчен, мисал итеп Орхон әлифбасыннан берничә сүзне укып күрик:  «ул ат анда» дигән сүз (монда беренче галәмәт – «у», икенче галәмәт – «лә», өченче галәмәт – «ат» (т), дүртенче галәмәт – «нд», бишенче галәмәт – «а» дыр);  «тота» дигән сүз;  «тагда» (тауда) дигән сүз (икенче галәмәт – «г», өченче галәмәт – «д»);  «Тәңредә» (ягъни күктә) дигән сүз (беренче галәмәт – «т», икенче галәмәт – «к, г», өченче – «р», дүртенче – «ы/е», бишенче – «дә», алтынчы – «а»);  «анда» дигән сүз.

Орхон язуында 38 хәрефтән башка тагы шул рәвештә «:» астлы-өстле ике ноктадан гыйбарәт бер галәмәт тә бар. Бу урында шушы

галәмәт турында бераз аңлату биреп үтик. Бу үзенә күрә бер тыныш билгесе дияргә ярый. Моның белән сүзләр яки хәрефләр төркеме бер-берсеннән аерыла һәм бу галәмәт юлның сулына да куела. Димәк, бу әлифбада моның хезмәте бер сүзне икенчесеннән аера бару, сүзнең беткәнен, соңын күрсәтү булган. Әмма юл башында бу галәмәт һич куелмаган. Тагын бу бар: бу язуда сүзләр бер юлдан икенче юлга бүленеп, һич күчерелмәгәннәр. Юллар һәрвакыт бөтен сүзләр белән беткән, шуның өчен дә юллар тигез итеп бармаганнар, керентеле-чыгынтылы булганнар. Тагын әлеге тыныш галәмәте – ике нокта – һәрбер сүзнең соңында куелмаган. Хәтта бу галәмәт белән аерылмастан, бер катардан язылып киткән ике вә хәтта өч сүзне бик еш очрата алалар. Шул дәрәҗәдә ки, хәтта боларны бер сүз икәннәр дип уйларга да мөмкиндер. Моны да язучының сәнгатькярлек хосусиятенә һәм сүзләрнең озын-кыскалыгына карап булгандыр дип уйлыйлар.

 – ат,  – ай,  – әр (ир) кебек бер генә хәрефтән гыйбарәт булган сүзләр һичвакыт әлеге ике нокта белән бер-берсеннән аерылып язылмаганнар, бәлки һәрвакыт югары яки түбән якларындагы сүзләр белән кушылып язылганнар. Ике хәрефтән гыйбарәт булган сүзләр дә күп вакытта башка сүзләр белән кушып, ягъни ике нокта белән аерылмастан язылганнар. Өч хәрефле сүзләрдә исә эш моның киресенчә булган. Болар инде әлеге галәмәт белән аерылып язылганнар. Гомумән, сүзләр күпме озын булса, шулкадәр дә аларның арасын бер-берсеннән



38 нче шәкел. *Билге каган һәйкәленнән (З. Вәлидидән)*

әлеге галәмәт белән аера бару кагыйдәсен нык сакланган дип табалар. Бу турыда истиснаны[1] бик аз күрәләр.

Орхон язуы – кытай язуы шикелле текә – гомуди, ягъни югарыдан түбәнгә язылып төшә һәм юллары уңнан сулга таба укылып бара торган бер язу. «Язулар башы белән – сулга, таягы белән уңга яткан кебек күренәләр. Юллар кытай һәм магул язуындагы кебек югарыдан түбәнгә таба укылырга тиеш. Түбәннән югарыга табан түгел. Икенче төрле әйткәндә, әгәр дә без, мәсәлән, бу язуның юлларын язуның аягы белән куеп ятык (офкый – горизонтально) кылсак, безгә аларны уңнан сулга таба укырга тиеш булыр иде» (Томсен).

Ләкин бу язуларның юллары ничек тезелгәннәр, ягъни боларны кытай язуындагы кебек уңнан сулгамы, әллә киресенчә, магуллардагы кебек сулдан уңга табанмы укырга тиеш? Менә бу турыда Томсен Радловның атласында соңгы систем, ягъни сулдан уңга таба укып бару алынганлыкны бәян итеп, шуны куәтле дәлилләр белән рәдд кыла[2], Орхон язуларының магуллардагы кебек сулдан уңга түгел, уңнан сулга таба укылганын исбат итә (Томсен мәкаләсе).

**Орхон язуының нәселе – тамыры кайда һәм кайчан тудырылган?** Орхон язуының үзеннән элек булган кайсы әлифбадан алынганлык мәсьәләсе һәм аның кайчан туган икәнлеге тәмамән катгый бер рәвештә хәл ителгән бер мәсьәлә түгел. Бу турыда төрле фикерләр бар. Моны башта рун әлифбасыннан алынган дип уйладылар. Бу уй әле Орхон язулары яхшы тикшертелеп каралмастан элек туган иде. Бу фикер Орхон язуының фәкать тышкы күренеше белән борынгы Скандинавия һәм готларда йөртелгән рун әлифбасына охшавына нигезләнгән иде. Орхон язулары яхшылап тикшерелгәннән соң, бу фикернең хата, төпсез бер фикер икәне ачык беленде. Бу фикерне каты рәдд итүченең дә берсе Томсен булды. Шуның урынына Орхон әлифбасының баш тамыры да башка әлифбаларныкы шикелле арами (сами) әлифбасы икәнлек фикере туып, шушы фикер игътибар казанды вә куәт алды. Томсен шул фикердә булган кебек[3],

[1] Истиснаны – искәрмәне.

[2] Рәдд кыла – кире кага.

[3] Томсен фикеренчә, Орхон әлифбасы күбрәк телнең авазларын туры аңлауга әсасланган асыл бер әлифба булып күренә. Әлбәттә, аны үзенә башка мөстәкыйль бер әлифба дию мөмкин түгел. Моның ерак мәнбәгы *(чыганагы)* итеп сами әлифбасын, хосусән, арами әлифбасын күрсәтү мөмкин. Чөнки анда Орхон хәрефләренә охшаган хәрефләр табыла. Томсен, әгәр төркләрнең Орхон язуларына турыдан-туры арами әлифбасыннан тәрәккый итеп китмәгән булса, аның тамыры Согыд әлифбасы булуны да ихтимал тота. *(Авт. иск.)*

Радлов та, әсасән[1], шул фикердә. Радлов Орхон әлифбасындагы сузык хәрефләрне бу әлифбаның аслый самилардан булуына дәлил итә. Төрк әлифбасында төрк теленең тавышлы авазларына җитәрлек галәмәтләр булмауга таянып, ул шулай ди, ягъни ул бу фикерендә Орхон әлифбасында мәд хәрефләре самилардагы кебек «әлиф», «вау», «йа»дан гына гыйбарәт булуына таяна. Шуның белән бергә Радлов рун язуының Орхон әлифбасына тәэсир иткән булу ихтималын йөретә. Бәгъзе хәрефләрнең рун язуына охшавы аңа шулай уйларга юл ача. Бу тәэсир дә һуннарның Яурупага чыккан вакытларында Атилла сараендагы бәгъзе готлар аркылы булгандыр дип уйлана.

Гәрчә үзенең югарыда әйтелеп үткән мәкаләсендә: «Орхон язуының асылы – нәселе турысында әле анык вә катгый бер нәрсә әйтергә иртә, мин ялгыз хәзергә бәгъзе галәмәтләрнең сами – пәһләви галәмәтләренә охшаган икәнлекләрен әйтү белән генә канәгатьләнәм», – дисә дә, һәрхәлдә, фикерләрне шул арамидан туганлык ноктасына каратып куя. Мелиоранский[2] шул ук үзенең югарыда әйтелеп үткән «Күлтәгин шәрәфенә булган хатирә» дигән әсәрендә Томсен сүзе рәтеннән: «Тукюлар аны, һәрбер ихтималга күрә, пәһләви, Харәзм һәм Согыд әлифбасыннан алганнар булырга кирәк. Ләкин бу соңгылар хакында мәгълүмат караңгы булганга, Томсен бу мәсьәләдә тәфсилгә[3] бирелә алмады. Бәлки ялгыз бу турыда 23 галәмәтнең азмы-күпме ихтималлыгы булган нәселләрен генә күрсәтеп үтү белән канәгатьләнде», – дип яза.

Томсен фикеренчә, арами әлифбасы, тукюлар алганнан соң, төрк теленең фонетикасына, табигатенә карап кына үзгәртелешкә очраган. Шуның белән ул төрк теленә яракландырылып алынган. Томсен Орхон язуындагы берничә галәмәтләрнең арами әлифбасыннан булмаган галәмәтләрдән тудырылган вә тәрәккый иттерелгән булу ихтималын да әйтә.

Енисей язулары – Орхон язуларына караганда язуның рәвеше ягыннан тагын да борынгырак, тагын да искерәк бер язу алар. Менә шуны игътибарга алып, аларны VII вә бәлки VI миладига кайтаралар. Тукюларның күтәрелә башлавы VI милади урталарында булганы безгә мәгълүм. Аларда язу башлану һәм әлифбаның башкалардан

[1] Әсасән – нигездә.
[2] Платон Михайлович Мелиоранский (1868–1906) – рус тюркологы, Шәрык белгече.
[3] Тәфсилгә – нечкәлеккә.

алынуы да шул ук вакытта булу ихтималын да йөретәләр. Тукюлар шушы Орхон әлифбасын нинди дә булса үзләреннән башка бер төрк халыкларыннан алган булуларын да уйлыйлар. Томсен шулай уйлый. Болай уйлаганда инде Енисей-Орхон әлифбасын VI гасырдан да элек булган бер заманга кайтара алалар.

Мелиоранский (югарыдагы әсәрендә): «Материалларның азлыгы астында бу мәсьәләне хәл итү кыен бер нәрсә булуга карамастан, О. Доннер[1] бу мәсьәләне катгый хәл итәргә тырышты. Бу турыда ул бераз муаффәкыять[2] тә казанды», – дигәннән соң, Доннердан алып шушы түбәндәге фикерләрне яза: «Аныңча, Орхон-Енисей әлифбалары милади II, III гасырда арами акчаларына язылган язуларга бигрәк якын килә. Соң, тагын да искерәк булган бу арами әлифбасы ничек итеп алай VI гасырдагы төркләргә килеп керә ала? Хәлбуки[3], иң иске Енисей язулары фәкать VI гасырга нисбәт бирелә ала. О. Доннер бу мәсьәләне катгый хәл итми. Бу менә шулай булырга мөмкин? Шәрыкта, Төркестанда арами-арсак әлифбасы милади III гасырдан озаграк бер вакытлар сакланып килә алган булыр. Шулай ук төркләрнең кайсысы булса да бу әлифбаны VI гасырдан байтак вакытлар элегрәк бер заманнарда алган булулары да ихтимал.

Әмма Н. Аристов[4] исә Орхон язуын тукюлар дәүләтенең нәкъ шәрык өлешендә заһир булган һәм ул борынгы төрк тамгаларыннан төзелгән, дип таба. Ләкин, безнеңчә, бу фикер – бөтенләй хата бер фикер. Томсен охшашларын таба алмаган бәгъзе галәмәтләр өчен әнә шушы тамгалар алынган булса булыр».

Мелиоранскийдан күчерелгән шушы сүзләргә, Радлов фикеренчә, һуннарда да шул ук Орхон язуы кулланылган булу фикерен дә китереп кушсак, һәрхәлдә, бу язу бик иске бер заманда мәйданга килгән бер язу булып кала. Бу тәкъдирдә аның башлануы миладның III–IV гасырларында ук булуы бик мөмкин. Орхон хәрефләре төрк тамгаларына, әлбәттә, бик охшыйлар. Моны инкяр итәр хәл юк. Шул хәлдә Аристов шикеллеләрнең фикерен дә бөтенләй хатадыр

[1] Отто Доннер (1835–1909) – фин лингвисты, угрофиновед һәм сәясәтче. О. Доннер 1875 елдан 1905 елга кадәр Гельсингфорс университетында (хәзерге Хельсинки университеты) санскрит һәм чагыштырма-тарихи тел белеме профессоры вазифасын башкара.

[2] Муаффәкыять – уңыш.

[3] Хәлбуки – ләкин.

[4] Николай Александрович Аристов (1847–1910) – шәрыкшинас, этнограф һәм тарихчы галим.

диясе килми. Әлифбаларның әсасын арамидан – сами әлифбасыннан алган булганда да, һәрхәлдә төрк тамгаларының байтак төрләре шушы Орхон әлифбасының хәрефләре эченә кереп киткән булуы туры бер фикер булыр. Татар-башкорт авылларында сакланып калган «приговор», «расписка»лар да бу фикерне куәтлиләр.

Авылларда сакланып калган язуларда түбәндә 35 нче шәкелдә күрсәтелгән тамгалар очрый[1]. Бу тамгалар XIX йөзнең соңгы ярымында язылган приговор һәм расписикалардагы кул куюлардан гыйбарәт. Менә шушы тамгаларга каралганда, Орхон хәрефләренең – боларга, боларның да Орхон хәрефләренә охшаганлыклары ачык күреләә.

Бөтене белән тамгалардан төзелгән булу фикерен каты рәдд иткән Мелиоранский да, югарыда күргәнебезчә, моны мөмкин саный.



35 нче шәкел. *Тамгалар*

Орхон язуы, әлбәттә, тукюлардан күп заманнар элек эшләтелеп, тәдриҗән[2] тәрәккый иттерелеп килгән бер язу булган. Ләкин аның иң тәрәккый иткән, югарылашкан вакыты тукюлар дәверенә, аларның да шәп вакытлары булган VII, VIII гасырлар арасына туры килә. «Бу язу, VII гасырда Мәгыйлән каганның атасы Илтәрәс каган тәхеткә утырганнан соң, аның Кытай тәрбиясе алган укымышлы вәзире Төньюкукның тәшәббесе[3] белән, төрк илендә рәсми хөкүмәт язуы буларак кабул ителгән булырга кирәк. Бу Төньюкукның кабере өстенә утыртылган шактый озын язулы таш та хәзерге көнгә кадәр сакланган»[4].

[1] Орхон хәрефләренең тамгалардан төзелгән булу фикеренең күпме дөрес икәнен белү өчен авыллардагы иске язулардан тамгаларны эзләп тикшереп йөренгән чагымда, 1925 ел, мин боларны Башкортстан җөмһүрияте Мәсгуд кантоны Иделбай авылыннан таптым. Шушы авылның Шакир Дәүләтшин дигән картта күп кенә иске язулар сакланган икән, углы граждан Нургали дигән кеше аркылы шуларны карап, югарыдагы тамгаларны җыеп, күчереп алдым. Габденнәфигъ, Габдеррәфикъ һәм Фәхрерразый Хәбибуллиннан да байтак язулар алып файдаландым. Моның өчен аларга бу урында рәхмәт әйтүне үземә бурыч саныйм. *(Авт. иск.)*

[2] Тәдриҗән – әкренләп.

[3] Тәшәббесе – инициативасы.

[4] Татар әдәбияты тарихы, б. 36. Радловтан. *(Авт. иск.)*

Орхон язуының өстән түбәнгә һәм уңнан сулга таба язылуы Кытай тәэсире белән булганлыкны да әйтәләр (Томсен шулай ди). Әлбәттә, бу язуның Кытай тәэсире астында калган булуында шөбһә юк. Шуның өчен Орхон язуларының бәгъзе галәмәтләре Кытайның иҗек язу галәмәтләреннән алынмадымы икән, дигән фикер дә башка уза. Әмма бу турыда күрсәтә торган куәтле дәлилләр юк.

**Уйгур әлифбасы.** Төркләрдә икенче төрле әлифба – уйгур төркләренең әлифбасы. Соң уйгурлар кемнәр алар? Уйгурлар – тукюларның кардәшләре, болар да борынгы һуннар мәмләкәтендәге төркләрнең токымнарыннан яки шул ук һуннарның үзләре. Тарихлар безгә боларны милади белән III–IV гасырларда шул ук Монголиядә – Байкал күленең җәнүбендә Орхон вә Сәләңгә елгалары буенда яшәгән итеп күрсәтәләр. Боларның пайтәхетләре дә Карабалгасун шәһәре булып, моны да шул ук уйгурлар тәэсис иткән[1], диләр. Хәлбуки, шул ук шәһәр тукюларның да пайтәхете булган була. Шуның өстенә кытай тарихчыларыннан уйгурларның телләре дә һуннарныкы белән бер булганын аңлыйбыз.

Шул хәлдә, димәк ки, уйгурлар да төбендә шул ук һун вә тукюларның туганнары булган төркләр булалар. Тукюлар исеме белән мәшһүр бер дәүләт мөнкариз булып[2], аның урынына шул ук төркләрдән «уйгур» дип аталган бер җәмәгать шул төрк дәүләтен үз исемнәрендә яңадан төзеп, тәрәккый иттереп алып китәләр. Уйгурлар башта тукю дәүләте җимерелгәнгәчә, ягъни VIII миладиның урталарынача тукюлар хакимияте кул астында шуларның тәбәгасе булып[3] яшәгәннәр. Бер вакытларда болар Енисей һәм Сәләңгә елгалары тирәсеннән Тянь-Шань тауларынача булган җирләрдә торалар.

«Уйгур» сүзе – «оешмак, тәртипләнмәк, берләшмәк» мәгънәсендә булган бер сүз. Хәзерге көндә дә «оешу, оешма» сүзләре бездә дә сәясәт телендә йөртелә. Руханилар телендә дә бу «имамга ою» рәвешендә йөртелеп килде. Бездә хәзер «катык оету» дигән сүз дә мәгънә ягыннан шул асылдан.

[1] Бу хакта татар телендә З. Вәлидинең «Төрк-татар тарихы» белән (б. 51) Г. Рәхим, Г. Газизләрнең «Татар әдәбияты тарихы» (б. 48) ында да мәгълүмат бар. Уйгурлар хакында Г. Рәхим, Г. Газизләр яхшы ук озак тукталганнар. Шуларга каралсын (б. 91 дән). *(Авт. иск.)*

[2] Мөнкариз булып – юкка чыгып.

[3] Тәбәгасе булып – буйсынып.

Мәшһүр үзбәк тарихчысы Әбүлгази[1] бу сүзне төркләрдән аерым бер кабилә яки аерым бер ыруг итеп күрсәтми, бәлки шул ук бер нәселдән булган төркләрнең бер оешмасына Угузхан тарафыннан үз янына бергә оешып килгәнлекләре өчен бирелгән бер исем итеп кенә күрсәтә һәм «уйгур» сүзен дә шул мәгънәдә изах итә[2]. Әбүлгазига таянып, бу исемне бергә оешып, сәяси бер бүлек тудырган яки бер дәүләт төзегән күптөрле төрк кабиләләренең сәяси бер оешмаларының исеме дип аңлаучы башка тарихчылар да бар. Болар «уйгур» дип бер-берсе белән тагын да ныграк оешып, шәһәрләр корып, тагын да күбрәк мәдәниләшкән, тагын да күбрәк утрак бер тормышка күчкән бөтен бер төрк җәмгыятен аңлыйлар[3].

Боларның тәмам шәһәр тормышына күчүләре төрк теленең яңа шивәләре туугa сәбәп булган[4].

Менә шундый төшенчәләр аркылы без уйгурлардан соң аларның урынын тоткан һәм тукюлар дәүләте урынына яңа бер зур төрк дәүләте төзегән вә телләре бераз үзгәргән бер төрк җәмгыяте дип аңлый алабыз. Болар, әлбәттә, мәдәнияттә тукюлардан күп тәрәккый иткән булалар. Болар – ул вакыттагы төрк халыкларыннан иң мәдәни булганнары.

Шимали Монголиядә тукюларның хәләфе[5] булган шушы уйгур дәүләте IX милади урталарынача дәвам итә[6].

Аннан соң болар өстенә төп токымнары һун төркләреннән булган кара кыргызлар һөҗүм итәләр. Шуларның кысулары белән уйгурлар, тезелеп, җәнүбкә таба, үзләренең Шәркый Төркестанда яшәп килгән кардәшләре янына күчә башлыйлар. Милади X гасырда инде җәнүбтә болар ике кечек ханлык тудыралар. Боларның берсе – шәркый, икенчесе – гарби уйгурлардыр. Шәркый уйгурларның урыны – Кытай Төркестаны, ягъни Җунгария, икенчесенең урыны

---

[1] Әбүлгази хан (1603–1664) – Шәйбанилар династиясеннән Хива ханы, тарихчы һәм язучы.

[2] «Шәҗәрәи төрк», б. 16–17. «Уйгур сүзе турында Радловның «К вопросу о булгарах» дигән китабында каралсын. *(Авт. иск.)*

[3] З. Вәлидинең «Төрк-татар тарихы» (б. 12) һәм Н. Гасыймның «Төрек тарихы» (б. 44). *(Авт. иск.)*

[4] Радлов доклады. «Зап. Вост. Отд. Имп. Русск. Арх. О-ва». XXI җилд, IV җөзе. *(Авт. иск.)*

[5] Хәләфе – алмашы.

[6] Аларның (Монголиядәге уйгурларның) мәмләкәте 744 дән 840 елгача дәвам итә (З. Вәлиди. «Төрек тарихы», б. 57). *(Авт. иск.)*

да Луб-нур күл[1], Тарим елгасы тирәләрендә була. Беренчеләрнең пайтәхете – Биш балык («Биш шәһәр» дигән сүз. Гомумән, уйгурлар Җунгариягә Биш балык дигәннәр. Кытайлар моңа «шималь юлы» мәгънәсендә «Пә – лу» дигәннәр), икенчеләренең пайтәхете Кашгар булган (моңа уйгурлар – «Алты шәһәр», кытайлар «Нан-лу» дигәннәр. «Җәнүб юлы» дигән сүз).

Уйгур әлифбасы дигән әлифба – менә шушы төркләрнең кулланган һәм шуларга нисбәт бирелеп мәшһүр булган бер әлифба. Бу әлифба бигрәк тә уйгурлар Монголиядә яшәгән вә хакимият сөргән вакытларында Шимали һәм Гарби Монголиядә тарала. Болар да, чамалап әйткәндә, Билге хан һәм Күлтәгин һәйкәлләреннән илле ел соң, 784 елларда, алардан 30 чакрым кадәр шәркый җәнүбидә уйгур каганнарыннан берсенең каберенә бер һәйкәл утыртып калдырганнар. Бу һәйкәл-ташбилге Карабалгасун шәһәренең хәрабәсендә табыла. Ләкин бу һәйкәлгә орхонча да, уйгурча да язылган була. Димәк, бу вакытларда төркләр бер-берсенә якын булган ике төрле әлифба кулланган булалар. Берсе – Орхон, икенчесе – уйгур әлифбасы.

Уйгур әлифбасының күп таралган һәм гомумиләшкән урыны бигрәк Шәркый һәм Гарби Төркестанда була.

Бу әлифбаның төп тамыры – анасы сөрьяни әлифбасы (Сүрия әлифбасы – сәтре инҗил), чөнки бу әлифба сөрьяни әлифбасыннан үзгәртелеп тудырылган (Кытайдагы настори әлифбасы дигән бүлеккә каралсын) настори әлифбасының баласы. Настори раһибләре[2], үзләренең дини тәгълиматларын төрк халыклары – уйгурлар арасына тараткан вакытларында, шушы үз әлифбаларын да уйгурларга кабул иттергәннәр.

Бу да менә шулай була: Гайсә диненең настори мәзһәбендәге адәмнәре һәм насторилар фиркасе, Сүриядә каты кысынкылык вә хөкем астында калгач, үзләренә Иран падишаһлыгында оя ясыйлар. Монда алар Иран монархларының (сасаниларның) аерым бер химаяләре[3] астында булалар. Настори мәзһәбе Иранда үзенең дини тәгълимат мәктәпләрен ача. Менә шушы мәктәптән чыгучы

---

[1] Луб-нур (Каракошүккүл) – хәзерге Кытайның көнбатышында, Кашгар (Тарим) тигезлегенең көньяк-көнчыгыш өлешендә, Синьцзян-Уйгур автоном районы территориясендә урнашкан корыган күл.

[2] Раһибләре – монахлары.

[3] Химаяләре – саклаулары.

вагыйзлар[1] фәүкыльгадә[2] бер энергия белән, һич тартынмастан, курыкмастан, үз тәгълиматларын Азия халыклары арасында тарата алучылык белән мөмтаз булалар[3]. Болар милади VII һәм VIII гасырларда инде Кашгарда, Һератта, Сәмәркандта, хәтта Һиндстан белән гарби Кытайда үзләренең миссионерлык эшләрен бик уңышлы бер рәвештә тәрәккый иттерәләр.

Әнә шул вакытларда болар үзләренең христианлык дини тәгълиматлары белән бергә шул җирләрдә Азия халыклары арасында үзләренең настори язуларын – настори әлифбаларын да тараталар.

Азия халыклары эченнән һәм төркләрдән элек башлап настори әлифбасын кабул итүчеләр дә уйгурлар була. Ләкин бу әлифба аларда гайнән[4] сакланып бара алмый. Уйгурлар аны бераз үзгәртәләр. Бу үзгәртү дә, бер яктан, уйгурчаның авазлар һәйәтенә карап була. Ягъни алар 32 сөрьяни хәрефе эченнән бары 18 не генә алалар. Икенчедән, алынган хәрефләрнең шәкелләренә бераз үзгәрү кирә. Бу да уйгурларның язу техникасы кытайча булганлыгыннан була. Чөнки кытайлар, мамыктан ясалган йомшак, ялтыраксыз кәгазь кулланып, шуларга кечкенә пумала белән язганар. Уйгурлар да шулай иткәннәр.

Петербург асаре гатика[5] җәмгыятенең шәрык бүлемендә ясаган докладында Радлов бу турыда: «Хәтта «сәтре инҗил»нең гайне[6] диярлек дәрәҗәдә булган настори әлифбасы уйгурларда язу өчен кытай пумаласы (безнең каләм урынында язуга махсус) истигъмаль ителгәнлектән шундый үзгәрешләргә очрады, җитмәсә тагы бу бар: Урта Азиянең үзендә Кытай пумаласы кулланмаган, гарби өлешләрендә бу язу хасил була алмады»[7], ди.

Уйгур язуы гарәп язуына да охшап кала. Аслый сөрьянидан настори әлифбасыннан булгач, әлбәттә, бу табигый: монда, гарәп язуы

---

[1] Вагыйзлар – әхлак өйрәтүчеләр.

[2] Фәүкыльгадә – гадәттән тыш.

[3] Мөмтаз булалар – аерылып торалар.

[4] Гайнән – шул көенчә.

[5] Асаре гатика – археологик истәлекләр.

[6] Гайне – нәкъ үзе.

[7] Радлов доклады «Зап. Вост. Отд. Имп. Русск. Арх. О-ва» мәҗмугасы XXI җилдә IV җөзе. Радлов шул ук докладында, Турфаннан С.Ф. Эльденбург тарафыннан китерелгән фрагмент – язу кыйтгалыннан ике үрнәк күрсәтеп, шулар аркылы сөрьяни язуына тагын да якынрак булган иске уйгур язуы белән, үзендә Кытай тәэсирен тагын да ачык күргән яңа уйгур язуының хосусиятләрен билгеләп күрсәтә. Һәм уйгур язуы белән төркләр генә түгел, иранлылар да файдаланган икәнлекләрен әйтә. *(Авт. иск.)*

| Настори әлифбасы | Уйгур әлифбасы. Баш, урта, ахыр хәрефләр | Магул әлифбасы. Язганда хәрефләрнең офкый янтык юлларда күренеше. Баш, урта, ахыр хәрефләре | Магул әлифбасы хәрефләренең өстән аска таба язылгандагы күренешләре. Баш, урта, ахыр | Маньжур әлифбасы Баш, урта, ахыр | Хәрефләрнең исемнәре | Мәгънәләре |
|---|---|---|---|---|---|---|




40 нчы шәкел. *Уйгур, магул әлифбасының нәселе*

| Настори әлифбасы | Уйгур әлифбасы. Баш, урта, ахыр | Магул әлифбасы. Баш, урта, ахыр | Магул әлифбасы хәрефләренең өстән аска таба язылган вакытларындагы күренешләре. Баш, урта, ахыр | Маньжур әлифбасы. Баш, урта, ахыр | Исемнәре | Мәгънәләре |
|---|---|---|---|---|---|---|




41 нче шәкел. *Уйгур, магул әлифбаларының нәселе (40 нчы шәкелнең дәвамы)*

шикелле, хәрефләр дә баш, урта, ахыр, ялгыз рәвешендә сүздә алган урыннарына карап төрләнәләр. Һәм сүзләрдә хәрефләр бер-берсе белән тоташып язылалар.

Орхон язуы шикелле уйгур язуы да ул вакыттагы мәдәният дөньясына танылган мәшһүр бер язу булган. Ул – Кытайда да[1], Рум империяторлыгында (Бизанста) да, ислам мәмләкәтләрендә вә гарәпләрдә дә укылган, танылган бер язу. Төркләргә языла торган рәсми кәгазьләрне дә алар шул уйгур язуы белән яза торган булганнар. Магул-татарларда да шушы әлифба кабул ителеп (бу хакта сүз түбәндә тагын киләә), Җүҗи олысында, Алтын Урда һәм Чыгытай

[1] «Вәл-әһли Масыйн вә Сыйн ләгате галә хидәтин вә мәга һәза әһлел-әмсар минһим яхсәнүнәт-төркия вә мәрасилеһем иләйна би-хаттыйт-төркия» («Масыйн һәм Сыйн халкының теле аерым, ләкин шәһәрләрдә торучылары төркичәне яхшы беләләр һәм төрки язуы ярдәмендә хәбәрләшәләр») (Мәхмүд Кашгари. Китабе Диване ләгат әт-төрк»). *(Авт. иск.)*

олысында, Мавәраэннәһердә дә кулланыла. «Мигъраҗнамә», «Тәзкирәи әүлия», «Бәхтиярнамә» шикелле чыгтай әдәбиятыннан булган әсәрләрнең XV гасырда уйгур язуы белән язылган нөсхәләре дә табыла. Хәтта уйгур әлифбасы белән язу XVIII гасырның башларынача дәвам итә.

Ләкин моннан соң уйгур әлифбасы ислам дине тәэсире белән басып килгән гарәп язуы – гарәп әлифбасы алдында тәмам көчсез кала. Аның белән та[1] X миладидан башланган көрәшен инде дәвам иттерергә булдыра алмый. Гарәп миллияте белән нык сугарылган ислам дине, уйгур язуы кебек, гарәпнекеннән башка язуларга үз иярченнәрен тәмам нәфрәт иттертә.

Ниһаять, ул төркләр арасында урынын тәмам гарәп әлифбасына бирергә мәҗбүр булып, үзе фәкать ислам тәэсиреннән читтә торган магуллар, калмаклар һәм маньҗурларда гына сакланып кала. Хәзерге көндә дә боларда бераз үзгәреш белән, әсасән, шушы уйгур әлифбасы кулланыла. Шулар белән матбугатлары нәшер ителә.

Фәкать боларның хәзерге язуларын уйгур язуы белән чагыштырганда, менә шушы хосусиятне күрәләр: боларда тавышлы хәрефләр күптән бирле тавышсыз хәрефләр белән берләшеп, мөмкин булмаган бер рәвештә әллә никадәр иҗек комбинацияләре (оешмалары) ясалган яки төзелгән. Моннан башка тагы магул, калмак һәм маньҗурлар кытайлар тәэсире астында хәрефләрнең әүвәлгечә, самилардагы кебек, уңнан сулга таба язылып бару хосусиятен тәмам ташлаганнар, текә (гомуди) юллар белән өстән аска һәм сулдан уңга таба язуны үзләштергәннәр. Шуның өчен хәзер дә аларның хәрефләре үзләренең асыллары булган уйгур язуыннан бөтенләй башка бер хәлдә тезеләләр[2].

Әмма «Китабе Диване лөгат эт-төрк»[3] иясе Мәхмүд Кашгари: «Вә ли уйгур лисан туркийә махда вә люга ухра мимма йәтәкәлләмунә биһа фима бәйнәһүм. Вә китабә би хатт ат-туркийә әл-мөәлләфә мин әрбәгатин вә гыйшринә хәрфән әл-ләти бәянтүһа фи садрил-китаб, йуктабү биһа әр-расаил. Вә китабә ләһүм вә лис-сыйн ухра йүктәбү биһа әс-сухуф вәд-дәвавин лә йәкърауһә гайрүл-гулюҗ минһүм», –

[1] Та – башлап.

[2] *Шницер Я.Б.* История письмен. Б. 130–133. *(Авт. иск.)*

[3] Бу китап һиҗри белән 466 елда Кашгарда язылган вә өч җилд булып Истанбулда басылган. Димәк, бу китапның язылуы «Котадгу белег»тән өч ел соң буладыр. *(Авт. иск.)*

дидер. Ягъни: «Уйгурларның теле – саф төрки бер тел, шуның белән бергә аларда икенче бер төрле лөгать тә бар. Бу – аларның үзара сөйләшә торган телләре. Янә уйгурларның егерме дүрт хәрефтән гыйбарәт төрки язулары да бар. Моның белән алар рисаләләр язалар. Аларның һәм хытайларның[1] аннан башка тагы бер язулары бар. Моның белән алар кәгазьләр һәм канцелярия эшләрен йөрткәннәр. Бу язуларны үзләренә махсус кешеләрдән башкалар укый алмаганнар». 24 хәрефтән гыйбарәт төрки язуының хәрефләрен дә ул, «аслый[2]» вә «фәргый[3]» дип икегә бүлеп, аслый булганнар барысы 18 хәреф икәнен әйтеп, шушы рәвештә бергә җыеп күрсәтә: «ахукь (اخوک), ләф (لف), сәмәҗ (سمج), тәзак (تزق), бәзәр (بذر), шәтйа (شتيا)»[4]. «Бу хәрефләр (барысы – 18) язуда мотлакан күрсәтелә, ягъни язылалар», – ди. Әмма калган җиде «фәргый хәреф»ләр сөйләгәндә әйтелә, ә язганда, язуда күрсәтелмиләр, ди. Асыл хәрефләрнең дә ул аерым рәвешләрен 42 нче шәкелдәгечә күрсәтә.

Бу хәрефләрне дә бер-берсе белән кушылып язганда, Мәхмүд Кашгари 43 нче шәкелдәгечәдә күрсәтелгәнчә җыела, ди.

«Фәргый хәрефләр» (иярченнәр) дигәнен болай саный: «Вә һийә әл-баэ әс-сулба вәл-җим әл-гарәбийә вә һийә гариза фи һәзиһил-лугати вәз-зәй әл-мөтәвәллидә бәйнә мәхраҗәй

---

[1] Мәхмүд Хытайны бер урында «вә һияс-Сыйн» дип изах кыла. «Сыйн» белән «Масыйн» (Чин белән Мачин)ны төрк ыругларыннан саный. *(Авт. иск.)*

[2] Аслый – асыл, төп.

[3] Фәргый – өстәмә, икенче дәрәҗәдәге.

[4] Фәкать Мәхмүд Кашгари китабының башында бу хәрефләрне төрк теленең хәрефләре дип саный. Бу хәрефләр хакында бу урында китерелгән сүзләрнең һәммәсе дә шушы төрк теле турында бара. Әмма уйгурларга килгәч, аларның да шул ук хәрефләр белән язганын әйтә. Ләкин югарыдагы үз сүзеннән аңлашылганча, уйгурларның аннан башка тагы бер язулары, ягъни хөкүмәт язулары булганын әйтә.

Янә ул бу урында: «вә ли – әһли Масыйн вә Сыйн лисане галә хидәтин вә мәга һәза әһлел-әмсар минһим яхсәнүнәт-төркия вә мәрасилеһем иләйна тәкүнә би-хаттыйт-төркия» ди («Мачин вә Чин әһеленең үзенең аерым лөгате бар. Шулай булса да болардан шәһәр әһелләре – әһле әмсар-е төркине яхшы күрәләр. Аларның безнең белән хәбәрләшүләре дә төрки язуы белән була», ди) дә, әлеге уйгурлар белән «Син» (Чин) нарның язуларын сөйләп беткәч, «вә һәзал-ләзи сәмәйтеһем әһлел-әмсар» («шәһәр әһелләре дип атаганым шулардыр») дип куя.

Менә моннан, һәрхәлдә, төркләр (тукюлар) уйгурларның үзе үк булмаганы аңлашыла. Ягъни төрк халыкларының башка ыруглары белән бергә «төрк» дигән ыругы булганлык беленә. Хәзердә дә Фирганәдә Нәманган тирәсендә «төрк» дигән бер кабиләнең барлыгын, аның сөйләшүен дә саф төркичә икәнен Фирганәдә вакытта ишеткән идем. Ләкин үзем барып күрә алмадым. Уйгурларның икенче рәсми язулары булганлык хәбәре дә – безнең өчен бик мөһим нәрсә. Әнә шушы язуның хатирәләре кайда? Менә шуны эзләргә кирәк. *(Авт. иск.)*



42 нче шәкел



43 нче шәкел

әз-зәл вәш-шин. Вәл-фәэ әл-гарәбийә вәл-гайн әл-могъҗәмә вәл-кяф әл-мөтәвәллидә бәйнә мәхраҗәй әл-каф вәл-кяф. Фә һәзиһи әл-әхруф әсгаб лин-нутк ли гайрит-турк. Вә йүктәбү һәзиһи әл-әхруф әл-фәргийә галә сыйфәтил-хоруф әл-аслийә, ләкиннәһә тункату фә йугърафу биһа». Ягъни: «Бу хәрефләр – каты әйтелә торган «ба» (ب), гарәп «җим»е (ج). Бу – шушы лөгатьтә табигый булган бер хәреф. Аннан соң «ذ» (з) белән «ش» (ш) авазлары уртасында булган «ژ» (з), гарәп «фа»сы (ف), «каты гайн» (غ), «каф» (ق ) белән «кяф» (ک ) арасында булган «гәф» (گ). Бу хәреф – төркләрдән башкалар өчен әйтүгә иң авыр булган бер хәреф. Фәргый хәрефләр асыл хәрефләр шәкелендә язылалар. Фәкать боларга нокта куела да, алар шуның белән аерылып беленәләр. Янә Кашгари әйтә: «Һәр өст (фәтхә), әйтүдә һич әлиф булып әйтелмәсә дә, бу язу белән язганда, ул әлиф булып әйтелә. Шулай ук сөйләүдә аслый булмаса да, һәрбер өтер (заммә) язуда «вау» булып әйләнә. Һәрбер аст (кәсрә) дә әйтелештә аслый булмаган хәлдә һаман «йа» булып языла. Бу нәкъ гарәпчәдәге «аб, ах» («أَب، أَح») сүзләренең язылуына охшый, чөнки боларда «Һәзә әбукә, вә раъәйтү әбәкә, вә мәрартү би-әбикә»[1] рәвешендә хәрәкәт өчен бер хәреф арттырып языла (әб+у, әб+ә, әб+и).

[1] Тәрҗемәсе: «Бу синең атаң. Мин синең атаңны күрдем. Мин синең атаң янынннан уздым».



44 нче шәкел. *Бу клише Радлов тарафыннан нәшер ителгән «Котадгу белег» тән алынды*[1]

[1] Табыла алмый торган бу китапның шушы нөсхәсеннән берсе Галимҗан Ибраһимов көтепханәсендә булып, клише шуннан алдырылды. *(Авт. иск.)*

Шушы югарыдагы язуны да М. Кашгари: «Вә галә һәзәл-хатт кәтәбә әл-хаканийә вәс-сәлятын мәрасиләһүм мин кадимед-дәһр иләл-йәүм. Мин Кәшгар иләс-Сыйн әл-гулйя мөхдикан ли-җәмиг диярет-төрк» («Шушы югарыдагы язу белән каганнар вә солтаннарның китаплары һәм хәбәрләшү кәгазьләре языла. Бөтен төрк илләре эченә кергән хәлдә, Кашгардан алып та югары Чингача борынгы заманнан хәзерге көнгә кадәр шулай язылып килде»), – ди. Кашгарның шушы хәбәреннән без төрк илләрендә бу әлифбаның ул вакытында бик күптән бирле кулланып килгәнен ачык аңлыйбыз. Аның бу әлифбаны асылда «төрк язуы» дип йөретеп, уйгурларның да шуның белән язуларын кушып куюына караганда, хакыйкатән, бу әлифба борынгы заманда ук бөтен төрк илендә гомуми бер әлифба булган була. Кашгарның, югарыдагыча, уйгур вә чиннарның китап язуыннан башка канцелярия вә хөкүмәт язулары да булганлык хәбәре безне «әллә ул язу Орхон язуы булдымы икән» дигән фикергә китерә, чөнки Кашгарның, һәрхәлдә, Орхон язуы турысында бер сүзе булу кирәк иде. Әлеге кыска гына әйтеп киткән сүзе әнә шушы турыда булу бик мөмкин.

Моннан соң Мәхмүд Кашгари төрк телләрендә ث، ط ، ظ ، ص، ض، ح، هـ[1]، ع хәрефләре вә авазлары һич булмаганлыкны яза.

**Орхон әлифбасымы, уйгур әлифбасымы элек туган?** Бу мәсьәлә тәмам катгый чишелмәгән бер мәсьәлә түгел. Шулай да Орхон язуы ягындагы фикерләрнең таянычы куәтлерәк. Ягъни Орхон язуы, һәрхәлдә, уйгур язуыннан борын тудырылып, аннан элегрәк эшкә ашырылган булырга тиеш. Бердән, без югарыда хәтта борынгы һуннар шул Орхон язуы белән язган булу ихтималын күреп үттек (Радлов фикереннән). Бу тәкъдирдә ул милади III, IV гасырлардан ук истигъмаль ителә башлаган булырга мөмкин. Икенчедән, уйгур әлифбасының анасы настори әлифбасы булып, аның шуннан хасил булганлыгы, югарыда аңлатылганча, инде тәмам катгый бер нәрсә санала. Хәлбуки, насториларның дини тәгълиматларын һәм әлифбаларын Төркестанга уйгурлар арасына алып килүләре VII–

[1] Хотаннарның сөйләшүендә « ـهـ » табыла, ләкин ул – һинд тәэсиренең нәтиҗәсе. Кунҗак телендә дә бу бар. Чөнки ул тел төрки түгел: «Вә кад түҗәдү әл-һәъү фи кәлям хутн ли әннәһү мин нәтиҗәтел-һинд. Вә фи кәлям көнҗак кәзалик ли әннәһү ләйсә би төрки» (Тәрҗемәсе: Әл-һәъү [хәрефе] хутан сөйләмендә булырга мөмкин, чөнки ул һинд [теленең] йогынтысы. Шулай ук көнҗак сөйләмендә, чөнки ул төрки тел түгел) («Китабе Диване лөгат әт-төрк»). *(Авт. иск.)*

VIII гасырларда гына булган. Шулай булгач, аның төркләр арасына таралуын һәм аннан уйгур әлифбасының заһир булуын, һәрхәлдә, милади VIII гасырдан да арыга кайтарып булмый. Өченчедән, VI гасырда Рума императорына – Бизанс кайсарына[1] төркләр тарафыннан язылган язу бар. Әнә шуны Орхон әлифбасы белән язылган булуны куәтлиләр. Менә бу яктан да Орхон әлифбасының уйгурныкыннан, һәрхәлдә, элек туган икәне күрсәтелә.

Хасил[2], гәрчә бу ике әлифба тукюлар вакытында да, алардан соң уйгурлар дәверендә дә байтак вакытлар буенча икесе дә бәрабәр кулланылып килгән булсалар да (югарыда әйтелеп үткән бер ягы – уйгурча, бер ягы орхонча язылган ташбилге дә шуны күрсәтә), бу гына уйгур язуының Орхоннан элек туган булуына дәлил була алмый. Моны ялгыз менә шулай гына аңларга мөмкин: уйгурлар настори тәгълиматының тәэсире белән настори әлифбасын алга куеп, аны Орхон әлифбасына рәкыйб[3] ясаганнардыр. Шул рәвешчә, ахырда аны уйгурныкы итеп, миллиләштереп алгач, аны күбрәк гомумиләштерергә, таратырга, ә Орхон әлифбасын көчсезләндерергә тырышкан булырлар. Орхон язуы да, ниһаять, уйгур әлифбасына юл куярга мәҗбүр булган булыр.

Уйгурлар бит алар гаять милли тәгассыблы[4] бер халык булганнар. Настори әлифбасын дини тәэсир астында кабул итеп, шуны үзләштереп алганнан соң, әлбәттә, аны үзләренеке итеп нык саклау аларның шушы үз табигатьләренә муафикъ бер нәрсә иде. Аларның бу язуын гарәп язуына каршы куеп, ислам динен кабул иткәннән соң әле аны һаман каты саклап килүләре һәм аны Чыңгызга вә аның балаларына кабул иттерүләре, шул рәвешчә, аны бөтен татар-магул әлифбасы итеп калдыру юлына керүләре – менә бу хәлләр уйгурларның шушы үз язуларына ничек караганлыкларын, әлбәттә, безгә ачып бирә алалар. Болар шул әлифбаны тарату юлында башка төрк әлифбаларының эштән чыгуы белән дә һич хисаплашмаганнар булырга охшый. Кыскасы, «уйгурларда һәрхәлдә милли хис дини хистән өстен булган»[5]. Шуның өчен алар үз әлифбаларын саклау өчен хәтта гаять көчле ислам һәм гарәп әлифбасы тәэсиренә каршы да бар көчләрен, бөтен

[1] Кайсарына – императорына.
[2] Хасил – нәтиҗәдә.
[3] Рәкыйб – конкурент.
[4] Тәгассыблы – фанатизмлы.
[5] Бартольд. Туркестан в эпоху монгольского нашествия. Б. 419. *(Авт. иск.)*

сәркәшлекләрен[1] сарыф иткәннәр. Боларның әнә шул сәркәшлеге Орхон әлифбасының озын тарихы бердән киселүгә сәбәп булганнар.

## Башка төркләрдә язу

Гарби һәм шәркый тукю (төрк) мәмләкәтләре мөнкариз булгач, төркләр тагы төрлесе-төрле урында мәмләкәт торгызалар. Шуларның берсе уйгурлар иде. Боларны үткәндә күрдек. Ләкин менә шулардан башка тагы Чу елгасы буенда, Җидесуда һәм Сырдәрьяның түбән агымында дәүләт торгызучылар да булган. Тукюлардан соң болар, кирәк гаребтә, кирәк шәрыкта булсын, дәүләт торгызучылар «огуз» (яки гуз) яисә «тукыз огуз» дип аталып китәләр. Шәркый Төркестанның иң ерак бер өлешендә дәүләт торгызган тукюлар да гарәпләргә «тукыз – огуз» исеме белән мәгълүм булалар. Менә шуларның бер кыйсеме гаребкә күчеп, анда Сырдәрьяның түбән агымында дәүләт торгызалар[2].

Менә шушы төркләрнең асыл әлифбалары кайсы әлифба булган: Орхон әлифбасымы, уйгур әлифбасымы? Менә бу мәсьәләдә күбрәк ихтимал белән җавап бирергә туры килә. Болар төбендә тукюлардан булганлык өчен, әлбәттә, боларның беренче әлифбалары Орхон хәрефләре белән булган булырга тиеш.

Ләкин соңыннан хәзерге Җидесу вилаятендә[3] (Әүлия ата тирәләрендә. Хәзерге Әүлия ата шәһәре ул вакытта Талас дип аталган) карлук төркләре хаким булалар. Төрк халыклары эчендә иң күп ислам мәдәнияте тәэсире астында калучылар да – шушы карлуклар.

Менә шушы төркләрнең әлифбалары янә кайсы әлифба булган: Орхонмы, уйгур әлифбасымы – бу мәсьәләдә катгый бер нәрсә әйтү кыен. Боларның X миладида үзләреннән шәрыкта шушы гасырда бөтен төркләрнең иң шәүкәтле вә көчлеләреннән булган тукыз огуз-

[1] Сәркәшлекләрен – астыртын хәйләләрен.

[2] Боларның кышкы пайтәхетләре «Яңы гинд» (Казанлинскидан гарби җәнүбидә, хәзерге Җанкинд харәбәләре) дигән шәһәр була. Шулай ук монда мөселманнар тарафыннан Җәнд (Петровскидан җәнүбдә) дигән шәһәр дә салына *(Авт. иск.)*

[3] Җидесу дип аталган җир Гарби Төркестан белән Шәркый Төркестан уртасында булган. Моңа Балхаш күле хаузасының шәркый җәнүби кыйсеме, Чу егласының югары өлеше белән бергә Иссык күл хаузасы һәм Сырдәрьяга койган Нарын хаузасы (башынан алып Фирганә тауларыннан чыккан урынгача) кергән. (Монда элек төркләрдән «өсеннәр» яшәгәннәр). *(Авт. иск.)*

лар[1] химаясендә булуларын һәм тукыз огузларның да тукюлар икәнен искә алганда, боларда янә Орхон язулары кулланылган булырга тиеш.

Кытай сәяхы[2] Суэн-Сан[3] заманында[4] Амурдәрьядан Сырдәрьягача булган урыннарда бертөрле мәдәният булган. Халыкның киеме, язулары һәр урында бертөрле булган. Әлифбалары (сөрьяни ыругыннан булган язу булса кирәк дип уйлана) 32 галәмәттән торган. Югарыдан түбәнгә язганнар. Тарихи әсәрләре булган. Диннәре манихейлык дип уйлана (бу гарби төрк дәүләтенә туры килә[5]).

Шулай булса, карлукларның да язулары шушы Орхон әлифбасы булырга тиешлеге тагы куәтләнә.

Янә шул ук X миладида Җидесу Урта Азиянең гарби ярымы һәм Кашгар, Яркәнд, Хотан шәһәрләре вә Шәркый Төркестанның бер кыйсеме эченә кергән хәлдә, шушы хөдүд[6] эчендә караханилар яки илханилар сөляләсе[7] заһир була[8]. Ягъни X гасырның соңында Шәркый һәм Гарби Төркестанда шулар падишаһлык кылалар. 999 елда болар Мавәраэннәһерне фәтех итәләр[9]. Бохараны да саманилар кулыннан алалар. Боларның пайтәхете булган шәһәрләрдән берсе дә Чу елгасы хаузасындагы Баласагун шәһәре була[10]. Әмма Мавәраэннәһернең төркләшүе дә менә шушы заманнан башлана[11].

Менә бу төркләрнең язуы, соңыннан бу якларда уйгур әлифбасының өстенлек алып китүенә караганда, уйгур әлифбасы булган булырга тиеш.

---

[1] Бу шәүкәтле дәверләрендә боларга Ыссык күл кырыендагы Барсхан шәһәре дә караган. Ләкин бу вакытларда Енисейның югары агымында яшәгән кыргызлар килеп, бу шәһәрне тукыз огузлардан алалар. *(Авт. иск.)*

[2] Сәяхы – сәяхәтчесе.

[3] Суэн-Сан – Сюаньцзан (602–664), буддачы кытай монахы, галим, философ һәм Тан династиясе чорындагы тәрҗемәче.

[4] Суэн-Сан Будда диненең раһибе булып, бу раһиб гарби Төркестанны 629–648 миладта йөргән. Монда ул Аксу шәһәрендә булган (Мәхмүд Кашгари бу шәһәрне Мәдинәт әл-бәйза дип йөртә). *(Авт. иск.)*

[5] Самойлович. Западный Туркестан. *(Авт. иск.)*

[6] Хөдүд – чикләр.

[7] Сөляләсе – династиясе.

[8] Болар көчәеп, боларда исламият көч алганда, гаребтә Идел-Урал буйларында болгарлар көч ала, ислам анда көчәя *(Авт. иск.)*

[9] Фәтех итәләр – яулап алалар.

[10] Баласагун шәһәре Җидесуның төрк патшаларының пайтәхете була. Бу шәһәрнең иң элек пайтәхет ителүе һәм мәгълүм булуы да шушы мөселман патшаларының сөләләсеннән караханилар заманасында була. Бу шәһәрнең урыны кайда икәне бик үк ачык мәгълүм булмаса да, бирелгән тарихи мәгълүматларга карап, Чу елгасы буенда булгандыр дип уйлыйлар *(Авт. иск.)*

[11] Брокгауз-Ефрон. Җ. XXXIV. *(Авт. иск.)*

Самойловичның Бартольдтан кыскартып язганы «Западный Туркестан» дигән әсәрендә угызлар, ягъни төрекмәннәрне сөйләп килгәндә: «Берничә елдан соң Исфинҗаб Баласагун ханы Карахани сатукның хәләфе Муса углы Богра хан Һарун тарафыннан алына» (бит 69), – диядер. Менә моннан янә бу җирләрдә уйгур тәэсире аның әлифбасы булуга ачык ишарә бар. Шуның белән бергә караханилар шул ук уйгурлар булганы аңлашыла. Н. Гасыйм һәм З. Вәлиди тарихында боларның уйгурлар икәне тагы да ачык күрелә. («Төрек тарихы», бит 238, «Төрк-татар тарихы, бит 60). Шул хәлдә боларның әлифбалары шул ук уйгур әлифбасы икәне бу яктан шөбһәсез бер нәрсә булып кала.

Ләкин Радлов үзенең 1910 елда Петербург (хәзер Ленинград) Археология җәмгыятенең шәрык бүлемендә укылган докладында[1] милади белән 1068–1069 елларда язылган «Котадгу белег» иясе Йосыф Хас Хаҗибнең Баласагун шәһәреннән (Җидесу кешесе) икәнен, аның шунда туганлыгын бәян итә. Ул «Котадгу белег»не иң элек, уйгур язу теленең тәэсиреннән читтә торып, гарәп хәрефләре белән язган була. Ниһаять, бу дастанның уйгур тәэсиренә бирелүе аның язылып тәмам булып та, ханга тәкъдим ителгән урыны булган Кашгарда булганлыгын һәм хан шушы китапны халык арасына тарату өчен аны яңадан уйгур хәрефләре белән язарга боерганлыгын сөйли.

Радлов кебек бер ышанычлы галим, әлбәттә, бу сүзләрен бер әсассыз[2] сөйләмәс дип уйлыйбыз. Әгәр хакыйкатьтә бу шулай булган булса, X гасырларда уйгур язуы фәкать Кашгарда асыл уйгурларда гына булып, бөтен төркләргә бу язу үз хөкемен тәмам йөретә алмаган була. Бәлки югарыдагы Бартольд сүзеннән аңлашылуга караганда, Җидесуда, караханилар сөяләсе дәверендә үк, гарәп хәрефләре, гарәп әлифбасы хөкем сөрә башлаган була.

Шулай ук Мәхмүд Кашгариның «Ли тубут лисан галә хида вә кәзалик ли хутан китаба вә луга галә хида вә лә йухсабани ат-туркийә»[3] сүзе янә XI гасырда уйгур язуы бөтен Шәркый Төркестанда тәмамән гомуми бер язу булмаганын күрсәтә. Мәхмүд Кашгариның үзенең гарәп әлифбасы белән шундый зур бер әсәрен язуы да – бу вакытта гарәп язуының каты хөкем сөрә башлавына дәлил.

---

[1] Зап. Вост. Отд. Имп. Русск. Арх. О-ва, т. III, с. 106–119. *(Авт. иск.)*

[2] Әсассыз – исбатсыз, аргументсыз.

[3] Тибетның аерым теле бар. Хотанның һәм аерым теле вә язуы бар. Болар икесе дә «төркине яратмыйлар» дигән сүз.

Менә шулардан бер хөласа[1] чыгарып әйткәндә, караханилар сөляләсе дәверендә төркләр арасында гарәп әлифбасы кулланыла һәм уйгур әлифбасы истигъмальдән[2] чыга башлаган була.

XIII гасырда Төркестанда төп урыннары хәзерге Маньҗурия булган мәҗүси караханилар яки кәйданилар (болар асылда татарлар иде) мәмләкәте төзелә (1135 миладида). Болар, Кытай җиңгәннән башлап та, Хәзәр диңгезенәчә булган бөтен өлкәләрне үзләренә буйсындыралар. Ханнары Гүр хан дип атала. Болар бигрәк тә Җидесуда Баласагун тирәсендә яшиләр һәм XII гасырның икенче ярымында шушы шәһәрне пайтәхет итәләр. Талас (Әүлия ата) шәһәре белән Исфинҗаб[3] шәһәре дә шул ук гасырда караханилар тарафыннан фәтех ителә[4]. Бу икесе шул дәүләт кул астында аерым бер улус тәшкил итә[5], уйгурлар да Гүр ханнан мәгълүб булып[6] (536 һ. – 1141 м.) карахытай төркләре кул астына керәләр. Болар Төньяк Кытай мәмләкәтен дә үз кулларында тоталар.

Карахытайларның патшасы исә кытайлашкан мәшһүр каһарман (529 һ. вафат) Ялу Таши була (Кара батыр дигән сүз). Бу кеше зур сәяси [зат] булу белән бергә галим, хаким һәм әдип бер адәм булган. Ул Пекинда Лин-Я исемендә академия – дарелфөнүн тудыручы бер кеше. Тарихлар[7] безгә менә шушы галим төрк патшасының төрле гыйльми китаплар язарга боерганын һәм, мәктәпләр ачып, үз телләрендә, үз язулары белән укыттырганын әйтәләр. Менә боларның кытай язуына охшаш үз телләрендә махсус язулары булганлык бәян ителә[8]. Ләкин бу язу нинди язу булган, аның хатирәләре кайда? Менә бу турыда мәгълүмат юк. Кытай язуына охшаш булганның соңында, һәрхәлдә, бу язуның уйгурча яки гарәп язуы булмаганы ачык бер нәрсә. Моның Орхон язуы булу ихтималы юк түгел. Ләкин әүвәлдә боларның Кытайны идарә итүләре һәм Ялу Ташиның Кытай мәмләкәте идарәсе башында торып, кытайлашкан бер төрк

---

[1] Хөласа – нәтиҗә.

[2] Истигъмальдән – кулланылыштан.

[3] Исфинҗаб – Арыс елгасының мәдәни җирләре һәм аның тармаклары янында булган бер шәһәр. Бу шәһәр булынган урын шәрыкка табан Таласкача булган җирләрне эченә алган *(Авт. иск.)*

[4] Фәтех ителә – яулап алына.

[5] XIII гасырда Талас янында караханиларның гаскәре Харәзем шаһы Мөхәммәд тарафыннан ватыла, туздырыла. *(Авт. иск.)*

[6] Мәгълүб булып – җиңелеп.

[7] Тарихлар – тарихи язмалар.

[8] З. Вәлиди. Төрк-татар тарихы. Б. 91. *(Авт. иск.)*

булуы безне янә бу турыда шөбһәгә төшерә. Һәрхәлдә, бу язу, бу әлифбаның нинди бер әлифба икәне томанлы бер нәрсә булып кала.

**Татар-магулларда язу-әлифба.** Боларда язу-әлифба мәсьәләсенә керүдән элек, бу урында асыл татар һәм магулларның кем икәнлекләре турысында тукталып үтмичә булмый. Аларның этнографи якларын фәнни-тарихи бер юл белән тулырак итеп ачарга кирәк. Тарихчыларның хәзергәчә булган күп фәнни-тарихи тикшерүләре нәтиҗәсендә без инде татарлар белән магулларның, бер үк халык булып, төрк ыругларыннан берсе икәнлекләре турысында катгый бер фикергә килә алабыз.

Гареб тарих галимнәренең дә, Шәрык тарихчыларының да фикерләре шуңа кайта, шул ноктада бәрелешә[1]. Боларның яшәгән төп урыннары Байкал күленең җәнүб ягы булып, боларның гарби җәнү-

[1] «Тарих әл-камил» ли Ибн әл-Әсир: «Заһәра әт-тәтар илә билядел-ислам вә һум нәүгъ кәсир минәт-турк вә мәсакинүһүм җибаль Тамгаҗ мин нәхвис-Сыйн» (бит 149). (Ибн әл-Әсирнең «Тарих әл-камил» [китабында әйтелгән]: «Ислам илендә татарлар пәйда булды, алар төрле төрки кавемнәрдән гыйбарәт иделәр. Аларның тора торган урыннары Кытай тарафындагы Тамгаҗ тауларында иде» (бит 149)). «Китабе Диване лөгат әт-төрк» – төрк кабиләләрен санап китеп: «Фә әүвәлел-кабәил курбәр-Рум бәҗәнг сүммә кыйфҗак сүммә угуз сүммә йәмәк сүммә бәшгарт сүммә сәмәл сүммә кай сүммә йәбаку сүммә татар сүммә кыркыр вә һәзихи курбәс-Сыйн» («Румларга иң якын булган кабиләләрнең беренчесе бәҗәнәк, алардан соң кыйфҗак, алардан соң угыз, алардан соң йәмәк, алардан соң бәшгарт, алардан соң сәмәл, алардан соң кай, алардан соң йәбаку, алардан соң татар, алардан соң кыркыр. Соңгысы Кытай янында [яши]»). Әбүлгази: «Әленҗә ханның ике углы бар ирде. Икиз Туккан угылының аты – Татар, кечекенең аты – Магул. Әленҗә хан Корыган суның илене, бүлеп, ике угылыга бирде. Бу икесе бире-бире бирлән яманлык кылмай, яхшылык бирлән дәүләт сөреп гомер үткәрделәр» (Шәҗәрәи төрк, б. 10–11).

«Магул бирлән Татар падишаһ булгандин та Байдо заманыгача һич араларында низаг юк ирде. Магул хан угланнары үз иликә падишаһлык кылырлар ирде. Татар угыллары үз иликә падишаһлык кылырлар иде. Байдо фикерсез, зәгымсез екет булды: Магул хан угыллары бирлән яу булды. Такы *(тагы)* аларның илләрен чаба башлады. Үлү вакытта әҗәл килеп якасындин тотып, атасының катыга *(катына)* алып китте. Андин сернең углы Сөенеч хан атасы урнында ултырды. Сөенеч ханның заманыда Магул бирлән Татар иленең арасында дошманлык уты андак күп яттыкым, әгәр Амур дәрьясының суыны салсалар, сүнмәкәй ирде. Һәмишә Магул галиб килер ирде». 912 б. Радлов «татар» сүзе турысында: «Название народа, вероятно монголы, живущие по Онону» («Опыт словаря тюркских наречий», 901 б., 3 җ.)

Бартольд: «Монгольский или как он сам себя называл в то время – татарский народ разделялся на множество племен: белых, черных и диких татар» (Зап. Вост. Отд. Импер. Рус. Арх. О-ва, т. III, с. 106–119).

Янә рус энциклопедияләреннән «Просвещение» китап ширкәте тарафыннан нәшер ителгән «Большая энциклопедия»нең XVIII җилденә, Брокгауз – Ефронның XXXIV җилденә, «Новый энциклопедический словарь»ның 27 нче җилденә һәм «Гранат» энциклопедиясенең татар, магул, төрк-татар маддәләренә мөраҗәгать итәргә мөмкин. *(Авт. иск.)*

биясендә – найманнар, шәркый җәнүбиясендә караитлар яшәгәннәр. Болар икесе дә янә татар-магуллар ыругыннан булганнар.

Кыскасы, төрле тарихи вакыйгалар сәбәпле, бер үк төрк ыругыннан булган бер кыйсем халыкның бер өлеше – магул вә бер өлеше дә татар дип йөртелеп киткән икәнлеге инде фәндә ачылган бер нәрсә санала. Бартольд «Дада (татар) дип аталганнар», ди[1]. Брокгауз – Ефрон камусында[2] (ж. XXXII, татар маддәсе) болай диелә: VII миладида «тата», «татар» яки «татан» исеме астында (һәр ихтималга күрә «татар» сүзе дә шуннан булса кирәк) Монголиянең шәрык шималесендә һәм кыйсмән Маньҗуриядә Халха, Крүлән вә Сөнгәр елгалары арасында хосусан Буер-нура[3] тирәләрендә яшәгән монгол ыруы аңланды.

Кытай тарихларында IX миладида очрый торган «тата» сүзенең «татар» сүзе икәнендә шик юк. Чөнки кытайларда «р» хәрефе булмаганлыктан, «төрк» сүзен «тукю» дип язганнары һәм «кыргыз» сүзендә кі-лі-кі-сі рәвешендә «р»сыз әйтүгә мәҗбүр булганнары кебек, татар дигән сүзне дә алар «дада», «тата», «тадза» рәвешендә әйткән һәм шулай язган булулары – табигый бер нәрсә. Моның шулай икәнлеге лингвистика, тарих һәм археология ягыннан соңгы тикшерүләрнең нәтиҗәсендә ачык мәгълүм булды. IX гасырдан әүвәлге якка, ягъни VIII гасырга кайтып карасак, монда инде тагын да ачык бер таяныч күрәбез, ягъни VIII гасырдагы Орхон язуларында да «татар», «тата» дигән сүзләргә очрыйбыз.

Боларда «татар» сүзе – өч, «тата» яки «татаби» сүзе сигез мәртәбә тәкрарлана[4]. Һәм бер урында «огуз будун отуз татар бирлә тәрилеп кәлти»[5] диелә (мәгънәсе «огуз халкы отуз татар белән җыелып, берегеп килде» дигән сүз. Тәрилеп – тирилеп, димәкдер).

Шул ук IX гасырда язылган кытай мәнбәгъләренең кайсылары магулларның «әкә мангол», «су мангол» дип бүленеп тә, су манголларның бер елга исеме белән «татар» дип аталганлыкларын, боларның телләре, төсләре дә бертөсле булганлыгын язалар. Хәзер

[1] Бартольд. Туркестан в эпоху монгольск. нашествия. Б. 409–410. *(Авт. иск.)*

[2] Камусында – сүзлегендә.

[3] Бессарабия губернасында Аккирмән өязендә Кугиленелек суының уң ягында бер урынның хәзердә дә «Татар бунары» яки «Татар бунар» дип аталуы озак тарихларның галәмәте булса кирәк (Брокгауз – Ефрон. Шул ук җилд). *(Авт. иск.)*

[4] Тәкрарлана – кабатлана.

[5] Сборник трудов орхонской экспедиции IV. «Древне тюркские памятники в Кашо-Цайдане» (Мелиоранский белән Радловныкы). *(Авт. иск.)*

дә Том губернасында, Калинский өяздә «Тартас» исемендә бер су булганлык янә шушы язылганны куәтли[1], чөнки филология ягыннан караганда, «тартас», һич шөбһәсез, «тартар», «татар» сүзеннән алынганлык күренеп тора.

Орхон язуларындагы «отуз татарлар»дан максат – мугуллардыр[2]. Бу язудагы татарларны Радлов та Онон елгасы буенда торучы магуллар булуын уйлый. Димәк, «татар» – бик борынгы бер төрк кабиләсе. Әбүлгази[3] да түбәндәге сүзләре белән шуны ачык аңлата: «Татар иленең зикере. Аның аты кадимдә вә бу вакытта һәм мәшһүр торыр. Кадим йитмеш миң өйлек ирделәр. Күп орук[4] ирделәр. Һәркайсысы фәлән илмез тип[5] әйтерләр ирде. Һәр оруклары башка-башка бир йирдә ултырырлар ирде. Әмма яхшылары вә күбәке Хотайга якын Буюрнаур тикән йирдә ултырырлар ирде. Хотай падишаһларына итагать кылырлар, хезмәт кылырдар ирде. Гяһ-гяһ[6] Кытай бирлән яу булырлар ирде. Андак Кытай падишаһы ләшкәр (гаскәр) йибәреп, үлтертеп вә чаптыртып, такы үзегә бакынтырыр[7] ирде» (Шәҗәрәи төрк, б. 43).

Татарлар берничә төрлегә бүленеп, кара татар, ак татар, үз башлы яки вәхши татар дип аталганнар. Ягъни үзләренең мәдәни дәрәҗәләренә карап, кытайлар тарафыннан шулай аерылып йөртелгәннәр[8]. Ак татарлар Җәнүби Монголиядә Кытай коймасы (сәд-е чини) тирәләрендә яшәп, болар Кытай мәдәнияте тәэсиренә ныграк

[1] Бу су да Июган сазлыгыннан чыгып, сазлыклы урманнар арасында яткан ике увал арасыннан ага да, чүлгә, степькә килеп керә, аннан янә Иске татар авылының уң ягыннан агып, үзенең коя торган Өх елгасына кадәр бара (Брокгауз – Ефрон камусы, җилд XXXIIдә). *(Авт. иск.)*

[2] Н. Гасыйм. Төрек тарихы. Б. 119. *(Авт. иск.)*

[3] Әбүлгази Баһадир хан (1603–1664) – Хива ханы, тарихчы буларак танылу алган. Ике зур тарихи хезмәте бар: «Шәҗәрәи төрекмән» (1661) һәм «Шәҗәрәи төрк» (1852 елда Казанда басыла). Гомеренең ахырында үзбәк телендә Чыңгыз нәселе һәм Шәйбан нәселе тарихы хакында китап яза башлаган була.

[4] Орук – ыру.

[5] Тип – дип.

[6] Гяһ-гяһ – вакыты-вакыты белән.

[7] Бакынтырыр – буйсындырыр.

[8] Бартольд. «Археология җәмгыятенең язмалары» дигән мәҗмугадагы мәкаләсе. *(Авт. иск.)*

бирелгән булганнар[1]. Кара татарлар исә[2], асыл монголлар булып, хәзерге Монголиянең күп өлешен биләгәннәр. Болар – мәдәни халыкларның даими тәэсирләре астында калмаган татарлар. Мәдәни халык кешеләре бу җирләргә сәүдәгәрлек сыйфаты белән генә килеп-китеп йөргәннәр. Чыңгыз да шушы кара татарлар кабиләсеннән булган[3]. Ул Онон елгасы кырыенда кара һәм вәхши татарлар (урман татарлары, үзбашлы татарлар)ның мәмләкәтләре хөдүдендә (1155 миладида тирәләрендә) дөньяга килгән[4]. Чыңгыз ханның анасы янә «та – та» иде[5], ягъни «ак татар»дан иде[6]. Аның анасы «татар» иде[7]. Есукәй (Чыңгызның әтисе), ак татар кабиләләренә мәнсуб булып, хатынын кытай коймасы (сәд-е чини) тирәләрендә яшәүче хоңгерат (коңрат) кабиләсеннән алды. Әнә шул хатыннан Тимучин (Чыңгыз) һәм аның туганнары туды[8]. Урман татарлары һәм вәхши татарларның күбесе хәзерге Байкал арты областенда һәм Шимали һәм Гарби Монголия урманнарында сәрсәри (үз башына каңгырап йөреп) хәят кичергәннәр. (Болар арасында шаманизм үзенең бөтен сафлыгы белән сакланган. Чыңгыз хан заманында да бу тараф бу хакта беренче, ягъни классик саналган).

«Магул» сүзе үзе дә хәзерге «монгол» дип аталган халыкның борынгы үз исеме, милли исеме булмаган, бәлки аны соңыннан үз халкы өчен Чыңгыз үзләштергән. Соңыннан Чыңгыз император булып (1206 миладида) Тимучиннан Чыңгызга әйләнгәч, ул шушы «магул» дигән исемне Урта Азиядәге бөтен магулларга гомуми бер исем итеп гомумиләштереп җибәргән. Шуныңча[9] магуллар һаман татар

[1] Боларны Бартольд «Археология җәмгыятенең язмалары» мәҗмугасындагы мәкаләсендә «Өнкөтләү» дип тә йөртә. Б. 113. Бу турыда янә Әбүлгазиның «Шәҗәрәи тӛрк»ендә 14–18 нче битләргә күз ташлансын. *(Авт. иск.)*

[2] Бартольд «Археология җәмгыятенең язмалары» мәҗмугасында (б. 198, җ. 10) найманнар белән караитларны кара татарларның көчле ыругларыннан саный. *(Авт. иск.)*

[3] Кытайларча бу – шулай. Әмма монгол риваятьләренчә, Чыңгыз тайҗут кабиләсенә мәнсуб кыят (кыют) кабиләсеннәндер. Тайҗут исә – урман кабиләләреннән берсе. *(Авт. иск.)*

[4] Бартольд. Археология җәмгыятенең язмалары. Җ. 10, б. 109. *(Авт. иск.)*

[5] Большая энциклопедия. Татар маддәсе. *(Авт. иск.)*

[6] Самойлович. Западный Туркестан. (Б. 112). Һәм Бартольдның «Туркестан в эпоху монгольск. нашествия»се. Б. 410. *(Авт. иск.)*

[7] Брокгауз – Ефрон. Төрк-татар маддәсендә. Җ. XXXIV. *(Авт. иск.)*

[8] Бартольд. Югарыдагы мәкаләсе. Б. 109. Бартольд үзе Рәшидеддиннән файдаланган. *(Авт. иск.)*

[9] Шуныңча – шуңа кадәр.

дип йөртелгәннәр. Шуның белән бергә Чыңгыз фөтухатыннан[1] соң, Урта Азиядәге бөтен төрк кабиләләре дә шушы сәяси гомуми исем астына кереп, шуның белән аталып китәләр. Ягъни магуллар яки татар-магуллар диеләләр.

Моның болай булуы да магул кабиләсенең үз туганнары татарларга вә башка төрк ыругларына караганда көчлерәк, гайрәтлерәк булып чыгуыннан булган булса кирәк. Әбүлгази да үзенең «Шәҗәрәи төрк»ендә: «Ул төрк илләрендә магулның тире үтмәгән[2] вә кулы йитмәгән ил юк ирде. Бу сәбәптән барча илләр магулны көниләп: «Аһ, синеме!?» диләр ирделәр» (30 б.). Янә татарның магулга өстен килгәнен (31 б.) сөйли дә, аннан соң тагы магулның татарга катгый рәвештә галәбәсен[3] бәянга керешеп: «Татар берлән магул икесе саф тартып орыштылар. Магул, галиб килеп, олугларын кылычдин үткәреп, кечекләрен бәндә кылды. Түрт йөз әллик (дүрт йөз илле) ел булганда, каныны вә малыны алды. Таки ата йортыда үлтерде, ул йирдә ултырган төрк халкының ыругларының эчендә татардин күбе вә тугушлысы[4] булмас ирде. «Әргәнә кун»дин чыкып, татарны кырып, ата йортыда ултыргандин соң, магул татар йиренә, барча илләргә баш булды, бәгъзе илләр магулны магулга бә-нам килтереп[5], магул булмасалар, һәм магулмыз тип, үзләрене магулга куштылар» (34 б.), – дидер. Әбүлгазиның шушы сүзләре дә бу хакта мәсьәләне ачышуга байтак ярдәм итә ала. Ягъни магул яки магул-татар исеменең соңыннан ничөн бөтен Урта Азиядәге төрк ыругларына гомуми исем булып китүенең бер сәбәбен ача барадыр. (Әбүлгази сүзләрендә тыныш билгеләре безнең тарафтан куелды).

Кытай хөкүмәте элекке заманда үзе өчен куркынычлы булган бер күчмә халыкны икенче күчмә халыкка каршы коралландырып, сугыштырып килгән. Шундый сугыш тәмам булгач ук, үзенең иттифакчысына каршы янә шушы чараны күрә торган булган.

Бу турыда мәсьәләнең чын тарихи ягы менә шулай була: XII гасырның яртысында Шимали Кытайда патшалык сөргән Маньчжур сөляләсе Цзинь (Шимали Кытайда хакимлек сөргән) мангу (яки мәнгү) дада кабиләсе белән, ягъни магуллар белән сугыш кыла.

[1] Фөтухатыннан – яулап алуыннан.
[2] Тире үтмәгән – угы үтмәгән.
[3] Галәбәсен – өстенлеген.
[4] Тугушлысы – сугышчанрагы.
[5] Бә-нам килтереп – атап.

1147 миладида Цзинь императоры магул падишаһы Аоло – Боцзило[1] белән солых кыла[2]. Бу магул сөяләсе үзе 1161 миладигача дәвам иткән дип исәпләнә. Шул вакытларда Цзинь императоры мангу дада өстенә һөҗүмгә килүе хакында манифест чыгара. Моннан соң тиз үк магуллар кардәшләре булган татарлар (һәр ихтималга күрә, боернур татарлары) тарафыннан талана, туздырылалар. Шушы гасырның соңында Кытай хөкүмәте әлеге каршы[3] кирәет һәм магулларны коралландыра.

Менә шушы сугышлар вакытында беренче мәртәбә буларак үзенең сахра аристократиясеннән җыйнаган дружиналары белән Чыңгыз күтәрелеп мәйданга чыга. (Бу вакытта Шәркый Магулстанда беренче дәрәҗәдә кирәет ханы танылган була.) Бу дружиналар үзләренең башлыклары Тимучинны каган дип игълан кылалар[4]. Тимучин да үзенә кирәет ханы Ван ханның ризалыгы белән каганлык гонванын кабул итә. Шуннан соң ул Хутула ханнан[5] соң Монголиянең үзендә үк беткән, югалган магул ыругының атыны яңадан китереп чыгарып, шуны яңадан торгыза вә аны тәмам гомумиләштереп җибәрә. Мән-хуна[6] ның хәбәренә күрә, Чыңгыз хан заманында «магул» сүзе магулларның үзләренә һич мәгълүм булмаган, ул фәкать рәсми бер атама – истилях кына булган. Юань сөяләсенең рәсми язуларында да әле магуллар һәм алар белән катышкан халыклар Кытайда – магул дип, Монголиядә дада (татар) дип аталганнар.

Тимучин (Чыңгыз) үз халкы өчен шушы магул исемен алып, шуның белән ул үзен Хутула каганның хәләфе (приемнигы[7]) дип

---

[1] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*

[2] Бу исемне Бартольд «Хутула каган» дигән исемнең үзгәртелгәне булыр, ди. *(Авт. иск.)*

[3] Каршы – *биредә:* татарларга каршы.

[4] Тимучин, шулай итеп, тәхеткә сахра аристократлары тарафыннан утыртыла. Әмма татар-магуллар эченнән ярлы халык, Җамука тирәсенә җыелып, Тимучинга (Чыңгызга) каршы торалар. Җамука үзе җайрат кабиләсенең башлыгы була. Бу җегет үзенә кара кытайлылар ләкабе булган «Гүр хан» ләкабен тага. Аның тирәсенә Чыңгызга да, кирәет ханнарына да буй сонарга теләмәгән бөтен ярлы кабиләләр – улуслар җыела (1201). Ул шулай итеп, магул-татарларда демократия хәрәкәте башында торып, аларга юлбашчылык итә. Ләкин Чыңгыз соңыннан бу халыкчылык, ягъни демократия хәрәкәтен бастыра (Бартольд). *(Авт. иск.)*

[5] Хутула хан (1111–1161) – XII гасыр уртасында эре ыруглар берләшмәсе юлбашчысы булган монгол хакиме.

[6] Мән-Хуна – 1221 елда Сөн сөяләсе патшасының Җәнүби Кытайда җүрҗеннәргә каршы монголлар белән иттифак ясамак өчен җибәргән вәкиле (Бартольд, б. 38). *(Авт. иск.)*

[7] *Кирилл хәрефләре белән язылган.*

игълан кылган була. Хәтта ул шушы хан белән үзен (ләкин бу хәбәр әсассыз бер ихтимал санала) кардәш дип тә дәгъва кылган була[1].

Хасил XII вә XIII гасырларда татар-магул вә хосусан татар дигән сүз Урта Азия белән Шәркый Европаны тар-мар китерүче бөтен магул, төрк һәм башка ыругларның һәммәсен үз эченә җыючы бер атама булып китә. Безгә тарихтан мәгълүм: Чыңгызның өлкән улы булган Җуҗи баласы Бату командасы астында татар-магуллар Гаребтә асыл төрк җенесеннән ике төрле халыкның өстенә килеп, аларны үзләренә караталар, аларның дәүләтләрен юк кылып, шуларның урынына үз хакимиятләрен урынлаштыралар.

Бу төрк җенесеннән булган ике халыкның берсе хәзәрләр – кыпчаклар (яки команнар, половецлар)[2] булса, икенчесе дә болгарлар иде[3]. Магул-татарлар менә шушы төрк халыкларын да үз кул астларына алып, үзләренә багындырганнан соң, «татар» исеме Идел-Урал буендагы төрк ыругларына да тагылып, алар да шушы гомуми исем белән аталып китәләр. Гәрчә күптән бирле мөселманлыкны кабул итеп, шаманлыктан аерылган кыпчаклар һәм болгарлар әле мәҗүси, ягъни шаман динендә булган татар-магулларга начар карап, һаман үзләрен «татар» димичә «төрк», телләрен дә «татар теле» димичә «төрк теле» дисәләр дә, тарих вә сәясәттә һаман татар-магул исеме астында дәвам итәләр (шуның белән бергә татар-магуллар үзләре дә сизмәстән шундагы мәдәнияттә үзләреннән өстенрәк булган төркләрнең тәэсире астында тел ягыннан да, гореф-гадәт ягыннан тәмам төркләшәләр. Сәясәттә галиб булган халык, шулай итеп, мәдәнияттә

[1] Бартольд. Туркестан в эпоху монгольского нашествия. Б. 410–430 (Петербург басмасы, 1900 да басылган). *(Авт. иск.)*

[2] Боларның яшәгән урыннары җәнүб ягыннан – Кавказ таулары, гаребтә – Азов диңгезе һәм Днепр елгасы, шималь ягыннан – Болгар дәүләте, ягъни Идел буе болгарлары, шәрык ягыннан башкорт һәм башка күчмә халыкларның җирләре булган. Бу халык, ягъни хәзәр төркләре элек Хәзәр диңгезенең гареб ягында Сәмәндәр шәһәрендә (хәзерге Тарик елгасы тирәсе) җыелган булганнар. Соңрак инде, сугышчы гарәпләрдән имин булу өчен, шимальгә Итил (Волга тамагында) шәһәренә, хәзерге Әстерхан тирәсенә күчкәннәр. Болар мөселманлыкны 737 дә кабул итәләр. *(Авт. иск.)*

[3] Болгарлар – хәзәрләрдән соңрак, ягъни II миладида мәгълүм булган бер халык. Болар төрк-фин нәселеннән. Болар да – хәзәрләр кебек мәдәни төрк җәмгыятьләреннән берсе. Бу төрк дәүләте Иделнең урта агымында, Кама белән Самара суы арасында төзелгән булган. Бу дәүләтнең пайтәхете дә Иделнең сул кырыена салынган Болгар шәһәре була. Болгарлар ислам динен болгар ханы башында булган хәлдә 310 һиҗридә, 922 миладида рәсмән кабул китәләр. Шуннан игътибарән мөселман төрк дәүләте төзиләр. *(Авт. иск.)*

мәгълүб була. Ниһаять, шуның өстенә монда болар ислам динен дә кабул итүгә мәҗбүр булалар).

Соңыннан Урта Азиядәге халыклар этнографик яктан тикшерелеп, бер-берсеннән аерылып танылганлыктан, шуның нәтиҗәсендә «татар» сүзе төрк ыругыннан фәкать Гарби Себердә, Кавказда, күбрәк өлеше дә яурупаи Русиядә яшәп, төрк телләренең төрле шивәләрендә сөйләшүче һәм кыргыз, казакъ, үзбәк, төрекмән, башкорт кебек үзләренә аерым бер исем ала алмаучы бөтен халыкларга исем булып кала. Моңа да Себер татарлары, Алтай татарлары (телеутлар, ак калмыклар, катун чулымнар, шорлар, кара татарлар – урманлыклар, команнар, абаканнар), Кавказ татарлары[1], нугайлар, Кырым татарлары, Әстерхан татарлары, башкортлар арасындагы типтәр татарлары, мишәрләр, ниһаять, Казан татарлары, ягъни иң тар мәгънәсе белән булган татарлар керә. Болар, ягъни Казан татарлары – кыпчак вә Алтын Урдада дәүләт торгызучыларның хәләфләре. Болар – кыпчак, фин, болгар, үзбәк, башкорт ыругларыннан катыш бер халык.

Менә, татар-магуллардан башлап хәзерге татарларга килгәнче, татарларның этнографи вә сәяси тарихлары шулай.

Инде киләбез менә шушы татар-магулларның иң борынгы әлифбаларына. Татар-магуллар Чыңгыз ханга кадәр язуга малик булмаганнар[2], хәтта, Җүвәйни[3] сүзенчә, татарларның үз әлифбалары булмаган да[4].

Болар язуны уйгурлардан алганнар, гомумән, Чыңгыз хан кул астына тупланган магуллар хәтта үзләренең ыругдашлары булган кирәет һәм найманнар белән чагыштырганда да мәдәнияттә иң түбән бер дәрәҗәдә булганнар.

Шунлыктан магуллар, Монголияне берләштергәннән соң ук, әле мәдәни мәмләкәтләрне фәтех иткәнчегә кадәр, бик тизлек белән үз кул асларына кергән халыклардан үзләренә мәдәни кирәкләрне алырга тиеш тапканнар.

Чыңгыз ханның сараенда (әле 1203 елгача) иң беренче мәдәният вәкилләре мөселман сәүдәгәрләре, ягъни ислам мәмләкәтләреннән

[1] Болар, ягъни Кавказ татарлары, борынгы бәҗәнәкләр, аварлар, аланнар, нугайлар белән катышкан хәзәрләр, кыпчаклар һәм иранлыларның калдыклары, Иран тибындагы азәрбайҗаннар белән Дагстандагы комыклар һәм шулар җөмләсеннән. *(Авт. иск.)*

[2] Бартольд. Туркестан в эпоху монгольского нашествия. Б. 42. *(Авт. иск.)*

[3] Җүвәйни – XIII гасыр фарсы тарихчысы.

[4] Бартольд. Югарыдагы әсәре. Б. 416–417. *(Авт. иск.)*

килүче сәүдәгәрләр була. Чыңгыз дәүләтендә әле эшләүне язу аркылы йөретү иртә башлап китә калмый. Бу эш ялгыз аның найманнарны үзенә буйсындырганнан соң гына була. Найман ханының печатен саклаучы уйгур Ташатун (яки Ташатангун) Чыңгыз хан сараенда шундый ук мәэмүриятене (ягъни печатьне саклаучылык – нәдимлек мәэмүриятен) ала. Шуның өстенә тагы аңа ханның (Чыңгызның) балаларына уйгур язуын өйрәтү вазифасы тапшырыла.

Моның сәбәбе дә, бердән, Чыңгызның «Яса» дигән канунын, ягъни магулларның горефе-гадәте, хокукларын төзү өчен имкян табарга тырышу булган. Икенчедән, үзенең идарә вә канцелярия эшләрен җиңеләйтү, тәртипләндерү. Өченчедән, күршеләрендәге мәдәни халыклардан мәдәнияттә калышмаска тырышу һәм үзләренең кул астына кергән вә үзләре белән күрше булган мәдәни халыклар белән хәбәрләшү эшләрен җиңелләштерү теләге булган.

Хакыйкатән, уйгур язуын кабул итүнең беренче нәтиҗәсе дә магулларның гадәти хокук кануннарын («Яса»ны) кодификация ясау, ягъни мәгълүм бер системга кую булган. Бу хокукый кануннар да Чыңгызның хикмәтләре (ягъни «белег»е) белән бергә күп заманнаргача магул ханнары өчен иң югары дәрәҗәдә авторитетлы бер нәрсә булып килә[1].

Уйгур язуын магуллардан иң элек өйрәнеп алучы кеше дә Чыңгызның якыннарыннан Шики-Хутуху нойон булган. Бу үзе – нәсел ягыннан татар.

Ул әле яшь вакытыннан ук Чыңгыз ханның хатыны тарафыннан угыллыкка алынган булган. Чыңгыз хан бу кешегә хөкем-суд эшләрен тапшырган[2].

Шулай итеп, ниһаять, уйгур әлифбасы күчмә тормыш белән гаклый мәдәниятне бергә җыйнарга тырышучы Чыңгыз тарафыннан бөтен татар магулларның әлифбасы итеп тәмам рәсмән кабул ителә, һәм шул әлифба болар арасында хөкем сөреп китә. Магулларның беренче мәдәни мөгаллимнәре булган уйгурлар да магул дәүләтендә иң беренче эш йөртүчеләр, язу эшләрен башкаручылар булып калалар (фәкать магул-татарлар, уйгурларның моннан башка күзгә күренерлек тәэсирләренә бирелмәгән кебек, башка ислам, настори, будда миссионерларының дини тәгълиматларына да җиңелмәгәннәр. Үзләренең шаманлыкларында күп заманнар нык торганнар).

[1] Бартольд. Туркестан в эпоху монгольского нашествия. Б. 416–420. *(Авт. иск.)*
[2] Бартольд. Югарыдагы әсәре. Б. 420. *(Авт. иск.)*

Чыңгыз уйгурларның язуларын гына түгел, хәтта уйгур телен үзен дә дәүләтнең рәсми бер теле итеп ала. Уйгур язуын Чыңгыз үзенең рәсми язуы, уйгур телен дә үзенең рәсми теле итүе 1204 елда була. Әлифбадан башка магуллар тагы уйгурлардан яңа аңнар һәм шулар белән бергә сүзләр дә алдылар. Магулларның буддилыкка даир күп истиляхлары[1], кирәк язуларында, кирәк телләренең хәзинәсендәгеләре булсын, уйгур токымыннандыр[2].

Чан-чүә[3] исемле Кытай сәяхының сүзенә күрә, Чыңгыз фәрманнарын, хатларын вә хәтта көндәлек хатирәләрен дә уйгур язуы белән язган. Уку-язуга өйрәнүдә, сәвад чыгару[4] эшләрендә дә шул кулланылган. Шул ук дәвердә магуллар тарафыннан аларның халык риваятьләренең мәҗмугалары төзелгән, җырлары, мәкальләре һәм каһарманлык хатирәләре язылган булуын да исәпләргә юл бар. Киресенчә булганда, магулларның 1240 елда «Юан-чао-ми-ши»нең[5] үзе аркылы танылган вакаигънамәсе дә языла алмаган булыр иде[6].

Магуллар, кытайлардан алган рәсми гадәтләре буенча, ханнарның хикмәтле сүзләрен яза һәм, алар үлгәннән соң, шуларны нәшер итә булганнар (ләкин болар ханның рөхсәте белән генә язылганнар). Бу вакытта янә ханнарның сүзләрен тезмә рәвешенә яки һич булмаса сиҗыглы чәчмә[7] рәвешенә куярга тырышканнар. Бу хикмәтле сүзләрдә төрк сүзе белән «билик» дип аталган Чыңгыз ханның хикмәтле сүзләре татар-магуллар өчен хәтта дәрес маддәсе ителгән[8].

Чыңгыз хан гаиләсеннән әүвәлге дүрт хан дәверендә уйгур-магул язуы Чыңгыз балаларының гаять киң вә зур булган бөтен мәмләкәтләренә таралды. Бу хакта янә Иранда Һулакуга[9] мәнсуб ханнарның шул ук уйгур-магул язуы белән француз короле Дүртенче Филиппка язган мәктүбләре шаһид була ала.

Алтын Урдада магул-уйгур әлифбасы һәм язуы кулланылган булуны Алтын Урда ханы Габдулла ханның 1848 елда Екатеринбург

[1] Истиляхлары – төшенчәләре.
[2] А. Панов. К истории народов Средн. Азии. *(Авт. иск.)*
[3] Биредә сүз Чан-чунь исемле кытай монахы турында бара булса кирәк. Чан-чунь Чыңгызхан хозурына 1218 елда бара һәм шул хакта үзенең истәлекләрен язып калдыра.
[4] Сәвад чыгару – язу.
[5] Биредә сүз монголларның «Юань-чао би-ши» («Монголларның яшерен тарихы») дип аталган безгә мәгълүм беренче әдәби-тарихи ядкәре турында бара булса кирәк.
[6] Брокгауз – Ефрон камусы. Монгол маддәсендә *(бүлегендә)*. *(Авт. иск.)*
[7] Сиҗыглы чәчмә – рифмалы проза.
[8] Бартольд. Туркестан в эпоху монгольского нашествия. *(Авт. иск.)*
[9] Һулагу хан (1217–1265) – Чыңгыз ханның оныгы, монгол ханы.

вилаятендә һәм башка җирләрдә табылган хатирәсе күрсәтеп тора. Уйгур язуы Чыңгыз мәмләкәтендә рәсми бер язу гына түгел, бәлки әдәбият язуы да иде. Фарсыча «Бәхтиярнамә» исемендәге романның Һулаку дәверендә магул теленә тәрҗемәсе Оксфорд көтепханәсендә саклана[1].

Хәтта 1379 миладида әле уйгур язуыныннан әмир Тимер (Аксак) үзенең Днепр ярлары тирәсендәге язулары өчен файдалана иде[2].

Уйгур әлифбасы исламиятнең таралуыннан соң да, һиҗри белән IX гасыргача кулланылуда дәвам иткән. Хәтта «хатты дивани» дигәнебез дә – Тимер заманында уйгурчага тәкълид белән тудырылган бер рәсми хат. Тимердән соң әллә ничаклы заманнар уйгур язуы Һиратта вә башка төрк мәмләкәтләрендә кулланылганлыгын Вамбериның[3] Истанбулдан алып китергән «Котадгу белег» белән Айя-София көтепханәсендә булынган башка бер мәнзуманың шул ук тарихта күчерелеп язылган булуы исбат итә. Кирәк шул ике әсәргә, кирәк Парижда Паве де Куртей[4] кул астында бастырылган «Мигъраҗнамә»нең Истанбулдан китерелгән булуына каралса, Истанбул фәтех ителүдән соңгы заманнаргача госманлылар эчендә дә уйгур язуын аңлаган кешеләр булу белән хөкем итә алабыз[5].

Уйгур-магул язуының хатирәләреннән мәгълүм булган иң иске язу – Нерчинский округ әтрафында табылып та, Фәннәр академиясенең Азия музәханәсендә сакланмакта булган һәм дә Чыңгыз ташы дип аталган таштагы язудыр. Ләкин бу язуның гыйбарәсе әле тәмам укылмаган[6].

Татар-магуллар үзләре өчен уйгур әлифбасыннан башка тагы яңа бер әлифба ихтираг кылдырганнар[7]. Моны да Чыңгызның төп йортында ханлык итүче һәм бөтен Кытай, Һинд мәмләкәтләрен үзенә кушучы Кублай ханның[8] соравы буенча, Будда галимнәреннән Бакбала дигән кеше ихтираг иткән, ягъни эшләп чыгарган була.

[1] Брокгауз – Ефрон камусы, монгол маддәсе һәм «татар әдәбияты тарихы». Җ. 1, бүлек 2, б. 63. *(Авт. иск.)*

[2] История человечества. Җ. 2. *(Авт. иск.)*

[3] Вамбери – Арминий Вамбери яки Герман Бамберге (1832–1913), венгр ориенталисты, сәяхәтче, полиглот.

[4] Паве де Куртей – Паве де Куртейль Абдель-Жан-Батист (1821–1889), француз ориенталисты, төрек теле укытучысы.

[5] Н. Гасыйм «Төрек тарихы». *(Авт. иск.)*

[6] Брокгауз – Ефрон камусы. Монгол маддәсендә. *(Авт. иск.)*

[7] Ихтираг кылдырганнар – төзеткәннәр.

[8] Хубилай хан (1215–1294) – Чыңгызханның оныгы, Юань монгол дәүләтенә нигез салучы. Марко Поло язмаларына «Кублай-хан» исеме белән кергән.

| Хәзерге | Урта йөздәге | Классик | Борынгы | Иң борынгы | |
|---|---|---|---|---|---|
| Итальянча<br>Испаньолча<br>Французча<br>Инглизчә<br>Немецчә<br>Голландиячә<br>Шведча<br>Данча<br>Славянча<br>(катол[ик]) | Унциал<br>Латинча<br>Рун | Этрус<br>Латин<br>Умбри<br>Ускыяс | Борынгы Италия әлифбасы | Юнан әлифбасы | Яһүд-финикә әлифбасы |
| Русча<br>Болгарча<br>Сербча | Кириллица | Юнанча | Борынгы юнан әлифбасы | | |
| Глаголица<br>Албан | Юнанча курсив язу<br>Копт язуы | | | | |
| Немецча курсив | | Раши | Дүрткел яһүди | Арами әлифбасы | |
| Магул<br>Калмак<br>Манжур | Уйгур әлифбасы<br>Мәлхит<br>Настури<br>Якуби<br>Манди | Сатринҗил<br>Хауран | Пальмир | | |
| Гарәп<br>Төрек<br>Фарсы | Күфи<br>Нәсхи | Нәбатый | | | |
| Әрмән<br>Грузин | | Пәһләви<br>Зәнд | Иран<br>Бактри | | |
| Амгар | Хәбәши | Химьяр | Саби | Көньяк сами әлифбасы | |
| Сиам<br>Яван<br>Сәйлүн<br>Корея | Пали | | Сәфәви | | |
| Тибет<br>Гуҗари<br>Кәшмир<br>Бенгал<br>Малай<br>Канари | Диваны гари | | Асукый | | |

Бөтен дөнья әлифбаларының тамыр-нәселләрен күрсәтүче җәдвәл (бу җәдвәл Шницердан гайнән[1] алына).

[1] Гайнән – үзгәртелмичә.

Үзе уйгурчадан шәбрәк һәм мөкәммәлрәк булып эшләнә. Бу инде тәмам магулларның үзләренә махсус булган бер магул әлифбасы рәвешен ала. Үзе «дүрткел[1] әлифба» дип атала. Ләкин бу яңа әлифбаның Чыңгыз кабул иткән уйгур язуыннан аермасы һәм андый бер яңа әлифба тудыруның сәбәпләре мәгълүм түгел (Чыгтай, Бәркә вә Үзбәк ханнар ислам тәэсирендә иделәр. Кублай ул тәэсиргә бирелмәгән. Ләкин һәрхәлдә Кытай вә будда нөфүзеннән[2] читкә китә алмаган. Бу хан, һәрхәлдә, терек вакытында үз телен, үз язуын, үз горефен саклау юлында каты тәгассыб[3] һәм нык каршылык күрсәткән. Бакбаладан яңа бер әлифба тудыртуы да шундый бер магуллык тәгассыбы нәтиҗәсе түгелме икән, дигән бер фикер башка килә).

Бу әлифбаның халык арасында күпме таралуы һәм аның нинди хатирәләре булуы турысында мәгълүмат юк.

## Төрк халыкларында гарәп әлифбасы

Милади белән VII гасырда бөтен Урта Азиядә һәм Шәркый Яурупада хакимият сөргән төрк халыкларының (гарби һәм шәркый төркләрнең) VIII миладида гарәпләр белән мөнәсәбәтләре башлана. Гарәпләр, бер яктан Хәзәр диңгезенең гареб тарафыннан хәзәр, гуз-кыпчак төркләренә һөҗүм итсәләр, икенче яктан аның шәркыйҗәнүби ягыннан Иран аркылы Хорасан вә Мавәраэннәһергә (Сырдарья белән Амудәрья арасындагы мәмләкәткә) һөҗүм итәләр. Тукю төркләре белән бик каты сугышлары була. Ахырда гарәпләр өстен чыгалар. Бөтен Мавәраэннәһерне кулларына алалар. Хәзәр диңгезенең шималь якларындагы вә Сырдәрья тамакларындагы төркләр – гузлар-кыпчаклар аларның тәэсирләре астында калалар. Иделнең урта агымындагы болгар төркләре белән дә сәүдә мөнәсәбәтләре, дини вә мәдәни тәэсирләре башлана. Ниһаять, Сырдәрья тамагыннан бөтен шималь ягы белән (Шаш, ягъни хәзерге Ташкент та шуның эченә керә) аның башына таба килеп, төркләрнең бу якта Карадәрья елгасы кырыендагы Үзгәнд дигән шәһәренәчә булган җирләр гарәпләр – исламнар кулына керә. Сырдәрья елгасы да инде төрк халыкларының мәмләкәтләре белән ислам мәмләкәте арасындагы табигый бер чик булып кала[4]. Шул чик эче белән хәтта

[1] Дүрткел – шакмак.
[2] Нөфүзеннән – йогынтысыннан.
[3] Тәгассыб – үтә бирелгәнлек, фанатизм.
[4] Вәһия нәһрен кәбирен яфассалү бәянә билад ит-төрек вә билад ил-ислам (Тарих әл-камил. Ли Ибн әл-Әсир, җөзе 12, б. 149). *(Авт. иск.)*

Кашгаргача Фирганә вә бөтен Шәркый Төркестанга гарәпләр ислам тәэсирен нык урынлаштыра алалар. Сигезенче миладида гарәпләрнең, гомумән, бөтен Урта Азия халыклары белән сәүдә мөнәсәбәтләре башланып китә. Хәтта елына өч мәртәбә Енисейның югары якларына кыргызларның пайтәхетләренәчә кәрваннар катный[1]. Бу кәрваннар да карлук төркләренең җирләреннән үтәләр[2].

Менә шул рәвешчә гарәп баскынчылыгы (истилясы) гарәпнең дине вә аның Коръәне белән бергә гарәп әлифбасы да төркләр арасына килеп керә башлый. Милади X–XI гасырларда инде төрк халыкларының күбесендә гарәп әлифбасы йөреп китә. Гәрчә бер яктан уйгур әлифбасы, уйгур язуы дәвам итсә дә, гарәп әлифбасы аны һаман нык кысрыклый бара.

Безгә тарихтан мәгълүм: болгарлар милади X гасыр башларында (310 һ. – 922 м. да) рәсмән ислам динен кабул итәләр. Дин белән бергә гарәп әлифбасы да кабул ителә (ләкин гарәпләрнең дини тәэсирләре элек башланган). Димәк, моннан боларда гарәп теле вә әлифбасы X миладта тәмам йөреп киткән икән дип уйлый алабыз. Әмма болгарларда элек нинди язу гамәлдә булган да, гарәп язуы монда үзе белән кайсы язуны гамәлдән чыгарган – бу мәсьәлә безгә караңгы.

Гомумән, болгарларның гарәп язуын кабул итүләреннән элек язулары булганмы, юкмы мәсьәләсе – үзе моңынча чишелми килгән бер мәсьәлә. Гарәп тарихчылары да бу турыда бер нәрсә дә бирә алмыйлар.

Болгар төркләре гарәп әлифбасының күфи һәм нәсех хатлары белән язганнар[3]. XIII–XIV гасырның башында утыртылган кабер ташларының күбесе – күфи язуы белән, бәгъзесе дә сөлес белән язылган булган[4].

VIII гасырның беренче – икенче ярымында Җидесуда беренчелекне алып, үз хакимиятләрен корган карлук төркләре исә – гарәп тәэсиренә иң иртә һәм иң нык бирелүчеләрнең берсе иде. Төрк халыклары эчендә иң күп мөселман мәдәнияте тәэсире астында

[1] Катный – *биредә:* барып җитә мәгънәсендә.
[2] Самойлович. Западн. Туркестан. *(Авт. иск.)*
[3] З. Вәлиди. Төрк-татар тарихы. Б. 83. Мәрҗанинең «Мөстәфадел-әхбар»е. Ж. 1. Б. 12–13. *(Авт. иск.)*
[4] «Болгар тарихы» – Гайнетдин Әхмәров. «Мөстәфадел-әхбар» – Шиһабетдин Мәрҗани. *(Авт. иск.)*

калучылар да шулар. X миладида инде Талас (хәзерге Әүлия ата) шәһәрендә боларның берничә зур мәчетләре булган.

Менә боларда да, әлбәттә, иң кимендә IX–X гасырда ук гарәп әлифбасы йөри башлаган булса кирәк.

X гасырдагы караханилар яки илханилар – янә күптән ислам тәэсире астында калучылар иде.

Милади XI гасырның соңында Шәркый Төркестан вә уйгур төркләре инде исламга кереп беткән булалар. Ханнары да инде тәмам динле була. Ялгыз шәркый шималида татар һәм Кытай төркләре генә әле мөселманлыкны кабул итмиләр[1]. Шулар белән бергә тагы, татарлар кебек, Сырдәрьяның түбән агымында шушы елганың тамагына якын угыз җирләрендә XI миладида үз хакимиятләрен торгызган кыпчаклар гына (коман-половецлар) XII гасырның соңнарынача исламны кабул итми торалар[2]. Соңыннан болар да шуның нык тәэсире астында калалар.

Менә шушы тарихи фактлардан гомуми бер нәтиҗә чыгарганда, XII миладида төрк халыклары арасында гарәп әлифбасы тәмам кереп урынлашкан вә төркләрнең үз язуларыннан өстен бер хокукка ия булып алган буладыр. Уйгур язуының, гарәпкә юл куймыйча тартышып, XV гасыргача дәвам итеп килүе, һәрхәлдә, гарәп язуының ниһаять бөтен төрк халкында хаким булып алуына манигъ[3] була алмады.

Магул-татарлар булмаса, бәлки, уйгур язуы гарәп язуы алдында тиз җиңелгән дә булыр иде. Чыңгызның ул язуны үз мәмләкәте өчен рәсми бер язу итеп алуы, аның мәмләкәтендә шул язуның дәүләт язуы булып кулланып китүе, әлбәттә, уйгур язуының гомерен озынайтты. Шуның өчен ул Чыңгыз балалары вә аларның балалары кулында һаман гарәп язуына комачаулап килде. Хәтта Алтын Урда да мөселманлыкны рәсмән кабул итүче Бүркә хан[4] заманында һәм дә XIII гасырның дүртенче чирегендә ханлык итүче Тәдан Мәнгү[5] вакытында да мәмләкәтнең рәсми теле уйгурча булган кебек, язу да уйгур язуы иде. Хәтта XIV гасырда Тимер заманында бу язу әле

[1] Тарих әл-камил. Ли Ибн әл-Әсир. Җөзе 9, б. 194. *(Авт. иск.)*

[2] Брокгауз вә Ефрон. XXXIV җилд. Төркестан маддәсенә кара. Бартольд мәкаләсе *(Авт. иск.)*

[3] Манигъ – киртә.

[4] Бәркә хан (1209–1266) – Чыңгызханның оныгы, 1257–1266 елларда Алтын Урда ханы.

[5] Тәдан Мәнгү (Туда Мәнгү) – 1282–1287 елларда Алтын Урда ханы.

гамәлдә булган. Фәкать бу да, гарәп язуын кулланмыйча, ялгыз шул уйгурчаның үзен генә куллану мәгънәсе белән түгел, бәлки гарәп язуы белән бәрабәр дәвам итеп килү мәгънәсе беләндер.

Гарәп әлифбасы төркләр тарафыннан бөтене белән кабул ителде. Фәкать шуларга «گ، چ، ژ، ڭ» хәрефләре арттырылды. Төрк телләрендә гарәпнең «ث، ذ، ض، ظ، ح، ع، ط، ص» авазлары булмауга карамастан, һаман шушы хәрефләрне дә төрк телләрендә кулланып килделәр. Дөрес болар күбрәк гарәптән кергән сүзләрне язу өчен кулланылдылар. Шуның белән бергә төрк сүзләре дә һаман шулар белән языла бирде. Гарәпнең «әлиф», «йа», «вау»дан гыйбарәт өч сузык хәрефе төрк телләрендәге бөтен сузык авазларны язуга җитмәсә дә, шул ук XX гасыргача шушы өч сузык хәреф белән язып килдек.

Госманлы төркләре, чыгтай, үзбәкләр, татарлар, төрекмән вә казакълар – һәммәсе шулай яздылар. Госманлы төркләре әле һаман шул юл белән бaралар.

Ләкин татар галәмендә XIX гасырның ахырында Каюм Насыйри[1] татар теле өчен гарәп хәрефе җитешмәгәнлекне ача. Татарчада ун төрле сузык аваз күреп, шул ук гарәп хәрефләренә галәмәтләр арттырып, шуларның сигезенә сигез төрле галәмәт ясый. Алар шулар: а – арба, ә – әтәч, э – эт (калын һәм нечкә булып, Каюм моңа фәкать бертөрле галәмәт ала), у – ул, ү – үпкә, үрдәк, о – орлык, ком, ө – өч, өзмәк, и/ый – бирми, килми, сыйлаган, тыйган (бу да калын һәм нечкә булып, икесенә бер галәмәт).

Ләкин Каюм Насыйриның язуда кертергә теләгән бу яңалыгы үзе исән вакытта кабул ителми. Госманлы төркләреннән Шәмсетдин Сами да үзенең XX гасыр башларында бастырылган «Камусы төрки»сендә, сузык авазларны ун итеп билгеләп, шуларга менә шушы галәмәтләрне куя: و (вавы мәкъбузаи сәкыйлә – «u») – bu, şu; ۆ (вавы мәбсутаи сәкыйлә – «o») – yol, zor; ۏ (вавы мәкъбузаи хәфифә – «ü») – düz, süz; ۋ (вавы мәбсутаи хәфифә – «ö») – göz, söz; هٰ (фәтхәи сәкыйлә – «a») – ara, dahi; یِ (кәсрәи сәкыйлә) – sıra, katı.

Аның шушы алты галәмәте өстенә ی , ه , آ галәмәтләрен дә кушсак, бу тел вә лөгать мөтәхассыйсының[2] төрк телләре өчен тугыз

[1] Габделкаюм Габденнасыйр углы Насыйри (1825–1902) – мәгърифәтче, тел галиме, язучы, тарихчы, этнограф.

[2] Мөтәхассыйсының – белгеченең.

сузык аваз галәмәте куярга мәел күрсәткәнен[1] вә шуны үзенең лөгатендә гамәлгә куйганын күрәбез.

Татарларда 1899 елның май аенда Уфада тел, имля вә мәгариф мәсьәләләрендә бер зур җәмгыять ясалса да, бу җәмгыять имля вә хәрефләр мәсьәләсендә һичбер яңа эш эшли алмый. Ялгыз һаи рәсмия, ягъни (ە – «ә») не гарәпнең фәтхәсе урынына сүзләрнең ахырларында язуны гына кабул итә. Димәк, шулай итеп, сүз ахырында гына булса да «ە» галәмәте татар теленә голәмалар, имамнар вә татар зыялылары тарафыннан кабул ителгән була. (Ф. Кәримиләр[2] һәм шул җәмгыятьнең башында йөриләр. Бу җәмгыять турында аның «Аннан-моннан»ында мәгълүмат бар.)

Соңыннан «Йолдыз» гәзитәсенең мөхәррир вә нашире Һади Максуди[3], әлифбабызга бер яңа хәреф, ягъни «ۇ» хәрефен арттырып, шуны гамәлгә куеп җибәрә һәм үзенең гәзите, китаплары аркылы гомумгә кабул иттертә. Шуның өстенә гарәпнең фәтхәсе бәрабәрендә «ـَ» урынына сүзнең ахырында да, уртасында да «ـه – ە» галәмәтен кертеп, аңа мөстәкыйль бер хәреф хокукын бирдертә («пәрәмәч» (په ره مه چ) дигән сүздәге кебек).

Аннан соң Гыймад Нугайбәк[4], янә үзенең әсәрләре белән мәйданга атылып, бездә авазлары булмаган гарәп хәрефләрен татар теленнән чыгарып ташлауны һәм сузык авазларның галәмәтләрен, Каюм Насыйри эзеннән барып, унга җиткерүне таләп итеп чыга. [19]10 елларда Гыйбад Алпаров[5] татарның кабул иткән гарәп хәрефләренең шәкелләрен фәкать бер төрлегә – баш хәреф рәвешенә генә кую фикере белән башлап мәйданга атыла. Шул турыда мәкаләләр, рисаләләр яза. Шушы юлда «Татар әлифбасы» төзеп нәшер иттерә.

Закир (Дәрдемәнд) Рәмиевләрнең[6] да татар әлифбасындагы гарәп хәрефләрен бер генә шәкелгә калдыру турысында ляихәләре[7] төзелә.

[1] Мәел күрсәткәнен – омтылганын.

[2] Фатих Гыйльман улы Кәрими (1870–1937) – язучы, нашир, җәмәгать эшлеклесе.

[3] Әхмәтһади (Һади) Низаметдин улы Максуди (1868–1941) – җәмәгать һәм сәясәт эшлеклесе, педагог.

[4] Гыймад (Гыймадетдин) Шәрифҗан улы Нугайбәк (1881–1943) – тел галиме, журналист.

[5] Гыйбадулла Хәбибулла улы Алпаров (1888–1936) – тел галиме, профессор.

[6] Мөхәммәдзакир Мөхәммәдсадыйк улы Рәмиев (1859–1921) – шагыйрь, җәмәгать эшлеклесе, алтын приискалары хуҗасы.

[7] Ляихәләре – проектлары.

Хасил, шулай итеп, татар дөньясында үз телләренә муафикъ кылып, гарәп әлифбасын ислах[1] хәрәкәте кыза башлый. Бу хәрәкәтнең башында торучылар татар гаммәсенә[2], әлбәттә, нык тәэсир итәләр. Бу турыда мәсьәлә бик нык куерып китә. Хәтта бу хәрәкәт татар шагыйре Сәгыйд Рәми[3] тарафыннан татарның хәзерге гарәп әлифбасын латин әлифбасы белән алыштыру ляихәсе төзелү дәрәҗәсенә барып җитә.

1915 елда Уфада Уфа земствосы тарафыннан тел, имля мәсьәләсендә гыйльми бер киңәш мәҗлесе чакырыла. Бу мәҗлескә татарның телче вә имлячылары, язучылары, педагоглары катышалар. Шунда янә, татар телендәге бәгъзе авазлар өчен әлифбабызга яңа хәрефләр арттырып, аны ислах кылу мәсьәләсе куела. Шуның белән бергә хәрефләрнең шәкелләре, ягъни дүрт шәкелдән бергә калдыру мәсьәләсе дә күтәрелә.

Галимҗан Ибраһимов[4] шул җыелышта бу турыда озын бер доклад белән чыга, нәтиҗәдә, киңәш мәҗлесе тарафыннан әүвәлге гарәп әлифбасының *а, у, и* дигән өч сузык хәрефләре урынына Һади Максуди тарафыннан арттырылган һай рәсмия (ە – ـە) белән өтерле вау (ۇ )ыннан гыйбарәт ике хәрефне татар әлифбасына кертү тасдыйк итеәлә[5]. Шуның өстенә өтерле «ئُ» арттырыла. Шуның белән татарлар гарәп әлифбасына үзләреннән яңа хәреф (ە , ۇ , ئُ) арттырган булдылар. Болар, әлбәттә, асылда һаман гарәп хәрефләре булып, тик шуларга галәмәтләр, ягъни шул ук гарәпнең өтере (заммәсе) кушылып ясалдылар.

Бу мәсьәлә моның белән генә тукталмый: бер яктан, татарда авазы булмаган хәрефләрне татарга кабул ителгән гарәп әлифбасыннан чыгарып ташлау хәрәкәте дәвам итсә, икенче яктан, мәд хәрефләрен[6] унга җиткерү хәрәкәте дә кыза.

1917 ел февраль инкыйлабыннан соң Казанда булып үткән Бөтенрусия укытучыларының икенче корылтаенда янә шул ук

---

[1] Ислах – реформалау.

[2] Гаммәсенә – җәмәгатьчелегенә.

[3] Сәгыйть Лотфулла улы Рәмиев (1880–1926) – шагыйрь, прозаик, журналист, публицист, тәрҗемәче, театр белгече.

[4] Галимҗан Гыйрфан улы Ибраһимов (1887–1938) – язучы, галим, дәүләт эшлеклесе.

[5] Тасдыйк итеәлә – раслана.

[6] Мәд хәрефе – сузык аваз хәрефе.

югарыдагыча әсасән барысы алты мәд хәрефе кабул ителә[1], ләкин менә шушы галәмәтләр алына: ئا – ا , ه – هـ ,وُ ,و , يـ , ء . Гарәпчәдән кергән сүзләрне язганда, гәрчә ул сүзләрдәге авазларны әйтә алмаса да вә алар татарча да булмаса да, гарәпчәнең үз хәрефләре белән язу юлы үз көчендә калдырыла. 1918 ел октябрь инкыйлабыннан соң шул ук мәгариф эшчеләренең өченче корылтаенда янә бу мәсьәлә кузгалып, һаман шул икенче корылтай карары үз көчендә калдырыла. Тик бары гарәпчә сүзләрне алты мәд хәрефе белән язу кабул ителә (Зариф, Газыйм, Сабит, золым кебек)[2] .

[1] Гәрчә хәзер бу имля тәмамән гамәлдә булмаса да, тарихи әһәмияте булган өчен, бу съездда кабул ителгән карарны бу урында кергезеп үтәбез.

**Тел вә әдәбиятымызны һәм хәрефләремезне тәгъйин (шул вакыттагы үз имлясы белән)**

1 – Идел буе төрк-татар теле вә әдәбияты чын төрк-татарча сүзләр белән бәрабәр чит телләрдән күп үзләшкән вә читлеге онытылган сүзләрдән гыйбарәт.

2 – Төрк-татар телендә чын төрк-татар хәрефләре утыз бер булып, шуларга гарәп теленнән катнашкан сүзләрдәге хәрефләрне дә кушканда, төрк-татар әдәбиятында барысы утыз тугыз хәреф бар (гарәп теленнән кергән сүзләрдәге хәрефләр шулар: ث , ظ , ض , ط , ع , ذ , ح).

3 – төрк-татар телендә чын төрк-татар хәрефләре эченнән тавышсыз хәрефләр (хәреф галәмәтләр) шулар: ا ه (һәмзә – әлиф сурәтендә) ,ب , پ , ت , ج , چ , خ , د , ر , ز , ژ
س , ف , ق , ک , گ , م , ل , گ ڭ , ن , هـ , و , ى

Гыйлавә – «ص , ط» хәрефләре «س , ث» тавышларының икенче төрле шәкелләре үзендә калын хәрефләр булмаган сүзләрдә генә язылырлар.

4 – Төрк-татар телендә тавыш (мәд) хәрефләре алты.

**Имляда төп имлямыз**

1 – имля мәсьәләсендә төп имлямыз – Идел буе төрк-татарлары шивәсендә ишетелгәнчә язу.

2 – Телемездәге һәр авазның үзенә аерым хәреф булындыру.

3 – Бер аваз бәрабәрендә ике хәреф кулланмау.

4 – Сүзләрнең калынлык вә нечкәлегендә тавышсыз хәрефләрнең (саметләрнең) тавыш хәрефләренә (мәдләргә) ияргү әсас игътибар ителә. (Язуымыздагы хәрефләрнең саннарын күбәйтмәс өчен).

5 – Матбага өчен хәрефләрнең бер генә булуы матлуб.

[2] **Ишетелгәнчә язуны хәзерге көндә гамәлгә кую хакында**

1 – Бөтенрусия мөселман укытучылар бюросы тарафыннан хәзерләнгән ляихә яхшы табылса да, хәзерге көндә татбикъ итү читен булганлыктан, аны кичектерү мәслихәт күрелде.

Ишетелгәнчә язу хәзерге көндә шушы түбәндәге алты мәд хәрефләре белән гамәлгә куелыр: آ , ه – هـ , وُ , و , ئُ , ى . Мәсәлән, «бара», «бәрә», «өчен», «тозак», «ике», «алты», «бирде», «барды», «бирделәр», «бардылар», «икесен», «алтысын» дигән сүзләрдәге кеби.

3 – «ئُ , ى» мәд хәрефләре, сүзнең уртасында булганда, ябык һәҗаларда (*иҗекләрдә*) һәм мәгънә бозылмаслык урыннарда язылмас, әмма зарури урыннарда, мәркәзгә куелып, «ـئُـ» рәвешендә язылырлар.

Гыйлавә – шушы «ٔ» галәмәте «ى» ның өстенә куелып язылыр.

1919 ел беренче гыйнвардан игътибарән Казанда имля вә хәрефләр мәсьәләсендә мөтәхассыйслардан[1] гыйбарәт махсус конференция җыйнала. Монда хәрефләрне бер генә шәкелгә – баш шәкелгә генә калдыру беравыздан кабул ителсә дә, алты мәд хәрефен, татар теленең бөтен сузык авазларын белдерүгә җитәрлек кылып, унга җиткерү һәм алты мәд белән чикләнеп калу мәсьәләсендә нык тартыш, көрәш күтәрелә. «Алтычылар» үзләре «гамәли» һәм «фәнни алтычылар» исеме белән ике төркемгә бүленәләр. Ахырда бик аз күпчелек белән Каюм Насыйри вә Гыймад Нугайбәкләр юлы кабул ителә һәм шушы хәрефләр алына: ا (арба), ه – ە (бәрә, пәрәмәч), ـُ (килделәр, кешелек, килде), ی – ـ (алдылар), аеру, وُ (төз, көз), وٗ (тоз, кол), و (сүзем, түзем), وَ (туз, суза), ـِ (кил, килми), ـٖ (бармый, бармыйлар).

Шуның өстенә «унчылар» да, «фәнни алтычылар» да беравыздан «өч», «ат», «ике»дигәндәге кебек сүз башында куела торган һәмзәне бөтенләй ташлау ягын тотып, конференциядә бу да күпчелек белән кабул ителде. Димәк, бу яктан татар теленең гарәп әлифбасына нык кына бер үзгәртеш кертергә уйланылган була. Шул ук конференциядә гарәпнең татар телендә авазлары булмаган сигез хәрефен татар әлифбасыннан бөтенләй чыгарып ташлау кабул ителә.

«Гамәли алтычылар» исә шушы алты галәмәтне исрар[2] белән тәкъдим итәләр: ئُ – ـُ (калын да, нечкә дә әйтелергә), وُ (бу да шулай калын да нечкә дә), ـِ (калын да, нечкә дә), ـه – ە, ا , و . Ләкин болар

4 – *-ләр, -лар, -дән, -дан, -га, -ка, -гына, -кына, -на, -ма, -са, -ча, -чак, -мак, -мәк* (барачак, бармак, килмәк вә илх...) кеби кушымталар ишетелгәнчә, тиешле мәд хәрефләре калдырылмыйча язылырлар.

5 – *язып, язсын, алыр, белер, хатын, алтын, утыз, салкын, тулкын, сеңел, сарык, кызык, сызык* сүзләрендә булган кеби, ябык һәҗаларда мәд хәрефләре язылмас.

6 – ләвахикъның (кушымталарның) басымны – ударениене үзенә тартып ала торганнары җәүһәре кәлимәгә *(сүз тамырына)* кушылып язылыр, басымны үзенә тартмаганнары (гына, генә, өчен, кеби) аерым язылырлар.

7 – беренче имкян булгач та, һаи рәсмия (ه – ە шәкелләре)нең урынына фәтхәле әлифтән ясалган шушы «اَ» галәмәте кулланыла башланыр.

8 – кушымталар тавыш хәрефләрендә асыл сүзләргә ияргәләр (*яза, арбага, барган, биргән* кеби) тавышсыз хәрефләрдә сарыф кагыйдәләренә ияргәләр (*аннан, миннән, аннан, китте, качты, түкте, япты* кеби).

9 – гарәпчә сүзләр үз имлялары белән язылалар. Әмма гарәпчәдән, башка телләрдән алынган сүзләр үз имлямыз белән язылырлар.

10 – «و» һәм «ی» хәрефләре өчәр тавышка галәмәт булып йөриләр, «суз», «сүз», «таулык», «тәүлек», «сыйла», «килә», «бай», «бәйлә» сүзләрендәге кеби.

11 – сүз башындагы һәмзәләрнең язылышы: آ – мәдле әлиф, ئه – һәмзә вә һаи рәсмия рәвешендә бүтән урыннарда әлиф сурәтендә язылырлар. *(Авт. иск.).*

[1] Мөтәхассыйлардан – белгечләрдән.

[2] Исрар – үзсүзлелек.

калын сүзләрнең калынлык, нечкәлекләрен белдерү өчен калын сүзләргә (ٕ) галәмәтен алуны тәкъдим итәләр (سوٕ су дигәндәге кебек). Болар татар әлифбасыннан һәмзә (ٔ)не төшерүгә яки сүз башларында язмауга да нык каршы торалар.

Әхмәдҗан Мостафа татар өчен гарәпнекенә башкарак ялгыз хәрефләр эшләп, татар өчен үзенә махсус әлифба тәкъдим итсә дә, бу үтә алмый кала. Алты мәдчеләрнең «гамәли» юлдагылары, карарны бу көннән халык уртасында гамәлгә ашыру юлын тотучылар булып, болар татар әлифбасына фәкать калынлык галәмәте генә арттырып, шул элгәреге съездлардагыча алты мәд белән канәгатьләнеп калу юлын тотып, «ун мәд» карарына каты протест кылалар.

Әмма башында Әхмәдҗан Мостафа торган «фәнни алтычылар» исә: «Татарда сузык авазлар фәкать алты гына», – дип, шуларга махсус галәмәтне таләп итәләр. Болар да шул авазларга менә шушы түбәндәге галәмәтләрне тәкъдим кылалар: ـد , ـدُ , ۉ , ۇ , ـه , ا боларча, татарчада сузыла торган, ягъни сузык тавышлы «ی و» лар юк. Алар «су»ны – «سوٗو», «сүз»не – «سوُوز», «сыйла» дигәнне – «سىيلا», «кил» дигәнне дә «كىُيل» рәвешендә язылу кирәк, диләр.

Конференция, эшен бетереп, тарала. Ләкин «гамәли алтычылар» (боларның башында Г. Ибраһимов (үзе конференциядә була алмаса да) Г. Шәрәф[1], Ф. Сәйфиләр торалар) бу турыда үзләренекен кабул иттерү, шуны гамәлгә ашыру өчен гаять каты көрәш башлыйлар. Нәтиҗәдә, 1921 елдан игътибарән Татарстан җөмһүрияте менә шушы «гамәли алтычылар»ның тоткан юлларын катгый рәвештә рәсмән кабул итә, һәм шул Татарстан хөкүмәте мәгариф комиссарлыгы тарафыннан мәҗбүри рәвештә гамәлгә ашырыла, матбугат, мәктәпләргә кабул иттерелә. Һәмзә дә әүвәлгечә сүз башларында язылырга була[2]. Әүвәлге карарларга муафикъ гарәпнең сигез хәрефе чыгарыла. Ялгыз шәкелләр алына. Моннан башка янә бер яңалык кертелә: ул да татар әлифбасында гарәпнең фәкать ноктасыз ع, ح сы гына калдырылып, болар урынына нокталы غ, خ ташлана

[1] Галимҗан Шәрәфетдин улы Шәрәф (1896–1950) – җәмәгать һәм сәясәт эшлеклесе, тел белгече.

[2] Татарларда шушы хәреф имля вә гомумән тел, әдәбият мәсьәләләренең ничек барылышы һәм ничек хәл ителеше турысында тәфсилле рәвештә танышмак өчен Г. Ибраһимовның «Имля, тел, әдәбият мәсьәләләре» дигән әсәренә мөрәҗәгать ителүне тәүсыя итәбез *(киңәш итәбез)*. 1925 ел Казанда дәүләт нәшрияты тарафыннан басылган. Ялгыз шул бар: бу китапта ни өчендер Г. Ибраһимов иптәш 1919 елдагы әлеге талашны, конференцияне, андагы «унчы» вә «фәнни алтычылар»ның тоткан юлларын язмый калдырган. *(Авт. иск.)*

(бу да язуга җиңеллек ягыннан каралган булса кирәк). Калынлык галәмәте итеп тә шушы (ٖ) галәмәте алынып, бу галәмәт фәкать шөбһәле сүзләрдә генә язылырга була.

Менә шулай итеп, татарның гарәптән алган әлифбасы шушы елдан игътибарән менә шушы түбәндәге хәрефләрдән гыйбарәт булып кала. Сузыклар:

ـا – ه – ۮ – ۇ – و – يـ (ى)

Шуларга калынлык галәмәте (ٖ), («су» дигәндәге кебек) кушыла.

Тартыклар:

ئـ – بـ – پـ – تـ – نـ – جـ – چـ – حـ – د – ر – ز – ژ – ع – فـ – قـ – کـ – گـ – ڭـ – لـ – مـ – سـ – شـ (و – يـ – ى) هـ. Шул хәлдә, хәзердә гарәп әлифбасыннан бераз үзгәртелгән вә татар теленә яракландырылган яңа татар әлифбасында барысы 31 төрле хәреф вә бер калынлык галәмәте бар дигән сүз була. Шулар эченнән «ۇ» белән «يـ – ى» лар һәм сузыла торган хәреф, һәм сузылмый торган хәреф булып йөрүләрен исәпләгәндә, татарның әлифбасы барысы 29 төрле шәкелдән гыйбарәт булып калган була. Хәрефләрнең һәммәсенең шәкелләре исә түбәндә ун әсаска кайтып кала. Ягъни болар ун төрле әсаси шәкелдән ясалганнар:

1) بـ, پـ, تـ, نـ, ئـ, يـ, ۮ
2) جـ, چـ, حـ, ه
3) د
4) ۇ, و, ه
5) ا, ک, گ, ل
6) ر, ز, ژ
7) ء
8) ف, ق
9) مـ
10) سـ, شـ

Шул ук вакытларда татарлар өчен әсасән латин хәрефләре дә съездларда кабул ителеп куелды[1]. Фәкать моның гамәлгә ашырылуы киләчәк заманнарга, яңа гасырларга калдырылды.

[1] Азәрбайҗанда исә бу турыда ягъни төрек телләре өчен латын әлифбасын кабул итү турысындагы хәрәкәтләр хәзердә бик кызу бара.

## Китапны язганда файдаланылган әсәрләр[1]

### I. Төрк вә гарәп телендәгеләр:

1. Әбүлгази. Шәҗәрәи төрк.
2. Ш. Мәрҗани. Мөстәфадел-әхбар, I–II.
3. Зәки Вәлиди. Төрк-татар тарихы.
4. Нәҗиб Гасыйм. Төрек тарихы.
5. Мәхмүд Кашгари. Китабе диване лөгат әт-төрк. Бөтен җилдләре.
6. Әхмәд Рәфикъ. Бөек тарихы гомуми.
7. Ибн әл-Әсир. Тарих әл-кямил ли-Ибн әл- Әсир.
8. Ибне Баттута. Төхфәтен-ноззар фи гараибил-әмсар вә гаҗаибил-әсфар.
9. Морад бик «Тарихы гомуми»се.
10. Исмәгыйль Хаккый. Тарихы гомуми.
11. Габдерахман ибн Хәлдун. «Мөкаддимәте бине Хәлдун» һәм тарихы.
12. Морад Мәкки. Тәлфикыль-әхбар вә тәлкыйхел-асар.
13. Ш. Сами. Камусел-әгълям.
14. Әхмәд Рәфгать. Лөгате тарихия вә җәгърафия.
15. Гали Паша Мөбарәк. Холясате тарихил-гарәб.
16. Бүртәр. Ән-нәһҗел-кавим фи тарихил-кадим.
17. Җөрҗи Зәйдан. «Тарих әт-тәмәддун әл-ислами» бөтен җөзләре.
18. Мәхмүд әфәнде Шөкри. Бөлүгыль-әрәб фи тарихил-гарәб.
19. Нәүфәл әфәнде. Санаҗәтет-тарәб фи тәкаддематил-гарәб.
20. Мәсгуди. Мөрүҗез-зәһәб.
21. Әхмәд Ибне Яхъя Багдади (Бәлазөри). Китабы фөтүхил-бөлдан.
22. Табари. Тарихел-өмәм вәл-мөлүк.
23. Күперлезадә Мәхмүд Фуад, Шиһаб Сөләйман. Мәгълүматы әдәбия.
24. М. Рәүф. Юнаны кадим тарихы әдәбияты.
25. Шиһабетдин Сөләйман. Тарихы әдәбияты госмания.
26. Бабур. Бабурнамә.
27. Зәки Вәлиди. Лотфи һәм аның диваны.
28. Шаһ Кәрим. Төрек, кыргыз, казакъ һәм ханнар шәҗәрәсе.
29. Нәваи. Мәҗалисен-нәфаис.
30. Габделхәй әл-Ләкнәви. Әл-фәваидел-бәһия фи тәраҗимил-хәнәфия.
31. Йосыф бәк Вәзиров. Азәрбайҗан әдәбиятына бер назар.
32. Нәҗиб Гасыйм. Иске төрек язусы.
33. Риза казый. Асар.
34. Шиһабетдин әл-Мәрҗани. Вәфиятел-әслаф.

[1] Бу исемлек Г. Сәгъдинең үзе тарафыннан төзелгән.

35. Хөсәен ибне Мөхәммәд (Диярбәкри). Тарихел-хәмис фи әхвали әнфөсе нәфис.
36. Эдвард Фәндик. Китабы иктифаил-конуг би-ма һүвәл-матбуг.
37. Әхмәд Мидхәт тарихы һәм лекцияләре.
38. Ибне Хәлликян тарихы.

**II. Рус телендәгеләр[1]:**

1. Шницер. Иллюстрированная всеобщая история письмен.
2. Рубакин. Из тьмы времен в светлое будущее.
3. Струве. Происхождение алфавита.
4. К. Вейле. От бирки до азбуки.
5. Правдолюбов. История письма.
6. Соводник. Очерки по истории русской литературы.
7. Мюллер. История ислама.
8. Ашмарин. Материалы для исследования чувашского языка.
9. Лезин. Теории и психологии творчеств (8 томов).
10. Фирсов. Чтения по истории Среднего и Нижнего Поволжья.
11. Фирсов. История Сибири.
12. Литература Востока в 1–2.
13. Самойлович. Некоторые дополнения к классификации турецких языков.
14. Поппе. О родственных отношениях чувашского и тюрко-татарских языков.
15. Веселовский. История Востока.
16. Бартольд. Китаби-Куркуд.
17. Смирнов. Очерки истории турецкой литературы.
18. Дрепер. История умственного развития Европы.
19. Учен. зап. Казанского университета 1894 г., статья Катанова: Этнографический обзор тюркско-татарских племен.
20. Катанов. Опыты исследования урянхайского языка.
21. Корш. Классификация тюркских племен пожалуй тюркских языков (этнографического обозрение 1910 г.).
22. Фолев. Введение в изучение тюркских литератур и наречий.
23. Худяков. Очерки по истории Казанского ханства.
24. Наливкин. Туземцы раньше и теперь.
25. Крымский. История Персии, ея литературы.
26. Добросмыслов. Ташкент в прошлом и настоящем.
27. Бартольд. История изучения Востока в Европе и в России.
28. Панов. К истории народов Средней Азии.
29. Мусульманский мир (журнал).

[1] *Түбәндәге китаплар исемлеге кирилл хәрефләре белән язылган.*

30. Бартольд. История Туркестана.
31. Ковалев. Курс всеобщей истории.
32. Тохтарев. Очерки по истории первобытной культуры.
33. Флиттнер. Как научились читать иороглифы[1].
34. Смирнов. Черемисы.
35. Хомяков. Вотяки.
36. Перетяткович. Поволжье в XV, XVI, XVII и начале XVIII в.
37. Эйслер. Всеобщая история культуры.
38. Афганистан (сборник).
39. Вейле. Культура бескультурных народов.
40. Вейле. Элементы человеческой культуры.
41. Пинегин. Казань в прошлом и настоящем.
42. Смолин. Происхождение народности Камско-Волжских болгар.
43. Народная энциклопедия. Том VII.
44. Зап. Вост. Отд. Имп. Русск. Арх. О-ва XXI, (вып. IV), XIII, VII, III.
45. Брокгауз – Ефрон. Энциклопедический словарь.
46. Сборник трудов Орхонской экспедиции стат. «Урхонск. надписи по истолкованиям датского ученого»,
47. Самойлович. Западный Туркестан.
48. Труды Охронской[2] экспедиции. Атлас древности Монгол.
49. Сборник трудов Охронской экспедиции. IV «Древне тюркск. памятники в Каше-Цайдаме».
50. Бартольд. Туркестан в эпоху Монгольского нашествия.
51. Просвещение. Большая энциклопедия. Т. XVIII и XXXIV.
52. Новый энциклопедический словарь. Т. XXVII.
53. История человечества, перевод с немецкого, под ред. Радлова.
54. Древняя Европа и Восток.
55. Радлов. Опыт словаря тюркских наречий.
56. Его же. К вопросу об уйгурах (Зап. Им. Ак. Наук, т. LXXII. № 2. 1893 г.).
57. Руднев. Лекции по грамматике монгольского письменного языка.
58. Цыбиков. Пособие для практическ. изучения монгольского языка.
59. Бартольд. Место прикаспийских областей в истории мусульманского края[3].
60. Известия Общества Археологии, истории и этнографии.

[1] Иороглифы – иероглифы.
[2] Охронский – орхонский.
[3] Бартольдның бу китабы 1924 елда Урта Азия дарелфөнүненең Шәрык факультетында укылган лекциясеннән һәм шуңа кушылып басылган кыскача төрек һәм азәрбайҗан тарихыннан гыйбарәт. [19]25 елда басылды. *(Авт. иск.)*

# ЭЧТӘЛЕК

«Халык белән тел икесе бер нәрсә кебидер» . . . . . . . . . . . 5

**Сүз башы** . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 7

**Беренче баб. Телләрнең туулары һәм аларның үсүләре** . . . 11

Тел һәм борынгы иҗатлар . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 41

Бездә җырлар . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 76

Саф халык теле вә борынгы халык әдәбиятыбыз турысында гомуми төшенчәләр. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 91

**Икенче баб. Язулар-әлифбалар һәм аларның тарихи үсүләре**. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 99

Язуның дәверләре һәм үткәргән баскычлары . . . . . . . . . 109

Яһүд-финикә әлифбасының гаиләләре . . . . . . . . . . . . . 154

Хәзердә төрк халыкларында кулланылган гарәп язуының нәселе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 163

Җәнүби сами әлифбалары . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 179

Иран әлифбасы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 180

Һинд әлифбасы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 182

Яурупа әлифбалары яки Юнан-Италия әлифбасы гаиләсе . . 184

Рун язуы. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 189

Төрк халыкларында язу . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 191

Башка төркләрдә язу . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 226

Төрк халыкларында гарәп әлифбасы . . . . . . . . . . . . . . 242

Китапны язганда файдаланылган әсәрләр . . . . . . . . . . . . 252

**Габдрахман Сагди**

**ИЗБРАННЫЕ СОЧИНЕНИЯ**

**Том 3**

**Духовное наследие: поиски и открытия**

Выпуск 24

(На татарском языке)

Редактор Л. Г. Шарифуллина
Компьютерная верстка Н. Т. Абдуллиной
Дизайн обложки Т. В. Семиной

Подписано в печать: 23.12.2024.
Бумага офсетная. Формат 60×84 1/16. Гарнитура «Таймс».
Усл.-печ. л. 14,9. Уч-изд. л. 13. Тираж 300 экз. Заказ

Оригинал-макет подготовлен
в Институте языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова АН РТ
420111, Казань, ул. К. Маркса, 12

Издательство Академии наук Республики Татарстан
420111, Казань, ул. Баумана, 20